РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ
АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ

ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ



# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ, ТАРИХ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

УКУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ СТУДЕНТЛАРНЫҢ
XVI БӨТЕНРӘСӘЙ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ
МАТЕРИАЛЛАРЫ
(Мәгърифәтче-галим Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышлана)

АЛАБУГА – 2025

ББК 81.632.3 Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга
УДК 811.512. 145. институтының Гыйльми советы карары белән басыла
Т 23 (берткетмә № 2, 20 февраль 2025 ел)

**Бәяләүчеләр**:

**Галиуллин Р.Р.** – филология фәннәре кандидаты, Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты доценты.

**Шаймарданова М.Р.** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты доценты.

**Редколлегия:**

**Камаева Р.Б. –** филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы профессоры.

**Габидуллина Ф.И**. – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Даутов Г.Ф. –** филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Хәйруллина Ә.С.** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Т23 Татар теле һәм әдәбияты, тарих: үткәне, бүгенгесе, киләчәге:** укучыларның һәм студентларның XVI Бөтенрәсәй фәнни–гамәли конференция материаллары (Мәгърифәтче-галим Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышлана) (Алабуга, 31 январь, 2025 ел). – Алабуга, 2025. – 212 б.

*«Татар теле һәм әдәбияты, тарих: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» фәнни-гамәли конференциясенең материаллары тупланган җыентыкка укучыларның, студентларның, магистрантларның фәнни тикшеренү эшләре кертелде.*

*Россия Федерациясенең Татарстан, Чувашстан, Башкортостан республикаларында яшәгән укучылаһның фәнни мәкаләләрендә татар теле һәм әдәбиятының актуаль проблемалары, тарихның күпләрне борчыган һәм дулкынландырган мәсьәләләре, татар әдипләре иҗатында милли яшәешнең яктыртылуы турындагы тикшеренү нәтиҗәләре урын алган.*

©Авторлар коллективы, 2025
© КФУның Алабуга институты, 2025

# I. КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ. МӘГЪРИФӘТ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

---

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ МӘГЪРИФӘТ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Акмурзин Д.А.**
Яр Чаллы шәһәренең 13 нче урта мәктәп укучысы
Фәнни җитәкче: Харитонова Г.П.

Мәгърифәтче, тарихчы, этнограф, тел белгече һәм әдип Каюм (Габделкаюм) Габденнасыйр улы Насыйри 1825 елның 14 февралендә элекке Казан губернасы Олы Шырдан авылында мулла гаиләсендә туа. «Касыймия» мәдрәсәсендә белем ала. Казан дәүләт университетында ирекле тыңлаучы буларак лекцияләргә йөри, үзлегеннән рус телен өйрәнә. 1855–1871 елларда ул Казан руханилар училищесенда һәм Казан руханилар семинариясендә татар теле укыта. 1871 елда Казанда үз мәктәбен оештыра. 1879 елдан, нигездә, иҗади һәм фәнни эш белән шөгыльләнә. Гуманитар фәннәрнең төрле тармаклары үсешенә зур өлеш кертә, хәзерге татар әдәби теленә, аның фәнни терминологиясенә нигез сала.

К.Насыйриның әдәби һәм гыйльми мирасы хакында кыскача: ул үзенең 40 еллык иҗади эшчәнлеге чорында (1859–1899) барысы 37 исемдә әсәр яза, 24 календарь төзи. Басылган китаплары 4 мең, календарьлары 1200 — барысы 5200 биткә җыела. Китап һәм календарьларының басма саны 100 гә тула, күләме 350 басма табактан арта. Шуның өстенә Казан Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре мәҗмугасында рус телендә татар этнографиясенә караган мәкаләләре басылып чыга. 1886 елны «Кабуснамә» исемле китабы русчага тәрҗемә ителә. Насыйриның хезмәтләре турында 1880–1913 еллар арасында рус матбугатында профессорлардан Григорьев, Смирнов, Соловьев, Готвальд һ.б. язган өч дистәгә якын мәкалә басылып чыга.

К.Насыйри 1902 елның 20 августында вафат була. Казандагы Яңа бистә зиратында җирләнә.

К.Насыйриның яшәү һәм эшчәнлек гомере (1825–1902 еллар) Россия тарихындагы иң зур борылыш, иң зур алмашынулар чоры буйлап сузыла. Бу чор Россиясенең иҗтимагый, экономик төзелеше, феодализмнан капитализмга күчү этапын тәмамлап, капиталистик үсешнең иң югары стадиясенә — пролетариатның революцион көч булып оешу баскычына күтәрелә. Бу чорда Россия, феодализмнан капитализмга күчү чорының законлы продукциясе рәвешендә, бөек рус милли культурасы, ул тудырган җәмәгатьчелек фикеренең кояшы астында, дистә, йөзләгән халыкларның үз милли культураларын төзү эшенә аяк баскан бер ил булып әверелә.

Татар халкы — ул, күп милләтле бөек Россиядә туып үскән, үзенең милли культурасын, җәмәгатьчелек фикерен, дөньяга карашын рус культурасы барлыкка китергән рух белән сугарып төзегән күп халыкларның берсе. Моның шулай икәнлеген озын тарих буенча типчелә килгән реаль фактлар раслыйлар.

XIX йөзнең соңгы яртысында булып үткән татар мәгърифәтчеләре хәрәкәте үзе генә дә моңа ачык дәлил булып тора; чөнки бу хәрәкәтнең рухы 60 нчы еллар мәгърифәтчеләре дип аталган рус мәгърифәтчеләре эшчәнлегеннән алынган була. Дөресрәге, бу хәрәкәт 60 нчы елларда рус җәмәгатьчелек фикере тудырган алдынгы фикернең татар халкы тормышында чагылышыннан гыйбарәт була. Озын тарихлар буйлап нигезләнгән хакыйкать бу. Татар халкының рус халкы һәм, гомумән, Россиядәге бүтән халыклар белән тел–логать, гадәт–горефләр алмашып яшәве бик күптәннән, бик ерактан бирле дәвам итә; безнең сайрашып тормыш кичерүебез борынгы болгар бабаларыбыздап ук башланган, һәм без моның шулай икәнлеген, материаль тормыш, политик–административ мөнәсәбәтләр тармагы буйлап сузылган фактлардан гына түгел, бәлки идеология, дөньяга караш, ireккә, яктылыкка омтылыш өлкәсендә дә бик ачык күрәбез.

Мәгълүм ки, авыз әдәбияты — фольклор, кирәк кайсы гына халыкныкы булмасын, борынгы кешенең тормышка карашын, хәкимлеген, фәлсәфәсен чагылдырган иң ышанычлы документ. Билгеле, татар халкының да бик борынгы бабалары иҗат иткән фольклоры һәм шуның эченә салынган фәлсәфәсе, тормышка карашы, омтылышы, көрәш тарихы бар.

Алыйк, мәсәлән, «Ике былбыл» дигән әкиятне. Бу әкият болгар чорына карый. Моның идеясе — ислам дине тарафыннан хокуксызландырылган, кешелеге тапталган хатын–кызны азат итү, аның да, ирләр кебек үк, укырга, тормыш күтәргә, иҗтимагый эшләргә катнашырга сәләте бар икәнлеген ачып бирүдән гыйбарәт.

Бу әкият борынгы бабаларыбызның килмешәк ислам фәлсәфәсенә, аның законнарына нинди көчле протест белән чыкканлыгы һәм ул чорда ук инде яктылыкка, прогрессив культурага омтылышның көчле булганлыгы турында сөйли, һәм без моны Россия туфрагында яшәгән борынгы халыкларның барлыгы өчен дә уртак күренеш, уртак рух итеп таныйбыз.

Беренчедән, татарның художестволы әдәбияты үзенең башлангыч, туу чорында ук реалистик нигезгә корылган була, ягъни ул үзенең башлангыч чорында ук нииндидер күк арты яки җир асты тормышын кайгырту коралы буларак түгел, бәлки җир өстендә яшәүче кешеләрнең реаль тормышын төзәтү, аларның рәхәт яшәүләрен тәэмин итүне кайгыртучы әдәбият булып килә. Без моны татар әдәбиятының башлангычы саналган «Болгар кызы алтын чәч», Жпк мәргән», «Зыя–Түләк», «Ике былбыл». Гыйса угылы Әмәт» һ. б. шундый авыз иҗаты әсәрләреннән ачык күрәбез. Бу әсәрләрдә кешелек, намус, тугрылык, рәхәт тормыш, халык ирке, шәхес ирке өчен көрәш мотивлары төп урынны ала.

Икенчедән, татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең бу принципы Идел буе татарларына әдәби тел итеп «Тәрҗеман» телен тагарга маташучы

«пантуркистлар» мәкерен юкка чыгара; без үз культурабызны, рус халкы барлыкка китергән культура калыбына салып, үз телебездә дә төзи алабыз дигән тарихи хакыйкатьне ачып сала. Габдулла Тукайның 1906 елны «Фикер» газетасында басылган «Тәрҗеманның татарларга мөнәсәбәте» дигән кискен мәкаләсе әнә шушы тарихи чынбарлыкны тулысынча ачып бирә: «Минемчә, — ди ул анда, — «Тәрҗеман»ның без татарларга галәкасы (бәйләнеше) бөтенләй юктыр: чөнки әүвәлән аның теле безнең телебезгә бөтенләй кире бер Кырым теледер.

К. Насыйри бу романын «Әфсанәи Гөлрөх зә Камәрҗан» дип атый, вакытлы бер күренеш кенә булып, һичбер төрле йогынты ясый алмастан, җилли килгән, җилгә китә дигәндәй, тарих арасыннан төшеп кала. Соң татар мәгърифәтчеләренең, аерата Каюм Насыйриның тел өлкәсендә эшләүләре нидән гыйбарәт була?

Иң элек шуны әйтергә кирәк: мәгърифәтчеләр татар теленең үз эченә генә бикләнмиләр, киресенчә, алар татар халкына ике тел, ягъни татар һәм рус телләрен яхшы белү кирәклеген калку итеп куялар.

Күренә ки, аның хезмәтләре ул вакытта ук белгечләр каршында зур бәя алганнар. К. Насыйри татар теле фәнни грамматикасына нигез салучы була диләр белгечләребез. Бу, — билгеле, хакыйкать. Дөрес, Насыйри төзегән грамматика (ул «Әнмүзәҗ» дип атаган. 1895 ел.) тәртип буенча беренче түгел, хәтта алардан нәкъ йөз ел алда татар теленең грамматикалары төзелә башлый һәм аларның саны да байтак була. 1895 елларга Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри 43 килеп кергәндә Насыйри грамматикасының тарихи әһәмияте шунда ки, ул, беренчедән, турыдан–туры татарларның үзләре әчеп төзелгән, икенчедән, авторның үзе тарафыннан дөрес саналган методология (логик–формаль принципка) нигезләнгән, өченчедән, шушы чорның татар теленә, мәсәлән, аның орфографиясенә кертелергә тиешле яңалык, үзгәрешләрнең фәнни дәлилләрен үз эченә алган була. Татар теле фонетик төзелешендәге үзенчәлекләр, һәм гарәп әлифбасының аларны дөрес тәгъбир итә алмавы мәсьәләсен, беренче башлап, Каюм Насыйри әнә шушы «Әнмүзаҗ”ен дә кузгата. Насыйри «Ләһҗә–и–татария» исемендә, татар теленең аңлатмасы сүзлеген төзи. Әйтергә кирәк, аның бу хезмәте хәтта бүген дә бердәнбер килеш яши бирә, чөнки безнең әле татар теленең яңа аңлатмалы сүзлеген төзи алганыбыз юк.

К.Насыйри татар теленең грамматик төзелеше, орфография һәм орфоэпик кануннарына карата шактый зур принципиаль мәсьәләләрле күтәрә, гадәт сөйләү теле белән әдәби тел арасында булырга мөмкин аермаларны ачык бирә һәм әдәби сөйләмне киң катлау тарафыннан үзләштерүнең методик юлларын күрсәтә.

Өченчедән, бу хәрәкәт, үз чорына нисбәттән бөей бер борылыш — революцион борылыш буларак, татарның әдәби тормышына критик реализм карашларын тудыра, аның җәмәгатьчелек фикерендә чын фән, кешелек дөньясы алга сөргән прогрессив идеяләргә омтылу хисен уята. Ниһаять, әйдәп баручысы

Каюм Насыйри булган бу хәрәкәт татар тарихында демократик, большевистик идеяләрне күтәреп чыккан Тукай, Ямашевларның тууына ныклы җирлек әзерләгән тарихи реаль күренеш булып тора. Кыскасы, Каюм Насыйри, үз эпохасының иң объектив һәм актив кешесе буларак, күп милләтле, бөек Россия дәүләтен төзү, андагы халыклар туганлыгын ныгыту тарихында иң күренекле, бер фигура була.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М. Каюм Насыйри // Татар әдәбияты тарихы. – 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 258–273 б.

2. Җәләй Л. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри. – Kazanutlary.ru, 1945.

3. Насыйри Каюм — Татарстан Язучылар берлеге. – Sptatar.com

## КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ

**Ахунҗанова М. И.**

Алабуга шәһәренең «Инженер–технология лицее» укучысы

Фәнни җитәкче: Әхмәдуллина Р.Ф.

XIX гасыр мәгърифәтчесе, укытучысы, галим – энциклопедист Каюм Насыйриның күпьяклы гыйльми хезмәтләре, татар халкының кадерле, кыйммәтле хәзинәсе булып тарихка кереп калган.Үзеннең төп бурычларының берсе -татар халкын агарту, мәгърифәтле итү дип санаган К.Насыйри,балаларга әхлак тәрбиясе бирүдә халык авыз иҗаты әсәрләре зур роль уйнавына игътибар итә, һәм баланың сөйләм телен үстерү, туган телен һәм аның төзелешен өйрәтүдә, мәдәни мирасы белән таныштыруда фольклор материалларының алыштыргысыз булуын раслый.

Мин үземнең эшемдә Каюм Насыйриның татар фольклор өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнүне максат итеп куйдым. Шушы куелган максаттан чыгып, Каюм Насыйриның ижаты һәм аның китаплары, анда язылган мәкаль,табышмаклар,әкият,хикәятләр белән таныштым.К.Насыйри гомере буе халык авыз иҗаты әсәрләрен туплау, гыйльми өйрәнү һәм халкына җиткерү белән шөгыльләнгән. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге нигездәөч төп юнәлештәбара.

Беренчедән,ул татар фольклорын турыдан-туры халыкның үз авызыннанязып алып, тупланган материалларның иң яхшы үрнәкләрен бастырып чыгаруга зур игътибар бирә. Икенчедән, үз халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, аның дөньяга карашы белән башка халыкларны таныштыру максатында, К.Насыйри татар халык иҗаты әсәрләрен рус телендә бастырып чыгаруга көч куя. Өченчедән,мәгърифәтче-галимКөнчыгыш халыкларыфольклорын җентекләп өйрәнә һәм аның күп кенә үрнәкләрен, татарчага тәрҗемә итеп бастырып чыгара.

Фольклорны җыю һәм бастыру, аны лингвистик, тарихи-этнографик хезмәтләрдә, хрестоматияләрдә, уку китапларында файдаланудан тыш, халык

иҗатын махсус фән буларак өйрәнә башлауга нигез салучы да К.Насыйри була. Халык иҗатын кабатхалыкның узенә кайтарып бирүгә зур игътибар бирә.Ул мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, читләтеп әйтелгән сүзләр, җырлар, бәетләр, экиятләр, халык тәҗрибәләре (сынамышлар) жанрларын аерып алып өйрәнә. Аларның төрле вариантларын язып ала.Каюм Насыйри мәкальләргә аеруча зур игътибар бирә. Аны мәкальләрнең җыйнаклыгы, тапкырлыгы, образлылыгы сокландыра. Ул аларны "Үзе бер китаплык сүздер",- дип бәяләп үтә.Аның сынамышларында халыкның еллар буена килгән күзәтүләре, тормыш тәҗрибәсе, мифологик күзаллаулары ачык чагыла.Әйтик,1871 елга "Календарь"енда "Халык арасында тәҗрибә буенча көн һәм һава үзгәрүнең галәмәтләребәянында" дигән исем белән, күк җисемнәренең, хайваннар һәм кошларның үз-үзләрен тотышларына карап Һава торышының нинди булачагын билгеләүче 81сынамыш китерә. Календарьларда халык авыз иҗатының башка жанрларыннан да үрнәкләр бирелә.

1880 елда басылып чыккан «Кырык бакча» китабының кырыгынчы бакчасы("бүлеге"нә) 296 мәкаль, 116 кыска җыр , «Сәламнамә», «Мәдех Чәй», «Уңмаган килен» һәм «Әбъят» исемле бәетләр, «Зиһен сынашмак» исеме астында бирелгән өч табышмак-мәсьәлә («Ике көтүче», «Кәҗә, бүре, кәбестә», «Өч сәүдәгәр») керә.Бу китап 40 бүлектән тора. Монда кешенең яхшы һәм яман яклары турында сүз бара. Һәр бүлек бер сыйфатка багышлана. Кереш өлештә бала туу, үсү турында сөйләнелә. Беренче бүлеге –акыл, икенчесе–гыйлем, өченчесе–әдәп, дүртенчесе–зирәклек, җиденчесе–тугрылык. Шулай һәр "бакчада" яңа тема куела, яхшы сыйфатлар мактала, яманнарының зарары турында нәтиҗә ясала. Һәр бүлекнең диярлек ахырында мәкальләр һәм әйтемнәр, халык җырлары, бәетләр, табышмаклар урнаштырылган. Китап һәркем белергә һәм сакларга тиешле гадәтләрне укучыга җиткерә, аларны гыйбрәтле мисаллар белән күңелдә калдырырлык итеп тасвирлап бирә. "Кырык бакча" китабында мәңгелек афоризмнар, хикмәтле сүзләр, фикерләр байтак. Мәсәлән: "Кеше үзен-үзе таныса, камил, акыллы икәне шуннан беленер". "Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне-үзең үгрәт".

1884 елда Каюм Насыйриның «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» ("Әдәбият турындагы мәҗлесләр җимеше") әсәре Казан университеты типографиясендә 609 битлек китап булып басылып чыга. Җыентык көнчыгыш әдәбиятыннан алынган,К.Насыйри тарафыннан әдәби эшкәртелгән, узгәртелгән, өстәмәләр кертелгән, гыйбрәтле, уку өчен кызыклы хикәяләр бирелә.Алар шул чор иҗтимагый тормышындагы кимчелекләрне тәнкыйтьли, әхлакый тәрбия бирүне максат итә.Китапның 40 нчы бүлеге халык иҗаты әсәрләренә багышланган.Халык экиятләре стилендә язылган "Патша белән карт" хикәясендәге патшаны, чиновникларны әдип иң явыз кешеләр итеп сурәтли, халыкны җәберләүләрен фаш итә. Әсәрнең төп идеясе – ерткыч патшаларга һәм шул чордагы җәбер-золымнарына нәфрәт белдерү.Бу китапка: 27 табышмак , 117 кыска җыр,3 бәет, 315 мәкаль һәм әйтем керә.

К.Насыйри халык иҗаты әсәрләрен үзенең грамматика китапларында, сүзлекләрендә, тарих һәм этнографиягә караган хезмәтләрендә дә бастыра .

Татар теленең “Ләһҗәи татари” ике томлык аңлатмалы сүзлегендә (150 дән артык мәкаль һәм әйтем, җыр, такмак, табышмак текстлары);

“Әнмүзәҗ грамматикасы”.(68 әйтем һәм фразеологизм) “Хисаплык” дәреслеге(7табышмак-мәсьәлә)”.

Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр” дигән хезмәте (йолалар,ышанулар, им-том текстлары).

К.Насыйри күпкырлы эшчәнлек алып бара һәм иҗтимагый фикер үсешенә, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп бастыруда, алар белән башка халыкларны таныштыруда, яшь буынга тәрбия һәм белем бирүдә, ниһаять, әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетуда үзеннән зур өлеш кертеп, бай әдәби-мәдәни мирас калдыра.Акыл тәҗрибә булганда гына кыймматкә ия булуына басым ясап,аларның бер-берсеннән җир белән су кебек аерылгысызлыгын ассызыклый,тапкыр сүзләр аша бу фикерне укучыларына җиткерә.К.Насыйри олыларны хөрмәтләү, ялган һәм начар гадәтләрне тәнкыйтьләү, тырышлыкны зурлау, хезмәт аша байлыкка ирешү кебек фикерләрне һәр әсәрендә алга куя. Халык фикере аша халыкны тәрбияли. Аның хезмәтләре татар халкын белемле, тәрбияле итүдә үзенә күрә бер мәктәп, университет була.

**Әдәбият**

1.Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр (өченче том). – Казан: Татар. кит.нәшр., 2005

2.Нафикова Р. Каюм Насыйри иҗаты. //Мәгариф, 1992. – № 1. – ББ.19-21.

3.Олуг мәгърифәтче, галим вә мөгаллим. (К.Насыйриның тууына-170 ел) . //Мәгариф, 1995. – № 2. – ББ. 65-66.

4. Ханзафаров, Н.Г., Гайнуллин, М.Х., Гайнетдинов, М.В., Әхмәтов Р.Ә. Каюм Насыйри. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда/ Н.Г.Ханзафаров, М.Х.Гайнуллин, М.В.Гайнетдинов, Р.Ә.Әхмәтов. – Казан, 1985. – 258-274б.

## СӘЛАМӘТ РУХ – СӘЛАМӘТ МИЛЛӘТ

**Басырова Д.В.**

Алабуга районы Иске Юраш урта мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Юнусова Л.М.

Татар халкының тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын һәрьяклап тирәнтен өйрәнгән һәм туплаган галим–мәгърифәтче, педагог һәм язучы Каюм Насыйри халыкны белемле итү, аның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерүдә зур эш башкара, аң–белемне ана телендә бирүне, укымышлы кеше булу өчен үз телен белүне хуплый. “Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм камил тел ул”, – ди ул.

Бүгенге көндә татар халкын тел һәм милләтнең киләчәге борчый. Аларның киләчәгенә куркыныч янавы, әлбәттә, бик күп факторларга бәйле.

Әмма иң мөһим проблемаларның берсе – ата–бабаларыбыздан мирас булып килгән әхлак сыйфатларының югала баруы. Милләтенә әхлак тәрбиясе бирүне ул үз кыйбласы итеп сайлаган күренекле татар галиме Каюм Насыйри хезмәтләре милләтне сәламәт рухлы итеп тәрбияләргә сәләтле. Чөнки сәламәт рухлы милләт кенә үсә һәм яши ала.

Каюм Насыйриның тәрбия турындагы фикерләре–карашлары, халык тәрбиясе тәҗрибәсеннән ул туплаган тәгьбир–нәсихәтләр татар халкын, аеруча яшьләрне рухи–әхлакый яктан саф итеп тәрбияләргә, әйләнә–тирәдәге тискәре җинаятьчел күренешләрдән гыйбрәт ала белергә «нәфеснең җинаять җитәкчесе» булуын аңларга сәләтле итеп формалаштырырга ярдәм итәләр. Аларда явызлыкны күрә алмау, аңа нәфрәт, яшьләрне андый гамәлләрдән йолып калу, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек тәрбияләү төп максат итеп карала. Шунысы мөһим: К.Насыйри тәрбияви сабакларны еш кына гыйбрәтле мисаллар, җанлы сюжетлар ярдәмендә бирә. Бу исә үгет–нәсыйхәтләрнең тәэсирлеген тагын да арттыра.Ә бу үз чиратында, яманны һәм яхшыны, явызлыкны һәм тәүфыйклылыкны, нәфесне һәм чик–чаманы, уртачалыкны янәша куеп, чагыштырып төшенерга ярдәм итә.

Каюм Насыйри халык педагогикасына һәм аның озын тарихлы тормыш тәҗрибәсенә таянган. Күпсанлы, белемле, тырыш һәм эшчән милләтнең һәрьяклы алгарышка лаек икәнлеген һәм шуңа мөмкинлекләрен үз хезмәтләребелән дә раслаган. Мәгърифәтче галим «тәрбия» сүзенең эчтәлеген билгеләп, гаилә тәрбиясе белән иҗтимагый тәрбиянең үз вакытында һәм күбрәк булырга тиешлегенә басым ясый. «Балалар яшь агач кебектер. Кечкенә вә яшь вакытында тәрбияне кабул итмәк ансат булыр»,– ди ул. Мәгърифәтче балаларның тәрбияле, белемле һәм сәламәт булып үсүенә булышуны иң изге эш дип саный. Хәзерге көндә дә бик актуаль булган проблеманы – әхлак тәрбиясе, эчкечелек һәм тәмәкечелек проблемасын күтәрә.

“Аракы дигән эчемлек адәми зат өчен сарыф бер агудыр” дигән хезмәтендә бик тәфсилләп, аракы эчүчелекнең сәбәпләре һәм зыяны турында яза. Соңыннан үзенең сүзләрен тормыштан китерелгән мисал һәм аянычлы нәтиҗә белән дәлилләп тә куя. Чыннан да, гади кешегә төрле үлән белән төнәтелгән эчемлекнең кеше организмына ничек тәэсир иткәнен билгеләве бик кыен, ә эчәсе килгән кеше өчен эчү сәбәпләре бик күп, ул үзен күпмедер дәрәҗәдә аклар өчен, күп төрле сәбәпләр таба. Галим бу турыда болай ди:”...азрак аракы вә гайре эчемлек адәмгә файдалы дигән ялган ышанулар адәмнең бозылуына вә исереклекнең күбәюенә бер бик олуг сәбәптер...”. Чынлыкта хәзер дә: «Эчә белсәң, аракы ачы дару да», – диючеләр бар. Шулай дия–дия, алар үзләренең упкынга тәгәри барганнарын аңламыйлар да.

Галимебез сыра турында да искәртә:”Дәхи сыра дигән эчемлекнең зарары зыя да күптер…хәтта бәгъзеләр сыра файдалы...дип ялгыш уйлыйлар. Әмма адәмнең тәне бу нәрсәләргә мохтаҗ түгелдер...”–ди.

Күренекле галимебез милләтебезне начар гадәтләрдән арындырырга тырышып, бөтен ваклыклары белән исерткеч эчемлекләрнең кеше организмына

ничек тәэсир итүен, анда нинди үзгәрешләр барлыкка китерүен яза; вакытлыча гына арыганлык һәм авыру бетүләргә, кәеф һәм куәт артуларга ышанмаска, алар белән юанмаска куша; эчүчелек аркасында килеп чыга торган авыруларның исемнәрен саный. "Адәмнең һичбер әгъзасы эчемлекнең зарарын йөкләргә сәләтле түгелдер. Әгәр йөз авыру булса, иллесе эчемлектән пәйда булган авырудыр", – ди. "Исерек адәмдә оят вә тыйнаклык дигән нәрсә...билкөллиһи бетәдер. Шундаен вә шундаен кабахәт гамәлләр кыйладыр ки, аек чагында кыйнасаң да аларны эшләмәс иде", – ди. Эчкәннән соң махмырныңавырлыгын да, аның хурга калдыруын да, исерек адәмнәрнең нинди ямьсез кыяфәттә интегеп үлүләрен дә тәфсилләп сөйли.

"Эчемлек эчә торган кеше һәрбер чарканы эчкән саен үзен генә үтермәйдер, бәлки бөтен нәселен үтерәдер..." – ди. Әйе, олы туган ни күрсәтсә, кече туган шуны кабатлар, ди халык мәкале, исерек кеше үзе генә агуланмый, ә туганнарын, якыннарын да ияртә. Каюм бабабыз исеректән туган балаларның зәхмәтле, сәләтсез, ахмак һәм гарип булып туулары турында да әйтә. "Бер ахмак балага бер хәким карап торды да әйтте:"Сине атаң исерек чагында тудырган икән," – диде... " – дигән мисал да китерә. Аннан соң ул: "Кая китте элгәреге таза адәмнәр?"–ди ачынып.

К.Насыйри дөнья бозыклыгының сәбәпләрен исереклектә, әхлаксызлыкта күрә. Чыннан да, җинаятьләрнең бик күбесе исерек баштан эшләнә бит. Рухи яктан сәламәт, иманлы кеше беркайчан аракыга үрелми, начарлыклар эшләми, башкаларны да бу яман адымнан саклый. Кеше аракының матди яктан да, абруй, сәламәтлек ягыннан да файда китермәгәнен аңларга тиеш. Эчә торган кеше, гомерен файдасызга үткәреп, бәхет күрмичә үлүен аңласын иде.

"Тәмәке тартучының хәле"дигән хезмәтендә К.Насыйри тәмәке дигән агуны исерткеч кебек җирәнгеч сурәткә кертмәсә дә, сәламәтлекне аракы ирештергән дәрәҗәгә җиткергәнен әйтә. "Гафил булмаңыз, мәзкүр ике агу да яхшыга таба илтмидер," – ди ул, адәмне боза торган агуларны җитештерүчеләрнең һәм кулланучыларның артуына борчылып.

Тәмәке белән бергә тартучы да яна, ди халык мәкале. Хәзерге вакытта Россиядә тәмәке тарту аркасында килеп чыккан авырулардан елына 400 000 кеше үлә. Иң аянычлысы шул: тәмәке тарта башлаучыларның саны арткannан арта бара һәм аларның санын кече яшьтәге балалар һәм яшүсмерләр тәшкил итә.

"Кечкенә балалар тәмәке тарталар, мәгънәсен белеп тартмайлар, дәүләргә ияреп тарталар",– дип, өлкәннәрне начар гадәтләрне балаларга күчерүдә гаепли."Тән сәламәт булса, гакыл сәламәт була. Әмма тәмәке зәһәре белән тәне зәгыйфьләнгән кешедә ниткән гакыл булсын", – ди ачынып. Аннан соң тәмәкедә булган зарарлы матдәләрне саный башлый. Һәркайсының организмга нинди зыян китергәнен тәртибе белән аңлата, нинди авырулар китереп чыгарганын дәлилләп күрсәтә. Кыскасы, галим җаны–тәне белән милләтне начар гадәтләрдән арындырырга тырыша. Яңадан гаилә башлыгына мөрәҗәгать итә:"Ата булган кеше углым тәмәке тартмасын дисә, әүвәл үзе тартмасын вә

тартканын углына күрсәтмәсен. Ләкин вакыйган, моңар хилаф атасы әүвәл үзе дәлаләт кыла... Бара торгач, бу бала ник тәмәке тартмасын, әлбәттә, бер нәрсәдән кешене тыйсаң, әүвәл ул эшне үзең кылмаска кирәк".

Әйе, тәрбиянең 80–90 проценты гаиләдә бирелә, ди галимнәр.К.Насыйри: "Тәрбия кылмак вә тәрбия итмәк дигән сүз фәкать ашатып–эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки баланың холкын, фигылен ислах кыйлмак, вә төзәтмәк, вә хайванидан чыгарып, инсаният дәрәҗәсенә китермәк, вә укытмак, вә әдәп нигезе бирмәк мәгънәсендәдер", – ди "Тәрбия китабы"нда. Аның тәрбия турындагы фикер–карашлары, халык тәрбиясе тәҗрибәсеннән ул туплаган тәгъбир–нәсихәтләр татар халкын, аеруча яшьләрне рухи–әхлакый саф итеп тәрбияләргә, әйләнә–тирәдәге тискәре, җинаятьчел күренешләрдән гыйбрәт ала белергә өйрәтә. Аның һәр әсәре халыкның җанлы сөйләменнән алынган гыйбарәләр белән үрелеп бара. Шуңа күрә әсәрләр бик мавыктыргыч, укыганнан соң күңелдә зур тәэсирләр калдыра...

К.Насыйри хезмәтләре халык педагогикасына таянганлыктан аңлаешлы, нәсыйхәтләре яшь балалар күңеленә кереп калу сәләтенә ия, бик үтемле. Әхлаклы, начар гадәтләрсез тормыш итү милләтнең якты киләчәгенә юл ясый.

**Әдәбият**


1. Абдуллин Я. Мәгърифәт нуры ачар... – Казан: Татар.кит. нәшр., 1987.
2. Насыйри К.Сайланма әсәрләр 1т. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1975.
3. Насыйри К.Сайланма әсәрләр 2т. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1975.


## КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ ТАТАР ТЕРМИНОЛОГИЯСЕ ҮСЕШЕ


**Бахтиярова З.Р.**

Алабуга районының 2 нче урта гомуми белем мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Сәхәбиева А.М.


Терминология тел, әдәбият, мәдәният, фән, икътисад, техника һ. б. үсеше белән тыгыз бәйләнгән. Бүгенге көннәрдәге милли яңарыш һәм җанланыш, сүзлек хәзинәсенең ишәюе, баю да, һичшиксез, телдәге терминология үсеше мәсьәләләренә уңай тәэсир итә. Терминология үзеннән–үзе, тиз генә үсеп китмәгән: тел гыйлемендә, аерым милли телләрдә, шул җөмләдән рус, татар һәм башка телләрдә дә озын, каталаулы эволюцион үсеш юлы узган.

Н.А Баскаков, Л.Л. Кутина, Ф.С. Фасеев кебек галимнәр бу өлкәдә күп кенә фәнни хезмәтләр яздылар һәм терминология үсешенә зур өлеш керттеләр. Татар терминологиясе дә зур үсеш юлы узган. Бу өлкәдә татар мәгърифәтчесе, язучысы, галиме Каюм Насыйри да зур хезмәт куйган.УлXIX гасырның иң беренче булып татар теленең фән теле буларак кулланыла алуын дәлилләп чыккан, үзе дә төрле фән тармакларыннан терминологик сүзлекләр төзеп, терминнар ясап, кулланмалар, китаплар язып, фәнни терминнарны фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән.

Каюм Насыйри терминология турында язганда, терминнар ясаганда терминологиянең фән теле булуын, терминнарның фәнни телдә тәгъбирләнеп, фәнни төшенчәләрне дөрес чагылдырырга тиешлеген ассызыклап күрсәтеп китә.”Мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе анасыннан сөт имгән вакыттагы теледер, икенчесе – гыйлем вә фән лөгатьләре беләначылган теледер”, – ди ` К.Насыйри [К. Насыйри 1985:65]

Галим татар телендә фән атамалары ясауда, булдыруда, беренче чиратта, үзе башлап, башлыча, татар әдәби теленә нигезләнгән терминнар тәгъдим итә. Ул атамалар төрле фән тармагына карый: арифметика, геометрия, география, биология, ботаника, химия, тарих, этнография, археология һәм башкалар.

Термин һәм гадәти сүз мөнәсәбәте турында К. Насыйритүбәндәгечә фикер йөртә: “Һәр фәннең үзенә махсус истилахы бардыр вә үзенә махсус теле бардыр. Безнең телемездә кадимнән бу фәннәр языла килмәгәнлек сәбәпле урынынат мовафикъ вә килешә торган сүзләрне табуы читен...”[К. Насыйри 1985:65]

Галим, термин һәм гадәти лексик берәмлек, сүз мөнәсәбәтен дөрес аңлаган хәлдә, гамәли яктан да, назари яктан да кыю тәҗрибәләр ясый, термин эшләнүгә зур өлеш кертә. Моңа кадәр фәнни китаплар гарәп–фарсы, төрек телләрендә генә язылганлыктан, алардагы атамалар да шул телләргә карыйлар.

К. Насыйри, аерым алганда, үзгәрмәс нормалар рәвешендә урнашкан иске традицияләргә каршы барып, гарәп–фарсы, төрки терминнар урынына аларның татарча эквивалентларын таба: “гыйльме хисап” урынына “хисаплык”, “җәмгы”, “җыю”(кушу), “тәфрикъ” урынына “аеру”(алу), “зарып” урынына “сугу” (тапкырлау), “тәкъсим“ урынына “бүлү”, җыясы сан, киметәсе сан, калдык, аерма, сугылмыш сан, суккыч, чыгыш, бүленәсе сан, бүлгеч,өлеш һәм башкалар.Бу терминнарның күбесе әле дә татар теле дәреслекләрендә шул хәлдә кулланылыш таба.

Галим география дәреслекләрендә дә нигездә татар теленең үз сүзләренә мөрәҗәгать итә: төн ягы, төшлек тарафы, кояш чыгышы тарафы, ут тавы, сүнгән ут тавы, чишмә, елга башы һәм башкалар.

К. Насыйри ботаника, медицина терминнарын эшләгәндә, үз китапларында кулланганда татар сүзләреннән максималь файдалана: тамыр, үги ана яфрагы, кузгалак, алабута, мәтрүшкә, төчкерек үләне һәм башкалар. Галим кайбер терминнарны ясауда тәрҗемә–калькаларга мөрәҗәгать итә:арунова борода(лат/arum maculantum) урынына ”карун сакалы” һ.б.ш.

Галим үзенең китабында ботаника терминнарын, татарча вариантларын пропагандалый, аларның сүзлеген ясый, әйләнешкә кертеп җибәрә. Ул гадәти сүз һәм термин мөнәсәбәтен дөрес чагылдыра, соңрак телче– галим Ф.С.Фасеев та бу мәсьәләгә нык игътибар бирә". “Күләме ягыннан киңрәк категория булганга күрә, сүзнең эчтәлеге таркаурак, термин күләме ягыннан таррак, гомумиләштерү дәрәҗәсе югарырак” [Фасеев 1969: 41]

Физика, химия фәннәрендә кулланылган халыкара сүзләрне хезмәтендә куллана: азот, фосфор, калий, хлор, термометр, монометр, барометр һ.б.ш.

Мәгърифәтче галим татар теленнән грамматика китаплары яза, бу китапларында үзе ясаган яңа фәнни терминнарны куллана. Менә аның китаплары: “Краткая татарская грамматика”(1866)”Әнмүзәҗ” (1895), рус һәм татар телләренең чагыштырмалы грамматикасы, “Татарча–русча сүзлек”, “Русча–татарча сүзлек” һ.б.

К.Насыйри татар терминологиясен эшләүдә үз заманы өчен бик тә кирәкле, хәзерге заманда да әһәмиятен югалтмаган теоретик һәм гамәли эш башкарган. Галим татарча термин ясауда алтын урталыктан китми, зарурият булганда, башка телләрдән сүз алуга да, Европа телләрендә кулланылган халыкара сүзләрдән файдалануны да яклап чыга, үзе дә алардан файдалана.

Димәк, Каюм Насыйри – XIX гасырның мәгърифәтче галиме буларак, татар терминологиясе үсешенә зур өлеш керткән. Аның тел белемендәге күпьяклы гыйльми хезмәтләре бихисап. К.Насыйринең хезмәтләре әле дә көн үзәгендә, бүген дә зур игътибар белән өйрәнелә һәм кулланыла.

**Әдәбият**

1. Насыйри К. Истилахе гыйлеме һәндәсә – К., 1985. – 24 б.
2. Фасеев Ф.С. Татар телендә терминология нигезләре – Казан, 1969. – 41 б.
3. Бөтендөнья татар конгрессының интернет сәхифәсе: http://tatarcongress.org

## ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КАЮМА НАСЫРИ

**Биба Н.А**

ученик МБОУ «СОШ №19» г. Набережные Челны

Научный руководитель: Фатихова С.Г.

.

Незнание культуры своего народа, его прошлого и настоящего означает разрушение связей между поколениями, что наносит непоправимый урон в формировании и развитии личности. Лишь зная историю своего народа, его духовное наследие, общественно-педагогическую деятельность его лучших представителей, можно успешно решать задачи, которые стоят перед образованиеми воспитанием будущего поколения.

**Личность Каюма Насыри заслуживает особого внимания как просветителя XIX века.** Это был уникальный человек. Он горячо любил свою родину, свой народ и много сделал для его развития.

Каюм Насыри родился в образованной семье. Его отец был известным богословом и мастером каллиграфии, преподавал в школе. Там же получил свое первое образование и Каюм. Позже отец отправил сына в Казань, где он продолжил обучение в медресе. КаюмНасыри хорошо знал персидский, арабский и турецкий языки, отдельно интересовался и русским. После окончания медресе поступил в Казанский университет, посещал его на правах вольного слушателя.

КаюмНасыри15 лет работал преподавателем татарского языка в духовном училище. Потом организовал школу для татарских детей. Сколько было испытаний на его пути, сколько притеснений, оскорблений, но он не сдавался, продолжал своё дело.

**Просветительская деятельность КаюмаНасыри**была направлена на развитие национальной культуры, письменности и языка.Он составил и издал «Грамматику» татарского языка (1894), «Толковый словарь татарского языка» (1896) и учебники для начального обучения «Правила правописания» (1892), «Слог, или Букварь» (1894).

**Учёный стремился сблизить татарский язык с русским**. Он разработал основы методики обучения татар русскому языку, составил учебники «Русское чтение» (1889), «Образец или грамматика» (1891) и учебные татарско-русские (1875) и русско-татарские (1892) словари.**КаюмНасыри уделял много времени этнографии и собирал фольклор**. В его коллекции были стихи, сказки, поговорки, обряды и обычаи татарского народа.

**Учёный составил для татарских школ первые учебники**на родном языке по арифметике, геометрии, географии, истории, основам анатомии, создал татарскую учебную терминологию по этим предметам.

Будучи просветителем, Каюм Насыри всю свою жизнь посвятил распространению среди татарского населения науки и знания, культуры и прогресса.

Трудом всей жизни Каюма Насыри можно назвать объёмистый том его своеобразных проповедей и наставлений *«Плоды собеседований»,* который вышел в печать в 1884 году в университетской типографии. Это произведение представляет собой выражение всей татарской просветительской идеологии.

Всю свою жизнь Каюм Насыри посвятил литературной и научной деятельности. Его работоспособность была необычайно велика.Он является автором первых календарей, выполнявших роль татарской периодической печати в те годы, когда издание газет на татарском языке не разрешалось правительством. Для своих календарей учёный начертил множество географических карт, например, карту восточного полушария в календаре за 1878 год, карту сел казанской губернии в календаре за 1881 год.

Почерк К. Насыри был изумительно красив. Все свои произведения он переписывал собственноручно, как первоклассный каллиграф.

Главной миссией своей жизни учёный считал просвещение татарского народа. К.Насыри желал видеть татар образованными, знающими родной язык, свою историю и национальную культуру. За свою жизнь Насыри издал более 40 научных трудов и учебников на татарском языке.

Просвещение народа для него было первым шагом к достижению цели и средством улучшения жизни народа.

Каждый ребенок, считал педагог, должен знать и изучать родной язык матери, жить в родной культуре, сохранять традиции старшего поколения, любить свой отчий дом, большую и малую родину, уважать своих соседей,

изучая их язык, знакомясь с их культурой. В этой глубокой мысли ученого заключено понимание воспитательного идеала человека.В своей небольшой по объему "Книге о воспитании" (Китаб-эт-тәрбия, переведенной и на русский язык), содержащей наставления, поучительные истории и притчи, он поднимает многие проблемы воспитания молодежи, которые актуальны и в наше время. В книге К. Насыри 113 наставлений. Но эта книга не религиозный трактат, а сборник мудрых правил, педагогическое руководство по воспитанию подрастающего поколения. Она и сейчас может быть настольной книгой для читателей, родителей, учителей и воспитателей.

В тридцать четвёртом наставлении книги КаюмаНасыйри есть и такие строки: «О сын мой, когда придётся тебе воспитывать детей, будь особенно старателен, пока они малы. Знания, полученные в детстве, подобны орнаменту, выбитому на камне. Прут легче гнётся, покуда тонок. В нежном возрасте следует внушать понятия о многих науках и давать кое-какие знания даже по математике. Вопросы образования детей требуют глубокого вдумчивого изучения».

Как видим, просветительская деятельность К. Насыри многогранна. Его труды являются своеобразной школой, университетом в деле просвещения и воспитания народа. Все его произведения актуальны по сей день, ценность их познается с годами.

**Литература**

1. Насыри Каюм. Избранные произведения – Казань: Татарское книжное издательство, 1977.
2. Гайнуллин М. Каюм Насыйри и просветительское движение. – Казань: Магариф, 1974. - Б. 19-23.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ИҖАТЫ

**Борнашева С.Р.**
Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы
Фәнни җитәкче: Усманова Р.Н.

Каюм Насыйри исеме миңа “Әбугалисина“ әсәре белән кечкенәдән күңел түремә кереп утырган. Бу әкиятне миңа кечкенә вакытта әбием укыды.

Әбүгалисинада булган үткенлек, зирәклек мине һәрчак таң калдыра иде.Аның башкалардан аерылып торуы,мәктәптә иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь салып куйгач, аны сизүе, Мисырга барып чыккач, фәкыйрь хәлвәфрүшкә ярдәм итә башлавы, патшалар белән конфликтка керүе, һәм инде төрле маҗаралы вакыйгалардан өстен чыгуы минем өчен зур могҗиза иде. Шушы әсәр белән сихерләнеп мин аның тормыш юлын өйрәнә башладым. Эшебезне аның турында башка галимнәр иҗат иткән китаплар, язылган мәкаләләр белән танышудан башладым. Каюм Насыйри эшчәнлек алып барган түбәндәге өлкәләрне билгеләдем: тел өлкәсе, тарих өлкәсе, педагогика һәм тәрбия, музыка, матур әдәбият, медицина, арифметика, география һ.б.

Каюм Насыйри 1825 елның 14(2) февралендә Казан губернасы Зөя өязенең Югары Ширдан авылында туа. Насыйровлар гаиләсе башкалардан аның башлыгы Габделнасыйрның укымышлы кеше булуы белән аерылып тора, ул заманда авылларда бу сирәк күренеш була. Булачак галимнең этисе каләмне яхшы белә, рус, фарсы һәм гарәп телләрен белә. Ул берничә китап язган. Габделнасыйр балаларга хезмәткә, китапларга мәхәббәт тәрбияләгән. Галим һәм язучының балачагы туган авылында уза. Каюм Насыйриның эшчәнлеге, крепостной строй яшәгән вакытларда башланып, Россиядә капитализм үскән чакларга туры килә. Аның беренче әсәрләреннән "Мәҗмәгыл–әхбар" ("Хәбәрләр җыентыгы") 1859 елда языла. Басылып чыккан беренче әсәре – "Кыскача нәхү китабы". Бу китап, русча өйрәнүче татарларны күздә тотып, рус телендә языла, "Краткая татарская грамматика" исемендә 1860 елдабасыла.

Балаларга һәм башлангыч белем алучыларга табигать күренешләре турында кыскача мәгълүмат биргән "Буш вакыт" әсәре дә шул ук елда басыла. Ул татар телендә язылган әдәби–фәнни популяр әсәрләрнең беренчесе. 1868 елда К. Насыйри "Буш вакыт"ның икенче вариантын бастыра. 1860 елгы басма 12 битле генәбулса, икенчесе 87 биткә җитә.

К.Насыйриның матур әдәбият өлкәсендәге хезмәте "Кырык вәзир кыйссасы" исемле мәшһүр әсәрне татар телендә эшләп, 1868 елда бастырып чыгаруы белән башлана. 1874 елда Насыйри "Әбүгалисина кыйссасы"н татарчалаштыра.

1879 елда К.Насыйри аеруча зур күләмле "Фәвакиһел–җөләса фил–әдәбият" ("Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше") исемле хезмәтен яза башлый. Аның кыскартылган вариантын, "Кырык бакча" исеме белән, 1880 елда бастыра.

1884 елда К.Насыйриның "Фәвәкиһел–җөләса фил–әдәбият" исемле, 609 битле әсәре Казан университеты типографиясендә басылып чыга.

Каюм Насыйриның балалар китабына таләпләре, аның үрнәкләре татар балалар әдәбиятын үстерүгә нигез булып тора.

Вакытлар, еллар үткән саен, К. Насыйриның тарихи урыны, хезмәте тагын да ачыла бара.

К.Насыйриның әдәби һәм гыйльми мирасы хакында кыскача: ул үзенең 40 еллык иҗади эшчәнлеге чорында (1859–1899) барысы 37 исемдә әсәр яза, 24 календарь төзи. Басылган китаплары 4 мең, календарьлары 1200 — барысы 5200 биткә җыела. Китап һәм календарьларының басма саны 100 гә тула, күләме 350 басма табактан арта. Шуның өстенә Казан Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре мәҗмугасында рус телендә татар этнографиясенә караган мәкаләләре басылып чыга. 1886 елны «Кабуснамә» исемле китабы русчага тәрҗемә ителә. Насыйриның хезмәтләре турында 1880–1913 еллар арасында рус матбугатында профессорлардан Григорьев, Смирнов, Соловьев, Готвальд һ.б. язган өч дистәгә якын мәкалә басылып чыга.

Алай гына да түгел, ул татар лексикографиясен дә яңа биеклеккә күтәрә: ул үз заманы өчен тулы ике томлы "Татар теленең аңлатмалы сүзлеген" төзи:

«Ләһҗәи татари» (Казан, 1895.— 328 Б; 2 нчеөлеш. (Казан, 1878. – 120 б.; 1895.— 157 б.). Әле ул тулы рус–татар сүзлеге ( Казан, 1892. — 263 б.), шулайук татар–рус сүзлеге авторы да ( Казан, 1878. — 120 б.).

Каюм Насыйри телне иҗтимагый күренеш дип саный, һәркемгә аңлаешлы булган телне, ягъни гомумхалык телен өйрәнмичә җәмгыятьнең үсеше мөмкин түгеллеген тирән аңлый. "Әхлак рисаләсе («этика буенча Трактат», беренче басма елы — 1881),» Казан татарларына мөрәҗәгать (кульязма) әсәрләрендә ул үсеп килүче буынның алдагы буыннар тәҗрибәсен кабул итү өчен телне өйрәнүен яклый. Җәмгыятьнең үсеше төрле фәннәрне һәм сәнәгать җитештерүе кагыйдәләрен, шулай ук идарәне өйрәнүдән башка мөмкин түгел. Аларны өйрәнү, мөгаен, теләсә кайсы телдә, әмма туган телдә яхшырак, дип яза ул.

Фәнни белемнәрне уңышлы үзләштерү өчен ул халыкны беренче чиратта һәркемгә аңлаешлы булган туган әдәби телне өйрәнергә өнди.

Мине бигрәк тә аның үз эшенә мөнәсәбәте, эшен җиренә җиткереп, төгәллелек белән эшләве, фикерен ачык, үтемле итеп әйтә белүе үзенә җәлеп итә .Ә бит 1825 — 1902енче еллар тарихта  катлаулы чорлар булып кереп калган. Ул вакытта Россия халыклары тормышының барлык өлкәләренә капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керү аркасында барлыкка килгән яңа иҗтимагый–сәяси агымнар тәэсирендә демократик мәгърифәтчелек хәрәкәте формалаша.

Каюм Насыйри үз алдына куйган максатыннан артка тайпылмыйча, гел алга карап, биеклеккә, яктылыкка омтылган. Үзенең бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган. Замандашлары арасында беренчеләрдән булып, әдәбият һәм фән телен халыкның сөйләм теленә якынайту мәсьәләсен күтәреп чыккан, иҗтимагый фикер үсешенә, татар теленең гыйльми нигезләрен булдыруда, халык авыз иҗаты әсәрләрен бастыруда, алар белән башка халыкларны таныштыруда, ниһаять, әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетуда Каюм Насыйри, үзеннән зур өлеш кертеп, бай әдәби – мәдәни мирас калдырган.

Шулай итеп, XIX гасыр мәгърифәтчесе, укытучысы, галим – энциклопедист Каюм Насыйриның фәннең төрле тармакларында күпьяклы гыйльми хезмәтләре, татар халкының кадерле, кыйммәтле хәзинәсе булып тарихка кереп калган.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин, М. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр.  – Казан: Татар. кит.нәшр., 1974. –Б. 19–23

2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда: Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 321 б.

# КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫ

**Габдрахманова Г.Р.**
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Әдип – мәгърифәтче һәм энциклопедист–галим Каюм Насыйри үзенең хезмәтләре белән татар фольклористикасы тарихында да тирән эз калдырды. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге, Х. Ярми билгеләп үткәнчә, нигездә өч төп юнәлештә барды. Беренчедән, ул, татар фольклорын турыдан–туры халыкның үз авызыннан язып алып, тупланган материалларның иң яхшы үрнәкләрен бастырып чыгаруга зур игътибар бирде. Икенчедән, үз халкының тарихы, тормыш–көнкүреше, аның дөньяга карашы белән башка халыкларны таныштыру максатында, К. Насыйри татар халык иҗаты әсәрләренең иң характерлы үрнәкләрен рус телендә бастырып чыгаруга күп көч куйды. Өченчедән, мәгърифәтче–галим Көнчыгыш фольклорын җентекләп өйрәнде һәм аның күп кенә үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итеп бастырды.

Әлбәттә, беренче юнәлеш дигәнне, ягъни фольклорны җыю һәм бастыруны, киңрәк һәм тирәнрәк мәгънәдә аңларга кирәк. Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм матбугатка чыгару процессында К. Насыйри аларны, билгеле бер системага салып, жанрларга аерды, бу жанрларга — билгеләмәләр, ә аерым әсәрләргә искәрмәләр, аңлатмалар бирде. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: К. Насыйриның фольклористик эшчәнлеге бөтенләй буш урында башланмады. Ләкин, болар белән чагыштырганда, К.Насыйри хезмәтләре, бер яктан, материалның күләме һәм сыйфаты, фольклорның барлык жанрларын да диярлек үз эчләренә алулары белән аерылып тордылар.

Икенче яктан, фольклорны җыю һәм бастыру, аны лингвистик, тарихи–этнографик хезмәтләрдә, хрестоматияләрдә, уку китапларында файдаланудан тыш (боларны аның элгәреләре дә эшләде), К.Насыйри халык иҗатын махсус фән буларак өйрәнә башлауга нигез салды. “Каюм Насыйри,— дип язды Х. Бәдигый,— Казан татарларының үз араларыннан чыккан һәм үзен чолгап алган надан муллалар, ишаннар, суфилар дин исеменнән халык җырларын, бәетләрен, такмакларын, көйләрен тыеп торганда, ул, аларның әһәмиятен аңлап, *аларны өйрәнүне аерым бер гыйлем санап,* шул бабда ишеткән, күргән материалларының берсен дә югалтмыйча дикъкатьләп өйрәнә һәм җыя баручы үз галимебездер” [Бәдигый 2007: 10].

Үзе чыгарган календарьларда, сүзлекләрдә һәм җыентыкларда К. Насыйри халык иҗаты үрнәкләрен урнаштыруга зур игътибар бирә. Халык тәҗрибәләре, төрле сынамышлар еш кына ритм һәм рифмага салынган. Мәсәлән, гыйнвар аеның “6 сында тулы ай – язгы ташу суга бай”, “6сында көн җылы – кырда икмәк бик куе”, “Март белән аяз – аяз булыр бөтен яз”, “Марттагы кар бакча җимешенә бик ярар” һ.б.

1881 елгы календаренда ул “Казан бәете”, “Шаһгали бәете” кебек әсәрләрне, Казан шәһәренең салынуы, Кабан күле һ.б. турында халыктан язып

алган күп кенә риваятьләргә кыскача тукталып, аларның халыкта киң таралган булуын күрсәтә: “Безнең Болгар йортында, кайсы авылга барсаң да, Алып хакында хикәят бар. Күп авылларда мүшһүрдер. Кырларында бер күркәмрәк тау булса, Алып чабатасын каккан дип хикәя кылалар. Бу дәлилдер ки, Болгар йортында бер зур кеше булгандыр. 800 елдан бирле бу сүз онытылмагандыр”.

1880 елда басылган “Кырык бакча” исемле китабының һәр бүлегендә диярлек мәкальләр һәм әйтемнәр урнаштырыла. Мәкальләр, аз сүз белән тирән мәгънә аңлатып, халык тәҗрибәсен җыйнак һәм образлы итеп белдерәләр. Акыл һәм тәрбия бирү максатларында чыгарылган бу китапта К. Насыйри халыкның “хикмәт энҗеләре”ннән киң файдалана. Аерым бер 296 мәкаль һәм әйтем, шулай ук 116 җыр (китап авторы аларны шигырьләр дип атаган), “Чәй бәете”, “Уңмаган килен” бәетләрен, “Фикер сынашмак” дигән исем астында 3 экият–табышмак урнаштыра.

К. Насыйрига бирелгән бу бәяләрнең никадәр хаклы икәнлекләрен күрү өчен, хәзер аның фольклорга караган хезмәтләрен янә бер кат барлап, кыскача гына булса да күздән кичереп чыгыйк. Дөрес, К.Насыйри үзе җыйган материалларны махсус фольклор җыентыклары итеп чыгара алмады, ләкин ул аларга үзенең аеруча әһәмиятле хезмәтләрендә махсус бүлекләр багышлау мөмкинлеген тапты.

1880 елда басылып чыккан «Кырык бакча» китабының кырыгынчы бакчасы (бүлеге) түбәндәге фольклор әсәрләрен эченә ала: 296 мәкаль, 116 кыска җыр, «Сәламнамә», «Мәдех Чәй», «Уңмаган килен» һәм «Әбъят» исемле бәетләр, «Зиһен сынашмак» исеме астында бирелгән өч табышмак–мәсьәлә («Ике көтүче», «Кәҗә, бүре, кәбестә», «Өч сәүдәгәр»).

1884 елда дөнья күргән «Фәвакиһел җөләса» китабының соңгы бүлеге тулысынча диярлек халык иҗаты әсәрләренә багышланган. Дөрес, аларның шактый өлеше «Кырык бакча»дагы материалларны кабатлый, ләкин яңа әсәрләр дә өстәлгән. Аеруча мөһиме: һәр жанрга автор кыскача билгеләмә бирә һәм бик күп әсәрләрне фәнни комментарийлар белән бастыра. Бу китапка кергән фольклор әсәрләре: 27 табышмак (болары «Кырык бакча»да юк иде), 117 кыска җыр, «Әбъят Мәхбүбләргә сәламнамә», «Әбъят чәй бәянында», «Әбъят уңмаган килен бәянында» исемле 3 бәет, 315 мәкаль һәм әйтем.

Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре, нигездә, өстә телгә алынган ике китаптагы материалларны кабатлаучы 28 табышмак, 244 мәкаль һәм әйтем, 116 кыска җыр һәм «Гыйшык хәлләре» дигән бәет, дөресрәге, кыска җырларга тартым шигъри куплетлар (алар «Кырык бакча»да «Әбъят» исеме белән бирелгән иде). Бу материаллар, татар телендә һәм русчага тәрҗемә ителеп, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте «Хәбәрләр»енең 1896 елгы 13 нче томында басылдылар [Хәсәнова 2014: 21].

Табышмаклардан соң халык җырлары, берничә бәет һәм 309 мәкаль һәм әйтем китерелә. Бу хезмәтләрендә К. Насыйри фольклор әсәрләрен төрләргә һәм жанрларга бүлеп карый, аларга аңлатмалар бирә. Җырларны да ул, татар

фольклористикасында беренче буларак, эмоциональ–мәгънәви эчтәлегенә карап, алты төркемгә бүлә. Сөйгән кешенең буй–сынын, күркәм сыйфатларын мактаган җырлар беренче төркемдә китерелә. Болардан кала, махсус исем бирелгән төркемнәрдә – аерылышу һәм ачыну, күрәсе–кавышасы килү, сагыну, зарлану һәм үпкә, өмет җырлары.

К. Насыйри татар халык җырларының төзелеше, табигате турында да фикерләр әйтә, күп кенә җырларда теләкне соңгы юллар аңлатуын, бер үк җырны төрле көйләргә җырларга мөмкин икәнлеген күрсәтә. Кайбер җырларга кыскача аңлатмалар да бирә.

*Күп кенә мәкаль һәм әйтемнәрнең дә мәгънәләре әйтеп барыла. Мәсәлән,*

*Атасы болан атмаганның углы колан атмас. Күбрәк һөнәрсез атадан һөнәрсез бала туа, димәктер.*

*Өрә белмәгән эт өенә кунак китерер. Җайсыз сөйләшеп, үзенә зарар сөйләгән кемсәнә хакында.*

*Узган болытны тотып булмый. Эш үткәч, үкенмәктә файда юк, димәк* [Хәсәнова 2014: 24].

Шушы ук «Хәбәрләр»нең 1900 елгы 16 нчы томында К. Насыйри П.А. Поляков белән берлектә «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» дигән тагын бер зур хезмәт бастыра. Анда халкыбызның 11 әкияте («Салам Торхан», «Ахмак угыл», «Үги кыз», «Гөлнәзек», «Байдек», «Өч угыл», «Акыллы угыл», «Төлке», «Мәче берлән Аю», «Аю берлән Төлке», «Сандугач берлән Бытбылдык») татар һәм рус телләрендә дөнья күрде. Хезмәтнең П.А.Поляков тарафыннан язылган теоретик өлеше дә бар.

К. Насыйриның «Казан татарларының ышанулары һәм гореф–гадәтләре» исемле зур мәкаләсе татар фольклорын өйрәнү тарихында беренче махсус фәнни хезмәт итеп саналырга хаклы. Дөрес, бу автор тарафыннан этнографик планда уйланылган, әмма тулысынча фольклор материалларына нигезләнеп язылган. Аның беренче бүлеге асылда татар мифологиясенең һәм тылсымлы әкиятләрнең сюжетларын һәм персонажларын классификацияләүдән гыйбарәт. Шунысы игътибарга лаек, автор, хезмәтнең темасы таләп иткәнчә, мифик затларга характеристика бирү белән генә чикләнми, ә әкиятләрдәге кеше образларын да тәфсилле итеп тасвирлый. Хезмәтнең икенче һәм өченче бүлекләрендә халкыбызның күпсанлы ышанулары, йолалары, им–томнары җентекләп анализлана.

К. Насыйриның бу хезмәте беренче башлап рус телендә дөнья күрде. Сүз Кыскача йомгак ясап әйткәндә, К. Насыйри татар фольклористикасы өлкәсендә гаять күп эш башкарды. Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм бастыру этабыннан аларны фәнни нигезләрдә өйрәнүгә күчү, ягъни татар фольклористикасының мөстәкыйль фән буларак формалаша башлавы нәкъ менә аның эшчәнлеге белән бәйләнгән иде.

**Әдәбият**

1. Бәдигый Х. К.Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлындагы хезмәтләре. – Казан, Татар. кит.нәшр., 2007. – 112 б.

2. Гайнуллин М. Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри. – Казан, Тат.кит.нәшр., 2005. – 384 б.

3. Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты. 8 нче сыйныф: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д–лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 2 кисәктә / Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2015. – 206 б.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ МИРАСЫ–МӘҢГЕ ТУТЫКМАС МОГҖИЗАЛЫ БЕР ГӘҮҺӘР

**Гайнанов Б. С.**
Алабуга шәһәренең «1 нче гимназия–Милли белем
бирү үзәге» гомуми белем мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Вагизова Л.Г.

Мәгърифәтче, галим, фикер иясе, тәрҗемәче, язучы, фольклорчы.Кайсы гына өлкәне алсаң да, Каюм Насыйриның белмәгәне булмагандыр төсле. Вафатыннан 121 ел узса да, безгә ул әледә яңа яктана чыла бара.

Габделкаюм Насыйри һәрбер эшен башлар алдыннан «бисмиллаһ» сүзен әйткән. Нәселенең башын, авылының тарихын Болгар белән бәйли. Ул 9 буын бабасының исемен терки, иң ахырдан «әл–Болгари» дип, ягъни Болгар җиреннән – гыйлем дөньясыннан чыгышын ассызыклый. Каюм Насыйри тамырлары борынгы мәдәнияткә бәйле.

Каюм Насыйри бөтен гомерен гыйлемгә багышлый. Ул, әхрәви фәннәр янәшәсендә дөньяви фәннәрне яңадан күтәрергә кирәк, дигән максат куя. Насыйри башлангыч белемне әтисе, бабасыннан ала. Габделхөсәен, Габденнасыйр – икесе дә гыйлем ияләре. Насыйри истәлекләрендә аларның исемнәрен зурлап яза. Аның бабасы 100дән артык Коръәнне кулдан күчергән. Әтиләре, бабалары гарәп теле, гарәп синтаксисы юнәлешендә эшләгәннәр, күпсанлы дәреслекләр калдырганнар. Ул сәяхәт кылган вакытта Каргалы мәдрәсәсендә аларның дәреслекләрен күреп, сокланып, рәхмәт сүзләре белән искә ала [Гайнуллин 1980: 265]

16 яше тулгач, әтисе Каюмны Казанда Сәгыйть әл Әхмәт мәдрәсәсенә укырга кертә. Фарсы, гарәп телләренә әлеге мәдрәсәдә өйрәнсәләр, дөньяви фәннәрне «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә үзләштергәннәр. Бу мәдрәсәдә Каюм Насыйри 13 ел укый, шәригать нигезләрен, телләр өйрәнә. Рус дөньясы белән бәйләнеш Насыйрилар гаиләсендә күптәннән була: әтисе рус телендә документлар тутыра, бабасы Мәскәүдә хезмәт итеп кайткан була.

Алдагы 15 елын Каюм Насыйри Казанның «Духовная семинария»се белән бәйли. Бу – алдынгы уку йортларының берсе була. Биредә христиан белән янәшә ислам динен, татар телен өйрәнәләр. Каюм Насыйри исә татар

телендә гамәли дәресләр үткәрә. Мондагы эшчәнлеген ул яңа мәгариф системасын булдырыр өчен куллана. Европа үрнәгендә булган яңа дәреслекләр яза. Шундый дәреслекләрнең беренчел үрнәге – «Краткая грамматика». Ни кызыклы, Каюм Насыйри «Духовная семинария»дә халык авыз иҗаты, татар экиятләреннән мисаллар китереп, дәресләр бирә. Аның дәресләрен укыган лингвист Филипп Фортунатов, Масловскийлар татар дөньясы белән шул рәвешле таныша.

Каюм Насыйри татар телен өйрәтүгә бик таләпчән укытучы булган, дип әйтәләр. Документларда шулай язылган. Иң югары балл – 10 балл була. Мәсәлән, бөтен фәннәрдән 10 балл алган Масловскийга Каюм Насыйри 8 баллдан артыгын куймаган [Хуҗиәхмәтов 2002: 46].

Беренче татар энциклопедиясен Каюм Насыйри төзегән. Әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнгән вакытта, әдәбиятта энциклопедия жанрын Каюм Насыйри башлап җибәрде, дигән фикер бар. «Фәвакиһелҗөласа фил–әдәбият» – беренче татар энциклопедиясе: кеше акылы, фән, этика, тел мәсьәләләре, фольклор, әдәбият, музыка кебек темаларга багышлана, 40 бүлектән тора, 1884–1905 елларда 7 тапкыр басыла. Әйтик, «Татар байлары», «Татар укымышлылары», «Шәрык укымышлылары» җыентыклары календарьләрдә генә дөнья күрә. Анда дистәләгән шәхеснең биографиясе, эшчәнлеге турында мәгълүмат бар. Ул аны галим буларак өйрәнеп, тәкъдим иткән.

Татар экиятләре, Әбугалисинага багышланган тәрҗемә әсәрдә, экияти формада булса да, химия, симия кебек фәннәр турында искәртелә. Дөньяви фәннәргә кагылышы булган китапларны алып, Насыйри баштан балаларга тәрҗемә итә, соңрак әдәби эшчәнлегенә шундый китапларның эчтәлеген, мәгънәсен кертеп җибәрә. Каюм Насыйри дөньяви милли мәгарифнең үрнәкләрен бирә. Бу үрнәкләр алга таба «Татарская учительская школа»да дәвам иттерелә.

Шул дәвердә Каюм Насыйри күп дәреслекләр яза, мәсәлән, географиягә багышлап, 4 китап чыгара: «Географик терминнар», «Африка кыйтгасы» һ.б. Мәсәлән, татар дөньясыннан күренешләрне математик мисал итеп әзерли. Әдәбият, тәрҗемә, тел өлкәсендә эшләгән, дидек. Моннан тыш, ул менә дигән картограф булган! Әйтик, Казан губернасы картасы, Европада үткән тимер юллар картасы, астрономик сызымнары булган.

Насыйри мирасында әдәби эшчәнлек бик зур: XI–XVIII гасырлар арасындагы әдәби үсешне ул әдәби эшчәнлегендә чагылдыра: «Кырык вәзир кыйссасы», «Кырык бакча» һ.б. Татар зыялысы элек телләрне бик яхшы белгән: татар, гарәп, фарсы, рус телләрендә китапларны укый алган. XIX гасырның бер үрнәге буларак, Каюм Насыйринең китапларында телләр синтез рәвешендә яңгырый. Анда гарәп, фарсы алынмалары шактый күп. Үгет–нәсыйхәт кенә түгел, Каюм Насыйри һәрвакыт диалог төзи торган кеше була.

Каюм Насыйриның зур эше – вакытлы матбугат булдыру. Бу эшкә ул 1862 елда ук керешә. Газетаның исеме «Таң йолдызы» була. Проект тыела,

тукталып кала. Проектның аерым дәвамы да була. Хөсәен Фәезханов шундый ук эчтәлектәге проект тәкъдим итеп карый, ләкин рөхсәт итмиләр. Проект тыелса да, Насыйри югалып калмый: «Тәквим» исемле фәнни–популяр альманах чыгара башлый. Тәквим, ягъни календарьләрнең эчтәлеге гаҗәеп бай, киң планлы була. Анда көндәлек тормыш, икътисад турындагы вакыйгалар хәбәр ителә. Шул ук вакытта татар байлары, татар мәчетләре, Казан шәһәре тарихы, Пугачев восстаниесе, татар һәм Шәрык галимнәре турында язмалар урын ала. Каюм Насыйри төрле өлкәләрдә сәгатьнең агышы төрлечә булганын рәсемдә чагылдырып аңлата. Шушы күренеш аша халкыбызның географик интеллектын киңәйткән. Аерым календарьларында ул хәтта электр батареяләрен, сабынны һ.б. ясарга өйрәткән [Зөлкарнәев1985: 270].

Каюм Насыйриның 40тан артык басма китабы бар. Казан университетына ул ирекле тыңлаучы булып кабул ителә. Озак та үтми, тарих, археология, этнография җәмгыятенең күренекле вәкиле була. Ул вакытта тюркологияне үстерер өчен бик күп тырышлык куйган Николай Федорович Катанов эшләгән. Каюм Насыйри да биредә тирәнтен эшчәнлеген башлый. Аның китаплары Казанда гына түгел, хәтта Санкт–Петербургта да басылып чыга. Ул китап татар халкының гореф–гадәтләре, ырымнарына багышлана.

Каюм Насыйри Болгар чоры эпитафияләрен өйрәнә, дин өлкәсендә дә зур эшчәнлек башкара. Дин өлкәсендәге эшчәнлеген «иҗтиһадымның иң олысы» дип билгели. Ягъни тырышлыкның иң бөек ноктасы, дип әйтә. «Мифтахәл–Коръән» – Коръән гыйбарәләре сүзлеге. Коръәннең ачкычы дип тәрҗемә ителә. Коръәннең асыл мәгънәсен ачып бирүче гыйбарәләрнең тезмәсе ул. Биредә 2000гә якын гыйбарә. «Бу китапны укыган кеше үзен Коръән–хафиз дип әйтә ала», – дигән Каюм Насыйри. Бу китап 2015 елда 100 данә тираж белән дөнья күрә. Китап кульязма рәвешендә университетның фәнни китапханәсендә 130 ел саклана.

Шул рәвешле, ул – татар дөньясында яңа төрле мәгариф системасына, дөньяви рухта булган мәдәнияткә төп нигез салучыларның берсе. Каюм коесыннан без һаман да су эчәбез, гыйлем коесыннан без һаман да азык алабыз. Каюм коесы – Каюм Насыйриның үз куллары белән казыган кое. Ул һаман да саклана. Әдәби хәзинәбездә дә «Каюм коесы» образы яши. Үз вакытында шагыйрә Эльмира Шәрифуллина «Каюм коесы» дигән поэма иҗат итте.

Татар ашларына багышланган иң кызыклы китапларның авторы – Каюм Насыйри. Аның китабында Европа, рус, фарсы ашлары да урын алган. Насыйри шуларның татар табынында урын алганлыгы турында яза. Бу ашлар татар стилендә табынга куелган. Татарлар бәрәңге, камыр ризыклары ашаган, дип әйтәләр. Каюм Насыйри китабын укыгач, фикеребез үзгәрә: татар гаиләләре табынында яшелчә ризыклары бик күп урын алган. Татар әбиләре чәй табынына чәкчәк, кош теле, кыстыбый, пироглар гына әзерләп калмаган, бламанжедә әзерләгән (сөттән әзерләнгән француз десерты. Желатин, каймак

(сливки), сөт яки эремчек кушып ясалган). Каюм Насыйри, ни гаҗәп, бламанженың төрле–төрле рецептларын яза [Гайнуллин 1980: 275] .

Каюм Насыйри кул остасы да була. Төрле слесарь эшләрен үзе башкара. Механизмнарны төзәтү, зәркән эшләнмәләрен ясарга өйрәнә. Китапларын да үзе төпли – китап төпләү җайланмасын үзе ясый. Ул вакытын дөрес итеп бүлә белгән, көч–куәтен дөрес итеп кулланып, акыл эшен кул эше белән аралаштырып яшәгән.

К.Насыйриның иҗаты, эшчәнлеге халыкчанлык белән сугарылган. Бу аның халык өчен әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрүендә, халык мәнфәгатьләрен яклавында һәм китапларында халык иҗатына киң урын бирүендә күренә.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М.Н., Мәһдиев М.М. Татар әдәбияты. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1980. – 280 б.

2. Зөлкарнәев Ф. М. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татар.кит. нәшр.,1985. – 269– 273 б.

3. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы: Укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 169–200 б.

## КАЮМ НАСЫЙРИ ТАТАР МИЛЛИ ӘДӘБИ ТЕЛЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

**Гайнетдинова Л.Д.**

Алабуга шәһәренең "Инженер-технология лицее" укучысы

Фәнни җитәкче: Гатауллина М.Г.

Каюм Насыйри бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт иткән, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре арасында иң мөхтәрәм урыннарның берсен алып тора. Галимнең иң зур хезмәтләреннән берсе – тел өлкәсендәге эшчәнлек. Телче буларак ул бик катлаулы, күп яклы хезмәтләр башкарды: татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын исбат итте. Татар телен практик һәм фәнни эшкәртү юлында гаять зур эшчәнлек күрсәтте.

Милли әдәби тел барлыкка килү чорында сөйләмә телнең роле бик нык үсә, милли телнең әдәби-сөйләмә формасы барлыкка килә. Бу - милли әдәби телнең, бер диалектка нигезләнеп, башка диалектлардагы үзенчәлекләр хисабына баю процессы белән тыгыз бәйләнгән. Тарихи юнәлештә сөйләү теленең нормалары формалашу – катлаулы һәм озак процесс. Структур яктан аерма булуга карамастан, әдәби телнең язма һәм сөйләмә формаларында эчке грамматик һәм семантик бердәмлек милли әдәби телләр үсешендәге әһәмиятле тенденцияләрдән санала.

XIX йөздә әдәби тел проблемаларына зур игътибар итүчеләрнеңиң күренеклесе Каюм Насыйри була. Ул әдәби нормаларны төрле яклап эшкәртүдә, аларны билгеле бер тәртипкә китерүдә нәтиҗәле өлеш керткән

мәгърифәтче-галимнәрдән санала. Шуңа күрә Г.Ибраһимов, К.Насыйри эшчәнлегенә югары бәя биреп, әдәби тел үсешендә К.Насыйридан яңа этап башлана дип күрсәтә һәм аны “халыкны татар дип, телне татар теле дип, шуның өчен саф татарча язарга юл ачу кирәк дип төп кыйбланы утыртучы” атаклы шәхес итеп бәяли. “Каюм баба,- ди ул, - борынгы дәвернең әдәби төрки теленнән ерып чыгып, яңа әдәби татар теленә башлап юл ачты. Шул юлны һаман киңәйтү, сафлату, баету юлында 40-50 ел буенча гамәли рәвештә эшләгән кебек иң башлап татар халкының татарча теленең имла, сарыф, нәфү, бәлягатьләрен тикшерде, эзләде,кыйммәтле мирас калдырып китте”[Хаков 1972: 13].

Әдәби тел тарихы, аерым фән буларак, Октябрь революциясеннән соң гына өйрәнелә башлады. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе өчен алшартлар бик күптәннән туалар. Милли телнең башлангыч формалашу чоры, аның язуда теркәлә башлавы ерак тарихка барып тоташа. Татар халкы Казан ханлыгы чорында үзәкләшкән дәүләт тәшкил итә.Ул дәвердә үк инде халык теле һәм шул нигездә әдәби тел нормалары формалашкан була. Ә моңа, үз чиратында, борынгы Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорындагы уңай традицияләр зур йогынты ясыйлар. Бу тарихи шартлар милли тел нормаларының киң сферага җәелү, ныгу, тотрыклану процессын тизләтәләр һәм әдәби телнең камилләшүенә юл ачалар.

Милли әдәби тел формалашу чорында күренекле мәгърифәтче К.Насыйри борын-борыннан дәвам итеп килгән традицион үзенчәлекләрне исәпкә алып, тел нормаларын эшкәртүдә, татар тел гыйлемен үстерүдә зур эш башкара, фонетика, орфография, орфоэпия, лексика, грамматика, этимология, стилистикага караган хезмәтләр иҗат итә. Татар халкының күренекле энциклопедист галиме буларак К.Насыйри рус-татар һәм татар-рус телләренең чагыштырма грамматикасына нигез сала. Аның хезмәтләре татар телен өйрәнүче руслар һәм рус телен өйрәнүче татарлар өчен фәнни нигездә язылган иң беренче лингвометодик кулланмалардан исәпләнә [Хаков В.Х 1972: 55].

Каюм Насыйри үзенең “Кыскача татар грамматикасы”, “Әнмүзәҗ” исемле хезмәтләрендә аваз чиратлашулары, авазларның үзара тәэсир итешүләре, сүз басымы һәм авазларны төркемләүнең кайбер принципларын бәян итә. Ул, беренче булып, татар телендә ун сузык аваз булуы, бары тик язуда гына аларның өч хәреф белән белдерелүен исбатлый. “Үз телебезнең кагыйдәсенә ихтыяҗ шул дәрәҗәдер ки, әгәр берәү үз теленең кагыйдәләрен белмәсә, аңа гайре телне үгрәнү гаять мөшкилдер”,- ди ул үзенең “Әнмүзәҗ” әсәрендә [Җамалетдинов 2004: 13].

Фразеологизм – бер төшенчәне белдерүче таркалмый торган тотрыклы сүзләр тезмәсе ул. Татар телендә дә, рус телендә дә алар – таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш һәм бөтенлек булу, сөйләмгә әзер килеш кереп килүләре белән аерылып торалар. Мәсәлән, баш вату-ломать голову, борын күтәрү - задирать нос һ.б. Тел белеменең әлеге төр сүзтезмәләрен өйрәнүче тармагын фразеология дип йөртәләр.

Татар фразеологиясенә нигез салучы булып Каюм Насыйри исәпләнә. Ул башлаган әлеге юнәлештәге эшне Ш.Рамазанов, Җ.Вәлиди, Г.Алпаровлар дәвам итә. Татар фразеологиясенең чын-чынлап аерым бүлек буларак үсеш алуы XX йөзнең 50-60 нчы елларына карый. Шул елларда һәм соңрак аеруча нәтиҗәле эшләгән галимнәрдән Г.Х.Әхәтов, Г.Х.Ахунҗанов, Н.Исәнбәт, И.Рамазанов, Ф.С.Сафиуллина һ.б. атарга мөмкин[Җамалетдинов 2004: 37].

Русча-татарча сүзлекләр арасында шактый урынны терминнар сүзлеге, ягъни төрле өлкәләргә караган терминнарны үз эченә алган сүзлекләр алып тора. Мондый сүзлекләрне иң беренче фәнни югарылыкта төзүчеләрдән К.Насыйри исәпләнә(Полный русско-татарский словарь с дополнениями из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины.-Казань, 1892.-263с.), XX йөз башында һәм әлеге гасыр дәвамында исә, аларны төзү эше аеруча киң колач ала.

Каюм Насыйри , татар халкының күренекле мәгърифәтчесе буларак, шулай ук башка фәннәрне өйрәнүгә  һәм алар буенча дәреслекләр төзүгә зур игътибар бирә. Аның басылып чыккан әсәрләре шул турыда сөйлиләр. К.Насыйри татар телен җентекләп өйрәнә, аның фән теле һәм бай тел икәнлеген раслый, фәнни грамматикага нигез сала. К Насыйри бердәм әдәби тел нормаларын эшкәртүне язма тел белән сөйләү телен якынайту юнәлешендә алып бара, әдәби телнең функциональ стильләрен үстерүдә, аларны төрле чаралар белән баетуда, фәнни терминологияне (математика, география, лингвистика, биология, медицина һ.б. фәннәр буенча) тәртипкә китерүдә үзеннән зур өлеш кертә. Ул һәр өлкәдә халык аңларлык дәрәҗәдә язарга тырыша.

Каюм Насыйри язма әдәби телнең халыктан читләшкән булуын, анда башка теллләрдән кергән сүзләрнең күп кулланылуын күрсәтеп, халык сөйләшкәнчә язуны үзенең төп максаты итеп куя. XIX йөзнең икенче яртысында милли әдәби тел нормалары барлыкка килгән чорда К.Насыйриның эше гаять күпкырлы. Ул- чын мәгънәсендә тарих тарафыннар тудырылган кеше. “Татар милли әдәби телен нигезләү, аның потенциаль мөмкинлекләрен һәм бик нечкәхасиятләрен ачып бирү, грамматик,орфографик һәм орфоэпик нормаларын кагыйдәләштерү бурычларын тарих Насыйрига йөкләгән”,- дип язды Ш.Рамазанов. Каюм Насыйри тел өлкәсендә төрле карашлар хөкем сөргән бик катлаулы чорда яшәде. Ул татар әдәби теленең үз специфик закончалыкларына нигезләнергә тиешлеген күтәреп чыкты, шул юнәлештә практик эшчәнлек күрсәтте, әһәмиятле хезмәтләр тудырды, төрле фәннәрне халыкка җиткерүдә күп эшләде. Бөек мәгърифәтченеңтөрле өлкәдәге иҗат эшчәнлегеаерым җыентыкларда басылып чыкты.Башка телләрне белү өчен ана телен белү кирәк. “... Кеше үзенең телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр”, - дип язды К.Насыйри.

**Әдәбият**

1. Җамалетдинов Р.Р. Татар һәм рус телләренеңчагыштырма грамматикасы: Дәреслек-кулланма. – Казан: КДУ нәшр., 2004. -144 б.

2. Насыйри К. Полный русско-татарский словарь с дополнениями из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины.- Казань, 1892.– 263с.

3. Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше.- Казан: КДУ нәшр., 1972. – 222 б.

## КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ

**Гилмуллина А.Л**.

Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы

Фәнни җитәкче: Гилмуллина Л.С.

Бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт кылган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре шактый күп: Утыз Имәни, Габдулла Тукай, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый... Болар арасында иң мөхтәрәм урыннарның берсен Каюм Насыйри алып тора.

1860 елдан башлап ярты гасыр дәвамында гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән Каюм Насыйри татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле була. Ул үз алдына куйган максатыннан артка тайпылмыйча, гел алга карап, биеклеккә, яктылыкка омтылган. Үзенең бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган. Замандашлары арасында беренчеләрдән булып, әдәбият һәм фән телен халыкның сөйләм теленә якынайту мәсьәләсен күтәреп чыккан, иҗтимагый фикер үсешенә, татар теленең гыйльми нигезләрен булдыруда, халык авыз иҗаты әсәрләрен бастыруда, алар белән башка халыкларны таныштыруда, ниһаять, әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетуда Каюм Насыйри, үзеннән зур өлеш кертеп, бай әдәби – мәдәни мирас калдырган.

Каюм Насыйриның эшчәнлеге, крепостной строй яшәгән вакытларда башланып, Россиядә капитализм үскән чакларга туры килә. Аның беренче әсәрләреннән “Мәҗмәгыл–әхбар” (“Хәбәрләр җыентыгы”) 1859 елда языла. Басылып чыккан беренче әсәре – “Кыскача нәхү китабы”. Бу китап, русча өйрәнүче татарларны күздә тотып, рус телендә языла, “Краткая татарская грамматика” исемендә 1860 елда басыла.

Балаларга һәм башлангыч белем алучыларга табигать күренешләре турында кыскача мәгълүмат биргән “Буш вакыт” әсәре дә шул ук елда басыла. Ул татар телендә язылган әдәби–фәнни популяр әсәрләрнең беренчесе. 1868 елда К. Насыйри “Буш вакыт”ның икенче вариантын бастыра. 1860 елгы басма 12 битле генә булса, икенчесе 87 биткә җитә.

К.Насыйри 1871 елда ярым журнал характерында, “Казан календаре” исемендә, еллык өстәл календаре чыгара башлый. Газета вазифасын өлешчә әнә шул календарьлар үти. Аның егерме дүрт ел дәвамында чыгып килгән

календарьларында, ел саен кабатлана торган гадәти материалларында фәнни һәм әдәби мәкаләләр урнаштырыла. Насыйри татарлардан беренче журналист–энциклопедист та булган.

К.Насыйриның матур әдәбият өлкәсендәге хезмәте “Кырык вәзир кыйссасы” исемле мәшһүр әсәрне татар телендә эшләп, 1868 елда бастырып чыгаруы белән башлана. Эчтәлеге, сәнгатьлелеге ягыннан укучыларны кызыксындырырлык бу әсәр халык арасында тиз тарала, сигез тапкыр басыла. Әсәргә кергән хикәятләрнең күпчелеге гаделлек, намуслылык, батырлык идеяләрен яклауга юнәлдерелгән.

Әсәрнең уңай образлары – тугрылыклы, хыянәтсез кешеләр. Насыйри аларның җиңеп чыгуларын күрсәтә. Ялганчы, башкаларга яла ягарга омтылучы, мәкерле кешеләр үзләре казыган базга төшеп һәлак булалар. Хикәятләр, эчтәлеге белән бер–берсеннән аерылып торса да, “Мең дә бер кичә”дәгечә бер төп идеяне үстерүгә, чишүгә хезмәт итәләр.

1874 елда Насыйри “Әбүгалисина кыйссасы”н татарчалаштыра. Халыкның бай хыялларын гәүдәләндергән, югары художество көченә ия булган, дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителгән бу әсәр героеның прототибы – Урта Азиядә яшәгән бөек галиме – философ, юрист һәм врач Ибне–Сина (980–1037) була. Легендар сюжетларны К.Насыйри очраклы тәрҗемә итми. Ул аның мәгърифәтчел теләкләренә, фәнни карашларына җавап бирә. Әсәрнең баш герое Әбүгалисинаның патшалардан акыллы, белемле булуы аркасында аларны җиңүче итеп бирелүе укучыларның игътибарын тарткан. Әсәр фантастик планда язылган, нечкә иронияле, кыска диалоглар, үткен сүзләр, аерым персонажларның үзенчәлекле сөйләмнәре, хатлары әсәрнең художество көчен үстерәләр, идея эчтәлеген отышлы ачалар.

1879 елда К.Насыйри аеруча зур күләмле “Фәвакиһел–җөләса фил–әдәбият” (“Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше”) исемле хезмәтен яза башлый. Аның кыскартылган вариантын, “Кырык бакча” исеме белән, 1880 елда бастыра.

Бу әсәрдә өйрәнелергә һәм сакланырга тиешле гадәтләр турында сөйләнелә, гыйбрәтле мисаллар китерелә. Аларның бер өлеше заманның социаль җитешсезлекләрен тәнкыйть итүгә, укучыларның аңын, культурасын күтәрүгә юнәлтелгән. “Кырык бакча” китабында мәңгелек афоризмнар, хикмәтле сүзләр, фикерләр байтак. Мәсәлән: “Кеше үзен–үзе таныса, камил, акыллы икәне шуннан беленер”. “Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне–үзең үгрәт”.

1884 елда К.Насыйриның “Фәвәкиһел–җөләса фил–әдәбият” исемле, 609 битле әсәре Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Тел белеме хезмәтләрендәге кебек, монда да искедән яңага омтыла, схаластик әдәбияттан арыну, халык аваз иҗатына игътибар итү кирәк дигән принципны үткәрә.

Халык экиятләре стилендә язылган “Патша белән карт” хикәясендәге патшаны, чиновникларны әдип иң явыз кешеләр итеп сурәтли, халыкны

җәберләүләрен фаш итә. Әсәрнең төп идеясе – ерткыч патшаларга һәм шул чордагы җәбер–золымнарына нәфрәт белдерү.

К.Насыйриның балалар әдәбиятына кергән “Тәрбия турында”, “Этика турында”, “Кырык бакча”, “Кабуснамә” һ.б. китаплары дидактик стильдә язылган.

“Әдәбият буенча әңгәмәдәшләргә китап” (1884), хрестоматия рәвешендә өлкәннәргә атап язылса да, аны балалар да уңышлы файдаланган. Халык шагыйре Г.Тукай да 8–9 яшьлек вакытында бу әсәрне авыл кешеләренә укуын искә төшереп язган.

К.Насыйриның “Җәвәһирел хикәят” китабы халык зирәклегенә, тапкырлыгына нигезләнгән, анда күптөрле мәсәлләр һәм хикәяләр тупланган (“Эт һәм сөяк”, “Ана һәм бала”, “Чеөлән һәм чыпчык” һ.б.)

К.Насыйриның халыкка аңлаешлы әсәрләрен ятратканнар, кулдан кулга йөртеп укыганнар. Мәдрәсәләрдә рөхсәт ителмәсә дә, шәкертләргә дә әлеге китаплар таныш булган. Аның балалар китабына таләпләре, аның үрнәкләре татар балалар әдәбиятын үстерүгә нигез булып тора.

К.Насыйри күпкырлы эшчәнлек алып бара һәм иҗтимагый фикер үсешенә, татар теленең гыйльми нигезләрен булдыруда, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп бастыруда, алар белән башка халыкларны таныштыруда, яшь буынга тәрбия һәм белем бирүдә, ниһаять, әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетуда үзеннән зур өлеш кертеп, бай әдәби–мәдәни мирас калдыра.Аның китаплары — хәзерге милли тормышыбыз өчен дә аваздаш булган бай хәзинә.

**Әдәбият**

1.Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 3 том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – 384 б.

2.Хөснетдинова Р. Андыйлар табигатьтә сирәк очрый // Казан утлары. – 1998. – №4. – Б.142

## “ӘБУГАЛИСИНА КЫЙССА”СЫНДА МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ИДЕЯСЕ

**Гобәйдуллин К.Р.**
Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.

Дөньяда гомерләрен, талантларын халкына багышлаган, аларны аңлы – белемле һәм тәрбияле итү өчен намус белән хезмәт иткән галимнәр, мәгърифәтчеләр бар. Шулар арасыннан мин лаеклы рәвештә Каюм Насыйрины атар идем.

Каюм Насыйри 1825 нче елның 14/2 февралендә элеккеге Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы, ачык фикерле Насыйр мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне атасыннан алганнан соң, Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга керә, анла гарәп – фарсы телләрен, үзлегеннән исә рус телен үзләштерә. Соңрак Казан

университетына ирекле тыңлаучы булып керә.Татар зыялылары, рус галимнәре белән якыннан аралашу, татар тарихы, Көнчыгыш һәм рус классикасы белән кызыксыну аның алдынгы карашлы, тирән белемле, бай шәхес булып формалашуына китерә | Шәймарданов 1997:89 |.

Каюм Насыйри – күпкырлы шәхес. Ул тәрбия, педагогика, тел,тарих, этнография, матур әдәбият, халык авыз иҗаты, тәрҗемә өлкәсендә армый – талмый эшли. Мәгърифәтчегалимнең төп максаты – халыкның аң – белемен күтәрү, тормышта үз урыннарын таба алырлык, үз иленә файда китерерлек әхлаклы, тәрбияле шәхес тәрбияләү. Галим яхшы аңлый: мәгърифәтчелек – халыкны алга илтүнең төп чарасы, шуңа күрә барлык көчен, талантын балаларга белем бирүгә, китаплар язуга, бастыруга, аларны таратуга багышлый.

Каюм Насыйри үзенең тәрҗемә әсәрләре белән дә татар балалар әдәбиятын баетуга ирешә. Шәрыкъ экиятләренә хас фантазиягә бай “Әбүгалисина кыйсса”сы, “Гөлрөх һәм Кәмәрҗан экиятләре, “Кырык вәзир кыйссасы” һ.б. Шулар арасында “Әбүгалисина кыйсса”сы – иң танылган әсәрләрнең берсе [Минһаҗева 2009: 38].

1872 нче елда К. Насыйри “Әбүгалисина кыйсса”сын татарчалаштыра. Халыкның бай хыялларын гәүдәләндергән, югары сәнгать көченә ия булган, дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителгән бу әсәрнең прототибы – Урта Азиядә яшәгән бөек галим – философ, юрист, табиб Ибне Сина (980 –1037). Легендар сюжетлы бу әсәрне К.Насыйри очраклы тәрҗемә итми. Ул аның мәгърифәтчел теләкләренә, фәнни карашларны популярлаштыру омтылышларына, демократик идеяларына җавап бирә. Әсәрнең баш герое Әбугалисинаның патшалардан акыллырак һәм белемлерәк итеп сүрәтләнүе, аларны җиңүе укучылар игътибарын җәлеп иткән. Халыкның үз экиятләрендәге шикелле үк, бу әсәрдә дә патшалар, вәзирләр, җәлладлар һ.б. җиңеләләр, мәсхәрә булалар. Әсәр фантастик планда язылган. Сурәтләнгән вакыйгалар реаль тормыштан ерак торалар. Ләкин шул фантастик сурәтләүләрдә гуманистик идеяләр яклана, хаксызлыкка, деспотизмга каршы көрәш алып барыла |Гайнуллин 2015: 232 |.

“Әбүгалисина кыйсса”сы – халыкчан әсәр. Сурәтләнгән вакыйгалар чынбарлыктан шактый ерак. Бер ата һәм анадан туган игезәк туганнар, төп геройлар – Әбүгалисина һәм Әбелхарис белемле, зиһенле геройлар буларак алынганнар, гипербола ярдәмендә тасвир ителгәннәр. Көнбатыш илендәге Фисагурис (Пифагор) исемле галимнең хезмәтләре сакланган мәгарәгә кереп, ел дәвамында белем туплау, симия гыйлемен үзләштерү аларны могҗизалар тудыру сәләтенәия ия итә. Мәгарәдән чыгып, үлем элмәгеннән котылганнан соң, ике туганның юллары аерыла, туры һәм әхлакый планда да. Чөнки алар гыйлем көчен төрле максатларда файдаланалар: Әбугалисина ярдәмчел, кешелекле. Ул гади халыкны үз итә, белемен кешеләргә файда китерү өчен куллана.

Әбелхарис– аның киресе. Белем дәрәҗәсе дә Әбүгалисинадан бераз кайтышрак. Югары катлау вәкилләренә ярарга тырыша һәм белемен явызлык

юлында файдалана. Нәтиҗә аянычлы. Ул патшага аталган агулы чәчәкне иснәп һәлак була.

Әсәр дәвамында бирелгән вакыйгалар аша идея ачыла. Кеше акылының көчен, аң – белемнең бөтен нәрсәдән өстен булуын күрсәтү – бу әсәр үзәгендә алынган төп фикер. Белем –кешеләргә ярдәм һәм яхшылык юлында гына файдаланылырга тиеш, югыйсә нәтиҗә аянычлы булырга мөмкин дигән фикер кыйссадагы һәр вакыйга – хәрәкәт аша укучыга җиткерелә|Минһаҗева 2009: 40|

Шулай итеп, гомере буе белем туплаган, аларны бөртекләп язган, акыллы кешеләрнең мәгърифәтчелек карашларын тараткан галим "Әбугалисина кыйсса"сында белемнең зурлыгына, олылыгына мәдхия җырлый, белемле кешенең патшалардан да өстен булуын күрсәтә. Төп герой – Әбүгалисина белемле, тәрбияле, әхлаклы, тырыш, язу эшенә дә оста, аның табигатендә зиһенлек, үткенлек, сәләт, белемнәрне тиз үзләштерү кебек сыйфатлар бар.

Унике яшенә җиткәндә, Әбүгалисина инде бик күпне белүче гыйлем иясе булып җитешә, төрле фәннәрдән үзе дә башкаларга сабак укыта башлый. Үзеннән күп зур балалар аннан килеп дәрес алалар|Насыйри 1990: 77 |.

Шулай итеп, Әбугалисина – тирән белемле, югары әхлаклы герой, аның уңай сыйфатларын башка кешеләр дә үзләрендә булдырырга тырышалар. Гомумән, татарлар укымышлы кешене хөрмәт итәләр, үзләре дә белем алырга, укырга тырышалар. Бу сыйфатлары аларны гомере буе озата бара. Олы яшьтәге әби –бабайларның мәктәп –мәдрәсәләрдә укып йөрүе шуңа дәлил булып тора. Әсәрнең теле гади һәм серле, укучыны үзенә тарта.

Әбүгалисина гомеренең соңгы көннәрен кайда үткәрә соң?Бу сорау, әлбәттә, укучыны кызыксындыра. Билгеле: ул гомере буе укый, үз өстендә эшли, танылган галим булып җитешә. Аның эшләре ал да гөл генә бармый, дошманнары да очрап тора, чөнки аның белеменә, сәләтенә, тылсымлы көченә кызыгалар, аны юк итәргә телиләр, шуңа күрә аңа яшәү урынын берничә тапкыр алыштырырга туры килә.

"Әбүгалисина таң белән йокыдан торды. Кунаклар бик тәмләп йоклыйлар иде. "Гаҗәп" шәһәрен юкка чыгарды.Үзе симия гыйлеме көче белән бу шәһәрдән бик еракта булган Һәмәдән шәһәренә күчеп китте. Анда зур бер галим белән танышып, гыйлем алу, китаплар язу эшенә кереште. Озак еллар буена шунда калып, Ибне Сина исеме белән дан казанган зур галим булып китте"|Насыйри 1990: 131 |.

Укучылар арасында К.Насыйриның "Әбугалисина" китабы зур популярлык казана. Бу фантастик повесть Каюм Насыйри яшәгән чорда да 7 тапкыр басыла. Бүгенге көндә дә бу әсәрне укучылар рус һәм татар телләрендә яратып укыйлар. Китаптагы вакыйгалар укучыларның күзаллауларын үстерә, фантастик күренешләр реаль күренешләр белән үрелеп барыла, халыкның караңгылыктан, усал көчләр изүе астыннан чыгарга омтылышы чагылдырыла {Хуҗиәхмәтов 1998: 208 ].

Йогаклап әйтсәк, мәгърифәтче галим һәм әдип Каюм Насыйри Шәрык, рус, Европа казанышларын, тәҗрибәсен өйрәнә, эшкәртә, татарның рухи

мирасы белән куша. Аның хезмәтләре нигезендә мәгариф, әдәбият һәм мәдәният үсеш ала. Шулай итеп, татар халкын танытуда, аның милли үзаңын үстерүдә аның эшчәнлеге бик зур була.

**Әдәбият**

1.Әмирхан Ф.З., Кутуй Г.Н., Насыйри К.Н., “Могҗизалар дөньясында”: Повестьлар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.– 255 б.

2. Гайнуллин М.М., Гайнетдинов М.В., Мәхмүтов Х.Ш.Татар әдәбияты тарихы. 3 том: XIX йөз. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015.– 551 б.

3.Минһаҗева Л.И., Мияссарова И.Х. Татар балалар здзбияты. – Казан: Татар. “Хәтер”. нәшр., 2009.– 383 б.

4. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгариф тарихы һәм фәлсәфәсе. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 1998.– 398 б.

5. Шәймарданов Р.Х., Сибгатуллина Ә.Т., Сибгатуллин Р.Г. Татар халык педагогикасы.– Яр Чаллы: “КАМАЗ” газета– китап нәшр., 1997.–135 б.

## КАЮМ НАСЫЙРИ – ТАТАР ДӨНЬЯСЫНА ЮЛ КҮРСӘТҮЧЕ

**Зайнагутдинов Б.А.**

Алабуга шәһәренең “Инженер–технология лицее” укучысы

Фәнни җитәкче: Агмалова Э.Э.

*Уйламаенча, ашыгып эш кылган кеше һичбер үкенеч татмый калмас.*

(Каюм Насыйри)

Әлеге тирән мәгънәле сүзләрнең авторы – күренекле галим, педагог, язучы һәм татар халкының мәгърифәтчесе Каюм Насыйри. Гомер буе халкына хезмәт иткән, халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәгән татар галимнәре, зыялылары бик күп. Шулар арасында иң мөхтәрәм урыннарның берсен Каюм Насыйри алып тора. 77 яшендә вафат булган галим ярты гасырдан артык милләткә хезмәт итә.

Габделкаюм Габденнасыйр углы Насыйри 1825 елның 14 февралендә элеккеге Зөя өязе (хәзерге Зеленодол районы) Югары Шырдан авылында рухани гаиләсендә дөньяга килә. Аның әтисе һәм бабасы заманының бик укымышлы кешеләре була.

Габделкаюм башлангыч белемне әтисеннән ала. Алга таба ул Казанның бер мәдрәсәсенә килә. Биредә аның 1841—1855 елларда укуы мәгълүм.

Мәдрәсәне тәмамлагач, К.Насыйри христиан руханилары һәм миссионерлары әзерли торган Казан Духовное училищесында һәм Духовная семинариясендә чирек гасырга якын татар теле укытучысы булып эшли. Аның 70 елларда бераз вакыт татар балаларына рус теле укытуы да билгеле. 1879 елда уку йортларында эшләвеннән туктый һәм калган гомерен, нигездә, фәнни–тикшеренү эшләренә багышлый.

Каюм Насыйри гомере буе укый, өйрәнә. Ул татар, гарәп, фарсы, рус һәм төрек телләрен камил белә, фәннең төрле тармакларыннан хәбәрдар була. Аның

рәсем ясау, сызым, китап төпләү, табиблык, балта һәм тимер эшләре белән шөгыльләнүе дә мәгълүм. К.Насыйри Казан университеты белән шактый тыгыз мөнәсәбәттә яши. Духовное училищеда эшләү вакытында университетка ирекле тыңлаучы буларак та йөри. К.Насыйри 1902 елның 2 сентябрендә вафат була. Кабере— Казан шәһәренең Яңа бистә зиратында.

К. Насыйри фикеренчә, телнең кеше, милләт тормышында әһәмияте бик зур. «Хәзерге заманда, — ди ул, — башка милләт халыкларының максаты — телне камилләштерүдер». Туган телне белү башка телләрне өйрәнү өчен дә кирәк. Әгәр «башка телне өйрәнәсе булсаң, — дип яза Каюм Насыйри, — ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү бик кирәк...»

К. Насыйри телдән тыш тарих фәне белән дә бик кызыксынган. Аның бу фән буенча төрле мәкаләләре, махсус китаплары да бар.

Аның математика, фәлсәфә, география, медицина (анатомия, физиология, гигиена...), юриспруденция, игенчелек, кулинария һәм башка фәннәр буенча язган китаплары да татар халкында уку–укыту әсбабы рәвешендә кулланылды.

Каюм Насыйри, халыкны агарту максатында, гәзит чыгару хакында хыяллана. Исемен дә «Таң йолдызы» дип уйлаган була. Әмма патша Хөкүмәте аңа бу хыялын тормышка ашырырга рөхсәт бирми.

Шулай да К. Насыйри халыкка аң–белем бирүнең яңа бер юлын таба. Ул — еллык өстәл календаре чыгару. Аның беренче саны 1870, ә соңгысы 1896 елда дөнья күрә.

К.Насыйри календарьлары (аларның уртача күләме—40— 70 бит) төрле характердагы материалларга бай була. Анда табигать турындагы белешмәләрдән тыш, фәнни мәгълүматлар, әдәби әсәрләр, тарихи хәбәрләр; тормыш яңалыклары һәм башка кызыклы мәгълүматлар да була.

Каюм Насыйриның эшчәнлеге — милләткә хезмәт итүнең бөек бер үрнәге. Аның китаплары — хәзерге милли тормышыбыз өчен дә аваздаш булган бай хәзинә.

**Әдәбият**

1.Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 3 том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.

2. Хөснетдинова Р. Андыйлар табигатьтә сирәк очрый // Казан утлары. – 1998. – №4.

## К. НАСЫЙРИНЫҢ ТЕЛ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Захарова А.В.**
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доцент Габидуллина Ф.И.

К. Насыйриның иң зур хезмәтләреннән берсе – тел өлкәсендәге эшчәнлек. Телче буларак ул бик катлаулы, күп яклы хезмәтләр башкарды: татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын исбат итте. Татар телен практик һәм фәнни эшкәртү юлында гаять зур эшчәнлек күрсәтте.

К. Насыйри тел гыйлеме, сүзлекләр төзү буенча аеруча күп эшләр башкарды. Бу өлкәдә ул кагылмаган, өлеш кертмәгән бер генә тармак та юк диярлек. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген (“Ләһҗәи татари”,1895) башлап ул төзи. Русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр төзеп бастыра.

К. Насыйри рус телен үзләштерү, рус китапларыннан файдалану өчен кирәк булган уку китапларын булдыру өстендә дә эшләде (“Кыйрәәте рус”,1889). “Рус теленең грамматикасы”н (“Нәмүнә, яки әнмүзәҗ”,1891) төзеп, бастырып таратты. Бу эшләрен үзенең практик укыту процессында сынап, ул бер телне икенче тел белән чагыштыру методын кулланды. Галим рус, татар грамматикаларында булган яңалыкларны, аермалыкларын, үзенчәлекләрен өйрәнде, аларны укучыларына төшендерде. К. Насыйри керткән бу яңалык хәзерге көндә дә уңышлы методларның берсе булып санала [Гайнуллин 1974: 15].

К. Насыйри, замандашлары арасында беренчеләрдән булып, әдәбият һәм фән телен халыкның сөйләм теленә якынайту мәсьәләсен күтәреп чыкты. “Инде телебезгә игътибар итеп, яхшы тикшереп карасак, билгеле ки, телебездә булган бәетләр, шигырьләр, мәкальләр, идиоматик әйтемнәр бик уңышлы рәвештә ритм һәм рифмага салынып төзелгәннәр, гарәп һәм фарсы телләреннән алынган сүзләр ярдәме белән мәгънәне тулы һәм матур итеп бирүдә башка телләрдән һич тә ким түгел, бәлки кайбер яктан үзенчәлекләре күбрәк булган урыннары да бардыр, бигрәк тә фигыльләрдә. Ләкин шуны да әйтеп китәргә кирәк: телебез, бер дә кузгалмыйча, бер урында утырып калган. Хәзерге заманда яшәүче башка милләт халкының теләге – тел өстендә эшләү, телне төзәтү һәм яхшырту”, - дип, әдип әнә шул эшләнмәгән эшләр мәйданына ташланды, көрәшеп яшәде [Гайнуллин 1974: 16].

Киң колачлы галим татар халкын төрле фәннәрнең нигезләре белән үз ана телендә таныштыру өчен тырыша. Математика, география дәресләре, ботаникадан үсемлек исемнәре китабын яза. Аның табигать белеменә багышланган “Буш вакыт” исемле китабы татар телендә чыккан беренче фәнни-популяр әсәр булып санала. Ул унбиш ел буе өстәл календарьларында табигать белеме һәм башка фәннәр буенча мәкаләләр урнаштыра, күп кенә файдалы киңәшләр бирә.

К. Насыйри, татар телен тирәннән өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килгән: “Әгәр дә без игътибар белән үзебезнең телебезне өйрәнсәк, аның сүзләр күләме, атамалар, төшенчәләр, гомумән, төзелеше буенча гарәп, фарсы телләреннән ким түгеллеген, кайбер яктан, бигрәк тә фигыльләр өлкәсендә, баерак та булуын күрәбез” [Гайнуллин 1974: 21].

Татар халкына туган телен өйрәтүдә аның фәнни хезмәтләре зур әһәмияткә ия булды. 1898-1899 елларда К. Насыйри тарафыннан төзелгән ике томлы “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” телебезнең никадәр бай икәнен күрсәтте. Аның бу сүзлеге бүгенге көннәрдә дә зур фәнни хезмәт буларак кулланыла. Анда еш очрый торган гарәп һәм фарсы сүзләренә аңлатма бирелгән, татар

теленең бәхәсле мәсьәләләре күтәрелгән, сүзләрнең килеп чыгышы күрсәтелгән.

1894 елда фонетика, сүз төркемнәре һәм берникадәр синтаксистан мәгълүмат кертеп язылган татар грамматикасы "Әнмүзәҗ" басылган. Насыйри бу китабында беренче тапкыр авазларга классификация ясап, аларны 10-сузык, 29-тартык авазга бүлеп күрсәтә.

1892 елда дөрес язу һәм орфография кагыйдәләре китабы "Кавагыйдә китабәт" басылып чыкты. Бу хезмәтендә Насыйри: "Һәрбер культуралы кешенең ике төрле теле була: шуларның берсе – анасыннан сөт имгән вакытта өйрәнгән тел, икенчесе – укытучыдан укыганда – гыйлем һәм фән терминнары белән ачылган тел...", - дип язды [Насыйри 2004: 35].

1894 елда аның "Иҗек һәм әлифба" китабы басылган. Балаларга аваз турында беренче мәгълүмат биргәндә сүзләр сайланышы белән бу әлифба бүгенге көндә дә методик кызыксыну уята әле.

Башка телләрне белү өчен ана телен белү кирәк. "... Кеше үзенең телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр", - ди К. Насыйри [Насыйри 2004: 59].

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М. Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2005. – 384 б.

2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр (2 басмасы). – Казан: Тат книгоиздат. Матур әдәбият редакциясе, 2016. – 408 б.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ БУЛАРАК ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

**Зиязиева Н.Ф.**

Минзәлә шәһәренең 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Хамаева Г.А.

Каюм Насыйри – татар халкының танылган мәгърифәтчесе, язучысы, һәм фольклорчысы. Ул татар мәдәнияте, әдәбияты һәм фольклорын өйрәнүдә зур хезмәт кертеп, халык авыз иҗатының мөһим аспектларын шәхсән анализлый. Насыйриның иҗатында халык авызы, аның мәгънәсе, традицияләре һәм күңел ачу формалары бик киң урын алып тора. Чыннан да, Каюм Насыйриның хезмәтләре – бүгенге көндә дә безнең өчен үрнәк. Аның фикерләре телне өйрәнүгә нигез булып тора.

Үзеннең төп бурычларының берсе – татар халкын агарту, мәгърифәтле итү дип санаган К.Насыйри педагоглык өлкәсендә дә зур эш башкара. Ул балаларга әхлак тәрбиясе бирүдә халык авыз иҗаты әсәрләре зур роль уйнавына игътибар итә, һәм баланың сөйләм телен үстерү, туган телен һәм аның мантыкый төзелешен өйрәтүдә, мәдәни мирасы белән таныштыруда фольклор материалларының алыштыргысыз булуын раслый. Шунлыктан галим балаларга

тәрбия бирүгә багышланган һәр хезмәтендә мәкаль һәм әйтемнәргә, табышмак һәм кыска җырларга урын бирә, алар аша халык фикерен яшь буынга җиткерә.

К.Насыйри үзе җыйган материалларны махсус фольклор җыентыклары итеп чыгара алмый, ләкин ул аларга үзенең аеруча әһәмиятле хезмәтләрендә махсус бүлекләр багышлау мөмкинлеген таба.«Кырык бакча» китабының кырыгынчы бакчасы (бүлеге) түбәндәге фольклор әсәрләрен эченә ала: 296 мәкаль, 116 кыска җыр, «Сәламнамә», «Мәдех Чәй», «Уңмаган килен» һәм «Әбъят» исемле бәетләр, «Зиһен сынашмак» исеме астында бирелгән өч табышмак–мәсьәлә («Ике көтүче», «Кәҗә, бүре, кәбестә», «Өч сәүдәгәр»).

«Фәвакиһел җөләса» китабының соңгы бүлеге тулысынча диярлек халык иҗаты әсәрләренә багышланган. Дөрес, аларның шактый өлеше «Кырык бакча»дагы материалларны кабатлый, ләкин яңа әсәрләр дә өстәлгән. Аеруча мөһиме: һәр жанрга автор кыскача билгеләмә бирә һәм бик күп әсәрләрне фәнни комментарийлар белән бастыра. Бу китапка кергән фольклор әсәрләре: 27 табышмак, 117 кыска җыр, «Әбъят Мәхбүбләргә сәламнамә», «Әбъят чәй бәянында», «Әбъят уңмаган килен бәянында» исемле 3 бәет, 315 мәкаль һәм әйтем.

“Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре” хезмәтендә 28 табышмак, 244 мәкаль һәм әйтем, 116 кыска җыр һәм «Гыйшык хәлләре» дигән бәет, дөресрәге, кыска җырларга тартым шигъри куплетлар урнаштырылган. «Хәбәрләр»нең 1900 елгы 16 нчы томында К.Насыйри П.А.Поляков белән берлектә «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» дигән тагын бер зур хезмәт бастыра. Анда халкыбызның 11 әкияте («Салам Торхан», «Ахмак угыл», «Үги кыз», «Гөлнәзек», «Байдек», «Өч угыл», «Акыллы угыл», «Төлке», «Мәче берлән Аю», «Аю берлән Төлке», «Сандугач берлән Бытбылдык») татар һәм рус телләрендә дөнья күрә.

Каюм Насыйриның “Әхлак исаләсе”, “Тәрбия”, “Балаларга тәгълим бирмәк”, “Китап – эт тәрбия” хезмәтләрендәге халык авыз иҗаты әсәрләре, галимнең үзе тарафыннан җыелып, лингвистик яктан эшкәртелеп биреләләр. Мәгърифәтче хикәятләрен туры сүзле мәкаль белән йомгакларга ярата һәм сүзнең тылсымлы көченә чын күңелдән ышана. Мәсәлән, ул: “Сүз бозау имезер. Бер хикаяткә ишарәттер. Күп сүзгә кереп китеп, эшеңне онытма, димәктер”– дип яза. Мәгърифәтче гореф–гадәтләрне саклауга милләтне саклау буларак карый. Бу хакта еллык календарьларында кабат–кабат яза. Әлеге гамәлләрдә борынгы мифик образларның онытылмавы да мөһим булуын билгели.

К.Насыйри үзе җыйган фольклор әсәрләрен “Кырык бакча” (1880), “Фәвакиһел–җөләса фил–әдәбият” (1884), “Китаб–әт–тәрбия” (анда 113 нәсихәт тупланган, 1891) китапларында бастыра. Аларда халкыбызның тормыш–көнкүреше, үзара мөнәсәбәте, эчке кичерешләре, тәрбия тәҗрибәсе тасвирлана. Бу һәм башка хезмәтләрендә, укытучылык эшчәнлегендә халыкның педагогик мирасына, тәрбиядә халыкчанлыкка һәм гуманлылыкка зур өстенлек бирә һәм бу аның төп педагогик принцибы булып әверелә. Чөнки ул халык тәрбиясенең

кешене белемле һәм әдәп–әхлаклы итеп үстерүгә гаять зур өлеш кертүен дәлилли, шуңа күрә татар халык педагогикасын һәрьяклап өйрәнүгә күп көч куя. Кыскасы, аның хезмәтләре татар халкының тәрбия тәҗрибәсенә нигезләнеп иҗат ителә.

Ул: " Ислам кабул ителүдән күп еллар элек татарның үз хыялында туган үзләреннән–үзләре татарлыкны күрсәтеп тора торган су иясе, убыр, бичура, албасты, ялмавыз, шүрәле" кебек мифик затларны әкиятләр, ырымнар, табышмаклар һ.б. аша яшь буынга милли тәрбия бирүдә файдаланырга өнди. Үзе дә балалар уен фольклорын җыюга, аны популярлаштыруга зур көч куя. Ул җыйган бишек җырлары, мавыктыргычлар, эндәшләр һәм такмазалар "Татар халык авыз иҗаты" сериясендә басылган балалар фольклоры томына кертелгәннәр. К.Насыйри кинаяләп әйтүнең турыдан әйтелгәнгә караганда үтемлерәк булуын да онытмый. Изге Коръәндә әйтелгән "бишектән ләхеткәчә белем ал" шигаре Каюм Насыйриның да тормыш девизына әверелә. Ул белем алуны яшьтән башларга кирәклеген ассызыклый, шунлыктан нәкъ менә кече яшьтәгеләргә кызыклы булган вакыйгалар аша "сабак бирә". Галим теоретик белемне гамәли тәҗрибәләр белән ныгытырга чакыра. Акыл тәҗрибә булганда гына кыйммәткә ия булуына басым ясап, аларның берберсеннән җир белән су кебек аерылгысызлыгын ассызыклый, тапкыр сүзләр аша бу фикерне укучыларына җиткерә.

К.Насыйри татар халык авыз иҗатында урын алган олыларны хөрмәтләү, ялган һәм начар гадәтләрне тәнкыйтьләү, тырышлыкны зурлау, хезмәт аша байлыкка ирешү кебек һ.б. төп фикерләрне һәр әсәрендә, дәреслекләрендә алга сөрә. Халык фикере аша халыкны тәрбияли.

**Әдәбият**

1. Җәләлиев Ш. "Дин вә мәгыйшәт"// 2 нче март, 2012 нче ел.

2. Насыйри К.. Сайланма әсәрләр (өченче том). .– Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

3. Нафикова Р. Каюм Насыйри иҗаты //Мәгариф, 1992. – № 1. – ББ. 19–21.

4.Олуг мәгърифәтче, галим вә мөгаллим. (К.Насыйриның тууына –170 ел) //Мәгариф, 1995.– № 2. – ББ. 65–66.

5. Хөснетдинова Р. Андыйлар табигатьтә сирәк очрый // Казан утлары. – 1998. – №4. – Б.142.

## КАЮМ НАСЫЙРИ - МӘГЪРИФӘТЧЕ

**Искәндәрова А.Р, Нәгимова Р.Р.**

Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучылары

Фәнни җитәкчеләре: Шакирова Л.М., Тимофеева Л.М.

Һәр галим – мәгърифәтче тарихта үз эзен калдыра. Каюм Насыйриүз халкының югары җәмгыять мәгарифен булдыруга бәяләп бетергесез өлеш керткән, реформа эшендә новаторларның берсе булды.

К. Насыйри әдәби әсәрләр иҗат иткән, тел белеме, табигать белеме, математика, арифметика, геометрия, география, игенчелек, ботаника, халык медицинасы, тарих, этнография, педагогика, халык авыз иҗаты, әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть буенча хезмәтләр иҗат иткән.

Һәр халыкның милли горурлыгы булган үз талантлары бар. Әмма кайбер бөек шәхесләрдә, хаклы рәвештә, үз халкы хакына эчкерсез һәм ихлас күңелдән кешелекле булуы белән сугарылган шәхесләр аерым урын алып тора. Аларны без гуманистлар һәм мәгърифәтчеләр дип атыйбыз.

Мондый кешеләргә якташыбыз Каюм Насыйри – үзенчәлекле шәхес, талантлы галим, шагыйрь кеpә. Зур фәнни һәм әдәби кыйммәттән тыш, аның хезмәтләре тагын кешеләрнең яңалыкка, белемгә, мәгърифәткәомтылышлары белән дә кызыклы.

Каюм Насыйри (Габделкаюм Габденнасыйрович Насыйров) – татар мәгърифәтчелегенең иң күренекле вәкилләреннән берсе, энциклопеди яктан белемле галим, язучы, фикер иясе–гуманист.

1825 елның 2 (14) февралендә Казан губерниясе Свияжск өязенең Югары Ширдан авылында (хәзер Яшел Үзән районының Кече Ширдан авылы) туган. Башлангыч белемне әтисенең мәктәбендә алган. 1841 елда белем бирүне дәвам итү өчен яшь Габделкаюм Казанга килә һәм 15 ел дәвамында шәһәрнең танылган уку йортларының берсендә укыган. Анда ул төрек, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнә.

Туган телен камил үзләштерә һәм башкалардан яшерен рәвештә рус телен өйрәнә. Үзенең үҗәтлеге һәм тырышлыгы, шулай ук табигый кызыксынучанлыгы аркасында К.Насыйри башка шәкертләрдән өстен чыга. Мәдрәсәне ул пишкадам дәрәҗәсендә тәмамлый (мәдрәсәнең тулы курсын тәмамлаган һәм анда мөгаллимлек эшенә әзерләнү өчен калдырылган кеше). Мәдрәсәне тәмамлагач, ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан университетында лекцияләргә йөри һәм анда рус галимнәре белән элемтәләр урнаштыра.Казан университетында дәресләргә йөрү һәм рус галимнәре белән аралашу аңа Европа фәне һәм мәдәнияте белән танышу өчен мөмкинлек ача.1855 елда К.Насырины православие дини училищесына, аннары дини семинариягә татар теле укытучысы итеп чакыралар. Ул анда 1871 елга кадәр эшли. Соңыннан ул татар балалары өчен рус телен өйрәнү мәктәбе ача.

Аңа ул вакытта татар балалары өчен мәктәп оештыру җиңел түгел. 1876 елда, укыту методикасы мәсьәләләрендә В.В.Радлов белән аерма аркасында, Каюм Насыйри мәктәптән китә һәм бөтен вакытын әдәби һәм фәнни–педагогик эшчәнлеккә багышлый. Бу елларда ул иң яхшы әсәрләрен яза. Ул шәхси дәресләрдән алынган акчаларга, гаризалар төзүдән, текстлар, татар документларын рус теленә тәрҗемә итүдән һәм үз китапларын сатудан кергән акчаларга яшәгән.

Бөтен гомерен Каюм Насыйри әдәби һәм гыйльми эшчәнлегенә багышлаган. Ул үзенең эш көнен бик оста оештырган. Әле ул физик хезмәткә дә вакыт биргән. Аның эшкә сәләте гадәттән тыш зур иде. Бик күп һөнәргә ия

булган: китапларны үргән, көзгеләр ясый, крахмал әзерли һәм электр ярдәмендә (гальванизация) көмеш һәм алтын йөгертү белән шөгыльләнә; музыка кораллары ясый, ләкин барыннан да бигрәк столяр эшен ярата һәм гомеренең ахырына кадәр аның белән системалы рәвештә шөгыльләнә. Каюм Насыйри рәсем ясый һәм сызып укый. Ул үзенең календарьлары өчен күп географик карталар, мәсәлән, 1878 елгы календарьда көнчыгыш ярымшар картасы, 1881 елгы календарьда Казан губернасы авыллары картасы һ.б. К.Насыйриның кульъязмасы гаҗәеп матур булган. Барлык әсәрләрен ул беренче класслы каллиграф буларак үз кулы белән күчереп язган.

Каюм Насыйри үз чорының бай сәләтле, һәрьяклап үскән кешесе булган. Ул музыканы бик ярата. Замандашлары аның берничә уен коралларында уйный белүен күрсәтәләр, мәсәлән, кубыз һәм курайда.

*Каюм Насыйри табигатьне яраткан.*

Каюм Насыйри 1855 елдан Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең актив әгъзасы була. Ул татар фольклоры материалларын җыя, җәмгыять каравына тапшыра, утырышларда докладлар белән чыгыш ясый. Каюм Насыйриның фәнни мирасы яшь буынга кыйммәтле бүләк буларак күчкән, аны милли мәдәниятнең демократик традицияләре, рухи кыйммәтләре белән баеткан.

Каюм Насыйри 1902 елның 20 августында (2 сентябрендә) 77 яшендә вафат була һәм Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкертләре тарафыннан җирләнә.

*Каюм Насыйриның әдәби һәм фәнни хезмәтләре.*

Каюм Насыйриның фәнни һәм әдәби эшчәнлеге крепость системасы вакытында ук башланган һәм Россия капитализмчорында үсеш алган. Беренче әсәрен 1859 елда яза. Аның беренче басма әсәре 1860 елда басылып чыккан "Неху китабы" ("Синтаксис") дәреслеге була. Шул ук елны ул балалар – мәктәп укучылары һәм үз–үзен укыту белән шөгыльләнүчеләр өчен табигать күренешләре турында "Буш вакыт" ("На досуге") брошюрасын бастыра. Бу татар телендә язылган беренче фәнни–популяр сочинение иде. Аннан татар балалар әдәбиятын булдыру да башланган.

Бу эшчәнлекне алга таба үстереп, ул теоретик һәм гамәли белемнәрнең төрле тармаклары буенча кайбер дәреслекләрне һәм кулланмаларны төзи. Мәсәлән, ул математика буенча «Хисаблык» (арифметика, 1873), «Гыйльми пэндэсэ» (“Геометрия”, 1895), география буенча «Истилахате джаграфия» (география терминологиясе, 1890), 1,2 һәм «Джаграфияи кабир» (зур география, 1894 – 1899) дәреслекләрен (зур география, 1894 – 1899) язган. Табигый фәннәр буенча, ул «Буш вакыт» (1860) китабын, игенчелек буенча – «Гыйльми зирагат» (1892), ботаника буенча «Голзар вэ чэманзар или нэлэк вэ чэчэклек» (1894), анда үләннәр һәм чәчәкләр турында шактый тулы мәгълүмат биргән.

Рус һәм татар халыклары дуслыгының ялкынлы көрәштәше булган Каюм Насыйри беренчеләрдән булып татар халкын туган телендә рус тарихы белән

таныштырган. Анның «Зобэде мин тэварихе рус» («Россиянең кыска тарихы», 1890 ел) китабы татар телендә чыккан бу өлкәдә беренче хезмәт булып тора.

*Каюм Насыйриның агарту эшчәнлеге.*

Татар җәмгыятенең барлык реакцион көчләре нык каршы торуга карамастан, Каюм Насыйри башлап җибәргән хезмәтләр урынсызкалмады. Бу хезмәтләр үз вакытында халыкка мәгърифәт таратуда зур ярдәм күрсәттеләр, алар яшь буынга да күчтеләр, аны уңай традицияләр белән баеттылар. Татар язучылары 20 гасыр башында Каюм Насыйри хезмәтләрен өйрәнүдән әдәби эшчәнлеген башлап җибәрә. Татар халык шагыйрьләре М.Гафури белән Г.Тукай, татар театрына нигез салучы Г.Камал үзләренең автобиографик очеркларында К.Насыйри әсәрләрен бик яратып укыганнарын искә төшерүләре очраклы хәл түгел. "Кич белән, китапларны тикшергәндә, кулына К.Насыйриның «Плоды для собеседников» («Фэвакихел – жолэса») китабы эләкте. Мин аны укый башладым. Китап ахырында басылган шигырьләрне аеруча мавыгып укыдым», – дип яза Г.Тукай үзенең автобиографик очеркында.

Шулай итеп, К.Насыйри фәнни хезмәтләр һәм әдәби–публицистик әсәрләр иҗат итеп кенә калмаган, халык массаларының алардан ничек файдаланырга тиешлеге белән дә кызыксынган. Халыкны таныту анын өчен максатка ирешүгә һәм халыкның тормышын яхшырту чарасы булуга беренче адым булган.

**Әдәбият**


1. Махмутов, Х.Ш., Алишев, С.Х., Гайнутдинов, М.В. Каюм Насыйри. Избранные произведения. Перевод с татарского языка/ Х.Ш.Махмутов, С.Х.Алишев, М.В.Гайнутдинов. – Казан: Тат. кн.изд–во, 1977. – с.80–83, с.100–114.
2. Миңнегулов, Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар/ Х.Миңнегулов. – Казан университеты нәшр., 1988. – 3–11б.
3. Ханзафаров, Н.Г.Каюм Насыйри. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда/ Н.Г. Ханзафаров, М.Х. Гайнуллин, М.В. Гайнетдинов, Р.Ә. Әхмәтов. – Казан, 1985. – 258–274б.


## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ “КИТАБ–ӘТ–ТӘРБИЯ” КИТАБЫ ҺӘМ АВТОР НӘСИХӘТЛӘРЕНЕҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


**Кәримова Т.И., Фәтхуллин Н.Р.**

Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары

Фәнни җитәкче: Низамбиева Р.Р.


Татар халкының тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын тирәнтен өйрәнгән һәм бөртекләп җыйган мәгърифәтче галим, педагог һәм язучы Каюм Насыйри халыкка аң–белем тарату, аның телен, әдәбиятын үстерү юнәлешендә зур эш башкара. «Китаб–әт–тәрбия» китабы — татар халкының гасырлар дәвамында туплаган рухи байлыгының бик кадерле бер өлеше.

*Эшнең актуальлеге.* Күренекле мәгърифәтче туплаган әлеге китап

укучыда кешелеклелек, тырышлык кебек әхлак сыйфатлары тәрбияли. Автор нәсихәтләрендә күтәрелгән мәсьәләләр, гасырлар узуга карамастан, бүген дә әһәмиятле.Каюм ага Насыйри әсәрләренең теле үзенчәлекле, аны өйрәнү текстның эчтәлеген, үгет–нәсыйхәтләрен аңларга ярдәм итә.

*Эшнең максаты.* Каюм Насыйриның “Китаб–әт–тәрбия” китабына кертелгәнөченче һәм бишенчетәрбиягә караган текстка лингвистик анализ ясау һәм текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау**.**

*Төп өлеше.*Тикшерү өчен “Өченче тәрбия” һәм “Бишенче тәрбия” дип исемләнгән текстлар сайлап алынды. Текстта кулланылган сүзләрнең кайберләренә аңлатма биреп китү мөһим, чөнки хәзерге заман укучысы өчен бу кирәк. Беренчедән, текстның эчтәлеген аңларга, икенчедән, автор кулланган сүзләрнең асылын, кулланылыш үзенчәлеген билгеләү өчен кирәк дип саныйбыз.

1.Тәхсин – татар телендәге берничә мәгънәле сүз: 1.мактау, хуплау, бүләкләү (сүз белән); рәхмәт.2.Хикмәт–татар телендә берничә мәгънәгә ия булган исем: зирәклек, зирәклек; белем. Мәсәлән, “халык хикмәте” “халык зирәклеге”,“зур хикмәт иясе ", “бөек акыл иясе”; фәлсәфи тәгълимат, фәлсәфә; "яшерен мәгънә"; " яшерен сәбәп "(мотив); сер.Мәсәлән, “монда ниндидер бер хикмәт бар, монда ниндидер сер яшеренгән.3.Фәһем– акыл, аңлау, зирәклек;4.Локман хәким — борынгы акыл иясе.  Исламда тәкъва кеше буларак хөрмәт ителә. Давыт пәйгамбәр заманында Гарәбстанда, Оман төбәкләрендә яшәгән. Аның исеме Изге Коръәндә телгә алына һәм сүрәләрнең берсенә «Локман» исеме бирелә (31 нче сүрә). Бу сүрәнең 12 нче аятендә: «Без Локманга хикмәт бирдек», – диелә.

*Тикшерү өчен текст. ӨЧЕНЧЕ ТӘРБИЯ.* Бер падишаһның берничә углы булып, араларыннан берсе — зәгыйфь, кыска буйлы, кечкенә нәрсә иде. Гайреләре озын буйлы, матур йөзле иделәр, әмма аталары ул углына нәфрәт вә кимсетү белән карар иде. Ул углы бер зиһен иясе вә мәгърифәтле бала иде. Әйтте: «Әй ата, гакыллы тәбәнәк надан озыннан яхшырак түгелме? Һәрнәрсәнең кыйммәте күләменә карап йөрмәйдер. Мунча ташы бик ире, йөге бер тәңкә, энҗе бик вак, мыскалы ун тәңкә»,— диде. Аталары вә дәүләтнең зур кешеләре барчасы көлештеләр вә тәхсин кыйлыштылар... Бәс, әй угыл, гыйлем вә мәгърифәт дигән нәрсә буйга вә кыяфәткә карап булмайдыр.

*БИШЕНЧЕ ТӘРБИЯ.* Локман хәкимнән сорадылар: «Син хикмәтне кемнән үгрәндең?» — диделәр. Әйтте: «Күзсез кешеләрдән үгрәндем, чөнки алар аяк басасы урынны күрмәенчә аяк басалар»,— диде... Әй угыл, монда сиңа тәрбия шулдыр ки, Локман хәкимнең сүзен яхшы фәһем итеп кара, ягъни ул: «Күзсезләр, аяк басасы урынны күрмәенчә, я абыналар, яки төртеләләр, яки екылалар, шулай ук аңы юк кешеләр вә наданнар — сүзнең урынын белмәй сөйләшәләр, вә ахырын уйлап сөйләшмәйләр. Аларның наданлыкларын күрдем дә хәким булдым»,— диде.

*1.Гомуми күзәтү.*Китап зур булмаган кереш сүздән башлана. Анда «тәрбия»төшенчәсенең асылы ачыла. Шуннан соң гыйбрәтле хикәяләр,

гыйбрәтле хикәяләр рәвешендә бирелгән 114 үгет–нәсихәт китерелә.

*2.Абзацлар бүленеше.* Тикшерү өчен сайланган ике текст та бер абзацтан тора. Өзекләр диалог һәм монологлардан төзелгән. Әдип, сәнгати әсәр тудырудан бигрәк, үгет–нәсыйхәт стиленә мөрәҗәгать итә, шуңа күрә аңа текстның образлылыгы түгел, мәгънә, фикер ягы мөһим.

*3.Текстның лексик составы.*Текстның төп лексикасын гомумтөрки сүзләр һәм гарәп–фарсы сүзләре тәшкил итә. *Гомумтөрки сүзләргә* күбрәк туганлык атамалары( углы, аталары), тән төзелешенә караган сүзләр(күзләр, аяк, йөз), алмашлыклар( ул, син, алар) кергән.

*Алынма сүзләр ( гарәп– фарсы сүзләре):* зәгыйфь, әмма, нәфрәт, зиһен, мәгърифәтле, һәрнәрсәнең, кыйммәте,дәүләтнең,зур, тәхсин, кыяфәткә, хикмәтне, фәһем. *Искергән сүзләр*: углы, гайреләре, углын, гакыллы,бәс, үгрәндең?

*Контекстуаль синонимнар*: *зәгыйфь, кыска буйлы, кечкенә* нәрсә иде;*озын буйлы, матур йөзле* иделәр; *нәфрәт вә кимсетү* белән карар иде; *зиһен иясе вә мәгърифәтле* бала иде; *гыйлем вә мәгърифәт*; *буйга вә кыяфәткә* карап булмайдыр; *я абыналар, яки төртеләләр, яки екылалар*; *аңы юк кешеләр вә наданнар. Антонимнар: ире*, йөге бер тәңкә, энҗе бик *вак;*

Аерым бер сүзләрнең фонетик тышчасына игътибар итәргә кирәк. Болар – искергән (архаиклашкан) формалар, хәзерге татар әдәби телендә алар актив түгел, ә XX йөз башы текстлары белән эшләгәндә без әле алар белән очрашабыз:

–йөрмәйдер (йөрмидер), ире (эре), күрмәенчә (күрмичә), екылалар (егылалар), белмәй (белми), сөйләшмәйләр (сөйләшмиләр).

*Антропоним:* Локман хәким

*4. Сурәтләү чаралары*

К. Насыйриның без өйрәнү объекты итеп алган хезмәтендә дә күпмәгънәле сүзләрнең шушы максатка хезмәт итү очраклары кешегә бәя бирү полисемия күренеше ярдәмендә тормышка ашырыла: “Дәүләтнең зур кешеләре падишаһка әйттеләр”. Бу очракта “зур” сүзе үзенең төп мәгънәсеннән үсеп чыккан күчерелмә семантика белән баетылган һәм кешенең иҗтимагый статусын билгели торган үзенчәлекле метафора булып киткән. “Тәрбия китабы”нда метафоралар турыдан–туры дидактик максатка хезмәт итәләр.

*Чагыштыру:* Мунча ташы бик ире, йөге бер тәңкә, энҗе бик вак, мыскалы ун тәңкә». Автор белем, мәгърифәтне энҗе белән чагыштыра.

*5. Морфологик үзенчәлекләр*

Бирелгән ике текстта бу очракта бер генә ялгызлык исем кулланыла. Локман Хәким — борынгы акыл иясе.Текстта ул төп урынны алып тора, урынлы киңәшләрен бирә, әхлаккә өйрәтә. Әсәрдә төп теманы, геройларның хис–кичерешләрен, эчке дөньясын ачып бирү өчен, К.Насыйри абстракт мәгънәле исемнәргә еш мөрәҗәгать иткән. Бирелгән ике текстта 20 дән артык исем кулланылган (гаилә кешеләре, нәфрәт, наданлык, тәрбия, зиһен иясе). Сыйфатлар, бигрәк тә исемләшкән сыйфатлар актив кулланылган( кыска,

кечкенә, озын буйлы, мәгърифәтле, *күзсезләр*). Бу сыйфатларны автор кешеләрнең уңай һәм тискәре сыйфатларын ачу өчен файдаланган.

Алмашлыклар да текстта күп кулланылган. Бер үзенчәлек ачыкланды. Ул алмашлыгы берничә урында зат алмашлыгы да, күрсәтү алмашлыгы булып та файдаланылган. Тагын текстта сорау һәм билгеләү алмашлыклары да кулланылган.

Фигыльнең бирелеше кызыклы: ике текстта 19 фигыль формасы кулланылган. Иде ярдәмче фигыле еш кабатланган. Заман мәсьәләсенә килгәндә, хәзерге заман хикәя фигыльнең кулланылыш ешлыгы башка формалардан артык булуы күренә. Хәл фигыльнең юклык формасын куллану үзенчәлекле: *күрмәенчә*. Мәсәлән:

– Әй угыл, монда сиңа тәрбия шулдыр ки, Локман хәкимнең сүзен яхшы фәһем итеп кара, ягъни ул: «Күзсезләр, аяк басасы урынны *күрмәенчә*, я абыналар, яки төртеләләр, яки екылалар, шулай ук аңы юк кешеләр вә наданнар – сүзнең урынын *белмәй* сөйләшәләр, вә ахырын уйлап сөйләшмәйләр.

Бәйләгеч сүз төркемнәреннән текстта тезүче һәм иярүче теркәгечләр күп. Мәсәлән: чөнки, ки, бүлүче теркәгечләр я, яки, вә җыючы теркәгече ике урында кулланылган.

*6. Синтаксик үзенчәлекләр.*

Әлеге текстларда автор гади җөмлә, кушма җөмләләр куллана. Гади җөмләләр тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылган.Диалог һәм монолог бар.Текстта эндәш сүзләр, тиңдәш кисәкләр, гомумиләштерүче сүзләр дә берничә җирдә очрый.

*7. Пунктуацион үзенчәлекләр.*

Өзектә күпнокта 2 тапкыр, сорау – 2 мәртәбә (диалогта) бирелгән, калганнары хикәя җөмләләр.

*9. Нәтиҗә.*

Текстның төп лексикасын гомумтөрки сүзләр һәм гарәп–фарсы сүзләре тәшкил итә;искергән сүзләр күп кулланылган; К.Насыйри әлеге тикшерелә торган текстларда контекстуаль синонимнарны уңышлы кулланган. Контекстуаль синонимнар чынбарлыктагы күренешләргә бәя бирү, аларны характерлаулау өчен файдаланылган;текстта исем, фигыль, сыйфат, рәвеш, алмышлык сүз төркемнәре актив кулланыла; текстның тел үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнү эчтәлекне, авторның укучыга җиткерергә теләгән фикерен аңларга ярдәм итә.

Шулай итеп, «Китаб–эт–тәрбия» хезмәте XIX гасырның икенче яртысында К.Насыйри үзе нигез салган әдәби телебездә язылган булуы белән кыйммәтле.Әлеге хезмәтнең теле бай, укучыга аңлаешлы.Иң мөһиме:укучыны уйландыра, яхшылыкка өнди, әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә төп урынны алып тора.

**Әдәбият**

1. Аминова А.А.,.Едиханов И.Ж. Структурно–семантические особенности произведения К.Насыри «Тәрбия китабы» и его переводана руский язык.–

Казань: изд–во. Казанский федеральный университет.
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4томда,4 том /К.Насыйри ;[кереш мәк. авт. Р.Кадыйров]. – Казан:Татар.кит. нәшр., 2006. – 400б.
3.Насыйри К. Китаб–әт– тәрбия – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 142б.
4.Огнева Е.А. Художественный перевод: проблемы передачи компонентов переводческого кода. Монография/ Е.А. Огнева.– Белгород: изд–во БелГУ, 2004. – 228 с.

## ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕГЕНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ВӘКИЛЕ

**Лотфуллина Л.В.**
ЯрЧаллы шәһәренең 13нче урта мәктәп укучысы
Фәнни җитәкче: Лотфуллина З.З.

Күренекле галим, укытучы–педагог һәм әдип К. Насыйри татар мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм әдәбияты үсешендә зур роль уйнаган. Аның күптармаклы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге халыкка хезмәт итү, милләтнең аң–белемен күтәрү, киң күпчелеккә аңлаешлы татар әдәби телен гамәлгә ашыру теләге, демократик караш һәм халыкчанлык рухы белән сугарылган. Ул татар халкын үз традицион мәдәнияте нигезендә, гыйлем бабындагы түбәнчелектән заман югарылыгына күтәрү юнәлешендә конкрет практик эш алып бара. Бу – олылык билгесе. 77 яшендә вафат булган бу игелекле зат ярты гасырдан артык, алны–ялны белмичә, милләткә хезмәт итә. Ул дауламый да, шауламый да, дәгъвалар да куймый, бәхәс – конфликтка да керми – халыкның нәкъ үзе кебек – меңләгән кыенлыкларны сабыр гына, тавышсыз–тынсыз гына җиңә–җиңә эшли дә эшли, эшли дә эшли. Аның өчен байлык та, дан–шөһрәт тә мөһим түгел. Каюм Насыйри тырышлыгы белән күпләрне соклandyрырлык . Каюм Насыйри соңгы көннәренә кадәр укуын һәм язуын ташламый. «Үзегез карт, күзләрегез зәгыйфь булса да, язуыгызны дәвам итәсез икән», – дигән кешегә ул: «Алла мине язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», – дип җавап бирә торган була.

К. Насыйриның гыйльми–мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарында яшь буынга төрле уку китаплары һәм дәреслекләр язудан башлана. Аның иң зур хезмәтләреннән берсе – тел өлкәсендәге эшчәнлеге. Телче буларак ул бик катлаулы, күп яклы хезмәтләр башкара: татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын исбат итә.

Тел – укыту, тәрбия бирүнең, милли үзаңны үстерүнең төп предметы. Нәкъ менә шуңа күрә дә «олуг мөгаллим» төп игътибарын телгә юнәлтә. К. Насыйри язган китапларның шактый өлеше татар телен һәм аны өйрәнү турында. Аның иң беренче хезмәте – «Нәху китабы», ягъни татар теле синтаксисы. Текстлар татар һәм рус телендә бирелгән.

Татар телен практик һәм фәнни эшкәртү юлында гаять зурэшчәнлек күрсәтә. К. Насыйри тел гыйлеме, сүзлекләр төзү буенча аеруча күп эшләр башкара. Бу өлкәдә ул кагылмаган, өлеш кертмәгән бер генә тармак та юк

диярлек. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген беренче булып ул төзи. Русча–татарча, татарча–русча сүзлекләр төзеп бастыра. Әдип математика, география һәм табигать фәннәре буенча киң массага аңлаешлы терминнар булдыру өстендә дә эшли. Дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен аңлаткан беренче кулланма – "Кавагыйде китабәт" (1892) хезмәтен яза. Татар теленең фәнни грамматикасын – "Әнмүзәҗ" (1895) төзүдә бик мөһим эш башкара. Тагын "Кыскача татар нәхүе", "Ләһҗәи татари"(1895), "Иҗек"(1895) хезмәтләре бар. Аның бу хезмәтләре үз вакытында ук тел галимнәренең югары бәясен ала.

К. Насыйри татар теленең байлыгын рус теле белән чагыштырып карый. Рус матур әдәбиятындагы сурәтләүләрне татарчага уңышлы тәрҗемә итә.

«Татар теле ул – урам теле, ломовойлар теле, әдәби гыйльми тел булырга сәләте юк аның», дигән карашлар яшәгән заманда, К. Насыйри халкыбызның туган телен кайнар яклап чыкты: «Ялган, яла бу! Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел. Бүтән телләрдән бердә ким түгел, эшләмәгәнлек сәбәпле генә ул шулай артта калган», – дигән ялкынлы фикерләре белән эш алып бара. Татар теленең фән теле була алуын, моңа аның тулы хакы һәм мөмкинлекләре барлыгын исбат итә. К. Насыйри, телебезне гыйльми һәм гамәли яктан өйрәнеп, татар лингвистик фәнен тудыруга үзеннән зур өлеш кертә.

**Әдәбият**


1. Ахунов А. "... Ят яраткан раббысы" // Татарстан.– 2005,– №1.
2. Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр (2 басмасы). – Казан: Таткнигоиздат. Матур әдәбият редакциясе, 1956 ел.
3. Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр (икенче том).– Казан: Татар. кит. нәшр., 1975 ел.
4. Хуҗиәхмәтов Ә., Рәсүлева З. Мәгърифәт йолдызлыгында. – Казан: "Матбугат йорты" нәшр., 1998.
5. Рахмани Р. Мәгърифәтнең мәгарәсе хуҗасы //"Мәдәни җомга".– 11 февраль, 2000 ел.


## КАЮМ НАСЫЙРИ БЕЗНЕҢ ЯКТЫ ЙОЛДЫЗЫБЫЗ


**Минголова А.Ф.**

Әлмәт шәһәре 17 нче урта мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Ибраһимова Г.А.


Каюм Насыйри татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле. Кызганычка каршы, аның кыю фикерләре, әдәби, фәнни хезмәтләре үз чорында җитәрлек бәяләнмәгән. Әмма Каюм Насыйри мәгърифәт эшеннән туктамаган. Ул татар халкының бәхетле тормышка ирешүенә чын күңелдән ышанган. Каюм Насыйриның хезмәтләре зур игътибар белән өйрәнелә, хөрмәт белән искә алына. Аның Ватанга мәхәббәт, дуслык турында әйтелгән сүзләре хәзердә бик зур урын алып тора.

Мин үземнең эшемдә Каюм Насыйриның тормыш юлын, иҗатын һәм тел өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнүне максат итеп куйдым. Башта аның китаплары һәм аның турында башка галимнәр иҗат иткән китаплар, мәкаләләр белән таныштым. Каюм Насыйри белән бик күп галимнәр кызыксынганнар һәм үзләренең күп төрле хезмәтләрен аңа багышлаганнар. Р.Гыйләҗеваның “ Олуг мәгърифәтче, галим вә мөгаллим Каюм Насыйриның тууына 170 ел” һәм Р.Ганиеваның “Каюм бабабыз” дигән кызыклы мәкаләләре “Мәгариф” журналларында басылганнар, ә Н. Хуҗиәхмәтованың “Мәгърифәт йолдызлыгы” дигән хезмәте, Р.Хөснетдинованың “Андыйлар табигатьтә сирәк очрый” дигән мәкаләсе “Казан утлары” дигән журналында басылган һәм башка галимнәрне күп төрле хезмәтләре белән танышып чыктым. Димәк, Каюм Насыйри тел өлкәсе, тарих өлкәсе, педагогика һәм тәрбия, җыр, матур әдәбият, медиөина, арифметика, география һәм башка өлкәләрдә эшчәнлек алып барган.

Шулай итеп, Каюм Насыйри XIX гасыр мәгърифәтчесе, укытучысы, галим энциклопедист булып тарихка кереп калган.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров – Каюм Насыйри –1825 елның (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында туган. Каюм Насыйровның атасы һәм бабалары укымышлы кешеләр булганнар.

Каюм Насыйриның балачагы Шырданда узган. Башлангыч белемне атасыннан алган. 1841нче елда аны Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга биргәннәр. 1855нче елга кадәр шул мәдрәсәдә укыган, гарәп, фарсы телләрен өйрәнгән, яшерен рәвештә русча укыган.

Беренче укытучылык эше 1855нче елда христиан руханилары әзерли торган Духовное училищеда татар теле укытучысы булып эшләүдән башланган.

1829нчыелдан башлап Каюм Насыйри барлык көчен китаплар, дәреслекләр язуга сарыф иткән.

1885нче елда Каюм Насыйри Казан университеты каршындагы “Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте” әгъзасы итеп сайланган.

Каюм Насыйриның беренче әсәре  “Мәҗмәгыл–әхбар” 1859нчы елда язылган. Басылып чыккан беренче әсәре – “Кыскача нәхү китабы”. Бу китап, русча өйрәнүче татарларны күздә тотып, рус телендә язылган, “Краткая татарская грамматика” исемендә 1860нчы елда басылган.

“Буш вакыт” әсәре балаларга һәм башлангыч белем алучыларга табигать күренешләре турында мәгълүмат биргән.

Каюм Насыйри 1871нче елда ярым журнал характерында, “Казан календаре” исемендә, еллык өстәл календаре чыгара башлаган. Каюм Насыйри журналист – энциклопедист та булган.

“Кырык вәзир кыйссасы” исемле әсәре халык арасында тиз тарала, сигез тапкыр басыла. Әсәргә кергән хикәятләрнең күпчелеге гаделлек, намуслылык, батырлык турында язылган.

Миңа “Әбүгалисина кыйссасы” бик ошый. Андагы һәрбер күренеш мавыктыргыч. Әсәрнең баш герое Әбүгалисинаның патшалардан акыллы, белемле булуы аркасында аларны җиңүче итеп бирелүе укучыларның игътибарын тарткан. Әсәр фантастик планда язылган.

Аеруча зур күләмле “Фәвакиһел–җөләса фил–әдәбият” исемле хезмәте зур урын алып тора. Аның кыскартылган варианты “Кырык бакча” дип атала. Бу хезмәттә башта үзеңнең белемеңне күтәрергә кирәклеге турында сүз бара. Монда искелектән яңага омтылыш ачык чагыла.

Халык әкиятләре стилендә язылган “Патша белән карт” хикәясендә патшаларны иң явыз кешеләр итеп сурәтли, халыкны җәберләүләрен фаш итә. Шул чордагы җәбер–золымнарга нәфрәт белдерә.

Каюм Насыйриның балалар өчен язган “Тәрбия турында”, “Этика турында”, “Кырык бакча”, “Кабуснамә” һәм башка китаплары да бар.

Каюм Насыйриның иң зур хезмәтләреннән берсе–тел өлкәсендәге эшчәнлек. Телче буларак бик катлаулы, күп яклы хезмәтләр башкарган. Сүзлекләр төзү буенча аеруча күп эшләр эшләгән. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзегән. Русча–татарча, татарча–русча сүзлекләр төзеп бастырган. “Рус теленең грамматикасы”н төзеп, бастырып тараткан.

Каюм Насыйри, замандашлары арасында беренчеләрдән булып, әдәбият һәм фән телен халыкның сөйләм теленә якынайту мәсьәләсен күтәреп чыккан.

Каюм Насыйри тарафыннан төзелгән ике томлы “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” телебезнең никадәр бай икәнен күрсәтте. Аның бу сүзлеге бүгенге көннәрдә дә зур фәнни хезмәт буларак кулланыла.

“Әнмүзәҗ” исемле китабында беренче тапкыр авазларга классификация ясап, аларны 10–сузык, 29–тартык авазга бүлеп күрсәтә. Аның “Иҗек һәм әлифба” китабы да зур әһәмияткә ия.

Каюм Насыйри күп кырлы эшчәнлек алып бара һәм иҗтимагый фикер үсешенә, татар теленең гыйльми нигезләрен булдыруда, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп бастыруда, алар белән башка халыкларны таныштыруда, яшь буынга тәрбия һәм белем бирүдә, ниһаять, әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетуда үзеннән зур өлеш кертеп, бай әдәби–мәдәни мирас калдыра.

**Әдәбият**

1.Гайнуллин М. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 2 томда.– Казан: Татар. кит.нәшр., 1974. – 19–23 б.

2. Гыйләҗева, Р. Олуг мәгърифәтче, галим, вә мөгаллим К. Насыйриның тууына–170 ел //Мәгариф. – 1995. – № 2.

3. Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. – Казан: Казан университеты нәшр., 1999.

4. Хөснетдинова Р. Андыйлар табигатьтә сирәк очрый // Казан утлары. – 1998.–№ 4.

5. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы: Укытучылар, педагогика колледҗлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2002.– 169–200 б.

# КАЮМ НАСЫЙРИ – КҮРЕНЕКЛЕ ТЕЛ БЕЛГЕЧЕ

**Муфтиева З.Р.**
Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе
“Салават күпере талантлары”, “Краеведение “ түгәрәге әгъзасы
Фәнни җитәкче: Набиуллина Л.З.

Татар телен фән буларак мәктәпләрдә өйрәнү кирәклеген пропагандалаучыларның берсе – Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров . Ул тәрҗемәче, тарихчы, эпиграфист, тел галиме, лексикограф һәм педагог буларак танылa.

Каюм Насыйриның гыйльми–мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарыннан башлана: нәкъ шушы чорда ул төрле уку китаплары һәм дәреслекләр яза башлый. 1860 нчы елда аның «Нәхү (Рус телендә язылган һәм «Краткая татарская грамматика» дип атала): Русча өйрәнүче мөселман егетләре вә татарча өйрәнүче рус егетләре өчен тәсниф кыйлынды» дигән китабы дөнья күрә. Үзенең «Фәвакиһел җөләса» хезмәтендә К.Насыйри, татар һәм рус телләренең грамматикасын яхшы белгән мәгърифәтче–укытучы буларак, чагыштырма методка нигезләнеп болай дип яза: «...Ләкин гайре телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кавагыйдатен белмәк зарурдыр» («Фәвакиһел җөләса»). Әлеге дөньякүләм танылган хезмәт бүген дә әһәмиятен югалтмаган.

Каюм Насыйриның иң зур хезмәтләреннән берсе — аның тел өлкәсендәге эшчәнлеге. Бу өлкәдә ул бик катлаулы һәм күпьяклы хезмәтләр башкарды. К. Насыйри татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуңа хакы һәм сәләте барлыгын исбат иткән. Аны практик һәм фәнни яктан эшкәртү юлында гаять кыю һәм зур эшчәнлек күрсәтә. К. Насыйри тел гыйлеме һәм сүзлекләр төзү буенча катлаулы һәм кирәкле эшләр башкара. Бу өлкәдә ул кагылмаган, хезмәт күрсәтмәгән бер генә тармак та юк.

Каюм Насыйриның балаларны ана телендә укыту таләбе белән чыгыш ясавы ул чор өчен прогрессив адым булган. Татар теле белем бирү чарасы, әдәби–гыйльми тел булсын өчен аның нигезен эшкәртергә, грамматик һәм лексик үзенчәлекләрен өйрәнергә кирәк иде. Менә шуңа күрә дә татар теле белеменә нигез салу эшенә беренчеләрдән булып К. Насыйри алына. Яшь буынны тәрбияләүдә гарәп, фарсы, төрки телләре өстенлек алган вакытта татар теленең фәнни нигезләрен эшкәртмичә, ана теленә карата тискәре карашны бетерергә мөмкин түгеллеген ул яхшы аңлаган. "Бәла татар теленең ярлылыгында түгел,— ди Насыйри,— ә татарларның үз телләрен белмәвендә. Безнең тел — бай, ләкин бу телне белүче юк". Ул бу сүзләрне туган телгә реакцион караштa торучыларга карата әйткән. К. Насыйри, татар телен игътибар белән өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килгән: "Әгәр дә без игътибар белән үзебезнең телебезне өйрәнсәк, аның сүзләр күләме, атамалар, төшенчәләр, гомумән төзелеше буенча гарәп, фарсы телләреннән ким

түгеллеген, кайбер яктан, бигрәк тә фигыльләр өлкәсендә байрак та булуын күрербез".

Татар телен чит тел буларак укыту методикасының фәнни нигезләрен К. Насыйриберенчеләрдән булып өйрәнә. Әлеге чорда төп игътибар телне өйрәнүгә, татар теленә өйрәтүнең максатларына, ысул һәм алымнарына юнәлтелә. Лингвистика, шулай ук методика фәннәренең барлыкка килүе һәм үсеше Каюм Насыйри эшчәнлеге белән бәйле. XIX гасырның икенче яртысында рус–татар мәктәпләренең күпләп ачыла башлавында Каюм Насыйриның да роле бик зур.

Аның беренче басылып чыккан китабы — "Татар теленең кыскача грамматикасы" — рус телендә язылган, ул русча өйрәнүче татарларга һәм татар телен өйрәнүче башка милләт вәкилләренә ярдәм итүне күздә тотып төзелгән. Каюм Насыйри татар әдәби телен фәнни яктан нигезләү, аны башка әдәби телләр дәрәҗәсенә күтәрү өчен күп көч куя. Телнең сафлыгы, халыкчанлыгы өчен көрәшә.

Каюм Насыйри фәнни белемнәрнең төрле өлкәләренә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Аның татар тел гыйлеме буенча хезмәтләре аерым игътибарга лаек. Каюм Насыйри хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы тел галимнәренең иң күренеклесе булып кала. Ул татар теленең фәнни атамаларын эшләүгә шактый зур өлеш кертә, грамматика һәм синтаксис буенча гаять әчтәлекле китаплар яза. Татар теле буенча беренче хезмәте – «Кыскача нәхү китабы» 1860 нчы елда басылып чыга.Ул татар телендә укучылар өчен берничә дәреслек яза. 1891 нче елда"Иршад әл–әхиба ли тәгълими әлифба", 1895 нче елда "Иҗек" китаплары чыга. 1892 нче елда дөрес язу һәм орфография кагыйдәләрен үз эченә алган "Кагыйдәләр китабы" ("Кавагыйде китабәт") басылып чыкты. Бу хезмәтендә ул: "Һәрбер культуралы кешенең ике төрле теле була: шуларның берсе — анасыннан сөт имгән вакытта өйрәнгән тел, икенчесе укытучыдан укыганда — гыйлем һәм фән терминнары белән ачылган тел...",— дип язды. Күргәнебезчә, К. Насыйри фәнни 170 төшенчәгә, терминга зур игътибар биргән, тел, әдәбият һәм башка фән тармаклары буенча фәнни терминалогия булдыруга зур хезмәт куйган.1894нче елда аның татар телендә "Иҗек һәм әлифба" китабы басылган. Балаларга аваз турында беренче мәгълүмат биргәндә, сүзләр сайланышы белән бу әлифба беренче көндә дә методик кызыксыну уята. Ә 1895нче елда нәшер ителгән «Әнмүзәҗ» китабы мәгърифәтче галимнең татар тел гыйлеме буенча күпьеллык тикшеренүләренең нәтиҗәсе булып тора. Бу хезмәттә татар теленең фәнни грамматикасына нигез салына, аның фонетикасына һәм морфологик үзенчәлекләренә һәрьяклы бәяләмә ясала.Бу хезмәттә тел,сүз дигән төшенчәләр генә татар телендәгечә , калган терминнар гарәп теленнән алына.Бу китапта фонетика, сүз төркемнәре һәм синтаксистан мәгълүмат кертелгән. Монда беренче тапкыр авазларга классификация ясап, аларны 10 сузык авазга, 29 тартык авазга бүлеп күрсәтә, рус терминологиясендә кулланылган теш, тамак, аңкау, борын терминнары файдаланыла. Әйтергә кирәк, күпчелек телчеләр шикелле үк К. Насыйри да хәрефләрне авазлардан аермаган. Сүз төркемнәрен

тикшергәндә ул өч сүз төркемен күрсәткән: исем (исем, сыйфат, сан), фигыль хәрефләр (ярдәмлек сүзләр). К. Насыйри мондый классификацияне грамматик формалардан чыгып түгел, ә сүзләрнең логик мәгънәләреннән чыгып ясый. Шул ук вакытта, аның грамматикасында кайбер сүзләрнең мәгънә төслекләре аерып бирелгән. Мәсәлән, ул күрсәтү алмашлыкларының кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклап, "шул" — ераклык, "бу" — якынлык дип аңлаткан. Ул иң бай сүз төркеме итеп фигыльне күрсәткән, аның ясалыш формаларына игътибар итеп, бер тамырдан йөзгә якын ясалма сүз барлыкка килүен әйткән.

Шулай ук аның гади җөмлә синтаксисы буенча да күзәтүләре кызыклы. К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә татар теленең сүзлек составын чистартуга да зур әһәмият биргән, гарәп, фарсы сүзләрен татар һәм рус теле сүзләре белән алыштыруны яклап чыккан. Төрки телләргә ияреп, "бар" сүзен "вар" дип, "бирде" сүзен "вирде" дип, "кирәк" сүзен "кәрәк" дип язучыларны кискен тәнкыйть иткән.Әлеге китабы белән Габделкаюм Насыйри татар телен алга таба өйрәнүне дәвам итү өчен бай фәнни җирлек әзерли.

Стилистика һәм матур язу фәнни мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган «Кавагыйде китабәт» («Язу кагыйдәләре» – 1892 нче ел) хезмәтендә ул татар теленең фонетикасын, лексикасын һәм башка грамматик нормаларын киң яктырта. Галимнең татар теленең лексик байлыгы мәсьәләләренә багышланган ике томлык «Ләһҗәи татари» дигән китабы татар теленең лексикографиясе буенча иң зур хезмәт булып тора. Ул татар теленең лексикасын формалаштыруда һәм аның фәнни атамаларын эшләүдә мөһим роль уйный.

Татар халкына туган телен өйрәнүдә галимнең  фәнни хезмәтләре зур әһәмияткә ия булдылар. 1898–1899 нчы  елларда Каюм Насыйри тарафыннан төзелгән ике томлы "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" татар теленең никадәр бай икәнен күрсәтте. Аның бу сүзлеге бүгенге көннәрдә дә зур фәнни хезмәт буларак кулланыла. Бу сүзләрдә еш очрый торган гарәп, фарсы сүзләренә аңлатма бирелгән, татар теленең бәхәсле мәсьәләләре күтәрелгән, сүзләрнең килеп чыгышы чагылдырылган.

Каюм Насыйриның хезмәтләре  рус телен татар теле белән чагыштырма планда өйрәнү өчен зур әһәмияткә ия. Ул татар телен өйрәнүне рус теле белән бергә бәйләгән. “Ана телен белү башка телләрне өйрәнүгә ярдәм итә”, – ди Насыйри. –Башта ана теленең грамматикасын бик яхшы белергә кирәк, һәр телнең грамматик төзелеше була. Грамматик төзелешне өйрән.Башка телләрне өйрәнү өчен ана телен белү кирәк. “...Кеше үзенең телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр”, – ди Насыйри. Үзенең тәҗрибәсеннән чыгып, ул менә шундый нәтиҗәгә килгән. “Әнмүзәҗ” китабында ул: “Утыз–утыз биш елдан бирле ике фәннән, ягъни үз телебездән һәм рус теленнән сабак укытканда, бигрәк тә рус телен укытканда, үз телебезнең грамматикасына аңлатучы бер китапка мохтаҗ була идем. Милләтебез халкыннан бер булдыклы кеше чыгып, телебез өчен грамматика төземәсме икән дип көтә идем. Берәү дә сикереп чыгучы булмады. Үз

телебезнең кагыйдәләренә мохтаҗлык соң дәрәҗәдә зур иде...", – дип язды. Менә шуңа күрә дә татар грамматикасын төзүгә К. Насыйри үзе алынган.

1889 нчы елда К. Насыйри татарларны русча укырга–язарга өйрәтү өчен «Кавагыйд кыйраәт русия» («Русская азбука») дигән китап яза, ягъни "Рус теленең уку кагыйдәләре" дигән китабы иң күренекле урынны алып тора. 24 битле бу әлифба, 50 дәрескә бүлеп, рус һәм татар хәрефләрен, сүзләрен чагыштырып, җентекләп эшләнгән.Һәр дәрестә укучы рус теленең байлыгы белән таныштырыла, рус хәрефләр һәм рус сүзләре татар хәрефләре һәм татар сүзләре белән чагыштырылып барыла. Каюм Насыйри татар балаларын русча укыту эше белән шактый озак шөгыльләнә, китаптан аның бөек мәгърифәтче, галим һәм оста педагог икәнен ачык күрсәтә. «Сүзләрне берәм–берәм ятлап, һәрбер ишеткән сүзне исеңдә тотып, берәм–берәм зиһен тубалына тутырырга кирәк. Моның мисалы менә шундый: берәү, бер чиләк алып, урманга җиләк җыярга бара. Иң элек, урман авызына кергәч, чиләгенә бер җиләк өзеп сала. Шулай кичкә чаклы йөреп, чиләген тутыра» («Русча–татарча лөгать»тән).

**Әдәбият**

1. Татар әдәби теле тарихы.1 том. – Казан: «Мәгариф», 2015. – 694б.

2. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгрифәт йолдызлыгы – Казан: «Мәгариф»" кит. нәшр., 2002. – 288 б

3. Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана. – Казан: «Мәгариф» кит. нәшр., 1993. – 256 б

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ "КИТАБ–ӘТ–ТӘРБИЯ" ХЕЗМӘТЕНДӘГЕ НӘСЫЙХӘТЛӘРНЕҢ БҮГЕНГЕ КӨНДӘГЕ ӘҺӘМИЯТЕ

**Мухаметдинов К.Р.**

Әлмәт шәһәре 17нче урта мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Кашипова Н.Җ.

Күренекле татар мәгърифәтчесе, бөек галим Каюм Насыйри кешелек бәхете өчен көрәшкә зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе. Бүгенге көндә олылар арасында гына түгел, яшьләр аудиториясендә дә танылган мәгърифәтчеләрнең эшчәнлеге турында сүз алып бару, аларның нәсыйхәтләрен өйрәнеп, шулар нигезендә камиллеккә ирешергә омтылу теләге үсә. Укытучыларыбыз дәресләрдә Шиһабетдин Мәрҗәни, Ризаэддин Фәхреддин, Җәлил хәзрәт Фазлыев хезмәтләрен кулланып, безнең һәммәбезне тәрбияле, белемле, эшлекле кешеләр итеп олы юлга аяк басарга әзерли.

Каюм Насыйриның "Китаб–әт–тәрбия" хезмәте 1891 елда язылып, анда 113 нәсыйхәт тупланган. Бүгенге көндә бу нәсыйхәтләрнең һәркайсы кыйммәтле сүз булып йөри, кешелекне дөрес юлга бастыруда әһәмиятле чыганак булып хезмәт итә ала дисәк тә ялгышмабыз. Ризаэддин Фәхреддиннең "Нәсыйхәт" китабын ничек теләп кулланабыз, "Китаб–әт–тәрбия"не дә шул максатта файдалану мөмкинчелеге киң.

Язмабызда Каюм Насыйриның “Китаб–әт–тәрбия” хезмәтендә китерелгән берничә мөһим тәрбиягә тукталып үтәрбез. Шуларның беренчесе – һөнәргә ия булу, аны тормышта тиешенчә куллана, аннан файда ала белү сыйфаты. “Бер хәким балаларга шуйлә нәсихәт бирде ки: «Әй җаннарым, угланнарым, нәсихәтне ишетегез — һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас. Алтын–көмеш — сәфәр кешесенә хәтәрдер; вә йорт–йир кешесенә дәхи хәтәре бар: я угры алып китәр, яки утка яныр китәр. Әмма һөнәр — бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләтдер. Һөнәр иясе әгәр дәүләттән төшсә дә, кайгы юк. Имде, әй угыл, бу урында максуд бер хикаять түгелдер. Син дә шулай ук һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән»[Насыйри1992:14]. Шушы юллар аша галим укучыга дөнья малларының вакытлыча, ә яшьтән алынган хезмәтнең гомерлек икәнлеген төшендерә, Һәр кеше тормышта кулланырлык белемнәр белән коралланырга тиеш. Кеше үзенең алган белемен эштә файдалана алмаса, ул тормышка яраксыз була: мондый кешенең үзенә дә, башкаларга да файдасы булмый, ди Каюм Насыйри.Үз заманында галим уку йортларында слесарь эше, кул хезмәте, җирчелек нигезләре, өй эшләре предметларына күбрәк вакыт бирүне таләп иткән. Хезмәт тәрбиясен әхлак тәрбиясенең нигезе итеп күрсәткән.

Галим хезмәтенең алтынчы тәрбиясендә шундый нәсыйхәт китерелгән: “ Олуглардан бер адәм үзенең углын бер галим остазга тәгълим вә тәрбия өчен тапшырды. Вә әйтте ки: «Әй остазе камил, ошбу баланы тәрбия кыйл вә укыт ки, галим вә гакыйл булсын»,— диде. Берничә вакыт бу баланы остаз тәрбия кыйлды вә укытты. Әмма һичбер гыйлем әсәр кыйлмады. Ул баланы атасына кайтарып йибәрде. Әйтте: «Бу бала, һичбер белемгә сәләтле түгелдер, хәтта үземне диванә кыйлды»,— диде [Насыйри1992:22]. Бүгенге көндә кечеләргә дә, олыларга да тәрбия җитеп бетми. Минем белән бик күпләр килешер, мөгаен. Бала тәрбияле булсын өчен әти–әниләр үзләре тәрбияле булу мөһим. Чөнки игелеклелек, әдәплелек, кешелеклелек, намуслылык, ихласлык, гаделлек, дөрес сүзлелек, ярдәмчеллек кебек кешелеклелек сыйфатларын бала күңеленә әти–әнисе җиткерергә тиеш. Бала тәрбияләүдә таяк, тән җәзасы түгел, ә ышандыру көче зур әһәмият уйный, дигән Каюм Насыйри. Ата–ана агачның нигезе булса, балалар шул агачның җимешләре булып торалар, дип искәрткән галим. Агач яхшы үссә, аның җимешләре дә яхшы була икәнен онытмаска кирәклеген искәрткән.

Чиратта – утыз дүртенче тәрбия. “Әй угыл, балаларга тәгълим бирсәң, кечерәк вакытта бик иҗтиһад кыйл, “Әлгыйльме фи с–сәгъри кә нәкаши фи л–хәҗәри” мазмунынча[2] чыбыкны нечкәрәк чагында бөгү уңайракка киләдер. Кечерәк вакытта күп фәннәргә төшендермәк кирәк, математиканы аз–аз белдермәк тиеш. Әмма бу балаларга сабак укыту хосусында сиңа яхшырак тәрбия бирәсем бар”[Насыйри1992:78]. Аңлавыбызча, Каюм Насыйри укытучы хезмәтенә зур бәя бирә һәм катгый таләпләр дә куя: укытучы укучыларга һәрвакыт игътибарлы булырга тиеш; аларның психологиясен исәпкә алырга, тән җәзасы бирмичә генә укытырга тиеш. Укытучылар балага һәрьяклап үрнәк:

мөлаем йөзле, яхшы гадәтле, оптимист, таләпчән, җыйнак, мәхәббәтле булырга тиеш. “Әгәр син педагог икәнсең, укучыларыңны шулай итеп тәрбиялә ки, син биргән тәрбия укучыңа якын тормышыңда төп юнәлеш булсын”,–дип яза галим. Мондый таләпләрне без Ризаэддин Фәхреддиннең “Нәсыйхәт” китабында да укып узабыз. Гасырлар узып торса да, тәэсилелеген югалтмаган олы сүзләр...

Каюм Насыйри кешеләрне бер–берсенә карата яхшылыклар кылырга, тел белән ямьсез сүзләр әйтеп үпкәләтмәскә, рәнҗетүдән сакланырга чакырып, “Китаб–әт–тәрбия” дә сиксән тугызынчы тәрбияне язып калдыра. Биредә шундый юллар китерелгән: “Әй угыл, кешенең күңеленә хилаф килә торган сүзне телеңә китермә. Бер сүзне син пәйвайсыз әйтеп йибәрерсең, ишеткән кешенең күңеле җәрәхәтләнә торган сүз булыр, күңеле рәнҗер.Кеше күңелен рәнҗетүдән бик саклан”[Насыйри 1992:81]. Әлеге юлларның актуальлеге бүгенге көндә дә югалмаган. Үземнең яшьтәшләрем арасында да, кечкенә сыйныфлардагы укучылар арасында да, урамда, җәмгыять урыннарында яңгыраган “колакларны шиңдерелек” әшәке сүзләрне ишетәсең дә, Каюм Насыйриның шушы тәрбиясен укып күрсәтәсе, һәр кешенең күңеленә галим язып калдырган акыллы фикерне җиткерәсе килә. Гомумән, “Китаб–әт–тәрбия” хезмәтен кулланып, бөтен кешелек дөньясын яхшы якка үзгәртәсе килә.

Язма ахырында ишеттерәсе фикерем шул: гасырлар узган саен бөек мәгърифәтче галим Каюм Насыйри хезмәтләре үзенең тәрбияви көчен киметми, арттыра гына бара. Шул нәсыйхәтләрне һәр буын кешесе кирәгенчә файдалана белсен дә, үзеннән соң килгән буыннарга васыять итеп калдырырга омтылсын иде.

**Әдәбият**

1. Насыйри Каюм. Китаб–әт–тәрбия. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1992 – 144б.

2.Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы. – Казан: Мәгариф.,2002 – 279б.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫ

**Мухлисуллина А.Х**

Әлмәт шәһәре 17нче урта мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Махиянова Р.М.

Бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт кылган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре шактый күп: Утыз Имәни, Габдулла Тукай, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый... Болар арасында иң мөхтәрәм урыннарның берсен Каюм Насыйри алып тора.

1860 елдан башлап ярты гасыр дәвамында гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән Каюм Насыйри татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле була.

Бөтен гомерен безнең халкыбызны агартып, аңа культура хезмәте, әдәби хезмәт күрсәтүгә багышлаган өлкән агабыз – бөек рус халкы ярдәмендә татар халкының да бәхетле тормышка ирешүенә чын күңелдән ышанган, татар балаларын, беренче буларак, русча укыту эшенә җиң сызганып керешеп, кагылу– сүгелүләргә, эзәрлекләүләргә карамастан, армый – талмый эшләгән К.Насыйринең хезмәтләре зур игътибар белән өйрәнелә, хөрмәт белән искә алына.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров – Каюм Насыйри – 1825 елның 14(2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында туа. Каюмның бабалары һәм атасы ул заманның укымышлы кешеләре була.

К.Насыйри балалык вакытларын әнә шундый укымышлы кешеләре булган гаиләдә, туган авылы Шырданда уздыра. Башлангыч белемне атасыннан ала. 1841 елда аны Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга бирәләр. 1855 елга кадәр шул мәдрәсәдә укый, гарәп, фарсы телләрен өйрәнә, яшерен рәвештә русча укый, шәкертләрнең күпчелегеннән аермалы буларак, җәмгыятькә файдалы, белемле кеше булып җитлегә.

Каюм Насыйри 15 ел Казанның «Духовная семинария»сендә татар теле укыта. Аның үзенчәлекле методикасы була. Телне ул халык авыз иҗаты, татар әкиятләреннән мисаллар китереп өйрәтә. Татар балаларына да рус телен өйрәтү зарурлыгын күтәреп чыга. Шуның өчен үзе еш кына кыен ашаган, «урыс Каюм» дип йөрткәннәр.

Үзе дә Казан университетында ирекле тыңлаучы булып торган. Казан император университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография» җәмгыятендә фәнни эшчәнлек алып барган.

1829 елдан башлап К.Насыйри, рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итмәстән, барлык гомерен язучылык эшенә һәм фәнгә багышлый. Аның зуррак күләмле фәнни, әдәби хезмәтләре шул вакытларда туа. Әдип барлык көчен китаплар, дәреслекләр язуга, акчасын аларны бастыруга сарыф итә. Кайбер балаларны үз акчасына укыткан. Татар балаларының белемле, зирәк, заманча фикерли белүе өчен борчылган.

Каюм Насыйриның эшчәнлеге, крепостной строй яшәгән вакытларда башланып, Россиядә капитализм үскән чакларга туры килә. Аның беренче әсәрләреннән “Мәҗмәгыл–әхбар” (“Хәбәрләр җыентыгы”) 1859 елда языла. Басылып чыккан беренче әсәре – “Кыскача нәхү китабы”. Бу китап, русча өйрәнүче татарларны күздә тотып, рус телендә языла, “Краткая татарская грамматика” исемендә 1860 елда басыла.

Балаларга һәм башлангыч белем алучыларга табигать күренешләре турында кыскача мәгълүмат биргән “Буш вакыт” әсәре дә шул ук елда басыла. Ул татар телендә язылган әдәби–фәнни популяр әсәрләрнең беренчесе. 1868 елда К. Насыйри “Буш вакыт”ның икенче вариантын бастыра. 1860 елгы басма 12 битле генә булса, икенчесе 87 биткә җитә.

К.Насыйри 1871 елда ярым журнал характерында, “Казан календаре” исемендә, еллык өстәл календаре чыгара башлый. Газета вазифасын өлешчә әнә

шул календарьлар үти. Аның егерме дүрт ел дәвамында чыгып килгән календарьларында, ел саен кабатлана торган гадәти материалларында фәнни һәм әдәби мәкаләләр урнаштырыла. Насыйри татарлардан беренче журналист–энциклопедист та булган.

К.Насыйриның матур әдәбият өлкәсендәге хезмәте “Кырык вәзир кыйссасы” исемле мәшһүр әсәрне татар телендә эшләп, 1868 елда бастырып чыгаруы белән башлана.

1874 елда Насыйри “Әбүгалисина кыйссасы”н татарчалаштыра. Халыкның бай хыялларын гәүдәләндергән, югары художество көченә ия булган, дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителгән бу әсәр героеның прототибы – Урта Азиядә яшәгән бөек галиме – философ, юрист һәм врач Ибне–Сина (980–1037) була. Легендар сюжетларны К.Насыйри очраклы тәрҗемә итми. Ул аның мәгърифәтчел теләкләренә, фәнни карашларына җавап бирә. Әсәрнең баш герое Әбүгалисинаның патшалардан акыллы, белемле булуы аркасында аларны җиңүче итеп бирелүе укучыларның игътибарын тарткан.

1879 елда К.Насыйри аеруча зур күләмле “Фәвакиһел–җөләса фил–әдәбият” (“Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше”) исемле хезмәтен яза башлый. Аның кыскартылган вариантын, “Кырык бакча” исеме белән, 1880 елда бастыра.

1884 елда К.Насыйриның “Фәвәкиһел–җөләса фил–әдәбият” исемле, 609 битле әсәре Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Халык экиятләре стилендә язылган “Патша белән карт” хикәясендәге патшаны, чиновникларны әдип иң явыз кешеләр итеп сурәтли, халыкны җәберләүләрен фаш итә. Әсәрнең төп идеясе – ерткыч патшаларга һәм шул чордагы җәбер–золымнарына нәфрәт белдерү.

К.Насыйриның балалар әдәбиятына кергән “Тәрбия турында”, “Этика турында”, “Кырык бакча”, “Кабуснамә” һ.б. китаплары дидактик стильдә язылган.

“Әдәбият буенча әңгәмәдәшләргә китап” (1884), хрестоматия рәвешендә өлкәннәргә атап язылса да, аны балалар да уңышлы файдаланган. Халык шагыйре Г.Тукай да 8–9 яшьлек вакытында бу әсәрне авыл кешеләренә укуын искә төшереп язган.

К.Насыйриның “Җәвәһирел хикәят” китабы халык зирәклегенә, тапкырлыгына нигезләнгән, анда күптөрле мәсәлләр һәм хикәяләр тупланган (“Эт һәм сөяк”, “Ана һәм бала”, “Челән һәм чыпчык” һ.б.)

К.Насыйриның халыкка аңлаешлы әсәрләрен яратканнар, кулдан кулга йөртеп укыганнар. Мәдрәсәләрдә рөхсәт ителмәсә дә, шәкертләргә дә әлеге китаплар таныш булган.

К.Насыйри тел өлкәсендә дә телче буларак бик катлаулы, күп яклы хезмәтләр башкарды: татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын исбат итте. Татар телен практик һәм фәнни эшкәртү юлында гаять зур эшчәнлек күрсәтте.

К.Насыйри тел гыйлеме, сүзлекләр төзү буенча аеруча күп эшләр башкарды. Бу өлкәдә ул кагылмаган, өлеш кертмәгән бер генә тармак та юк

диярлек. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген (“Ләһҗәи татари”,1895) башлап ул төзи. Русча–татарча һәм татарча–русча сүзлекләр төзеп бастыра.1898–1899 елларда К.Насыйри тарафыннан төзелгән ике томлы “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” телебезнең никадәр бай икәнен күрсәтте.1894 елда фонетика, сүз төркемнәре һәм берникадәр синтаксистан мәгълүмат кертеп язылган татар грамматикасы “Әнмүзәҗ” басылган. Насыйри бу китабында беренче тапкыр авазларга классификация ясап, аларны 10–сузык, 29–тартык авазга бүлеп күрсәтә.1894 елда аның “Иҗек һәм әлифба” китабы басылган. Балаларга аваз турында беренче мәгълүмат биргәндә сүзләр сайланышы белән бу әлифба бүгенге көндә дә методик кызыксыну уята әле.

К.Насыйриның иҗаты, эшчәнлеге халыкчанлык белән сугарылган. Бу аның халык өчен әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрүендә, халык мәнфәгатьләрен яклавында һәм китапларында халык иҗатына киң урын бирүендә күренә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин, К.Насыйриның гаять күп кырлы эшчәнлеге төп ике зур тармакка бүленә: гыйльми–мәгърифәтчелек һәм әдәби–тәрҗемәчелек юнәлешләре. Яңа татар әдәбияты үсеп китәр өчен гүяки ул туфрак йомшарта, түтәлләр әзерли, үзе дә беренче гөлләр үстерә башлый. Шуңа күрә аны зур галим генә түгел, зур әдип дип тә атыйлар.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 19–23б.

2. Ганиева Р. Каюм бабабыз. Казан: Мәгариф. – 1996.– №11.

3. Гыйләҗева Р. Олуг мәгърифәтче, галим, вә мөгаллим К.Насыйриның тууына – 170 ел. – Казан: Мәгариф, – 1995.–№2

4. Махмутов Х.Ш, Алишев С.Х, Гайнутдинов М.В. Каюм Насыйри. Избранные произведения. Перевод с татарского языка. – Казан: Тат.кн.изд–во.,1977. – с.80–83, 100 –114б.

## ПЕДАГОГИЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ КАЮМА НАСЫЙРИ/ КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ПЕДАГОГИК МИРАСЫ

**Нуриева Д.Р.**
Общеобразовательная школа «Университетская»
Елабужского института КФУ
Научный руководитель: Сахабиева Г.Х.

К. Насыров жил и работал во второй половине XIX века – в период бурного развития науки, литературы, научного обоснования теоретических основ педагогики.

Идеи Пирогова, Ушинского, Толстого, революционных демократов и целой плеяды их последователей, несомненно, оказали большое влияние на взгляды Каюма Насырова, на его педагогическое творчество.

К идее народности в воспитании Насыров пришел благодаря постоянному общению с простыми людьми, в частности, с крестьянами. Очень близко принимал он к сердцу страдания широких народных масс, их бесправие.

О положении народа в дореформенной России он писал в письме к своему старшему брату (1859 год): «Новых вестей нет. Но народ очень истощал. Нет ни одного, кто бы не жаловался».

Насыров страстно верил в творческие силы народа; именно у него просветитель черпал вдохновение для своих трудов, собирал фольклор, исторические и этнографические материалы, часто выезжал в деревни и уездные города.

Он придавал большое значение изучению и распространению устного народного творчества, которое способствовало укреплению стихийно–материалистического мировоззрения в народных массах.

Источник принципа народности педагогических и просветительских взглядов Каюма Насырова строится на его идее о том, что только трудовой народ и народное воспитание могут сделать человека полно– ценным гражданином отечества. С этим связаны и мысли об обучении детей на родном языке. Лишь родной язык и родная литература дают возможность привить дух своего народа, его нравственные идеалы, характер.

Татарские писатели начала XX века начинают свою литературную деятельность с изучения трудов Каюма Насыйри.

Татарские народные поэты М. Гафури и Г. Тукай, основатель татарского театра Галиаскар Камал в своих автобиографических очерках с уважением вспоминают, что они с самых ранних лет с увлечением читали произведения К.Насыйри.

«Вечером, когда перебирал книги, в руки попалась книга К.Насыйри «Плоды для собеседников». Начал я её читать. С особенным увлечением читал и старался понять стихотворения, помещенные в конце книги»,– пишет Габдулла Тукай в своем автобиографическом очерке.

И действительно, знакомство с светской литературой и татарским фольклором Г. Тукай в девятилетнем возрасте начинает с произведений К. Насыйри.

Читавшему до этого в стенах деревенской школы только книги религиозного содержания, Габдулле Тукаю произведение «Плоды для собеседников» вначале кажется несколько странным. Но в это же время народные песни, помещенные в конце этой книги, оказывают сильное влияние на Тукая. Вскоре Тукай сам, как и Каюм Насыйри, начинает собирать и изучать народные песни. Любовь к своему народному языку через эти песни с каждым днем у него усиливается.«Любовь к песням, которые с малолетства закрепились у меня в памяти, впоследствии зародила у меня любовь к родному языку»,– говорит Г.Тукай в своей лекции о народной литературе [2]. Глубоко интересовался Каюм Насыйри и вопросом доходчивости своих

произведений до читателей. Он искал всевозможные пути для привлечения народа к учению.

В своем воспоминании, напечатанном на страницах журнала «Шура», М. Тюнтари приводит маленькую, но характерную деталь: «Во время одной беседы он (К.Насыйри) показал мне экземпляр своего сочинения о вреде пьянства, напечатанном на большом листе в виде плаката, и для подтверждения своего суждения сказал: «Причина печатания этой книги на таком большом листе в виде плаката заключается в том , чтобы её можно было вывесить на стене с тем, чтобы её читали поневоле, чтобы она бросалась в глаза, иначе народ книгу не читает. … человек, потеряв всякую надежду на пробуждение любви к учению у своего сына, приобрел тексты отдельных уроков и учебники и вывесил их на стенах комнаты. Сына он поселил в эту комнату. Мальчик, куда бы ни смотрел, везде видел учебники и, наконец, начал их читать и таким образом вступил на путь учёбы» [4].

Таким образом, К.Насыйри не только создавал научные труды и литературно–публицистические произведения, но и практически был заинтересован в том, как ими должны пользоваться народные массы. Просвещение народа для него было первым шагом к достижению цели и средством для улучшения жизни народа.

Для широкого распространения просвещения среди народа учащейся молодежи необходимо было знать родной и русский языки.В создании учебной литературы и беллетристики на родномязыке учащихся Насыров, подобно выдающимся педагогам, прежде всего, обратился к неиссякаемому источнику живого народного творчества. Работая преподавателем духовной семинарии, он стал собирать произведения татарского фольклора, чтобы использовать их в учебных целях.

Ценными пособиями в овладении татарами русским языкомбыли «Татарско-русский словарь» (1875) и «Русско-татарский словарь» (1892), составленные Насыровым. Они были первыми словарями, написанными на казанско-татарском языке. Полный русско-татарский словарь с дополнением иностранных слов – научных терминов — был довольно обстоятельным для своего времени и послужил культурному развитию татарского народа [3].

Каюм Насыров является создателем учебных пособий на татарском языке, а также по другим предметам: арифметике, геометрии, земледелию, физиологии, истории и т.д.

Надо отметить, Каюм Насыров был одним из основателей светской татарской детской литературы. Считая чтение лучшим видом досуга, онговорил, что книга — это прекрасный сад, ее строки — это цветы нарцисса. Он осуждал тех родителей, которые запрещают читать книги, особенно произведения художественной литературы светского содержания. Ребенок, читая книги, заполняет свой досуг полезным делом и усваивает научные и жизненно необходимые знания.

Насыров считал, что лучшим учителем является книга: она – советчик, который предохраняет от многих затруднений и помогает человеку во всяком деле. Поэтому, как и многие видные педагоги других народов, К. Насыров значительное внимание в своем творчестве и деятельности уделял созданию детской литературы.

Значение Насырова было велико не только для той исторической эпохи. Произведениями просветителя пользуются ученики современных школ, к его методическим советам и ныне обращаются современные учителя татарского и русского языков, на созданную Насыровым научную терминологию опирается вся научная, техническая, научно-популярная, научно-фантастическая, художественная литература татарского народа. Его произведенияв нашей стране издавались многократно и массовыми тиражами, ими пользовался весь народ.

Прогрессивные педагогические идеи Насырова, защищающие общенаучное образование молодежи, особенно с усилением преподавания естественно математических предметов, послужили основой учебного плана многих татарских школ. Педагог К. Насыров высоко ценил роль воспитания и воспитателя, выступал с защитой прав ребенка, за гуманное отношение к нему. Он выступал за творческие поиски учителя, за внедрение новых форм, методов и приемов педагогического труда. В этом отношении он являлся примером для многих поколений учителей.

**Литература**

1. Каюм Насыри. Китаб–эт–тәрбия. Книга о воспитании. – Казань: Татарское детское издательство, 2024. – 232 с.
2. Фахрутдинов Р.З., Даутова Г.Ж. Выдающийся просветитель–гуманист К.Насыри как гордость татарской культуры //Мәгариф, 2002.
3. Фахрутдинов Р.З. К.Насыри как просветитель–гуманист //Технологии совершенствования подготовки педагогических кадров: наука и практика. – Казань, 2002.– С.30–31.
4. Фахрутдинов Р.З., Даутова Г.Ж. Педагогическое наследие К.Насыри как неисчерпаемый источник возрождения национального образования и воспитания учащихся //Профессиональное образование, 2002, – № 4, –.88–96.

## ВЛИЯНИЕ ТРУДОВ И ИДЕЙ КАЮМА НАСЫРИ НА ПОСЛЕДУЮЩИЕ ПОКОЛЕНИЯ

**Прохоров К.Е**.
Общеобразовательная школа «Университетская»
Елабужского института КФУ
Научный руководитель: Назмутдинова А.И.

Каюм Насыри, выдающийся татарский просветитель XIX века, оставил значительное наследие, которое оказало влияние на развитие татарской культуры и образования. Его труды охватывают широкий спектр тем, включая

язык, культуру, образование и моральные ценности. В этой статье мы подробно рассмотрим его основные работы и их влияние на последующие поколения.

Каюм Насыри был новатором в области образования, внедряя новые методы обучения и педагогические подходы. Современные школы могут вдохновляться его примером, внедряя инновационные технологии и методики, такие как проектное обучение, использование цифровых ресурсов и индивидуализированный подход к обучению.

Одним из ключевых направлений деятельности Насыри было развитие татарского языка. Его работы в области лингвистики стали основой для стандартизации и развития литературного татарского языка.

– «Грамматика татарского языка»: Этот труд систематизировал правила татарской грамматики, что стало важным шагом в стандартизации языка. Насыри описал фонетические, морфологические и синтаксические особенности татарского языка, что позволило создать основу для дальнейших исследований и преподавания. Его грамматические исследования оказали влияние на последующих лингвистов и педагогов, таких как Габдулла Тукай Фатих Амирхан, которые использовали эти стандарты в своей литературной и образовательной деятельности.

Насыри уделял большое внимание изучению и сохранению татарского фольклора и этнографии. Его работы в этой области способствовали сохранению культурного наследия татарского народа.

– «Татарские народные сказки и легенды»: Этот сборник стал важным источником для изучения татарского фольклора. Насыри собрал и систематизировал множество народных сказок, легенд и преданий, что позволило сохранить их для будущих поколений. Его этнографические исследования вдохновили последующих исследователей и писателей, таких как Фатих Амирхан, на дальнейшее изучение и популяризацию татарской культуры.

Каюм Насыри также оказал влияние на развитие татарской литературы. Его работы по грамматике и стилистике способствовали стандартизации литературного языка. Это позволило следующим поколениям писателей и поэтов, таким как Муса Джалиль и Габдулла Кариев, развивать литературные традиции на родном языке.

Каюм Насыри был новатором в области образования, предлагая прогрессивные методы обучения и воспитания.

– «Методика преподавания»: В своих педагогических трудах Насыри подчеркивал важность практического обучения и критического мышления. Он предлагал использовать интерактивные методы обучения, которые способствуют активному участию учеников в образовательном процессе. Эти идеи были подхвачены следующими поколениями педагогов, которые стремились модернизировать систему образования, делая её более доступной и эффективной. В современной школе это может быть реализовано через акцент

на STEM–дисциплины (наука, технологии, инженерия и математика), а также через развитие навыков критического мышления и решения проблем.

Насыри уделял большое внимание вопросам морали и этики в своих трудах. Он считал, что образование должно не только давать знания, но и воспитывать нравственные качества.

– «Этика и мораль в образовании»: В данной работе он рассматривал вопросы морали и этики, подчеркивая их важность в образовательном процессе. Насыри утверждал, что образование должно способствовать формированию у учащихся таких качеств, как честность, трудолюбие и уважение к другим. Эти идеи нашли отражение в работах последующих педагогов, которые стремились воспитывать в учениках высокие нравственные стандарты.

Труды и идеи Каюма Насыри оказали глубокое влияние на последующие поколения татарских просветителей и педагогов. Его работы стали основой для развития татарской культуры и образования, вдохновляя новые поколения на сохранение и развитие национального наследия. Насыри оставил неизгладимый след в истории татарского народа, и его наследие продолжает жить в трудах современных педагогов и культурных деятелей. Его подход к образованию и культуре продолжает вдохновлять и сегодня, служа примером для тех, кто стремится к сохранению и развитию культурного и образовательного наследия.

**Литература**

1. Фахрутдинов Р.З., Даутова Г.Ж. Выдающийся просветитель–гуманист К.Насыри как гордость татарской культуры // Мэгариф, 2002.
2. Фахрутдинов Р.З., Даутова Г.Ж. Педагогическое наследие К.Насыри как неисчерпаемый источник возрождения национального образования и воспитания учащихся // Профессиональное образование, 2002, № 4, С.88–96 (авторских 0,2п.л.).

## ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КАЮМА НАСЫРИ

**Салихов И.Р.**
Общеобразовательная школа «Университетская»
Елабужского института КФУ
Научный руководитель: Назмутдинова А.И.

Каюм Насыри (1825–1902) — выдающийся татарский просветитель, чья деятельность сыграла ключевую роль в развитии татарского общества в XIX веке. Его работа охватывала множество аспектов, включая литературу, образование и этнографию, и была направлена на просвещение и культурное развитие татарского народа. Рассмотрим подробнее основные направления его просветительской деятельности.

Каюм Насыри был автором множества произведений, которые способствовали распространению знаний среди татарского населения. Он писал на татарском и арабском языках, создавая как научные труды, так и

художественные произведения. Его работы охватывали широкий спектр тем, включая педагогику, историю, философию и этнографию.

Одним из ключевых аспектов его литературной деятельности было создание учебников и пособий. Эти материалы использовались в учебных заведениях и способствовали повышению уровня грамотности и образования среди татар. Насыри стремился сделать знания доступными для всех, независимо от социального положения, и его труды стали важным инструментом в достижении этой цели.

Как педагог, Каюм Насыри активно работал над реформированием системы образования. Он выступал за введение светских предметов в учебные программы медресе, что было новаторским шагом для того времени. Насыри считал, что образование должно быть всесторонним и включать изучение как религиозных, так и светских дисциплин.

Он также подчеркивал важность обучения на родном языке, что способствовало более глубокому пониманию и усвоению знаний. Насыри создавал методические материалы и организовывал курсы для учителей, помогая им внедрять передовые образовательные методы. Его усилия способствовали улучшению качества образования и подготовке нового поколения образованных татар.

Каюм Насыри внес значительный вклад в изучение и сохранение этнографического наследия татарского народа. Он собирал и систематизировал народные обычаи, традиции и фольклор, что позволило сохранить уникальное культурное наследие. Его этнографические исследования стали важным источником информации для последующих поколений исследователей.

Насыри уделял особое внимание устному народному творчеству, записывая пословицы, поговорки и сказки. Эти работы не только сохраняли культурное наследие, но и служили инструментом просвещения, помогая людям лучше понять и ценить свою культуру.

Просветительская деятельность Каюма Насыри оказала значительное влияние на татарское общество. Его работы способствовали формированию национальной идентичности и культурного самосознания, укрепляя чувство гордости за свое культурное наследие. Насыри показал, как можно успешно сочетать традиции и новаторство, создавая основу для устойчивого развития культуры и образования.

Его идеи и труды продолжают оказывать влияние на современное татарское общество, служа источником вдохновения для исследователей, педагогов и культурных деятелей. Насыри оставил после себя богатое наследие, которое продолжает жить и развиваться, укрепляя национальную идентичность и культурное самосознание татарского народа.

Каюм Насыри был выдающимся просветителем, чья деятельность оказала глубокое влияние на развитие татарского общества. Его работа в области литературы, образования и этнографии способствовала просвещению и культурному развитию татарского народа. Насыри оставил после себя богатое

наследие, которое продолжает вдохновлять и служить ориентиром для новых поколений, стремящихся сохранить и развивать свою культуру и образование.

**Литература**

1. Абдуллин И., Закиев М. Каюм Насыри — основоположник татарского национального литературного языка // Советская тюркология.— Баку, 1975, № 3. — 128 с.

2. Гайнуллин М. Каюм Насыйри и просветительское движение. – Казань, «Магариф», 2002.

3. Хакимов Х.Х. Создатели первых татарских светских школ // Выдающийся просветитель–демократ Каюм Насыри. – Казань: Казанский филиал АН СССР, 1976. – 216 с.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТОРМЫШ БАСКЫЧЛАРЫ

**Сафина А.И.**
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доцент Хәйруллина Ә.С.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров (Каюм Насыйри) – 1825 елның искечә 14 февралендә элекке Казан губернасы, Зөя өязе (хәзерге Татарстан республикасы, Норлат районы), Югары Шырдан авылында туа. Каюм Насыйриның бабалары һәм атасы үз заманының шактый укымышлы, танылган кешеләре булалар. Каюм Насыйриның истәлекләренә караганда, аның атасы балаларының укуларына каршы килмәгән, ул вакытларда руханилар авызыннан кат-кат әйтелеп килгән «иҗтиһад заманы монкариз»(иҗади фикер йөртү заманы үтте) дигән реакцион карашка каршы булган. «Һәркемгә иҗтиһад – кирәк эш», - дип, балаларына һәрвакыт ишеттереп торган.

Каюмның балалык вакытлары, заманы өчен, әнә шундый культуралы семьяда, туган авылында уза. Башлангыч белемне ул атасыннан ала. Аннан соң 1841 елда Каюмны Казанның бишенче мәхәлләсендәге бер мәдрәсәгә укырга бирәләр. 1855 елга кадәр ул мәдрәсәдә укып, гарәп-фарсы телләрен өйрәнү өстенә, үзлегеннән татар телен дә яхшы үзләштерә. Яшерен рәвештә русча да укый.

1855 елда Насыйрины Духовное училище дип аталган рус мәктәбенә татар теле укытучысы итеп чакыралар. Насыйриның беренче практик эше – укытучылык хезмәте шунда башлана. Соңыннан ул Духовная семинариядә, академиядә татар теле укытучысы булып эшли. Анда укытучылар белән таныша, алар белән якыннан аралаша, алардан рус телен һәм башка фәннәрне тырышып өйрәнүен дәвам иттерә.

Аннары ул, Казан университетында ирекле тыңлаучы булып йөреп, югары белем ала.

Каюм Насыйри татар балаларына рус теле укытуга зур игътибар бирә. Аның семинариядә укыту эше 1870 елга кадәр, 15 еллар буенча бара.

1871 елны Насыйри, семинариядә эшләүдән туктап, татар балаларына рус теле укытуга ныклап керешә. Шул рәвешчә, реакцион көчләрнең каршы килүләренә карамастан, бик авыр шартларда, зур газаплар күреп, Насыйри татар балаларына рус теле өйрәтү юлында, беренче буларак, зур тырышлыклар күрсәтә.

1876 елда Насыйри русча-татарча башлангыч белем бирү мәктәбендә мөгаллимлек итү эшеннән туктый.

Каюм Насыйриның мөгаллимлек хезмәте моның белән генә чикләнми. Ул тагын ике-өч ел Яңа бистәдә рус-татар мәктәбендә укыта.

1879 елдан башлап, К. Насыйри калган гомерен, рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итмәстән, тик язучылык эшенә һәм фән хезмәтенә генә багышлый.

Аның иң яхшы әсәрләре шушы вакытларда языла. Каюм Насыйриның бу вакытлардагы килере хосусый рәвештә балалар укытудан, аерым кешеләргә гаризалар язып бирүдән, татарча документларны русчага тәрҗемә итүдән һәм басылган китапларын сатудан тора.

Каюм Насыйри гомерен, бөтенләй дип әйтерлек, Казанда яшәп, иҗат өстендә уздыра. Берничә мәртәбә агасы Гәбделхәй янына Мәскәүгә, Мәкәрҗә ярминкәсенә Түбән Новгородка һәм имтихан өчен Уфага бара. Соңрак ул Оренбургта (хәзерге Чкалов) була. Каюм Насыйри шул вакытларда, үзенең күргәннәренә багышлап, истәлекләр дә язган. 1894 елда чыккан календареның 33-37 битләрендә «Сәфәр» исеме белән бер истәлек бирелә. Каюм Насыйри бу истәлектә Оренбургка бару юлында күргәннәрен һәм анда килүенә беркем дә игътибар бирмәвен сөйләп килә дә шундый игътибарсызлыкның сәбәпләрен түбәндәгечә аңлата: «Шулай итеп, Оренбург шәһәрендә тугыз кичә-көндез җыясы ризыкым бар, имеш, барып ашап кайттым. Ләкин нә мин берәү белән таныштым, нә минем белән берәү танышты. Чөнки миндә юктыр кырык-илле мең тәңкә акча, таки байлары белән танышыр идем. Яки юк иде минем башымда зур чалма, таки голямасы (муллалары) белән танышыр идем...» [Насыйри, 2003 : 339]. Шул рәвешчә, Каюм Насыйрига, Казанда татар буржуазиясе читләтеп караган шикелле, Оренбургта да игътибар итүче булмый. Насыйри бу хәлнең ул кешеләр белән үзенең уртак нәрсәсе булмаганнан килгәнен ачык төшенә, игътибар бирмәүләренең сәбәбен дөрес аңлата.

Каюм Насыйри, бу сәяхәтләреннән тыш, һәр язны энесе Габделкавый белән туган авылы Югары Шырданга кайта, гади халык белән кырда эшли. Шунда Зөя һәм гомумән Тау ягындагы авылларга чыгып, андагы тарихи истәлекләрне тикшерә. Халык белән якыннан аралаша, аның телен, гореф-гадәтләрен өйрәнә, авыл картларыннан тарихи истәлекләр, фольклор материаллары җыя.

Каюм Насыйри бөтен тормышын иҗат эшенә, гыйльми эшкә буйсындыра. Күп вакытта, утырып эшләүнең, көннәр-төннәр буена язу өстендә утыруның кешене ялыктыруын искә алып, Каюм Насыйри ял вакытларында физик хезмәт белән дә шөгыльләнә торган була. Кул һөнәре, физик эш куллануы аңа тормышындагы бертөрлелектән арынырга да ярдәм итә.

Аның кул эшләре белән шөгыльләнүе күп төрле һөнәрләр белү характерында була. Ул китап төпләү, көзге ясау, крахмал, суыргыч, лак, кара хәзерләү, электричество ярдәмендә әйберләр көмешләү һәм слесарьлык эшләрен дә яхшы белгән. Төрле ашлар хәзерләүдә дә осталыгы булган. Ул бу һөнәрләрнең теориясен китаплардан укып һәм үзенең тәҗрибәсендә сынап карап өйрәнә.

Башкаларга да өйрәтү теләге белән, шул темаларга карата китаплар да яза. Ул бу һөнәрләрен үзенең практик ихтыяҗыннан чыгып файдалана: китапларын үзе төпли, үзе өчен кирәк булган нәрсәләрнең барысын да үзе ясый. Аның физик эшләрдән иң яратканы агач эше булып, ул бу эшне ахыр гомеренә кадәр һәрвакыт һәм системалы рәвештә алып бара. Ул: «Һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеша, мин һәр көн бер-ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле әйберләрне ясыйм», - дип әйтә торган булган [Насыйри, 2005 : 357].

Каюм Насыйри катлаулы һәм нечкәрәк һөнәрләрдән карта сызу, рәсем төшерү кебек эшләргә дә сәләтле була. Ул үз гомерендә төрле карталар сызып, аларны үзе чыгарып килгән календарьларында урнаштыра бара: 1878 ел өчен чыккан календаренда җир шарының көнчыгыш яртысының картасын, 1879 елда Россиянең Европа өлеше картасын һәм 1881 ел календаренда Казан губерниясенең бөтен авылларын күрсәткән картасын эшләп бастырган. Каюм Насыйриның рәсем төшерүе, төрле чәчәк һәм бизәкләр ясавы, бигрәк тә сызып ясаган кайбер эшләре аеруча игътибарга лаек.

Гомумән, Насыйри сәнгать эшендә булдыклы, аның һәр өлкәсе белән азмы-күпме таныш була. Ул музыка тыңларга ярата. Аның да берничә музыка коралында уйный белүен, стенасында балалайка һәм скрипка эленеп торганын сөйлиләр. Насыйри бу коралларда уйнаганмы-юкмы – билгесез, әмма гадирәк музыка коралларыннан кубыз һәм курайда яхшы һәм матур итеп уйный торган булган.

К. Насыйри 1865 елда Казанның Мөсәгыйть ямщик дигән кешенең кызы Зөһрәгә өйләнә, матур гына гаилә тормышы башлыйлар. Ләкин озакка бармый – хатыны баладан үлә. Насыйри бу югалтуны авыр кичерә, үзе укыган бер китапның битенә кайчан өйләнүе, хатыны һәм баласының үлү вакыты һәм кайда күмелүе турында язып куйган.

Язучы үзенең шәхси тормышына артык әһәмият бирми. Иҗат эше белән беррәттән физик хезмәт белән дә шөгыльләнүе нәтиҗәсендә аның өендә чисталык һәм пөхтәлек җитәрлек булмаган. Гаиләсенең тулы булмавы да моңа сәбәп булган.

Мондый шартларда яшәүгә карамастан, ул үзенең сәламәтлегенә зур игътибар бирә, халык медицинасын файдалана, ятып авырганы булмый. Бары тик гомеренең соңгы елларында гына аякларын җиңелчә паралич суга, ул электр ярдәмендә үзен-үзе дәвалый. Туктаусыз хәрәкәт итүе сәбәпле йөрерлек хәлгә килә.

Шундый авыр шартларда да Каюм Насыйри үзенең иҗат эшчәнлеген дәвам иткән. Ул 1902 елның 20 августында (2 сентябрьдә)77 яшендә үлә. Аның гәүдәсе Казанда Яңа бистә зиратында Ш. Мәрҗани белән рәттән күмелә.

**Әдәбият**


1. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. IV томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Т.1. – 368 б.
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. IV томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Т.3. – 384 б.


## К. НАСЫЙРИНЫҢ“ӘБҮГАЛИСИНА” ӘСӘРЕНДӘ БЕЛЕМ ТЕМАСЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ


**Сафина Л.И.**

Алабуга шәһәре “1 нче гимназия – Милли белем бирү үзәге” укучысы

Фәнни җитәкче: Илдарханова З.М.


Белем кеше тормышында әһәмиятле урын алып тора. Ул теләсә кайсы өлкәдә өстенлекне тәэмин итә. Һәрберебезгә җитди карарлар кабул итәргә, үз тормыш дәрәҗәбезне күтәрергә һәм уңышка ирешергә этәргеч бирә.

Кеше алган белемнәре нәтиҗәсендә табигать законнарын, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, тормышны танып белә, аларны кирәкле юнәлештә куллана ала. Белем дәрәҗәсе киңрәк булган саен, аңа үз алдына куйган максатларны, хыялларны тормышка ашырырга мөмкинлек арта.

Чыннан да, гыйлемлелек - кешенең дөньяга карашын ачучы, аны уйларга, фикерләргә өйрәтүче, авырлыклардан чыгарга, киләчәккә туры юл күрсәтүче төп көч. Бары акыл туплаган кеше генә каршылыклар алдында югалып калмый, һәрнәрсәдән чыгу юлын таба, алган белемнәре нәтиҗәсендә үз бәхетен таба.

Татар әдәбиятына, фольклорына игътибар итсәк, гыйлемлелекнең кеше тормышында ни дәрәҗәдә зур роль ачыклавын, кешелекне алга әйдәүче төп фактор икәнлегенә тагын бер кат инанасың. Нәкъ менә белемнең көчен, аның асылын безгә халкыбызның хәзинәсе булган мәкаль-әйтемнәр, әдәби әсәрләр җиткерә.

«Әбүгалисина кыйссасы» - К. Насыйриның иң күренекле һәм киң таралган әсәрләреннән берсе. 1872 нче елда әдип аны татарчага тәрҗемә итә. Халыкның хыялларын гәүдәләндергән, югары художество көченә ия булган, дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителгән бу әсәр героеның прототибы – Урта Азиядә яшәгән бөек галим – философ, юрист һәм врач Ибне-Сина. Легендар сюжетлы бу әсәрне К. Насыйри очраклы тәрҗемә итми. Ул аның мәгърифәтчел теләкләренә, фәнни карашларны популярлаштыру омтылышларына, демократик идеалларына җавап бирә. Әсәр фантастик планда язылган. Сурәтләнгән вакыйгалар реаль тормыштан ерак торалар, ләкин шул фантастик сурәтләүләрдә гуманистик идеяләр яклана, хаксызлыкка, гаделсезлеккә каршы көрәш алып барыла.

Әсәрнең үзәгенә гыйлем алу, аның тормышта кирәклеге һәм әһәмияте алынган. Бу тема кыйссаның төп герое - Әбүгалисина үрнәгендә яктыртыла.

Әбүгалисина үткенлеге, зирәклеге белән башка балалардан аерылып тора. Иптәшләренең шаяртып, киез астына куйган бер кәгазь битен сизүе дә аның шул дәрәҗәдә сизгер, игътибарлы булуы турында сөйли. “Белмим, мәктәпнең түшәме төшкәнме, әллә идәне күтәрелгәнме? Ни булса да, элеккечә түгел,”- дигән җавабы һәрберебезне таң калдыра.

4 яшендә мәктәпкә кергән малай бик яхшы укый, укытучы ни генә әйтсә дә, бик тиз төшенеп ала, белгәнен бер дә онытмый. Шулай ук, укытучы сөйләгәннәр белән генә канәгатьләнеп калмыйча, яшьтән үк китаплар укуга бирелә. Унике яшенә җиткәндә, Әбүгалисина инде бик күпне белүче гыйлем иясе булып җитешә, төрле фәннәрдән үзе дә башкаларга сабак укыта башлый. Үзеннән зуррак балалар да аннан дәрес алалар.

Тагын берничә ел үткәч, Әбүгалисина зур галим булып җитешә. Бохара тирәсендә аңа тиң, аның белән сүз көрәштерерлек кеше калмый. Әбүгалисина тагын да тирәнрәк белем алырга тели. Туганы Әбелхарис белән бергәләп, гыйлем өстәп, алар туган илләреннән еракларга китәргә уйлыйлар. Гыйлем серләре белән тулы мәгарә турында ишетәләр. Борын заманда яшәгән Фисагурис (Пифагор) исемле атаклы галимнең гыйлемнәре югалмасын өчен, аның китаплары мәгарәгә урнаштырыла, ишек төбенә сакчылар куеп саклана. Бу мәгарә ел саен бер вакытта өч сәгатькә генә ачыла. Анда һәркемгә башына сыйдыра алган кадәр белемнәр алып чыгарга рөхсәт ителә. Ике туган, 3 сәгатьтә генә әллә ни белемнәр туплап булмас дип, бер елга мәгарәдә калырга уйлыйлар һәм шуңа бик ныклап әзерләнә башлыйлар. Үзләрен аз ашарга һәм эчәргә күнектерәләр. Көнгә егерме тиеш көмеш акча авырлыгындагы зәйтүн мае белән тукланалар, айга бер мәртәбә су эчеп сусауларын басалар. Мәгарәдә яндыру өчен, бер елга җитәрлек май һәм башка кирәк-яракларны да әзерлиләр. Алар үзләре белән суган суы алып керәләр, шуның белән бик кирәкле белемнәрне язгалап та алалар. Әбүгалисина белән Әбелхарис мәгарәдә бер ел булып, күп кенә тырышлыклар, көч куеп, әллә никадәрле белем туплыйлар.

Үзләштерелгән белемнәр, әлбәттә, тормыш - яшәештә кулланылып, үзеңә, тирә-юньдәгеләргә файда китерергә тиеш. Бары шул чакта гына, гыйлем алуга сарыф ителелгән көчнең, хезмәтнең нәтиҗәсен күреп була.

Гыйлем халыкка, тормышны яхшыртуга хезмәт итәргә тиеш. Әбүгалисина, үзенең симия (ак магия) белемнәрен кулланып, гади халык вәкиле хәлвәфрүшкә булыша: хезмәтен җиңеләйтә, керемен арттыра, аның ярдәмчесенә әйләнә. Базар уртасына хәлвәфрүш өчен күп бүлмәле зур бер кибет барлыкка китерә. Кибәкләрдән иң тәмле хәлвә ясап, егетне шаккатыра. Хәлвәфрүш аның хикмәтле кеше икәнен белеп, аңа соклана, үзендә яшәргә калдыра.

Әсәрнең төп герое үзенең белеме, сизгерлеге, уяулыгы белән гади халыкка түбәнсетеп караган патша белән дә көрәшә. Хәлвәфрүш белән патша кызы арасындагы мөнәсәбәтләрне белеп, ул аларга ярдәм итәргә ашыга, аларны

очраштыру юлларын эзли. Сөйгән кызы белән һәр күрешү Хәлвәфрүшкә куркыныч алып килә. Патшаның һәр яңа мәкере аны сагалап тора. Ул Әбелхарис ярдәме белән кызның кайда булуын, кем белән очрашуын белергә тели. Әүгалисина, бу турыда алдан ук сизеп, хәлвә пешерүче егетнең бүлмәсен Һиндстан тирәсендәге Мосасакия утравындагы йортларга охшатып бизи. Кыз белән очрашучы егетнең урыны дип, патшаның башын бутый. Шулай итеп, төп каһарманның зирәклеге бу юлы кызның Хәлвәфрүш белән очрашуын белдерми кала.

Акыл иясе патша үтенече белән үз хикмәтләренең көчен дә күрсәтә. Ул аны ком сахрасында сусыз интектереп йөртә. Җиде башлы аҗдаһа белән очраштыра, чак кына исән кала. Шушы “могҗиза” лар да аңа сабак бирми. Ул тагын Әбүгалисинага биргән вәгъдәсен боза, аны Әбелхарисның ярдәме белән үз юлыннан алып атарга тели. Тик бу юлы да гыйлем көче өстен булып чыга. Күп михнәтләр күргән Әбүгалисина Хәлвәфрүшне үлемнән коткарып кала.

Патшаның явызлыгы тагын да көчәя. Аның фикеренчә, бары Әбүгалисинаны кулга төшереп кенә, ул бу түбәнчелектән котыла ала. Шул максат белән, сихерчеләр эзли башлый. Янәсе, алар ярдәме белән ул аны кулга төшерә, ә кызын Хәлвәфрүштән саклап кала. Гыйлеме белән дан тоткан героебыз бу хәлдән чыгу юлын да таба. Шәһәргә “бакалар яңгыры” яудыра. Җиргә төшкән бакалар үлеп, бөтен шәһәрне сасыта. Бу хәлгә халык түзеп тора алмый, патшага каршы күтәрелә. Шулай итеп, ил башлыгы үзенең кызын гади хәлвә пешерүче егеткә кияүгә бирергә мәҗбүр була. Ә Әбүгалисина үзенең “хикмәт” ләре белән Хәлвәфрүшкә тагын зур бүләк ясый. Шәһәр һәм сарай халкын җыеп, зур туй үткәрә.

Әбүгалисинаның белем көче үзенә каршы килгән мунча хуҗасына мөнәсәбәтендә дә күренә. Түләргә акчасы булмаган егет, хуҗадан түләүне кичектереп торырга сорый, вакытлыча яулыгын калдырып торырга уйлавын әйтә. Тик хуҗа аны начар сүзләр белән сүгә, риза булмый. Әбүгалисина әлеге хәлне авыр кичерә, үзенең гыйлем көче белән мунчадагы утны сүндерә. Тиздән мунчада су ката, стеналар бозга әйләнә. Автор төп геройның бу гамәле белән явызлыкның нәрсәгә китерүе турында җиткерә.

Әсәрдә Әбүгалисинаның ихфа гыйлеменә ия булуы да сөйләнә. Башкаларга күренмәс кешегә әйләнеп, ул мохтаҗ кешеләргә ярдәм итә, аларны авыр хәлләрдән коткара. Хәлвәфрүш тә, аның бу хикмәтенә сокланып, әлеге гыйлемгә өйрәнергә тели. Дусты аңа күзләренә ихфа сөрмәсе сөртә, сак булырга куша. Егет әлеге серне сөйгәненә сөйли, ә ул – үзенең тәрбиячесенә. Шулай итеп, егетнең саксызлыгы аркасында, бу сер чишелә. Егеткилгән бүлмәгә төтен җибәрелә, ихфа сөрмәсе юылып төшә. Егет патша янына китерелә, аны асарга хөкем ителә. Бу куркыныч хәлдән дә Әбүгалисина үзенең дустын коткарып кала.

Кыйссаның кыйсы гына бүлеген алсак та, анда Әбүгалисинаның гыйлем дәрәҗәсе, аның гади халыкка ярдәм итүе, аларга юл күрсәтүе турында сөйләнә.

Минемчә, автор әлеге образ аша алган белемнәрнең көче, аны тиешле урында, кирәк вакытта дөрес итеп куллану зур уңышка илтә дигән фикерне җиткерә.

К. Насыйриның “Әбүгалисина” әсәре үз укучыларында белем, һөнәр, сәләт, әхлаклылыкны үстерүгә зур хезмәт итә. Автор бернәрсәгә ныклап ышандыра: белем һәркемгә һәм һәрвакыт кирәк. Алган белемең кешеләр бәхетенә, матурлыкка, мәхәббәткә, гаделлеккә, яхшылыкка хезмәт итәргә тиеш. Олуг мәгърифәтчебезнең шундый эчтәлекле әсәрне татар теленә күчерүе халкыбызның мәдәни үсешенә, гуманистик тәрбиясенә зур йогынты ясый.

**Әдәбият**


1. Юзиев Н.Г. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.
2. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2014.
3. Ф.Ә. Ганиева, М.Д. Гарифуллина. Әдәбият. 6 сыйныф.– Казан: Татар.кит.нәшр., 2014.


## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ӘДӘБИ ЭШЧӘНЛЕГЕ


**Сафина Н.И.**

Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы

Фәнни җитәкчеләре: Ашрафуллина Р.И., Гомәрова Л.М.


XIX йөздә татар халкының үзаңында, иҗтимагый – тарихи күзаллавында билгеле бер үзгәрешләр туа.Үткән тарих белән кызыксыну, мөстәкыйль фикерләүне һәм эш–гамәлне яклау, башка халыкларның рухи мирасына игътибар көчәю–шуның ачык билгесе. Бу чор татар иҗтимагый һәм рухи фикер хәрәкәтенең башында Хөсәен Фәезханов, Шиһабеддин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави кебек күренекле затлар арасында галим, педагог, язучы, мәгърифәтче һәм башка исем–дәрәҗәләргә ия булган Каюм Насыйри хезмәтләре зур игътибарга лаеклы.

Галимнең фәнни һәм әдәби эшчәнлеге крепостнойлык чорында ук башлана һәм Россиядә капитализмның көчәйгән чорында үсә. «Мәҗмәгыл–әхбар» исемле беренче әсәрен ул 1859 елда яза. Аның беренче басма хезмәте 1860 нчы елда дөнья күргән «Нәху китабы» («Синтаксис») исемле дәреслек–китабы була. Шул ук елны ул мәктәп балалары һәм үзлегеннән белем алучы затлар өчен табигать күренешләре турында «Буш вакыт» дигән брошюра бастырып чыгара. Бу татар телендә язылган беренче фәнни–популяр әсәр була. Татар балалар әдәбиятын булдыру да шуннан башлана. Бу эшчәнлекне алга таба үстереп, ул теоретик һәм гамәли белемнәрнең төрле тармаклары буенча дәреслекләр һәм кулланмалар төзи. Мәсәлән, математикадан ул «Хисаблык» («Арифметика», 1873), «Гыйльме һәндәсә» («Геометрия», 1895), географиядән «Истилахатед жаграфия» («География терминологиясе», 1890), «Джаграфия кабир» («Зур география, 1894 – 1899) дәреслекләрен яза. Табигать фәннәре буенча ул «Буш вакыт» (I860), игенчелек буенча «Гыйльме зирагат» (1892),

ботаника буенча «Гөлзар вә чәманзар ягъни үләнлек вә чәчәклек» (1894) китапларын яза, анда үләннәр һәм чәчәкләр турында тулырак мәгълүмат бирә.

Рус һәм татар халыклары дуслыгын кайнар яклаучы буларак, Каюм Насыйри беренчеләрдән булып татар халкын туган телендә рус тарихы белән таныштыра. Аның «Зөбәде мин тәварих рус» («Краткая история России», 1890) дигән китабы бу өлкәдә татарча чыккан беренче хезмәте булып тора. Һәр фәндә Каюм Насыйри гамәлиякка игътибар итә, нәрсәгә хезмәт итүен аңлата.

К.Насыйриның татар матур әдәбияты үсеше тарихындагы хезмәтләре шактый зур. Ул үзе әдәби әсәрләр иҗат итә, башка халыкларның әдәби әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә, әдәбият белгече, фольклор җыючы буларак зур эш алып бара, әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнә.

1871 нчеелдан К.Насыйри өстәл календаре чыгара башлый, татар көндәлек газетасы чыгару турында да хыяллана. Ләкин патша хөкүмәте газета чыгарырга рөхсәт итми. 24 ел дәвамында системалы рәвештә чыга торган календарьда, чиста календарь белән беррәттән, бик күп фәнни һәм әдәби материал да урын ала. Шуңа күрә Каюм Насыйрины беренче татар энциклопедисты дип атыйлар.

Каюм Насыйри татар тел белеме өлкәсендә беренче оригиналь әсәрләр иҗат итә. Монда Галимҗан Ибраһимовның аның турында әйткән сүзләрен китерү урынлы: «гарәпчәдән татарчага кискен күчүдә Насыйри бездә ачыктан–ачык революционер булып саналырга тиеш. Халык, аның түбән катламнары өчен эшләгәнлектән, ул беренче булып «татар теле» сүзләрен куллана башлый һәм 50 ел бу өлкәдә эшли. Халыкның әкиятләрен, мәкальләрен, җырларын ул ниндидер аерым бер мәхәббәт белән, кыйммәтле хәзинәләр кебек җыйган».

К. Насыйри беренче булып халык массаларына аңлаешлы татар әдәби теле булырга тиеш дигән фикер белән чыгыш ясый, татар теленең грамматикасын төзи һәм бастыра. Галимнең татар әдәби әдәбияты үсеше тарихындагы хезмәтләре шактый зур.

Ул төрек, гарәп, фарсы телләрендә басылган иң яхшы повестьларны, хикәяләрне җентекләп сайлап алып, татарчага тәрҗемә итә. 1872 елда Каюм Насыйри мәшһүр «Әбү–әли–сина турында повесть» ны эшкәртеп бетерә. Халыкның бай фантазиясен гәүдәләндергән һәм дөньяның барлык телләренә диярлек тәрҗемә ителгән бу повесть героеның прототибы булып X йөз ахыры– XI йөз башында (980–1037) Урта Азиядә яшәгән мәшһүр фәлсәфәче, юрист һәм медик ибне Сина (Авүсенна) тора.

Каюм Насыйри гомеренең соңгы көннәренә кадәр сәнгать иҗаты өлкәсендәге эшен туктатмый.Ул тарихи материалны халык риваятьләре рәвешендә җыюга аерым игътибар бирә. Татар халкының тарихын өйрәнгәндә, Каюм Насыйри хәзерге Казан татарларының ата–бабалары турындагы мәсьәләгә дә якын килә. Ул Казан татарларының бабалары болгарлар дип раслый.

Каюм Насыйри педагогика өлкәсендә дә уңышлы эшләде. Бу фән турында аның бик күп сүзләре сакланган. Озак еллар педагогик эшчәнлек белән

шөгыльләнеп, ул практик–укытучы гына түгел, бәлки педагог – фикер иясе дә булып кала. Каюм Насыйри укыту–тәрбия эшендә педантизмны тәнкыйтьли һәм аны тәртипкә китерергә чакыра. Каюм Насыйри хезмәтләре үз вакытында матбугатта рус телендә дә басылып чыга. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография фәнни җәмгыяте әгъзасы буларак, ул үзенең фәнни хезмәтләрен тарату өчен уңайлы мөмкинлеккә ия була. Университет галимнәре аңа үзләренең методик күрсәтмәләре белән системалы рәвештә эшлекле ярдәм күрсәтәләр, шулай ук хезмәтләрен бастырып чыгарырга ярдәм итәләр. Аның күпкырлы әдәби эшчәнлеге, халыкның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән армый–талмый мәгърифәтчелек эше көннән–көн күбрәк укучыларны җәлеп итә.

Каюм Насыйри безгә – яшь буынга–фәнни хезмәтләр рәвешендә искиткеч мирас калдырган.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М.Х.. Каюм Насыйри хезмәтләренең татар һәм рус телләрендә аерым басмалар булып чыккан библиографик күрсәткече. – Казан, 1948.

2. Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр (2 басмасы). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1956.

3. Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр (икенче том). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ФӘН ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Ситдикова А.А.**
КФУның Алабуга институты
“Университет”гомуми белем бирү мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С

Каюм Насыйри – XIX гасырның күренекле татар галиме, мәгърифәтчесе һәм педагогы, аның фәнни хезмәтләре Идел буе һәм Урал халыклары арасында фән һәм мәгариф үсешенә зур йогынты ясаганнар. Каюм Насыйриненңфәнни эшчәнлеге тарих, этнография, филология, шул рәттән табигый фәннәр өлкәсен дә кертеп, киң мәйданны колачлый. Әлеге мәкаләдә без Каюм Насыйриның фәнни хезмәтләренең төп аспектларын һәм аларның фәнни белемнәр үстерүдә әһәмиятен билгеләрбез.

Каюм Насыйри 1825 елда Казан губернасының Олы Шырдан авылында туа. Кечкенәдән үк фән белән кызыксына, моңа гаиләдә хөкем сөргән мөһит ярдәм итә: Каюмның бабалары һәм атасы ул заманның укымышлы кешеләре була. Каюмның әтисе мулла була һәм укыту белән шөгыльләнә, бу исә булачак галимнең дөньяга карашын формалаштыруда мөһим роль уйный. Насыйри «Касыймия» мәдрәсәдә белем ала, анда гарәп әдәбиятын, ислам хокукын һәм башка фәннәрне өйрәнә. 1855 елда мәдрәсәне тәмамлагач, аны Казандагы Руханилар училищесына татар теле укытучысы сыйфатында эшкә чакыралар.

Аннары ул әлеге уку йортының дәвамы булган Руханилар семинариясендә мөгаллим була [3].

Каюм Насыйриның гыйльми эшчәнлеге күпкырлы һәм төрле була. Ул белемнең төрле өлкәләренә зур өлеш керткән шәхес.

Насыйри фәнни эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе татар халкы тарихын өйрәнү була. Ул татарларның килеп чыгышы, мәдәнияте һәм гореф–гадәтләре, шулай ук Татарстан һәм күрше төбәкләрнең үсеше белән бәйле тарихи вакыйгалар турында язган. Аның тарих буенча хезмәтләре чыганакларны җентекләп анализлауга нигезләнгән һәм үз эченә Европа галимнәре хезмәтләренең тәрҗемәләрен дә алган.1890 елда ул рус тарихының мөһим чорларын чагылдырган «Зөбдәте мин тәварихе рус» хезмәтен бастырып чыгара.[1]

Каюм Насыйриның этнографик тикшеренүләре аның тарихи хезмәтләренә мөһим өстәмә булып тора. Ул татар крестьяннарының тормышы һәм көнкүреше, гореф–гадәтләре һәм ышанулары турында материаллар җыя. Бу мәгълүматлар аңа төбәктә барган этник процессларның бербөтен картинасын тудырырга мөмкинлек бирә.Галимнең бу өлкәдәге тикшеренүләре 1880 елда рус телендә «Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся помимо влияния на их жизнь суннитского магометанства» дип исемләнгән хезмәтендә басылып чыга. «Кырык бакча», «Фәвакиһел җөләса», «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре», «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» кебек хезмәтләремдә, шулай ук үзе чыгарган календарьларда ул күп санлы әкиятләр, бәетләр, риваятьләр, җырлар, мәкальләр һәм табышмаклар бастырып чыгара [2].

Насыйриның филологик тикшеренүләре татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә кагылган. Ул текстларны анализлау методларын эшли, төрле диалектларны чагыштырып тикшерә һәм сүзлекләр төзи. Аның бу өлкәдәге хезмәте татар филологиясенең алга таба үсешенә нигез булып тора.Галим халык иҗаты материалларын тел белеменә багышланган хезмәтләрендә, бигрәк тә сүзлекләр төзегәндә киң куллана. Аның «Ләһҗәи татари» дигән аңлатмалы сүзлеге аерым урын алып тора [1].

К.Насыйри тарафыннан 1898–1899 елларда төзелгән ике томлы “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” телебезнең байлыгын күрсәтә. Бу хезмәт хәзер дә зур фәнни казаныш булып тора. Анда киң таралган гарәп һәм фарсы алынмаларына аңлатмалар бирелә, татар лекасының катлаулы аспектлары тикшерелә һәм сүзләрнең этимологиясе бирелә.

1894 елда фонетика нигезләрен, сүзләр классификациясен һәм синтаксисның кайбер элементларын үз эченә алган «Әнмүзәҗ» исемле татар грамматикасы дөнья күрә. Монда Насыйри беренче булып сузык авазларны системага сала, ун сузык һәм егерме тугыз тартыкны аерып чыгара. 1892 елда «Кавагыйдә китабәт»исемле хезмәте басылып чыга. 1894 елда аның «Иҗек һәм әлифба»китабы дөнья күрә.[4]

Гуманитар фәннәрдән тыш, Каюм Насыйри табигать фәннәре белән дә кызыксына. Ул ботаника, зоология, геологияне һәм медицинаны өйрәнә, кыр тикшеренүләре үткәрә, үсемлекләр һәм хайваннар коллекцияләрен җыя. Аның бу өлкәләрдәге хезмәтләре халыкның киң катламнары арасында фәнни белемнәрне популярлаштыруга юнәлдерелгән. Аның табигать белеменә багышланган хезмәтләре: 1860 елда басылып чыккан «Буш вакыт» — «На досуге», ботаника һәм халык медицинасына багышланган 1894 елда чыккан «Гөлзар вә чәмәнзар» — «Цветы и травы», анатомия һәм гигиенага турында «Мәнафигел–әгъза вә кануне сиххәт» — «Функция органов тела и правила гигиены»(1894) хезмәтләре билгеле.[4]

Каюм Насыйриның фәнни хезмәтләре Татарлар арасында фән һәм мәдәният үсеше өчен зур әһәмияткә ия була. Алар татар халкының үткәне һәм бүгенгесе турында мөһим мәгълүмат чыганагына әверелде, мәдәни мирасны саклап калырга һәм аның алга таба үсешенә ярдәм итте. Каюм Насыйри үз заманының атаклы галиме. Аның хезмәтләре татар халкының милли үзаңын формалаштыруга сизелерлек йогынты ясый, фәнни белемнәрне таратуга һәм халык арасында белем дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә. Насыйри хезмәтләре бүгенге көнгә кадәр актуаль һәм кирәкле булып кала, хәзерге тикшеренүчеләр өчен кыйммәтле материал булып тора. Аның күпкырлы булуы һәм дөньяны танып белүгә омтылышы аны XIX гасырның татар мәгърифәтенең иң күренекле эшлеклеләренең берсенә әверелдерә.

**Әдәбият:**


1. Ахунов А.Выдающиеся татары прошлых веков. Каюм Насыйри// Цнинские Долины. – 2021. – №6. – С.2–3
2. Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркологическая лингвистическая школа/ сост. М.З.Закиев.– Казань: Татар.кн. изд–во, 2008. – С. 32–36
3. Исламов Р.Ф.Каюм Насыйри – татар календареның “атасы”– URL:https://kiziltan.ru/articles/obchestvo/2024–03–26/kayum–nasyyri–tatar–kalendareny–atasy–3701208 (мөрәҗәгать итү вакыты: 07.01.2025)
4. Шәйдуллина М.М.Каюм Насыйри – педагог, тәрҗемәче, фольклорист. – URL:https://multiurok.ru/files/f–nni–esh–kaium–nasyiri–piedaghogh–t–rzh–iem–chie.html(мөрәҗәгать итү вакыты: 07.01.2025)


## КАЮМ НАСЫЙРИ – ТӘРҖЕМӘЧЕ


**Ситдикова Р.Х.**

КФУның Алабуга институты студенты.

Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доцент Габидуллина Ф.И.


Каюм Насыйри, гәрчә ул оригиналь әдәби әсәрләр иҗат итмәсә дә, татар әдипләре рәтендә йөри. Г. Исхакый аны яңа дәвер әдәбиятының «атасы» дип атый. Ни өчен? Чөнки ул — татар укучыларын әхлакый һәм эстетик яктан тәрбия кылырлык күп кенә күренекле әсәрләрне татарча сөйләткән кеше.

Тәрҗемә вакытында Каюм баба татар кешесенең образлы фикерләвен, зәвыгын, туган телнең эчке мөмкинлекләрен, аһәңен шактый истә тотып эш итә. Менә бер мисал:

Голубушка, как хороша!
Ну что за шейка, что за глазки!
Какие перышки! Какой носок!
И верно, антельский быть должен голосок!
*(И. А. Крылов)*

К. Насыйри бу строфаны болай тәрҗемә итә:

Һай күгәрченгенәм, ниндәен һәйбәт!
Кара аның муенгынасын, кара аның күзгенәсен!
Ниндәен нәфис аның йонгынасы! Ниндәен матур аның борынгынасы!
Дәхи фәрештә тавышы кебек микән аның тавышкынасы!

Ике текстны чагыштыру шуны күрсәтә: тәрҗемәче, гәрчә ул шигъри яңгырашны сакламаса да, оригиналдагы эчтәлек һәм үзенчәлекне татар теле чаралары ярдәмендә шактый тулы, тәэсирле итеп бирүгә ирешкән. Бу уңай белән тәрҗемәченең аңлатмасы да кызыклы гына: *«Голубушка, глазки, перышки, носок, голосок* дигән сүзләр мәдех мәкамендә (ягъни мактау рухында) зикер ителгәндер (әйтелгәндер), – ди ул. – Бездә һәм бар: *мәсәлән, кугәрченгенәм, абзыкай, җанкай, кашкынасы, кузгенәсе...»* [Бәдигый 2007: 43].

К. Насыйри, нигездә, Урта гасыр Шәрык классикасының чәчмә әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Тәрҗемә вакытында ул оригиналны татарча төгәл дә күчерә, аерым кыскартулар да ясый, төп текстка теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр дә кертә; вакыйга-хәлләрне урыны белән татар тормышына яраклаштыру да бар.

«Әбугалисина кыйссасы» (1872) – К.Насыйриның иң күренекле һәм киң таралган әсәрләреннән берсе. Ул Октябрьгә кадәр дә, аннан соң да күп мәртәбәләр дөнья күргән. Аның Гасыйм Лотфи тарафыннан кыскартылган, гадиләштерелгән басмалары да бар.

Әбугалисина (980-1037) – дөньяга Ибне Сина, Авиценна исемнәре белән мәшһүр. Ул – Урта Азиядә яшәгән һәм иҗат иткән атаклы галим, философ, әдип. Аның тыйб (дәва) китабы Европа югары уку йортларында озак гасырлар буена медицинадан дәреслек рәвешендә кулланылып килә. Ибне Синаның фарсыча язылган шигырьләре дә шактый. Бу автор һәм аның гыйльми, әдәби әсәрләре татар укучыларына да күптәннән таныш.

Энциклопедист галим, бөек шәхес буларак, Әбугалисина хакында Шәрык дөньясында төрле легенда-риваятьләр киң таралыш таба. Шуларга нигезләнеп, аерым авторлар әдәби әсәрләр иҗат итәләр. Зыяддин Сәед Яхъя дигән төрек язучысының Әбугалисина турындагы “Кәнҗинәи хикмәт” (“Хикмәт хәзинәсе”) исемле китабы 1865 елда Казанда нәшер ителә. Каюм Насыйри бу әсәрне 1872 елда төрекчәдән “халык аңларлык итеп урыс мәмләкәтендәге мөселманнар теленә”, ягъни татарчага тәрҗемә итә.

Хыялый повесть жанрын хәтерләткән “Әбугалисина кыйссасы” мавыктыргыч вакыйгаларга, гыйбрәтле хәлләргә гаять бай. Анда кызыклы сурәтләр, тасвир чаралары бик күп.

Төп каһарман үзенең белем-һөнәре, сәләте белән кешеләргә, әхлаклылыкны үстерүгә хезмәт итә. К. Насыйриның шушындый эчтәлекле әсәрне татар теленә күчерүе халкыбызның мәдәни үсешенә, гуманистик тәрбиясенә зур йогынты ясый. Бу әсәр рус теленә дә тәрҗемә ителә.

1896 елда Каюм бабаның “Әфсанәи Гөлрөх вә Камәрҗан” романы басылып чыга. Әсәрнең үзәгендә — патша кызы һәм шаһзадә, аларның мәхәббәте. Гөлрөх белән Камәрҗан — икесе дә искиткеч гүзәлләр, әмма әүвәл берсе ир-атларны, икенчесе хатын-кызларны яратмый. Бервакыт ике пәри, үзара бәхәсләшеп, кыз белән егетне янәшә куеп карыйлар һәм матурлыкта аларның икесенең да тиң икәнлеген күрәләр. Төнлә бер-берсен күреп кенә калган егет белән кыз арасында мәхәббәт газаплары башлана. Ниһаять, егет сөйгәнен эзләп таба. Кавышу. Туй. Әмма янә аерылу, сәфәр маҗаралары, мәхәббәт газаплары. Әсәр бәхетле бетем белән төгәлләнә.

Бу маҗаралы роман — XVIII йөздә яшәгән төрек әдибе Гали Газизнең «Хыяллар» исемле әсәреннән тәрҗемә. Ул аны «Мең дә бер кичә»дәге Камәрҗан циклына нигезләнеп язган була.

К. Насыйриның “Кырык вәзир кыйссасы” (1868) да генетик яктан “1001” кичә җыентыгына барып тоташа.

Хатыны үлгәч, патша бер кызга өйләнә. Яшь хатынның үги улына күзе төшә. Әмма шаһзадә ярамаган эш-гамәлдән баш тарта. Шунда үги ана, егетне гаепләп, ирен улына каршы котырта. Патша шаһзадәне үлемгә хөкем итә. Әмма вәзирләр, егетне яклап, төрле хикәятләр сөйлиләр. 40 көннән соң шаһзадә хәлнең асылын әтисенә һәм вәзирләргә сөйләп бирә. Гаделлек тантана итә. “40 вәзир кыйссасы” шулай ук шактый мавыктыргыч һәм киеренке әсәр. Андагы сюжетлар (кыйссалар) чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия.

К. Насыйри әдәби тәрҗемәләрен аерым китап рәвешендә генә чыгарып калмый, төрле дәреслек-хрестоматияләрендә дә урнаштыра. “Тәрбия китабы”нда, “Фәвакиһел җөләса...” һәм “40 бакча” җыентыкларында андыйлар аеруча күп. К. Насыйри аеруча фарсы әдибе Сәгъди (XIII йөз) әсәрләренә еш мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, “Тәрбия китабы”ндагы күп кенә гыйбрәтле хикәятләр Сәгъдинең “Гөлестан” җыентыгыннан алынган. Алар-дагы кыска, мәгънәле сюжетлар аркылы кеше табигатенең һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең күп төрле хосусиятләре гәүдәләндерелә, алар ярдәмендә укучыларга әхлакый сабаклар бирелә. Ул хикәятләр кешегә үз-үзен һәм башкаларны ныграк аңларга ярдәм итә [Хәсәнова 2014:41].

К.Насыйриның тәрҗемә китаплары арасында “Кабуснамә” мөһим урынны били. Бу ядкяр 1082 елда фарсы телендә иҗат ителә. Аны Кейкавус дигән күренекле кеше улына үтет-нәсыйхәт рәвешендә яза. Китап тиз арада Шәрык дөньясының үзенә күрә бер дәреслегенә әверелә. Күп телләргә, шул исәптән

төрек теленә дә тәрҗемә ителә. Каюм Насыйри басмасы төрек текстына нигезләнеп эшләнгән.

“Кабуснамә”дә үгет-нәсыйхәтләр тормыш һәм яшәеш турында белем-мәгълүматлар, кызыклы сюжетлар, мавыктыргыч мисаллар белән үреп бирелә. Шуңа күрә дә бу китап халык арасында яратып укыла һәм тыңлана. Шунысы мөһим: Каюм Насыйриның “Кабуснамә” әсәре О. Лебедева (“Гөлнар ханым”) тарафыннан русчага да тәрҗемә итеп бастырыла.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М. Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 384 б.

2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр (2 басмасы). – Казан: Тат. книгоиздат. Матур әдәбият редакциясе, 2016. – 408 б.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮДӘ ПЕДАГОГИК МИРАСЫ

**Фазлиева З.Р.**
Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты
Фәнни җитәкче: Гыйләҗева А.Ф.

Татар халкы мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган шундый шәхесләрнең берсе – XIX гасырның танылган татар галиме–мәгърифәтчесе һәм язучысы Каюм Насыйри. 2025 нче елда күренекле галимнең тууына 200 ел билгеләнеп үтә. Шул уңайдан, республикабызда төрле чаралар үткәрелү каралган.

К. Насыйриның эшчәнлеге күпкырлы һәм нәтиҗәле була: ул татар әдәбияты өлкәсендә бик күп әсәрләр иҗат итә, аны пропагандалаучы һәм тәрҗемәче була, фольклорны актив җыя һәм өйрәнә, дәреслекләр яза, укытучылык эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Ул Шәрык әдәбиятыннан күп кенә гыйбрәтле хикәяләрне үзләштергән һәм эшкәрткән.

Каюм Насыйри үз чоры татарлары арасында иң югары белем дәрәҗәсенә күтәрелә һәм беренче галим–энциклопедист була. Ул рус телен мөстәкыйль өйрәнүгә зур игътибар бирә, шуның белән бөтен рус теленә каршы булган мөселман дин белгечләре тарафыннан тәнкыйть ута. Шуңа күрә ул үзенең укытучылык эшчәнлеген дини училищеда, аннары дини семинариядә татар теле укытучысы буларак башлый һәм 15 ел гомерен рус егетләрен татар теленә өйрәтүгә багышлый.

Укытучылык эшчәнлеге белән бер үк вакытта Каюм Насыйри Казан университетында ирекле тыңлаучы сыйфатында белем ала, анда «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» эшендә актив катнаша, 1885 елда аны аның тулы хокуклы әгъзасы итеп сайлыйлар. Казан университетында укыган елларында ул шул чорның күренекле галимнәре – тарихчылар Н.Г. Фирсов, М.М. Хомяков, шәрыкны өйрәнүчеләр Н.Ф. Катанов, Коръәнне гарәп теленнән рус теленә беренче тәрҗемәче Г.С. Саблуков белән якыная һәм хезмәттәшлек

итә. К. Насыйри 1871 елда Татар мәгарифе тарихында татар балаларына рус телен өйрәтүне оештыручы беренче кеше була [Насыйри 2003: 7].

Каюм Насыйри тәрбия эшендә табигый сәләтләрнең әһәмиятен таный һәм болай дип яза: “тәрбия табигый сәләтләре булганда кешегә йогынты ясарга мөмкин. Табигатендә сәләте булмаган кеше тутыккан тимер кебек, күпме генә уйсулык та ялтырамас”. Өстәвенә, бернәрсәгә дә сәләтсез кешеләр юк, һәм белем бирүне оста кую һәм үз сүзендә нык тору шартларында һәр нормаль кеше үзенең сәләтен һәм рухи көчен үстерә ала. Моннан тыш, тәрбия эшен оста кую һәм үзсүзлелек кешегә үз табигатенең йомшак сыйфатларын җиңәргә һәм “үз сәләтләре белән балкып тормаган һәм акылга сыймаслык булып күренгән балаларга да ачылырга” ярдәм итә ала. Шул ук вакытта тиешле тәрбия һәм өйрәтү булмаганда кешенең сәләте һәм сәләте сүнергә мөмкин [Насыйри 2003: 16].

Аның “Тәрбия китабы” нда сәләтлелек турындагы гыйбрәтле хикәя бар: «бер падишаһ улын остазга тапшырган да: “Әй, укытучы, бу баланы үз улың кебек тәрбиялә, аңа яхшы белем бир”, – дип әйткән. Остаз башка малайлар белән бергә патшабикә улын да бик тырышып укытырга керешә. Әмма патша улы гади халык улларыннан да начаррак укый. Падишаһ моның белән остазны шелтәли. Әмма тегесе: “И падишаһ, уку бер үк, сәләтләр дә төрле”, – дип җавап бирә. Шуны истә тот, углым: каралар балалары кайчак бай балаларыннан да җитезрәк һәм юанрак булалар. Менә ни өчен бай балаларын укыту күбрәк тырышлык таләп итә, чөнки алар артык иркә булалар” [Насыйри 2005: 13].

Каюм Насыйри кешенең, аның рухи дөньясының, физик һәм әхлакый сыйфатларының формалашуында чыгыш, социаль сыйфатлар түгел, ә белем һәм тәрбия хәлиткеч роль уйный дип саный.

Каюм Насыйри иске кануннарга һәм традицияләргә тугрылык саклаганда, яңаны кабул итә алырлык киң белемле кешеләрне формалаштыру мөмкин түгеллеген аңлый. Үсеп килүче буынны тәрбияләүнең кимчелекләрен тәнкыйтьләп, К.Насыйри болай дип яза: “Безнең балалар, кызганычка каршы, чын мәгърифәттән мәхрүм һәм хайваннардан сөйләмгә ия булулары белән генә аерылалар. Ата–аналары аларны ничек һәм ничек тәрбияләргә икәнен белмәгән һәм бу игелекле миссияне мәгърифәтле педагогка тапшыру мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән бик күп балаларыбыз бар. Балалар, кагыйдә буларак, хәлфә карамагына эләгә. Хәлфә кайчакта үз дәрәҗәсе буенча укучыларыннан түбәнрәк була, аларны ничек һәм нәрсәгә өйрәтергә дә белми... Нәтиҗәдә, алар акылны баетучы һәм акыл сәләтләрен үстерүгә ярдәм итүче фәннәр турында күзаллауларга ия түгел. Алар шулай ук кирәкле әхлакый чыныктыруны да алмыйлар, кеше тулай торагы нигезләрен начар беләләр һәм аралашу кагыйдәләрен белмиләр” [Насыйри 2003: 12].

Тәрбия һәм белем бирү проблемасына аның “Китабет–тәрбия” (тәрбия китабы), “Балаларга тәһлим бирмәк” (балаларга белем бирү), “Әхлак рисаләсе” (этика буенча трактат) кебек ике мөстәкыйль чыгарылышында, “Тәрбия” (тәрбия), “Мөгайнетдин”, “Бала тәрбия кылучы хатыннар” кебек әсәрләре

багышланган. “Нәсихәт” (балаларны тәрбияләүче аналарга киңәшләр) һ. б. Аларда К. Насыйри татар мәктәпләрендә һәм мәдрәсәләрендә белем бирүнең урта гасырлардагы схоластик системасын каты тәнкыйтьли, аларда тормыштан аерылуны күрсәтә.

Шул ук вакытта ул, шул чордагы рус педагогик фикеренең казанышларына таянып, тәрбиянең фәнни нигезләрен нигезли, аның эчтәлеген ача, укытуның алымнары һәм методикасы белән таныштыра. Каюм Насыйриның педагогик карашлары К.Д. Ушинский һәм Л.Х. Толстой йогынтысы астында үсә. Мөгаллим фикеренчә, һәр бала туган телен белергә һәм өйрәнергә, туган мәдәнияттә яшәргә, өлкән буын традицияләрен сакларга, туган йортын, зур һәм кече ватанын яратырга, күршеләрен хөрмәт итәргә, аларның телен өйрәнергә, мәдәнияте һәм дине белән танышырга, шулай ук, ниһаять, заманча фәннең югары ноктасына омтылырга тиеш [Насыйри 2003: 18].

Аның педагогик методлары һәм идеяләре арасында ул чор өчен иң мөһим һәм актуальләрен ачыкларга мөмкин.:

1) укучылар уку процессында реаль дөнья әйберләрен танып белсеннәр өчен, укытуны материалистик нигездә төзергә;

2) фәнни белемнәр укучылар тарафыннан эзлекле һәм катгый системада үзләштерелергә тиеш. Теләсә кайсы фәндә белем һәм күнекмә алдагы фәннән килеп чыга һәм үзләре дә алдагы фәнгә нигез булып хезмәт итә алалар;

3) фәнни положениеләрне үзләштерү аңлы булырга тиеш. Укыту формаль булырга тиеш түгел. Укучыларда үзешчәнлекне, кызыксынучанлыкны, дәрестә активлыкны үстерә торган, дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә торган методик алымнарны камилләштерергә һәм төрлеләндерергә кирәк;

4) укыту нигезендә күрсәтмәлелек ятарга тиеш;

5) укыту вакытында төрле педагогик һәм методик алымнар укучыларның көчен һәм яшен исәпкә алып кулланылырга тиеш.

К. Насыйри кешенең физик һәм рухи йөзен формалаштыруга кагылышлы проблемаларның киң колачын күтәрә. Кешенең нормаль физик үсешен тәэмин итү аның күзаллавында тәрбия бирүнең мөһим бурычларыннан берсе булып тора, бу үз чиратында әхлакый һәм акыл үсешенең нигезе булып тора. Өстәвенә, аның кирәкле компонентлары булып туклану, йокы (икесе дә акыллы норма чикләрендә), саф һава, чиста су, физик күнегүләр, гигиена һәм сәламәтлек саклау кагыйдәләрен үтәү тора.

Каюм Насыйриның сәләтле балаларны тәрбияләү эшендә үгет–нәсихәтләре, беренче чиратта, ата–аналар өчен бик файдалы. Ул кешегә хезмәт күнекмәләрен һәм һөнәрләргә өйрәтүне тәрбиянең мөһим өлеше дип саный.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М. Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2005. – 384 б.

2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр (2 басмасы). – Казан: Тат книгоиздат. Матур әдәбият редакциясе, 2016. – 408 б.

3. Ханзафаров Н.Г., Гайнуллин М.Х., Гайнетдинов М.В., Әхмәтов Р.Ә. Каюм Насыйри. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда Н.Г.Ханзафаров.М.Х.Гайнуллин, М.В.Гайнетдинов, Р.Ә.Әхмәтов. – Казан, 1985. – Б.258–274.

## КАЮМ НАСЫЙРИ – КҮПКЫРЛЫ ШӘХЕС

**Фархуллина Р.Р.**
Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты.
Фәнни җитәкче: Шаһиева Д.Г.

Татар әдәбияты дәресләрендә без Каюм Насыйрины 1825 нче елның 14 нче февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында мулла гаиләсендә тууын һәм аның бабасы Хөсәен дә, этисе дә үз дәверендә шактый танылган укымышлы кешеләр булалар дип өйрәнеп үтәбез. Алар гарәп, фарсы, рус телләрен белгәннәр, китап күчерүгә оста булганнар һәм төрле темаларга үзләре дә әсәрләр язганнар.

Башлангыч белемне Каюм этисеннән ала. 1841 нче елда аны Казандагы бер мәдрәсәгә бирәләр. Бу мәдрәсәдә ул унбиш ел укый. Гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Күп нәрсәне үзлегеннән үзләштерә.Төрек телендәге китаплар белән дә таныша. Аны Казандагы Духовное училищега татар теле укытырга чакыралар. К.Насыйриның мөгаллимлек хезмәте шунда башлана. Ул һәрвакыт белем алырга омтылып тора, шунлыктан куренекле галимнәрнең дә лекцияләрен тыңлый.

К.Насыйриның тормышы да бик авыр була. Ул кечкенә генә бер бүлмәдә яши. 1873 нче елда Казан мәдрәсәләрендә рус теле укытыла башлагач, К.Насыйри да бер мәдрәсәгә мөгаллим итеп билгеләнә. Әмма мәктәпләр инспекторы белән икесе арасында чыккан каршылык нәтиҗәсендә, 1876 нчы елда К.Насыйри бу хезмәтеннән туктый.

Яз, җәй айларында ул үзенең туган авылы Югары Шырданга еш кайта торган була. Кыр эшләрендә катнаша, гади халык белән якыннан аралаша. Гел эзләнүдә, өйрәнүдә булганлыктан, Зөя ягындагы авылларга да чыгып, борынгы кабер ташларын укый, картлардан авыл тарихларын, тарихи истәлекләрне язып ала, халыкның җанлы сөйләм телен, гореф–гадәтләрен, йолаларын өйрәнә, җырлар, бәетләр, әкиятләр, риваятләр җыя.

К.Насыйри бөтен гомерен бары фән һәм язучылык эшенә багышлый. Зуррак күләмле әсәрләре шушы чорга туры килә. Ш.Мәрҗани, Г.Ильяси кебек укымышлылар белән бергә докладлар ясый. Галимнәр аның хезмәтләрен югары бәялиләр. Язу–сызу, акыл хезмәте белән бергә, К.Насыйри физик эш белән дә шөгыльләнгән. “Һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеша, мин, һәр көн бер–ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле әйберләрне ясыйм”, – дип әйтә торган була. Аның бүлмәсендә кыру станогы һәм төрле кирәк–яраклар тора. Дәреслекләренә карталар сызу, басылган китапларын төпләү, рәсемнәр төшерү эшләрен дә үзе башкара. Ул бигрәк тә агачтан төрле әйберләр ясарга

яраткан. К.Насыйри халык медицинасыннан файдаланган, төрле үләннәр белән дәваланган, физик хезмәт белән дә шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, бөтенләй диярлек ятып авырмаган. Бары тик гомеренең соңгы елларында гына аякларын паралич суга, һәм ул үзен үзе электр белән дәвалый, гел хәрәкәттә булырга тырыша. Нәтиҗәдә, аяклары яңадан язылып, йөрерлек хәлгә килә. Хәзерге көндә дә халык медицинасын кулланып дәвалануны отышлы дип әйтә алабыз. Төрле үләннәрне җыеп киптереп, төрле төнәтмәләр ясап эчү уңай нәтиҗәләргә китерә.

Каюм Насыйрийның гыйльми–мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарында яшь буынга төрле уку китаплары һәм дәреслекләр язудан башлана. Аның иң беренче хезмәте – “Кыскача татар нәхүе”, ягъни татар теле синтаксисы. Бу китап 1860 нчы елда һәм шул ук елны аның “Буш вакыт” исемле китабы да басылып чыга. Бу хезмәтендә автор балаларны һәм дөньяви фәннәрдән башлангыч белем алучыларны анатомия, табигать белемнәреннән кыскача мәгълүматлар белән таныштыра.1868 нче елда әлеге китапның тулыландырылган икенче басмасы чыга. Бу хезмәтнең беренче бүлеге кешенең анатомиясенә багышланган. Автор кайбер ышану–ырымнарның нигезсез булуын да төшендерә. Мәсәлән, кан йөреше, йөрәк тибеш турында аңлатып килә дә албасты басты дип сөйләүләрнең юк–барга ышану икәнлеген искәртә. Китапның калган бүлекләрендә Җир һәм аның әйләнүе, һава, кыш, яз, җәй һәм көз, җылылык үлчәве, яңгыр, кырау кебек табигать күренешләре, төрле металлар турында кызыклы мәгълуматлар тупланган [Миңнегулов, 2011: 295].

Галимнең күпкырлы мәгърифәтчелек эшчәнлеге, тел өлкәсендә башкарган эшләре – аның гомере буена дәвам иткән иң зур хәзинәләреннән санала.Татар телен гамәлгә кертүдә, К.Насыйри эшчәнлегенең бер тармагы телнең үзен өйрәнү, кагыйдәләрен аңлату, сүзлекләр төзү була. 1892 нче елда аның “Кавагыйде китабәт” дигән кулланмасы басылып чыга. “Әнмүзәҗ” исемле хезмәте белән К.Насыйри татар теленең фәнни грамматикасына нигез сала.Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген төзеп бастыра. Каюм Насыйри шулай ук төрле фәннәрдән дәреслекләрне татар телендә язу, терминнарны татарча эшләү, орфографияне яңарту белән шөгыльләнә. Математика фәне буенча ул “Хисаплык”, “Гыйльме һәндәсә”дәреслекләрен бастыра. Географиягә караган “Истыйляхате җәгърафия”,”Җәгърафияи кәбир” китаплары чыга. Әлеге хезмәтләре җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә.

Каюм Насыйриның иҗатында миңа иң ошаганы һәм истә калганы “Әбүгалисина” повесте. “Әбүгалисина” – фантастик повесть, анда төрле могҗизалы хәлләр тасвирлана. Әсәрдән аңлашылганча, гадәттән тыш хәлләрнең чыганагы– Әбүгалисинаның белем көче.Ул гаҗәеп могҗизалар тудыра ала икән. Әсәрнең үзәгендә дә зур галим кеше алынган. Автор белем алуның ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген Әбүгалисина һәм Әбелхарис образлары аша җиткерә. Әбугалисина – кешелекле, ярдәмчел, гади халыкка гел ярдәм итеп тора. Повесть укучысында аң–белемгә, һөнәргә омтылыш тәрбияли. Әбүгалисина – чынлыкта булган реаль шәхес, Көнчыгышта киң танылган

галим. Аның медицина өлкәсендәге китаплары күп гасырлар буена Европада дәреслек буларак файдаланыла. К.Насыйри аны хыялый нигезгә күчерә. Акыл көче, гыйлем куәтен раслау авторның мәгърифәтчелек карашларына туры килә.

Бүгенге көндә безгә белем алу өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Әбүгалисина кебек бернинда мәгарә эчләренә дә кереп утырырга кирәкми. Бары тик үзебезнең тырышлык кына кирәк. Әлегә К.Насыйри кебек дәреслекләр язмасак та, бәлки, киләчәктә без дә үзебезнең нииндидер күренекле эшләребезне халыкка җиткерә алырбыз. Күргәнебезчә, К.Насыйри кайсы гына өлкәгә тотынмасын, ул барысын да нәтиҗәле өйрәнеп, безнең буынга тапшыра алган. Күренекле галим, укытучы педагог һәм әдип К.Насыйрины татар мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм әдәбияты үсешендә зур роль уйнаган шәхес дип әйтә алабыз.

**Әдәбият**


1. Миңнегулов Х.Й. Әдәбият (Борынгы һәм  Урта гасыр, XIX йөз татар әдәбияты): татар телендә төп гомуми белем бирү мәкт. Һәм гимназияләрнең 9 нчы с–фы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен д–лек /Х.Й.Миңнегулов, Ш.Ә.Садретдинов. –Төзәтелгән 4 нче басма. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2011. – 407 б.

2. Хатипов Ф.М. Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәкт.7нче с–фы өчен дәреслек–хрестоматия /Ф.М.Хатипов Ф.Г.Галимуллин. –Үзгәртелгән 4 нче басма. Казан  Мәгариф, 2006. – 287 б.


## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ МАТЕМАТИК ХЕЗМӘТЛӘРЕ


**Фәсхетдинов И.Р.**

Арча районы Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкчеләр: Салахова И.Г., Шиһапова Г.Х.


Татар халкының атаклы галиме, этнографы, педагог һәм язучысы Каюм Насыйриның тууына быел 200 ел тула. Ярты гасыр буенча түземле һәм нәтиҗәле иҗат итеп, тел, әдәбият, фольклор, педагогика, математика һәм башка бик күп төрле фәннәр (география,табигать һ.б.) буенча кырыктан артык әсәр биргән бу язучы чын мәгънәсе белән мәгърифәтче була.

Каюм Насыйри үз вакытында халыкка күпьяклы белем бирергә тырыша, дәреслекләр, методик ярдәмлекләр төзи. Аның күп кенә фикер–киңәшләре әле бүген дә актуальлеген югалтмый. К. Насыйриның математика турындагы кулъязмалары – моңа бик ачык дәлил. Нәкъ менә аның хезмәтләре арасында математика фәне үсешенә багышланганнары да шактый.

Математика фәненең нигезләре белән татар халкын үз ана телендә, беренче буларак, таныштыручы К Насыйри була. Ул “Хисаплык”(1873 ел), ”Гыйльме һәндәсә”(1895 ел) дәреслекләре язып чыга. Галим фән хакында мәгълүмат биргәндә, аны ничек тормышта файдалану якларын өйрәтүгә дә нык игътибар итә. К. Насыйри, дәреслекләр язганда, математика терминнарының

балаларга аңлаешлы булуына омтыла. Ул арифметика дүрт гамәлгә бәйләнешле барлык төшенчәләрне татарча исемләп чыга: җыясы сан, киметәсе сан, калдык яки аерма,  тапкырлау, сугылмыш сан, суккыч, чыгыш, бүленәсе, бүлгеч, өлеш һ.б.

Олуг шәхес  дәреслек язганда, беренче нәүбәттә балаларны күздә тота, балалар өчен яза. Хәтта “Хисаплык” дәреслегендә дә мәсьәләләрне шулай күңелле итеп төзи ки, балалар ирексездән ул мәсьәләне кызыксынып укырга тиешле булалар һәм аларны ашкынып чишәргә омтылалар. Катлаулы гына математика формалары образларда җанландырып күз алдына бастырыла һәм шуның белән фәнни теләкләр балаларга җиңел барып җитә дә. Шуннан берничә мисал :

«Бер җиде яшәр бала атасыннан сорады: әткәй,син ничә яшьтә? диде. Атасы әйтте : әй күземнең нуры углым, үзең яшең янына егерме тугызны кушсаң, мин ничә яшьтә икәнен белерсең,диде.Атасы ничә яшьтә булырга кирәк? (36 яшь)».

«Берәү үзенең кечкенә углына әйтте,әй җаным угыл,ишет,мин синнән бер сүз сорыйм,уйлап җавап бир : бер елда 365 көн (көн дигәне монда тәүлектән гыйбарәт),бер көндә 24 сәгать, бер сәгатьтә 60 дәкыйка , бер елда ничә дәкыйка була ? диде».(«Хисаплык», 1873, 83–84 нче битләр).

Үз заманының алдынгы галимнәре К.Насыйриның  дәреслекләренә карата хаклы бәяләрен бирә барганнар. ”Хисаплык”ның икенче басмасы басылып чыккач, Н.Ф.Катанов болай дип яза:

“Бу татарча китап, атаклы Казан галиме Габделкаюм Насыйри тарафыннан яхшы, гомумән, аңлаешлы телдә төзелеп, II басма буларак, 1200 данә чыгарылды. 1873 нче елгы беренче басмасыннан шактый күп артык басылып чыкты. Яшь татар балаларының аңын үстерү өчен бирелгән мәсьәләләр арасында гомумгә мәгълүм булган шушындый русчадан алынган мәсьәләләр бар: “Бүре кәҗә һәм кәбестә”, “Бер каз һәм казлар өере”, шулай ук “Берсе–берсеннән бер данә сарык сораган ике көтүче хакында”. Терминнар барысы да бик уңышлы сайланып, моңа кадәр булган дәреслекләрдәге аңлашылмый торган борынгы гарәпчә урынына, төп татарча сүзләрдән төзелгәннәр.Гомумән, Насыйриның дәреслеге татар педагогикасында игътибар ителергә тиешле гаять файдалы яңалык булып тора”, – ди.

1895 елда Казан Император университеты типографиясендә К.Насыйриның “Гыйльме һәндәсә” (“Геометрия дәреслеге”) дигән китабы дөнья күрә. Мәгърифәтче әлеге китабында да гарәпчә һәм татарча терминнарны янәшә куллана: “хатты мөстакыйм – туры сызык мәгънәсендәдер”, “хатты мөстәдир – түгәрәк сызык димәкдер”; “завия яки почмак дип әйтәләр”, “мәсәлләс – һәндәсә истилахында өчпочмак димәкдер” һ.б.

Мәгърифәтче үзе язган математика дәреслекләрендә үлчәү эшләрендә кулланыла торган түбәндәге терминнардан файдалана: сатых (өслек), сатхи мөстәви (тигез өслек), сатхи мөнхәни (тигезсез өслек), хатты (сызык), хатты мөстәкыйль (туры сызык), хатты офыкый (горизонталь сызык), хатты гомуди

(вертикаль сызык), хатты мөтавази (параллель сызык), хатты мәфруз (уйланма сызык), мәркәзи хатты (сызык уртасы), мөсафә (билгесез ераклык), тул (озынлык), мәсәлләс (өчпочмак), мәсәлләс каимеззавия (турыпочмаклы өчпочмак), мәсәлләс мөтәсавиеззавия (тигезьяклы өчпочмак), завия (почмак), рәэсзавия (түбә, оч), кабырга (як), завияи каимә (туры почмак), гомуми (перпендикуляр), мөсәви (тигез), мөнәсбәт (чагыштырма), сан (охшашлык), вәтәд (казык), мөсаһә зәнҗиры (үлчәү чылбыры), согмар гуниясы (эккер), сажин, сурәт (рәсем).

Практик әһәмияте ягыннан әлеге китапның соңгы – урынның планын алуга багышланган бүлеге бүгенге укучыга да шактый кызыклы.

Дәреслек башында ике әйбер арасындагы ераклыкны үлчәү өчен кулланыла торган җир үлчәгеч кораллар бәян ителә, аерым алганда, өч аршынга тигез булган сажин, карышларга (искечә 4,4 см чамасындагы озынлык үлчәве) бүленгән җир чылбыры (мөсаһә зәнҗиры), тимер очлы казык (вәтәд), вертикаль юнәлешлелекне ачыклау өчен асма, туры почмаклар төзү өчен конуссыман очлы, бер–берсенә аркылы куеп ныгытылган әвернә һ.б.

Дәреслектә геометрик мәгълүматларның көнкүрештә, көндәлек тормышта кайларда кулланылуы шактый тулы күрсәтелә. Мәчет манаралары, биналар, агачлар һәм тауларның биеклеген, елга һәм күлләрнең киңлеген, шулай ук ике предмет арасындагы ераклыкны табу кагыйдәләре бирелә.

Мәсәлән, елганың киңлеген үлчәү өчен, К.Насыйри түбәндәге ысулны тәкъдим итә: "... мәсәлән, бер кечерәк елганың киңлеген үлчәмәк булыйк. В ноктасында туктап, елганың аргы ягында бер агачны (А) билгеләп, елга аркылы шул агачка туры сызык фараз кыйлдык һәм бу урынымызга билге өчен бер казык кагып куйдык. Аннан соң елга буйлап түбән таба 25 сажинлап җирне барып, Е ноктасына туктадык. Баягы агачка таба янә бер туры сызык фараз кыйлдык. Бу торган җиребезгә янә бер казык кактык. Анан соң В дан Е га чаклы үлчәдек – 25 сажин булды. 25 нең биштән бере биш сажиндыр. Е ноктасыннан С ноктасына туры сызык тартып, анда бер казык утырттык. Янә елганың аргы ягындагы агачтан килә дип уйланылган сызыкны Е ноктасы аша уздырып, ниһаять, К ноктасына бер казык кактык. Аннан К казыгыннан С казыгына бер туры тартып үлчәдек, ике сажин ярым булды. Аны бишкә тапкырладык – унике ярым хасил булды. Бәс, елганың киңлеге унике ярымдыр".

Геометрия дәреслегендә галим шулай ук манара биеклеген, күлнең киңлеген үлчәү юлларын да тәкъдим итә.

Каюм Насыйри китапларын күздән кичергәч, аны берүзе берничә фәнне укыткан «олуг мөгаллим, милләт педагогы» дип атарга мөмкин булыр иде. Аның укучылары – бөтен татар дөньясы. Каюм Насыйри әйтерсең гомер буе тырышып сабак бирә, үз халкын белемле, тәрбияле итәргә омтыла.

**Әдәбият**

1. Беркутов В. Каюм Насыйри һәм математика – "Мәгариф" , 2008 ел, №7.

2. Геометрия . 7– 9 нчы сыйныфлар өчен дәреслек./ Л.С. Атанасян, В.Ф. Бутузов, С.Б. Кадомцев һ.б. – Казан: Мәгариф, 2010.–383 б.

3. Каюм Насыйри. 1825–1945 (тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)– Казан: Татгосиздат,1948.–202б.

4. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы. – Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2002.– 292 б.

.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ИҖАТЫ. МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Хәкимова Р.А.**

Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы

Фәнни җитәкче: Хайбрахманова А.А

Һәр халыкның бай тарихы, тарихында тирән эз калдырган, горурланып сөйләрлек күренекле шәхесләре була. Татар халкын мәгърифәтле итү өчен үзенең бөтен гомерен, белемен, сәләтен багышлаган кешеләр арасында Каюм Насыйри исеме зур урын алып тора. Ул татар мәгърифәтчеләре арасында иң күренеклесе.

Татар халкының күренекле галиме, мәгърифәтче, тарихчы, тел белгече, язучы, мөгаллим Габделкаюм Насыйри 1825 елның 14 февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе (хәзерге Яшел Үзән районы) Югары Шырдан авылында укымышлы Насыйр мулла гаиләсендә туган. Башлангыч белемне атасыннан алганнан соң, 1841 елда Габделкаюм Казанга мәдрәсәдә укырга килә һәм 15 ел дәвамында гарәп, фарсы телләрен өйрәнә, үзлегеннән рус телен үзләштерә.

XIX гасыр – зур үзгәрешләргә бай чор. Россиядә завод–фабрикалар төзелә, яңача укытыла торган мәктәпләр ачыла, галимнәр, язучылар үсеп чыга. Бу үзгәрешләр татарлар тормышына да йогынты ясый.Татарлар тормышында да җанлылык сизелз башлый: татарча китаплар бастыра башлыйлар, мәктәп–мәдрәсәләр күпләп ачыла.Татар халкы, үзенең яшәешен саклап калу өчен, көрәшә башлый

XIX гасырның икенче яртысында рус–татар мәктәпләренең күпләп ачыла башлавында Каюм Насыйриның да роле бик зур. 1855 елда Каюм Насыйри укытучылык эшенә керешә. Аны христиан руханилары әзерли торган Духовное училищега, ә аннары Духовная семинариягә укытырга чакыралар. Анда ул 1871 елга кадәр татар телен укыта, шул ук вакытта үзе дә рус телен яхшылап өйрәнә, соңыннан булачак галим Казан университетына ирекле тыңлаучы булып та керә. Габделкаюм Насыйри рус галимнәре белән еш аралаша, элемтәдә тора, аларга татар халкының милли мирасын барлауда һәм аның тарихи үткәне турында хезмәтләр әзерләүдә булыша. Казан университеты каршындагы «Археология, этнография һәм тарих җәмгыяте»нең татар милләте тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре буенча әгъзасы буларак, ул рус җәмәгатьчелеге алдында фәнни чыгышлар ясый. рус галимнәре белән аралашу Европа фәненә һәм мәдәниятенә якынаюга юл ача. 1879 елда мөгаллимлек эшчәнлеген туктата һәм

барлык гомерен тулаем фәнгә һәм язучылык эшенә багышлый. Каюм Насыйри белем алу һәм әхлакый тәрбия бирү мәсьәләләрен чагылдырган әсәрләр иҗат итә.”Әбугалисина”, “Кырык вәзир”,”Кырык бакча”, “Фәвакиһел җөләса фил–әдәбит” әсәрләре күпләргә таныш. К. Насыйри, нигездә, Урта гасыр Шәрык классикасының чәчмә әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Тәрҗемә вакытында ул оригиналны татарча төгәл дә күчерә, аерым кыскартулар да ясый, төп текстка теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр дә кертә; вакыйга–хәлләрне урыны белән татар тормышына яраклаштыру да бар.

«Әбугалисина кыйссасы» (1872) — К.Насыйриның иң күренекле һәм киң таралган әсәрләреннән берсе. Ул Октябрьгә кадәр дә, аннан соң да күп мәртәбәләр дөнья күргән. Аның Гасыйм Лотфи тарафыннан кыскартылган, гадиләштерелгән басмалары да бар. Әбугалисина (980—1037)—дөньяга Ибне Сина, Авиценна исемнәре белән мәшһүр. Ул — Урта Азиядә яшәгән һәм иҗат иткән атаклы галим, философ, әдип.

Мәгърифәтче галимнең иң күләмле хезмәтләренең берсе – «Фәвакиһелҗөләса фил–әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре») китабы. 1880 елда «Кырык бакча» исеме астында ул әлеге әсәрнең кыскартылган вариантын бастыра. Ә 1884 елда Казан университеты нәшриятында китап тулы килеш дөнья күрә. Кырык бүлектән торган бу зур әһәмияткә ия булган хезмәттә кеше тормышы һәм эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр яктыртыла, төрле киңәшләр бирелә.

Киңкырлы, энциклопедик белемле галим буларак, Каюм Насыйри татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдыра. Аның игътибарын фәнни проблемалар да, әхлакый, педагогик һәм әдәби–зәвык мәсьәләләре дә җәлеп итә. 1871 елда Казанда үз мәктәбен оештыра. Гуманитар фәннәрнең төрле тармаклары үсешенә зур өлеш кертә, хәзерге татар әдәби теленә, аның фәнни терминологиясенә нигез сала.

Әйтеп үтелгәнчә, К.Насыйриның әдәби һәм гыйльми мирасы шактый бай. Ул үзенең 40 еллык иҗади эшчәнлеге чорында барысы 37 исемдә әсәр иҗат итә, 24 календарь төзи. К. Насыйри туган халкын заманының алдынгы фәнни белемнәре белән таныштыру буенча да байтак эш башкара. 1860 елда аның «Буш вакыт» исеме белән табигать күренешләре турында гомуми мәгълүматлар туплаган җыентыгы басыла. Каюм Насыйриның иң зур эшчәнлеге тел өлкәсендә була.Ул 1895 елда татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген төзи. Телгә өйрәтүдә галимнең татарча–русча һәм русча–татарча сүзлекләре дә бар. 1889 елда К. Насыйри татарларны русча укырга–язарга өйрәтү өчен «Кавагыйд кыйраәт русия» («Русская азбука») дигән китап яза. 24 битле бу әлифба, 50 дәрескә бүлеп, рус һәм татар хәрефләрен, сүзләрен чагыштырып, җентекләп эшләнгән. Ул халкыбыз өчен бик тә кирәк булган төрле уку әсбаплары, дәреслекләр төзи. Аның тарафыннан татар теле, математика, геометрия һәм башка фәннәр буенча татар телендә дәреслекләр бастырыла. Дөрес уку һәм матур язу кагыйдәләрен күрсәткән кулланмалар да төзеп бастыра Ул математика буенча ике дәреслек авторы. Гарәп терминнары урынына татар

телендә терминнар кертә. Бу терминнар бүгенге көнгәчә мәктәп дәреслекләрендә кулланыла. Басылган китаплары 4 мең, календарьлары 1200 — барысы 5200 биткә җыела. К.Насыйри календарьлары (аларның уртача күләме— 40-70 бит) төрле характердагы материалларга гаять бай. Анда без, табигать турындагы белешмәләрдән тыш, фәнни мәгълүматлар, әдәби әсәрләр, тарихи хәбәрләр; тормыш яңалыклары һәм башкалар белән очрашабыз. Каюм Насыйриның чирек гасыр буена чыгарган календарьлары — билгеле бер дәрәҗәдә татар тормышының елъязмасы да ул.

К.Насыйриның тәрҗемә китаплары арасында «Кабуснамә» мөһим урынны били. Бу әсәр 1082 елда фарсы телендә иҗат ителә. Аны Кейкавус дигән күренекле кеше улына үтет–нәсыйхәт рәвешендә яза. Китап тиз арада Шәрык дөньясының үзенә күрә бер дәреслегенә әверелә. Күп телләргә, шул исәптән төрек теленә дә тәрҗемә ителә. Каюм Насыйри басмасы төрек текстына нигезләнеп эшләнгән. К.Насыйриның 1886 елда «Кабуснамә» исемле китабы русчага тәрҗемә ителә. «Кабуснамә»дә үгет–нәсыйхәтләр тормыш һәм яшәеш турында белем–мәгълүматлар, кызыклы сюжетлар, мавыктыргыч мисаллар белән үреп бирелә. Шуңа күрә дә бу китап халык арасында яратып укыла һәм тыңлана.

К.Насыйри үзенең яшәү дәверендә халык өчен шактый эшләр эшләп калдырырга өлгергән. Мәктәп ачкан, балалар укыткан, әдәби әсәрләр һәм фәнни хезмәтләр язган, тәрҗемә эше белән шөгыльләнгән, дәреслекләр төзегән. К.Насыйриның халык арасында алып барган мәгърифәтчелек һәм җәмәгатьчелек эшчәнлеге, әдәби мирасы, фәнни хезмәтләре ул яшәгән чорда ук югары бәяләнгән, өйрәнелгән. Үз заманында ук аны яхшы белгәннәр, К.Насыйриның хезмәтләре турында 1880–1913 еллар арасында рус матбугатында профессорлардан Григорьев, Смирнов, Соловьев, Готвальд һ.б. язган өч дистәгә якын мәкалә басылып чыга.

Шулай итеп, К.Насыйри татар мәгариф үсешенә үзенең зур өлешен керткән, туган халкына мәгърифәт нурларын чәчкән. Бай әдәби, гыйльми мирасы бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмаган.

**Әдәбият**

1. Антология педагогической мысли России второй половины XIX – начала XX в. / Сост. П.А. Лебедев. М.: Педагогика, 1990. 608 с.

2. Карурманны чыккан чакта…: XIX гасыр әдәбияты._Казан: Мәгариф, 2001.–319 б

3. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда: Т. 1. Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. 321 б.

# КАЮМ НАСЫЙРИ – УКЫТУЧЫ ҺӘМ ДӘРЕСЛЕКЛӘР АВТОРЫ

**Хөсәенов А**.С.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.к, доц. Хәйруллина Ә.С.

Каюм Насыйриның алдынгы педагогик фикерләре мәгърифәтчелек идеяләре җирлегендә башлана, үсә,формалаша. Аның беренче гамәли эше – укытучылык хезмәте – 1855 елда Насыйрины Духовное училище дип аталган рус мәктәбенә татар теле укытучысы итеп чакырудан башланып китә.Укытучылык эшен камилләштерү өчен соңрак шул ук училищеның дәвамы булган Духовная семинариядә, эшләвен дәвам итә. Семинария укытучылары белән аралашу аңа рус телен һәм башка фәннәрне киңрәк өйрәнергә булыша.

Семинариядәге китапханәнең бай булуы Насыйрига рус фәнни-педагогик әдәбият, төрле фәннәрдән дәреслекләр, рус һәм чит ил педагогларының хезмәтләре белән танышырга мөмкинлек бирә. Ул рус укытучыларының дәресләрендә була, укытуның класс-дәрес системасын үзләштерә, күрсәтмә әсбаплар әзерләргә һәм файдаланырга өйрәнә, укытуның актив формалары турында башка укытучылар белән әңгәмә кора, бәхәсләшә.Нәкъ шул елларда Насыйриның татар балаларына рус телен, рус балаларына татар телен укытуда бер телне икенче тел белән чагыштыру методикасы формалаша. Укыту методикасын практикага кертү һәм халкын мәгърифәтле итү өчен ул өзлексез эзләнә. Мәдрәсәдә биргән белем белән генә заман фәне югарылыгына күтәрелеп булмавын яхшы аңлый. Шунлыктан татар балаларына рус телен укыта торган мәктәп ачарга дигән фикергә килә. Ләкин аның омтылышы беренче адымнарыннан ук каршылыкка очрый. 1871 елда татар, кыргыз һәм башкорт мәктәпләре буенча инспектор В.В. Радлов Казанга килә. Каюм Насыйри аңардан татар балаларын русча укытырга мәктәп ачу өчен ризалык сорый. Каюм Насыйрины хезмәтләре буенча бик яхшы белгән В.В. Радлов бу эштә аңа зур булышлык күрсәтә; мәгариф министрлыгының ризалыгын алырга, аннары мәктәпне оештырырга ярдәм итә. Мәктәп шул ук елны ачыла. Каюм Насыйрига бу эшне башкару өчен күп көч куярга туры килә. Укыту бинасын табу, балаларны укуга тарту һ.б. Шул хакта ул үзе менә ничек яза: «Фатир табып булмый. Аена илле тәңкә бирсәң дә, балалар укытамын дигәч, фатир бирмәделәр. Ахры, нагыйлаж(чарасыз), Мокрый урамында, бер кабак өстендә фатир алып һәм капка өстенә игъланнар куеп, алты-җиде, бәлки, унлап бала җыелды. Бичара бу адәм дә чикте җафаны! Астында кабак, төн буе җырлыйлар, сугышалар, күрше бүлмәләрдә кайсы кәвешче, кайсы тегүче, кайсы скорняк. Ишек алдында уртадагы өйдә сыра заводы, ишек алды артындагы өйдә - ... яки кызлар ханәсе. Чыкса – урамы кабахәт, керсә – күршесе кабахәт. Халык сүзен ишетсә – яман сүз ишетә. Мең бәла белән ике айлар бу фатирда торды. Балалар укыта башлап, капка өстенә вывеска куйгач, частька барып әйткәннәр. Частьтан сотниклар килеп, сорашып йөрделәр...» [Насыйри, 2005 : 329].

Мондый шартларда эшләү өчен К. Насыйрига үз эшенә бирелгәнлек, балаларны ярату, бетмәс-төкәнмәс хезмәт дәрте генә ярдәм иткәндер. Ул үз сүзендә нык тора торган кеше булган. Инде 1876 елда ук Европа тибында парталар һәм күрсәтмә әсбаплар белән җиһазландырылган мәктәп оештыра ул. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә мәктәп материаль яктан елдан-ел ныгый, укытучының халык арасында авторитеты да үсә.

Зур азаплар күреп, мохтаҗлыкта яшәсә дә, Насыйри укытучылык иткәндә үз акчасын балаларга өс һәм аяк киеме алырга да тоткан. Укучы балаларның берсе, яз көне җир кипкәч, базарда сату эшенә керешкән. Аңа ияреп, башка балалар да укырга йөрми башлаганннар. Шуннан соң К. На-сыйри ул баланың базарда алган табыш акчасы кадәр акчаны көн дә үзеннән бирә барган. Шулай, төрле юллар белән ярдәм итеп, балалар укытуын дәвам иттерә.

Татар балаларына рус телен укыту методикасын практикага кертү өчен, К. Насыйрига уку дәреслекләре, күрсәтмә әсбаплар, күнегүләр җыентыгы, мәкальләр, дәреслекләргә кулланмалар әзерләүдә зур тырышлык күрсәтергә һәм кыенлыклар да кичерергә туры килә.

Зур түрәләр дә, аңа ярдәм итәсе урынга, комачау гына иткәннәр. Инспекторның мәктәпкә килүе турында Насыйри болай дип искә ала: «Инспектор мәктәпкә килгәч, балалардан имтихан ала башлады: «Бу нәрсә? Бу нәрсә?» Чиновникның йөзен бер генә тапкыр да күрмәгән, рус сөйләмен ишетмәгән, әле яңа гына рус әлифбасын өйрәнергә керешкән балалар дөрес җавап бирә алмадылар. Шул ук вакытта, инспектор балалар барында белешмәләр бирүне таләп итте: сәүдәгәр балалары ничә, мещан һәм крестьян балалары ничә? «Крестьян» сүзен ишетүгә, балалар куркып өйләренә таралдылар...» [Насыйри, 2005: 331]. Хикмәт шунда, балалар, безне чукындырырга җыеналар дип, куркып качалар.

Бу вакытта укыту процессын алып бару турында В. Радлов белән

К. Насыйри арасында фикер каршылыклары өлгереп җиткән була. Инспектор немец педагогикасын үрнәк итеп алган. К. Насыйри аның карашлары белән килешмәгән. Шуңа күрә, рус-татар мәктәбендә биш ел эшләгәннән соң, аңа бу эштән китергә туры килгән. Ләкин бу чорда да эшләгән эшләре аңарда зур канәгатьләнү хисе тудырган. Бу турыда ул: «Мин, мин дип мактану, эшең хак булса, урынына күрә ярый. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең эш башлавы...ушбу мөгаллимнәндер...», - дип язган үзе турында [Шунда ук : 324].

К. Насыйриның укытучылык хезмәте моның белән генә чикләнми. Ул тагын ике-өч ел Яңа бистәдә рус-татар мәктәбендә мөгаллимлек итә.

К. Насыйри укытучылар белән аралашкан, алар белән үзенең тәҗрибәсен, идеясен уртаклашкан, алдынгы педагогик методлар турында матбугатта мәкаләләр бастырып чыгарган, мәктәпләрдә, гимназияләрдә булган, аерым дәресләр дә биргән. Шуның белән бергә дәреслекләр, кулланмалар төзү эшенә дә алынган.

Аның басылып чыккан беренче дәреслеге – «Кыскача нәхү китабы». Бу китап, русча өйрәнүче башка халыкларны күздә тотып, рус телендә язылa һәм «Краткая татарская грамматика» исемендә 1860 елда басыла.

Каюм Насыйри тарафыннан татар телендә берничә дәреслек язылa. 1892 елда дөрес язу һәм орфография кагыйдәләрен үз эченә алган «Кавагыйде китабәт » («Кагыйдәләр китабы») басылып чыга. Бу хезмәтендә ул: «һәрбер культуралы кешенең ике төрле теле була: шуларның берсе – анасыннан сөт имгән вакытта өйрәнгән тел, икенчесе – укытучыдан укыганда гыйлем һәм фән терминнары белән ачылган тел...»,- дип яза [Насыйри, 2005 :299]. 1894 елда аның татар телендә «Иҗек һәм әлифба» китабы басыла. Балаларга аваз турында беренче мәгълүмат биргәндә сүзләр сайланышы белән бу әлифба беренче көннәрдә үк күп кенә укытучыларда кызыксыну уята. «Әнмүзәҗ» китабы 1895 елда нәшер ителә. Монда татар теленең фәнни грамматикасына нигез салына, аның фонетикасына һәм морфологик үзенчәлекләренә һәрьяклы анализ ясала.

Шул ук елны ул татар теленең аңлатмалы сүзлеге булган «Ләһҗәи татари» китабын төзи. Анда Каюм Насыйри сүзләрне русча-татарча һәм татарча-русча бирә, я башкача чаралар ярдәмендә күрсәтә. Атаклы тюрколог Н.Ф. Катанов «Ләһҗәи татари» турында язган мәкаләсендә: «Казан татар галиме мәшһүр К. Насыйри үзенең бу сүзлегендә гарәп, фарсы сүзләрен – татар теле белән, татар сүзләрен гарәпчә, фарсыча сүзләр белән аңлата. Урыны-урыны белән, сүзләрне халык теленнән алынган мисаллар ярдәмендә дә аңлата. Һәр сүзнең халык телендә нинди урында кулланауын күрсәтеп китә. Шуның өчен бу китапны рус теленә тәрҗемә итү бик кирәк. Чөнки Радлов, Будагов кебек галимнәрнең сүзлекләрендә мондый моментларга игътибар ителмәгән... Һәрхәлдә, тюркологлар өчен бу бик файдалы китап », - дип яза [Цит буенча: Насыйри, 1953: 23].

Бер үк вакытта К. Насыйри рус телен үзләштерү өчен дә китаплар төзи. «Кавагыйде кыйраәте рус» («Русча уку кагыйдәләре», 1889), «Зөбдәтен мим тәварихе рус» («Кыскача рус тарихы», 1890), «Нәмүнә яки әнмүзәҗ» («Гарәп теле үрнәгендә төзелгән рус теле грамматикасы», 1891), «Лөгате рус китабы» («Рус-татар сүзлеге», 1892) дигән дәреслекләр яза.Ул рус, татар грамматикаларында булган яңалыкларны, аерымлыкларны, үзенчәлекләрне өйрәнә һәм аларны укучыларына төшендерә бара.

Каюм Насыйри башлангыч сыйныфлар өчен дәреслек буларак «Буш вакыт»китабын яза. Бу китапның беренче бүлегендә кеше анатомиясе турында сөйләнә. Калган бүлекләрендә җир һәм аның әйләнүе, һава һәм һава шары, җылылык үлчәве, яңгыр, чык, кырау һәм болардан тыш бик күп табигать күренешләре турында гаять бай материаллар тупланган. Бу китап укыр өчен кызыклы итеп, аңлаешлы телдә язылган. Аны татар балалар әдәбиятын өйрәнүне нигезләү буенча башлангыч китапларның берсе итеп карыйлар.

Төрле фәннәрнең нигезләре белән татар халкын ана телендә беренче буларак таныштыручы да К. Насыйри була. Ул математика фәне буенча «Хисаплык», «Гыйльме һәндәсә» («Геометрия фәне») дәреслекләре язып чыга;

география фәннәре буенча «Истилахате җәгърафия» («География терминнары»), игенчелеккә карата «Гыйльме зирагать», ботаникадан «Гөлзәр һәм чәмәнзар, ягъни үләнлек һәм чәчәклек» исемнәрендәге китапларын бастырып чыгара. Ботаника турында язылган китабында үләннәр, чәчәкләргә атамалар биреп, татарча исемнәрен булдыруга да күп көч куя. «Сәнаигы гольфания» («Ювелирлык һәм слесарьлек эше») исемле китабында электрдан файдаланып металлны эшкәртү, никельләү юлларын өйрәтә.

Каюм Насыйри дәреслекләр, кулланмалар төзү эше белән шөгыльләнү нәтиҗәсендә гади укытучыдан күренекле галим-педагог дәрәҗәсенә күтәрелә.

**Әдәбият**


3. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. II томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1953. – Т.1. – 400б.

4. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. IV томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Т.3. – 384 б.

1.


## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ФӘННИ–ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ.


**Ягудина Р.Р.**

КФУның Алабуга институты студенты

Фәнни җитәкче: ф.ф.к, доц. Хәйруллина Ә.С.


Татар халкының иҗтимагый уяну тарихында К. Насыйри титаник хезмәтләре белән мактаулы урын ала. Ул бөтен гомерен халыкны агартуга, аның культурасын күтәрүгә багышлый. Әдәби, тарихи, педагогик хезмәтләре, татар халкының телен гыйльми калыпларга салуы, русча укытуга керешүе, кагылу-сүгелүләргә карамый, олы максатларына баруы К. Насыйрины фидакарь галим, энциклопедист-мәгърифәтче итеп таныта.

Ул татар теле, әдәбият, фольклор, этнография, тарих проблемалары буенча фәнни эшкәртмәләр булдыру өчен зур көч куйган. Шуңа күрә дә аны татар тел белеменә нигез салучы дип атаганнар. Бу эшкәртмәләре өчен аны 1855 елның 3 ноябрендә Казан университеты янындагы Археология, тарих һәм этнография Җәмгыятенең действительный члены итеп сайлаганнар. Шуның белән ул рәсми яктан да фән эшчесе булып саналган, гомеренең соңгы көннәренә кадәр бу Җәмгыятьнең әгъзасы буларак, бергәләп хезмәтләр бастырып чыгаруда катнашкан.

Каюм Насыйриның күп кенә хезмәтләрендә тарих өчен бай булган материаллар бирелә. Насыйри мифология һәм этнографиягә караган хезмәтләрендә ул вакытка кадәр тарихчылар тарафыннан тиешенчә кузгатылмаган, аз тикшерелгән материалларны табып, фән дөньясына тапшыруны үзенә бурыч итеп куя: «Безнең максудыбыз – рус историясендә булмаган эшләрне мәйданга чыгармактыр», - ди [Насыйри, 2005 : 215].

К. Насыйриның иң зур хезмәтләреннән берсе – аның тел өлкәсендәге эшчәнлеге. Бу өлкәдә ул бик катлаулы һәм күп яклы хезмәтләр башкара. Ул татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуңа хакы һәм сәләте барлыгын

исбат итә. Аның башка телләрдән артта торуын фәкать эшләнмәгәнлегеннән генә күрә. Аны практик һәм фәнни эшкәртү юлында гаять кыю һәм зур эшчәнлек күрсәтә. К. Насыйри тел гыйлеме һәм сүзләр төзү буенча шулкадәр катлаулы һәм кирәкле эшләрне башкара ки, бу өлкәдә ул кагылмаган, хезмәт күрсәтмәгән бер генә тармак та юк дисәк, ялгышмабыз.

К. Насыйри татар теленең байлыгын рус теле белән чагыштырып карый. Рус матур әдәбиятындагы сурәтләүләрне татарчага уңышлы тәрҗемә итә. Мәсәлән, рус һәм татар телләрендәге иркәләү һәм кечерәйтү сүзләрен чагыштыру өчен, ул И. А. Крыловның түбәндәге шигырь юлларын китерә:

Голубушка, как хороша!
Ну что за шейка, что за глазки!
Какие перышки! Какой носок!
И верно, ангельский быть должен голосок!

К. Насыйриның тәрҗемәсе:

Һай күгәрченгенәм, нинди һәйбәт!
Кара аның муенгынасын, кара аның күзгенәсен!
Ниндәен нәфис аның йонгынасы!
Ниндәен матур аның борынгынасы!
Дәхи фәрештә тавышы кебек микән аның тавышкынасы! [Насыйри, 2005 : 273].

К. Насыйри оригиналның эмоциональ бизәген саклап тәрҗемә итә, шунда ук түбәндәге аңлатуларны өсти: «Голубушка, глазки, перышки, носок, голосок дигән сүзләр мәдех мәкәмендә зикер ителгәндер. Бездә һәм бар: мәсәлән, күгәрченгенәм, абзыкай, дускай, җанкай, кашкынасы, күзгенәсе... нитәкки гавамның шигырьләрендә:

«Әгезү белән бисмила – һәр китапның баш кынасы,
Кара тузгак кебек ярылып ята-аласы ярның каш кынасы» –дигән халык җырын китерә [Шунда ук: 273]. Һәм шуның белән К. Насыйри тел байлыгының төп чыганагы халык аваз иҗатында булуын күрсәтеп үтә.

Ул хезмәтендә, этимология – белемнәрнең анасы, грамматика – атасы, ди. «Бу ике гыйлемне укып белмәктән гарыз шулдыр ки, сөйләшкәндә вә язганда телне хатадан сакламактыр ... Бу ике фәнне белмәстән күп фәннәр вә гыйлемнәр тугадыр», - ди [Насыйри, 2005 : 274].

К. Насыйри, замандашлары арасында беренчеләрдән булып, әдәбият һәм фән телен халыкның сөйләм теленә якынайту мәсьәләсен күтәреп чыга. Татар телен урам теле, ломовойлар теле; әдәби гыйльми тел булырга сәләте юк аның дигән карашларга каршы чыгып: «Инде телебезгә игътибар итеп, яхшы тикшереп карасак, билгеле ки, телебездә булган бәетләр, шигырьләр, мәкальләр, идиоматик әйтемнәр бик уңышлы рәвештә ритм һәм рифмага салынып төзелгәннәр, гарәп, фарсы телләреннән алынган сүзләр ярдәме белән мәгънәне тулы һәм матур итеп бирүдә башка телләрдән һич тә ким түгел, бәлки кайбер яктан үзенчәлекләре күбрәк булган урыннары да бардыр, бигрәк тә фигыльләрдә. Ләкин шуны да әйтеп китәргә кирәк: телебез, бер дә

кузгалмыйча, бер урында утырып калган. Хәзерге заманда яшәүче башка милләт халкының теләге – тел өстендә эшләү, телне күзәтү һәм яхшырту», - дип әйтте әдип [Насыйри, 2004 : 30].

Хәзерге чорда йөзләгән алдынгы язучыларның, меңләгән укытучыларның һәм гомумән күпсанлы интеллигенциянең, миллионланган хезмәт ияләренең бай рухи тормышларында аралашу чарасы буларак, бу тел тагын да югары баскычка күтәрелә, аның сүзлек составы байый һәм грамматикасы камилләшә.Ул хәзерге татар язучыларының әсәрләрендәге югары идеяләрне үз ана телебездә бирерлек, югары идеяле матур әдәбият әсәрләре тудырырлык әдәби тел булып формалаша. Мөһиме: яшь буында милли үзаң, патриотизм хисләре тәрбияләүдә зур роль уйный.

1879 елда К. Насыйри үзенең иң зур күләмле хезмәтләренең берсе булган һәм чын мәгънәсендә педагогик хезмәт дип бәяләнергә лаеклы китабын – «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият буенча әңгәмәләрнең җимешләре») әсәрен яза башлый. Ул аның кыскартылган беренче басмасын «Кырык бакча» дип атый.

1884 елда Казан университеты басмаханәсендә 615 битлек «Фәвакиһел-җөләса фил- әдәбият» исемле хезмәте тулысынча басылып чыга. Китапның ал битендә К. Насыйри бу хезмәтнең XIV гасырда Абашия авылында яшәгән Мөхәммәд ибне Әхмәд – әл – Хатыйбның «Мөстәтраф» («Мавыктыргыч») һәм XII гасырда Зәмәхшәр авылында яшәгән Мөхәммәд Касыйм Зәмәхшәринең «Раузел – әхъяр» («Изгелек кылучылар бакчасы») исемле әсәрләреннән файдаланып язылуын күрсәтеп үтә. Бу китап 40 бүлектән тора. Китапның һәр бүлегендә кешеләрнең тормышына һәм көнкүрешен дөрес оештыруга бәйле теге яки бу мәсьәләләр яктырыла һәм тәрбияви әһәмиятле киңәшләр бирелә. Һәр мәсьәлә буенча ул канатлы гыйбарәләр, мәсәлләр, хикәятләр һәм мәзәкләр китерә. Һәр бүлекнең башында мәшһүр галимнәрнең һәм хакимнәрнең – фәйләсуфларның, акыл ияләренең билгеле бер мәсьәләгә карата әйткән гыйбрәтле сүзләрен, гыйбарәләрен, педагогик мөһим фикерләрен китерә. Мәсәлән, «Яхшы холыклар вә яман холыклар» бүлегендә ул болай дип яза: «Сократ хәким әйтте: «Кемнең холкы яхшы – аның тормышы яхшы булыр, ул һәрвакытта сәламәт булыр, бөтен кешеләр аны яратыр. Ә инде кемнең холкы начар – аның тормышы да начар булыр, аның дошманнары күп булыр, бөтенесе аны күрә алмаслар һәм аннан качарлар. Начар холыклы кеше рәнҗетсә, аңа каршы сабырлык белән җавап бир, үзеңнең холкыңны бозма!..» [Насыйри, 2004 :128].

Әсәрнең беренче бүлегендә акыл төшенчәсе аңлатыла. Мисаллар: 1. «Ибн Карәһтән сорадылар: «Адәмиләрнең гакыллырагы кемдер?». Әйтте: «Адәмиләрнең гакыллырагы шул кешедер: заманасының халкы белән күркәм мөдарә кыйлыр», - диде [Шунда ук: 129].

2. «Әгәр дә бер адәм белән мосахәбә кыйлсаң, аның гакылына кара, диненә карама. Чөнки аның дине үзенә фәкать, әмма гакылы – үзенә һәм сиңадыр. Һәрбер эшне гакылыңа салып кара. Гакылың җаиз күрсә, әлбәттә, ул

эш саваптыр. Үзенә-үзе мохлис булган адәмдә гакыл юк. Гакыл иясенең сүзен колакка алмаган кешенең гакылы үләр »,– ди [Шунда ук: 301].

Икенче бүлеге гыйлем турында. Мисал: «Гыйлем сәбәпле хәлялне хәрамнан аерып беләсең. Гыйлем җомах юлын күрсәтәдер. Курку вакытында җуаныч була. Ялгыз вакытта иптәш була. Сиңа шатлык юлын ача, михнәт вә кайгы юлын бикли. Дусларың янында гыйлемлелек сәбәпле хөрмәт күрәсең. Дошманнарның катында гыйлемлек бер корал кебек була», – ди [Насыйри, 2004 : 302].

Өченче бүлектә әдәплелек турында язылган. Мәсәлән, «Берәүдән сорадылар: «Сине кем әдәпкә үгрәтте?» - диделәр. Әйтте: «Наданнарның әдәпсезлегеннән вә наданлыгыннан гыйбрәт алып сакландым, әдәпкә өйрәндем», - диде [Шунда ук : 305].

Автор тугрылык турында түбәндәге юлларны китерә: «Тугры сүзле булмак – чын мөселманлык галәмәте. Синең күңелеңдә ике эш җыелса, һәм кайсын эшләргә белмәсәң, кара: кайсы синең нәфескә муафикъ тоелса, аның хилафын эшлә. Шул раст булыр», - ди [Шунда ук: 307].

Бу уңай сыйфатлар барысы да мактала, югары бәяләнә. Галим боларны кеше өчен иң кирәкле сыйфат буларак санап күрсәтә.

Күп кенә бүлекләрдә аңгыралык, куркаклык, наданлык кебек тискәре сыйфатлар тәнкыйть ителә. Ахмаклык турында менә болай диелә: «Ахмак дигәнебез безнеңчә тинтәк диярләр. Ахырын тикшермичә, тәдбирсез эш кылган кеше – ахмактыр», - ди [Шунда ук: 32].

Шунда ук тәрбия методларын белмәгән хәлфәләрне, надан мулла һәм мөәзиннәрне, ишаннарны образлы сурәтләп, алардан сатирик көлә. Түбәндәге мисалны карап үтик: «Бер мөәззинне манарада күрделәр: кулында «Иман шарты» бар, азанын «Иман шарты»ннан карап әйтә. Сорадылар: «Ник карап әйтәсең, азанны күңелеңнән белмисеңме?» - диделәр. «Мулладан сораңыз», - диде. Муллага бардылар. Мулла ул вакытта ишегалдында иде. «Әссәламегаләйкем!» - диделәр. Мулла сәлам алмады, өенә кереп китте. Өеннән бер китап алып чыкты, актарды-актарды да: «Вәгаләйкемәссәлам!» - диде. «Хәер, мулласы да шулай икән», - дип киттеләр [Шунда ук : 85].

«Фәвакиһел – җөләса фил-әдәбият» китабының кырыгынчы «рауза»сы - бакчасы, ягъни тарихи бүлеге – әдәби яктан аеруча әһәмияткә ия. Биредә автор элекке көнчыгыш әдәбияты традицияләреннән котылып, гаять әһәмиятле оригиналь эшчәнлек күрсәтә. Тел белеменә карата булган әсәрләрендәге кебек, К. Насыйри монда да бер принципны, искедән яңага таба омтылу, схоластик әдәбияттан арыну, халык авыз иҗатына игътибар итәргә кирәк дигән принципны үткәрә.

Бүлек халыкның зирәк акылы, образлы һәм тапкыр фикер йөртүе тудырган табышмаклар белән башлана (27 табышмак китерелә). Кыскача аңлатма биреп, табышмакларның җавапларын да әйтеп бара. Мәсәлән, мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач. (Күктә йолдызлар арасында ай).

Табышмаклардан соң халык җырлары, берничә бәет һәм 309 мәкаль һәм әйтем китерелә. Бу хезмәтендә К. Насыйри фольклор әсәрләрен төрләргә һәм жанрларга бүлеп карый, аларга аңлатмалар бирә. Җырларны да ул татар фольклористикасында беренче буларак, эмоциональ – мәгънәви эчтәлегенә карап, алты төркемгә бүлә. «Моңаеп әйткән җырлар», «Мактап әйткән җырлар», «Кавышырга мөштак булып әйткән җырлар», «Һиҗран вә фирак җырлары» кебек тематик төркемнәргә бүленеп бирелә.

Күп кенә мәкаль һәм әйтемнәрнең дә мәгънәләре әйтеп барыла. Мәсәлән, «Атасы болан атмаганның углы колан атмас» (Күбрәк һөнәрсез атадан һөнәрсез бала туа, димәк), «Этнең – эткә, кошның – кошка» (Һәркемнең баласы үзенә кадерле, димәк), «Узган болытны тотып булмый» (Эш үткәч, үкенмәктә файда юк, димәк).

К. Насыйриның мәкальләргә аеруча зур мәхәббәт баглавы һич очраклы хәл түгел. Аларда галим халыкның бай тормыш тәҗрибәсе, тирән акылы һәм югары әхлакый сыйфатларын гәүдәләндереп, яшь буынга шәхси камилләшү юлын күрсәтә. Аның мәкальләренең җыйнаклыгы, тапкырлыгы, образлылыгы әдәби җанлы сөйләм үрнәге ролен үти ала. Шул ук вакытта Каюм Насыйри бу хезмәтләре белән үзен галим, язучы гына түгел, педагог буларак та таныта.

**Әдәбият**


1. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. IV томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. –Т.2. – 400 б.
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. IV томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Т.3. – 384 б.


## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ГЫЙЛЬМИ – МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕ


**Яковлева В.В.**

КФУның Алабуга институты студенты

Фәнни җитәкче: ф.ф.к, доц. Даутов Г.Ф.


Каюм Насыйри үз заманы өчен генә түгел, бүгенге көн махсус уку йортларында белем алган галимнәр арасында да үзенең киңкырлы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге белән күпләргә көндәш була алырдай талантлы шәхес булган. К.Насыйри эшчәнлегендә түбәндәге төп юнәлешләрне аерып карарга тулы нигез бар:татар һәм рус телләрен өйрәнү;мәдәби иҗат һәм тәрҗемә;тарих, этнография һәм археология мәсьәләләре;халык авыз иҗатын туплау, өйрәнү;журналистика өлкәсе (еллык өстәл календарьлары чыгару эше, “Таң йолдызы” проекты), педагогика (әхлак һәм тәрбия бирү) мәсьәләләре.

Халкыбызны караңгылыктан мәгърифәт дөньясына алып чыгуда Каюм Насыйриның вакытлы матбугатка зур өметләр баглавы билгеле. Аның “Таң йолдызы” исемле газета чыгарырга тырышуы хакында профессор М.Х.Гайнуллин хеэмәтләрендә искә алына. Бу турыда М. Х. Гайнуллин: “К.Насыйри 1871 елда ярым журнал рәвешендә еллык өстәл календаре чыгара

башлый. Шул ук елларда аңарда газета чыгару теләге туа... Газетасын “Таң йолдызы” дип исемләргә теләнә мәгълүм” дип күрсәтеп үтә [Гайнуллин 1968: 132]. Бу еллар Россиядә революцион-демократик хәрәкәтнең иң кульминацион чорына – туры килә. Бу яктан газета чыгарырга омтылу илдә барган революцион хәрәкәт л белән бәйләнештә, аның татарларга йогынтысы яктылыгында каралырга тиешлеге күренеп тора. Моның шулай булуын күзалларга мөмкинлек бирә торган башка фактлар да бар. Әмма “Таң йолдызы” газетасын чыгарырга патша хөкүмәте рөхсәт бирми. Кызганычка каршы, газета һәм журналлар чыгарырга омтылулар, “Таң йолдызы”на хәтле һәм аннан соң да, патша самодержавиесенең изелгән халыкларны караңгылыкта тоту, бигрәк тә христиан булмаган халыкларны аерата җәберләү политикасы киртәләрен үтә алмаган.

К.Насыйриның журналистика юнәлешендәге эшчәнлеге тормышка ашырылмаган проект дәрәҗәсендә генә калмый, әлбәттә. Ул патша цензорларыннан качу юлын таба – еллык өстәл календарьлары чыгара. Үзенең мәгърифәтчел карашларын халыкка җиткерү максатыннан К.Насыйри 1871 елда ярым журнал характерында, “Казан календаре” исемендә, еллык өстәл календаре чыгара башлый [Миңнуллина 2001: 168]. Заманында газета вазифасын өлешчә әнә шул календарьлар үти. Аның егерме дүрт ел дәвамында чыгып килгән календарьларында, ел саен кабатлана торган гадәти материалларында фәнни һәм әдәби мәкаләләр урнаштырыла. К.Насыйри 1871 елдан алып 1898 елга тиклем, өч ел гына өзеклек ясап, 24 календарь чыгара. Бүгенге көндә аның календарьларын өйрәнү шул чор тел хәзинәләре үрнәкләрен барлау өчен, XX йөз башы татар дөньясын, аның көнкүрешен, таләпләрен өйрәнүдә дә мөһим чыганак булып тора. Календарь ярым журнал характерында була һәм “Казан календаре” дип атала. Каюм Насыйри бу календарьларны үз исәбенә елга бер тапкыр чыгара. Календарьларның уртача күләме 40-70 бит тирәсе була. К.Насыйри календарьларында астрономия, география, тарих һәм башка фәннәргә кагылышлы материаллар урын алган. Димәка, бу календарьларның эчтәлеге бик киң булган. К.Насыйриның чирек гасыр буена чыгарган календарьлары – билгеле бер дәрәҗәдә татар тормышының әһәмиятле мәсьәләләрен яктыртучы беренче вакытлы матбугат органы ул.

К.Насыйри үзенең календарьларында законнар турында да язган. Аның әлеге законнар системасы белән таныштыруын без башка китаплардан, дәреслекләрдән укып беләбез. “Законны белмәү, ул әле аннан котылып калу чарасы түгел, без белергә тиеш” дигәнрәк гыйбарәне дә Каюм Насыйри әйткән. Шулай ук ул календарьларына үзе җыйган риваятьләрне дә, сирәк кенә булса да, әдәби язмалар да урнаштырган [Горохов 1948: 19].

Каюм Насыйри үзенең календарьларында системалы рәвештә төрле фәннәргә мөрәҗәгать итә. Тарих, география буенча шактый күп мәкаләләр бастыра. 1871 нче елда чыккан беренче календарында ул рус тарихы һәм географиясе турында мәгълүматлар бирә. 1873 елгы календарында Казан һәм

Казан ханлыгы турында очерклар, гомуми һәм Россия географиясе турында материаллар урнаштыра.1874 нче елда ул Хива сугышы тарихы турында язып чыга. 1876 нчы елгы календарьда ул үзенең укучыларын Россиянең географиясе белән кыскача таныштыра. 1877 елгысында Россия, Азия, Африка турында мәкаләләр, 1881 нче елда Казан тарихы турында яза. 1884 нче елгы календарында татар теле һәм аның барлыкка килүе турында, ә 1891 нче елда Төркиянең кыскача тарихы турында мәкаләләр урнаштыра.

Ул шул ук вакытта география фәне буенча календарьларында үзе сызган карталарны да бастырып тора. 1884 нче елда Азиянең, 1878 нче ел өчен чыккан календаренда җир шарының көнчыгыш яртысының картасын, 1879 елда Россиянең Европа өлеше картасын һәм 1881 ел календарында Казан губерниясенең бөтен авылларын күрсәткән картасын эшләп бастырган [Хәйруллина 1974: 63-65].

К.Насыйри һәрбер фән турында материал биреп кенә калмый, аларны ничек кулланырга, файдаланырга кирәклеген дә аңлата. Мәсәлән, ул технологиягә карата һәм химик үзгәртүләр юлы белән төрле әйберләр ясау мөмкинлеге турында киңәшләр биреп бара.

К.Насыйриның педагогика юнәлешендә иҗат иткән түбәндәге хезмәтләре мәгълүм: “Балаларга тәгълим бирмәк”, “Әхлак рисаласе”, “Тәрбия”, “Аракы эчәргә гадәтләнгән кешеләргә бер-ике калимә сүз”, “Аракы дигән эчемлек адәми зат өчен сарыф бер агудыр”, “Әхвале шәрабеддөхән”, “Китаб әт-тәрбия”. Шунысы игътибарга лаек, бу хезмәтләр бары тик балалар өчен генә түгел, зурлар өчен дә файдалы.

К.Насыйриның мәгърифәтчел карашлары аның балалар һәм башлангыч сыйныфларда белем алучылар өчен язылган хезмәтләрендә дә ачык чагылыш тапкан. Аның табигать күренешләре турында кыскача мәгълүмат биргән “Буш вакыт” әсәре 1860 елда басыла. Ул татар телендә язылган әдәби-фәнни популяр әсәрләрнең беренчесе. 1868 елда К. Насыйри “Буш вакыт”ның икенче вариантын бастыра. 1860 елгы басма 12 битле генә булса, икенчесе 87 биткә җитә. Педагогик мәсьәләләргә кагылышлы мәкаләләрен К.Насыйри үзенең календарьларында да бастырган була.

1887 нче елда чыккан календаренда ул “Могайнетдин” исемле мәкаләсен бастыра. Бу мәкаләсендә ул балаларну укыту-тәрбия итү эшләрендә булган җитешсезлекләрне тәнкыйть итеп чыга, укыту эшләрен тәртипкә салырга чакыра. Бу мәкаләсендә шулай ук балаларга укытылачак дәреслекләрне алдан билгеләргә, әзерләп куярга чакыра. Гомумән, К.Насыйри һәрбер календаренда тәрбия мәсьләсенә караган мәкаләләргә зур урын бирә. 1881 нче елда чыккан календаренда аның “Тәрбия” дигән махсус мәкаләсе басылган була. Ул бу мәкаләсендә укытучы булган кешенең киң белемле, төрле фәннәрдән хәзерлекле булуы өстенә, тәрбия юлларын белүен шарт итеп куя.

Каюм Насыйри иҗат иткән календарьларда тәрбия мәсьәләләренә күп урын бирелгән, дидек. Аларда ул белем-тәрбия бирүнең берлеген һәм дәвамчанлыгын, әхлакый һәм гуманистик тәрбиянең мөһимлеген күрсәтә,

“һәрбер нәрсәнең, - ди ул, - чиге... бардыр. Әмма гакылның чиге вә соңы юктыр... Гакыл вә тәҗрибә бер-берсенә ярдәмче булмакта җир белән су кебектер. (Мәгълүм ки), су белән җир бер-берсеннән башка бер нәрсә (дә) үстерә алмыйдыр...” К. Насыйри фикеренчә, ата-ана, мөгаллим шәхси яктан балага тәрбиялелекнең үрнәге булып торырга тиеш [Галиәхмәтов 1990: 55].

Алда билгеләп үткәнчә, К.Насыйриның белем һәм тәрбия бирү мәсьәләләрен өйрәнүгә багышланган хезмәтләре арасында “Фәвакиһел-җөласә”, “Китаб әт-тәрбия” кебек хезмәтләре аеруча зур әһәмияткә ия, күләмнәре ягыннан да зуррак булулары белән аерылып тора.

Шул рәвешле, К.Насыйриның киң кырлы эшчәнлеге төрле юнәлешләрдә алып барылганлыгын ачыкладык. Шунысы әһәмияткә ия: әдип һәр өлкәдә дә үзенең профессиональлеге, фәнне тирәнтен белүе белән таң калдыра. Аның ике гасырдан артык элек язылган бу хезмәтләре бүгенге көн фәннәре өчен дә актуаль булып тора.

**Әдәбият**

1. Галиәхмәтов И. Каюм Насыйри һәм К.Д.Ушинский./И.Галиәхмәтов // “Совет мәктәбе”, 1990. – № 3. – 54 б.

2. Гайнуллин М. Каюм Насыйри (тормышы һәм иҗаты) // Каюм Насыйри: 1825-1945: Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия матер. Казан: Татгосиздат, 1968. – Б.3-41.

3. Горохов В. М. Общественные и педагогические взгляды КаюмаНасыри / В. М. Горохов // КаюмНасыйри. – Казань: Татгосиздат, 1948.

4. Миңнуллина Л. Татар календарьлары тарихыннан / Л.Миңнуллин // Казан утлары. – 2001. – №7. – Б. 168.

5. Хәйруллина Д.К. Каюм Насыйри һәм татар телендә беренче басма календарьлар. // Тез.докл. III научной конф.молодых ученых. – Казань, 1974. – Б. 63-65.

## III.ТАТАР ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНЕҢ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

---

### ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ РЕАЛЬ ҺӘМ ИРРЕАЛЬ ДӨНЬЯ БИРЕЛЕШЕ

**Арсланова А.Ф.**
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче:ф.ф.к., доц. Габидуллина Ф.И.

Галимҗан Гыйльманов иҗаты әдәбият дөньябызда үзенчәлекле урын алып тора. Галимнәр хәзерге әдәбият турында сөйләгәндә, “әдәбият белемендә магик реализм исеме белән кереп калган юнәлештә язылган әсәрләр үзенчәлекле урын били. Мондый юнәлештә язылган әсәрләрдә кеше ике яссылыкта – реаль–гадәти тормышта һәм шул ук вакытта серле–сихерле, аңлап–аңлатып бетереп булмый торган дөньяда берьюлы гомер кичерә. Бу агым дөньяны могҗиза ярдәмендә ачу, бәяләү мөмкинлеген таба. Магик реализм иләнгән һәм сәер хәлләрнең төрле вакыт (бигрәк тә үткән һәм бүгенге), яшәү рәвеше, язмышларның кушылмасын бирә”, – дип язалар [Заһидуллина 2006: 255]. Бу күренешне Галимҗан Гыйльманов әсәрләрендә дә күзәтергә була. Ике дөнья чиген яки хәтта аларның кисешү нәтиҗәсен тасвирлау – әдип иҗатында сирәк күренеш түгел. Әлеге күренешне анализлау, шулай ук алга таба әдип иҗатында архетипик образлар, мифологик хронотоп бирелешен анализлау өчен язучының “Туй төне”, “Албастылар”, “Язмышның туган көне”, “Тимерчеләр”, “Төнге кош”, “Төнге күбәләк”, “Кырның җаны бармы?” һәм башка әсәрләре тикшерелде.

Галимҗан Гыйльмановның күп кенә әсәрләрендә реальлек һәм ирреальлек кисешә, бер–берсенә керешеп китә. Мистик–фантастик әдәбият өчен бу табигый булса да, Галимҗан Гыйльмановның күп кенә әсәрләрендә бу керешү гайре табигыйлык төсмерен ала. Нормаль хәләттә бу дөньялар кисешә алмый, кисешү һәм керешү өчен яшәешнең асыл кануннарына хилафлык килергә тиеш. Ешрак бу – трагик вакыйгалар нәтиҗәсе. Мәсәлән, “Дөнья чигендәге очрашу” хикәясендә ана тәненә улының җаны иңү белә бәйле сюжет үзәккә алына. Автор Теге дөньядагы җанның кичереш–халәтләрен тасвирлау хокукын алмый, әмма дөньяны хәзер улы кебек, улы тарафыннан кабул иткән хатын булып яшәү аңа бик авыр, ул үлем юлын сайларга әзер.

“Туй төне” новелласында да ирреаль дөнья чын дөнья белән шул кадәр буталган, аларны бер–берсеннән аеру өчен әсәрдәге вак детальләргә игътибар итү сорала. Хикәянең сюжеты катлаулы түгел, әмма аның үзәгендә иң көчле хис – мәхәббәт тора. Могҗизаи хис булганга, күрәсең, автор ирреаль дөньяның безнең дөнья вакыйгаларына багланышлы булуын, аларга катышуын мөмкин дип саный. Әмма мистика биредә алгы планда тормый, аның мистик хасиятләре дә аз–азлап кына ачыла. Хикәяләү Зәлидә исемле кыз тарафыннан алып барыла. Әйтерсең лә, ул укучы алдында иң яшерен хис–серләрен ача. Мәктәптән үк аңа

Илгиз исемле егет гашыйк була. Аның кызга карата хисләре саф, изге була. Кыз да аңа лаек, әлбәттә. Әмма Русланга булган мәхәббәт шашкынлыгы аның бар күңелен биләп ала. Автор тасвирына мөрәҗәгать итик: "Матур булды аларның мәхәббәте! Аерылышканда – сагынышып, күрешкәндә сөешеп туя алмый иде алар. Бу очрашуларда Русланга бөтен күңелен, җанын бирә иде Зәлидә. Җанын гына түгел, тәненең һәр күзәнәген бирә иде... Ләкин, ничек кенә үптерсә дә, назлатып сөйдерсә дә, актин–ак, сафтин–саф тәненә Русланның дәртле, мәхәббәтле һәм ымсындыргыч тәнен якын җибәрми иде... "Анысы туй төне өчен", – дип кала иде" [Гыйльманов 2014: 279]. Биредә без кабатлау алымы белән очрашабыз: әсәр исемендәге "Туй төне" сүзе ассызыклап бирелгән шикелле тоела. Әмма әсәр башыннан ук аңлашыла: кыз Илгиз белән туйга әзерләнә, чөнки Руслан көннәрнең берендә юкка чыга, ата–анасы да Казанга күчеп киткән, дигән сүзләр тарала. Зәлидә сүзләренә караганда, аңа ике юлның берсе кала: яки сагыштан үлү, яки Илгизгә кияүгә чыгу. Илгиз мәхәббәте шул кадәр олы була ки, туй төнендә дә ул кызны тәне белән дә үзенеке итәргә кыймый. Кан чыгарып, кызыксынучан җиңгиләргә шуны күрсәтергә була, дигән фикергә киләләр.

Мистик башлангыч беркадәр дәрәҗәдә туй көнне үк башлана. Кызга кемдер Русланның кайтуы турында хәбәр иткән шикелле була. Әмма хәбәрнең кем тарафыннан, ничек җиткерелүе дә автор тарафыннан ачык кына әйтелми:

Шунда кемдер Зәлидәнең колагына пышылдап китте дә инде:

– Руслан кайткан, ди, малайкаем... Сине сорашкан, ди... [Гыйльманов 2014: 280].

Бер яктан, гади авыл кешесе сөйләменә якын торган әлеге сүзләрнең кызга ишетелүендә илаһи көчләр, мистик көч тырышлыгы турында фикер туарга мөмкин. Туй төнендә, әйткәнебезчә, Илгиз кызны көчләп үзенеке итми, Зәлидә теләге буенча ялгызын калдыра. Һәм төн уртасында ялгыз калган Зәлидә нәрсәдер тоя: "Кемнеңдер салкын бармаклары кайнар тәненә кагылу белән, үзен үзе белештермичә сикереп торды ул. Караңгыда бер нәрсә күрмәсә дә, тыныннан–сулышыннан тойды – бу Илгиз түгел. Бу – аның Мәхәббәте, Язмышы!.." [Гыйльманов 2014: 282]. Укучы хәтта төгәл генә аңлый да алмый: саташумы бу, әллә Руслан чынлап та кайтканмы? Әмма әһәмиятле детальгә игътибар итү кирәк: егетнең куллары, бармаклары салкын була, ә Зәлидә – тере кешенеке – кап–кайнар. Салкынлык – укучыны сискәндерергә тиешле бердәнбер деталь түгел. Кыз үзенең сафлыгын вәгъдә иткән кешесенә бүләк итә һәм яшьләр төнне наз–сөешүдә үткәрәләр. Әмма инде мәңге Руслан белән бергә булачагына ышана башлаган Зәлидәне тетрәнү сүзләре көтә: "Беренче таң әтәчләре кычкыруга, мәхәббәт төненнән айнып, иң элек Руслан сикереп торды. – Миңа китәргә вакыт, болай да соңга калдым бугай... Әниләр дә югалткандыр... Без бит йорт–нигезне сатарга гына кайткан идек... Менә туең хакында ишеттем дә килдем..." [Гыйльманов 2014: 283].

Монда да укучыда шикләнү туа: бәлки Русланнар чынлап та йортларын сатарга гына кайтканнардыр? Әмма авторның нәкъ менә таң әтәчләре образ–

деталең кертүе сискәндерә: алардан бары тере кешеләр янында йөри торган үле җаннар, шайтаннар гына курка.

Галимҗан Гыйльмановның “Албастылар” роман–кыйссасында сурәтләнгән вакыйгаларда реаль дөнья белән ирреаль (мифологик) дөнья арасындагы чик аеруча да нечкә һәм вакыт–вакыт бөтенләй дә югала шикелле. Автор боларны Хәлим күзлегеннән тасвирлап бирә. Әсәрнең үзәгенә алынган вакыйгаларга кадәр Хәлим башка дөнья, башка үлчәмнәр, ым–сихер дөньясына артык ышанмый яши бирә. Әмма әлеге дөньяларның аның тормышында, ул яшәгән авылда инде кисешкән булуы тамгалар рәвешендә булса да урын ала икән. Хәлимнең уйларын–сүзләрен искә төшереп үтик:

- Нинди сихерче булсын ди бу космос заманында? Карт–коры әкияте! Ул киенде–ясанды да, капка–ишекләрне шалыратып ача–ача, урамга чыгып китте. Клуб ягына борылды. Шунда аның күзе капка баганасындагы бер тамгага төште. Бożра эченә тәре сызылган иде. Боҗра үзәгендә, ике сызык кисешкән урында кечкенә түгәрәк... Ак таш белән төшерелгән бу тамгага әллә ни игътибар итеп тормаган иде Хәлим. Менә хәзер шул рәсем аның исенәкелт итеп килеп төште [Гыйльманов 2003: 13].

Алга таба Галимҗан Гыйльманов героен ирреаль дөньяның нәкъ үзәгенә илтеп ташлый: ике сихерче карчык аның зиһенен һәм хәтерен алалар. Ел буена ул монда ярымкол хәлендә гомер итә, әмма сихерчеләр аны тулысынча үз ихтыярларына буйсындыра алмый, чөнки Хәлимне мәхәббәт көче саклап тора. Гомумән, иң көчле хисләр дөньяларның бер–берсенә мөнәсәбәтенә йогынты ясый. Мәхәббәт, яңарак әйткәнебезчә, Хәлимне ирреаль дөньяның явызлыгыннан саклап тора. Ә рәнҗеш, киресенчә, ирреальлекнең начар һәм шаукымлы йогынтысына юл ача. Кара урман эчендәге эпопеяның нәтиҗәсе шуннан гыйбарәт: “албастылар” утарында яшәүче ике ярым мифик карчык – кайчандыр Хәлимнең туган авылыннан куып, сөреп җибәрелгән, нигезләре туздырылган җан ияләре икән. Алар кешеләрнең шушы явызлыклары өчен гомер буе Кампәрле авылыннан үч алганнар: авыл кешеләрен урлап китеп, аларны үз утарларында кол–зомби итеп тотканнар. Хәлимне дә алар урлаган икән. Башка дөнья белән бәйләнешле кешеләрнең авылдан куылу мотивы “Тимерчеләр” кыйссасында да чагылыш таба.

Ирреаль дөнья кешеләр язмышына гайре табигый ситуацияләрдә, мисал өчен, явызлык, начар ният өчен җәза бирү максаты белән дә килеп керергә мөмкин. Бу очракта күбрәк түбән мифологик персонажлар хәрәкәт итә.

Реалистик дөнья тасвирын биргәндә дә, автор мистик–ирреаль дөнья белән чикләрнең бик нәзек булуы хакында искәртеп тора. Сабыйлар, балалар, картлар мистик көчләргә, илаһи көчләргә карата аеруча сизгер. Мәсәлән, “Язмышның туган көне” повестендә героиня–кызчык әбисеннән догалар өйрәнә, аларның көченә ихластан ышана. Кара көчләрнең кодрәте турында да билгеле Зөһрәгә:

– Беркөнне күрше ишегалдыннан кереп йөри торган кара эт чак кына тешләмәде үзен. Дөресен генә әйткәндә, тешләде, әмма аның хәтәр тешләре

Зөһрәнең итегенә туры килде. ... Зөһрә белә: кара эт, кара мәче – сихер–зәхмәт, кара көчләр галәмәте. Яман күзләр шундый кара этләр рәвешенә кереп йөри, имеш... Теге вакытта яман күздән, яман көчләрдән саклый торган доганы әйткән булса, эт тә тешләмәс иде, мөгаен [Гыйльманов 2005: 27].

Галимҗан Гыйльмановның күп кенә әсәрләрендә теге һәм бу дөнья иясе буларак Җан образы очрый. Кайчак ул кеше күңелендә яшәүче көч, нур буларак тасвирлана, “Төнге кош” хикәясендә кош сурәтендә, “Төнге күбәләк” хикәясендә күбәләк сурәтендә тасвирлана. Соңгы хикәядә бу образ үзәккә алынганлыктан, аңа тәфсиллерәк тукталыйк. Хикәяең исеме ике төрле укылышка ия: беренчедән, Мәдинә үзе яшәү рәвеше буеча тәне белә сәүдә итүче төнге күбәләк; икенчедән, төнлә һәлакәткә эләккән яшь кызның җаны күбәләк булып иясенә көч–ярдәм биреп тора. Мәдинә – реаль дөнья кешесе, реаль дөньяның иң ямьсез якларын, рәнҗү–хыянәтне күп татыган кыз–хатын. Нариманга гашыйк булу аны упкынга тәгәрәтә, назлы–алдавыч сүзләре белән иркәләп, Нариман аны тәне белән сәүдә итәргә мәҗбүр итә. Җаны, асылы белән очрашу исә машина юлында һәлакәткә эләккән мизгелдә була. Галимнәр: “җан – тәңгә тереклек бирә һәм тәннән башка да яши ала дип каралган, тереклек иясенең психик процессларын чагылдырган мәңгелек башлангыч; кешенең эчке дөньясы: аның табигате, кичерешләре, хисләре, уй–фикере, омтылышлары”, – дип язалар [Җамалетдинов 2006: 276]. Шул ук вакытта, дини әдәбиятта да җан төп төшенчәләрнең берсе булып тора, тере затның нигезе, яшәү энергиясе буларак аңлатыла. Барлык диннәрдә дә җан, рух кебек төшенчәләр ахирәт дөньясы, бакый дөнья турындагы өйрәтүләр белән бәйләнгән. Дини өйрәтүләр буенча, кешегә Алла җан иңдерә, аннары аны, теге дөньяда мәңге яшәтү өчен кире ала. Ф.И. Урманче язганча, “тәүге мифологик мәҗүси күзаллаулардан башланып, соңгырак чорларда ул төрле бигрәк тә дөньякүләм таралган диннәрнең Изге китапларына килеп керә һәм анда шулай ук үзәк һәм катлаулы төшенчәләрнең берсенә әверелә” [Урманче 2009: 43]. Исламга кадәр мәдәнияттә бабаларыбыз җанның тәннән аерылып Күккә ашынуына ышанган, кошка, күбәләккә әверелгән җан образы Галимҗан Гыйльманов әсәрләренең мифопоэтикасының әнә шул борынгы катламнарын актуальләштерә. Ислам дине буенча исә Җан, тәннән аерылганнан соң да мөстәкыйль хәрәкәт итә алмый, аның артыннан Газраил фәрештә җибәрелә. “Төнге күбәләк”тә, алдан әйтеп киткәнебезчә, тәннән мәңгелеккә аерылу һәм аерылмау чикләрендә торган җан образы күбәләк тасвиры аша бирелә. Бу күбәләкнең биюе – Мәдинәнең җанының мәңгелеккә китү һәм бу тормышта калу арасында бәргәләнә. Дөресрәге, аны бәргәләнүләргә Мәдинә дучар итә:

– “И җаным минем, кире кайтсана, кабат гомер бирсәнә!.. – Мәдинә үз җанына өзгәләнеп ялвара башлавын сизми дә калды. – Кайт!.. Кайт та бу упкын авызыннан чыгарлык көч бир!.. Син бит минем җаным гына түгел, син минем раббым!.. Кайт инде, ярдәм ит, җаным–раббым!.. – Ләкин шундук уйларыннан кире кайтты. – Юк, килмә, коткарма, мондый тормышта

яшәгәнеңнән яшәмәвең артык... Менә хәзер кулларны ычкындырам да юкка чыгам... Менә хәзер, менә хәзер...” [Гыйльманов 2014: 332].

Әмма җан гәүдәне ташлап китми, ә төнге күбәләк булып биеп, Мәдинәне тормышка, матурлыкка чакыра. Нәкъ шушы илаһи мизгелдә Мәдинә упкынга таба тәгәри башлаган, һәлакәткә дучар иткән тормышыннан ычкыну, ачу, яңача тормышны башлап җибәрү мөмкинлекләрен күрә башлый. Ул бит Нариман янында, аннан куркып торырга тиеш түгел, ә авылга, әти–әнисе янына кайтып тормышын яңадан башларга да мөмкинчелек бар!

Әлеге хикәядә җан – күбәләк образы халык мифологиясенә нигезләнә. Ф.И. Урманченең татар мифологиясенә багышланган энциклопедик сүзлегендә күбәләк сүзе юк, әмма күп кенә халыкларда җан – күбәләк тәңгәллеге очрый. Н.В. Мартынова искәртүенчә, борынгы Русьта күбәләкләрнең икенче кат туган җан булуына ышанганнар. Поляклар җанның тәнне күбәләк булып ташлап китүенә ышанганнар [Мартынова 2021: 10]. Борынгы грек алиһәсе Психея (аның исеме җан буларак тәрҗемә ителә) фрескаларда тормыш символы булып килгән күбәләк канатлы зат итеп тасвирлана.

“Кош – җан” параллелен дә Галимҗан Гыйльманов әсәрләре нигезендә күзәтергә була. “Төнге кош” хикәясендә героиняның йоклый алмыйча, шомлы уйлар эчендә газаплануы тасвирлана. Гаҗәбе шул: шомлануның сәбәбен ул үзе дә аңлый алмый. Әниләре өчен борчыла дияр идең, алар белән күрешеп торалар, мөнәсәбәтләр дә уңай; ире Наил дә аны ярата, кызлары Энҗе өчен дә үлеп тора. Уйлана торгач, Чулпан гаиләсе, мәхәббәте тарихына туктала. Аның тормышында ике егет зур роль уйный, икесе дә аны ярата. Илнар – беренче шашкын мәхәббәте, саф мәхәббәт. Сигезенче класстан бергә булган бу парга бар да сокланып карый. Мәктәптән соң Чулпан университетка, Илнар төзелеш институтына укырга керә. Алар, “кулга–кул тотынышып йөрүче гашыйклар яшеннән чыгып, олы тормыш хакында хыялланып яшәүче Ләйлә белән Мәҗнүнгә әверелә бардылар” [Гыйльманов 2014: 69]. Әмма Илнар авылда вакытта Чулпанның юлында Наил очрый. “Хәзер Чулпан белә инде, Наилнең иксез–чиксез мәхәббәте үзенә җәлеп итте аны. Андый мәхәббәтне Чулпанның киноларда гына күргәне бар иде. Бәй, уйлап карасаң, мөмкин хәл түгел бит бу – Наил бер ай буе Чулпанга чәчәк ташыды. Көн саен бер роза чәчәге. Көн саен бер... сүз. Сөю сүзе! Баштарак ул сүзләр Чулпанның йөрәгенә үтеп керә алмасалар да, бердәнбер көнне яшь, дәртле йөрәк түзмәде, Наилнең: “Син минем язмышым!” – диюенә дөрләп кабынды да китте...” [Гыйльманов 2014: 69]. Наил дә, Илнар да Чулпанга бер тормыш юлын үтәргә тәкъдим итәләр. Илнарга Себердә эш тәкъдим итәләр, ул шунда бергә китәргә өнди. Әмма Себергә күңеле тартмаган Чулпан Наилне сайлый.

Мәхәббәт тарихы турындагы бәян ретроспектива алымы ярдәмендә шулай тасвирлана. Әмма бу уйланулар тәрәзәгә тынгысызланып кагынган шомлы кош тасвиры, тавышы белән өздерелә, хәтта Наил дә кошның гадәти булмавын таный. Шомлануы мөлдеренә ташыган Чулпан әниләренә дә шалтырата, әмма аларның тормышына нисбәтле бер яман хәбәр дә ирешми.

Аның каравы ана кеше бик зур саклык белән икенче хәбәрне җиткерә: Илнар авариягә эләгеп вафат булган. Хикәядән аңлашылганча, төнге кош та Илнарның мәңгелек йортка киткәнче сөйгәнен күреп калырга теләгән җаны булып чыга.

"Оча торган кешеләр, яки иясез язмышлар хакында бәян" әсәрендә шулай ук үзәккә җан образы куела. Биредә без төрле халыклар мифологиясендә очрый торган күз һәм җан тәңгәллеге турындагы күзаллау белән очрашабыз. Хикәяләүче төп герой Сәүбәннең мәрткә китүе, төш күрүе, әмма күзләренең шул ук вакытты шыр ачык булуы белән бәйлелектә фәлсәфи уйларга бирелә:

– Күзләр – кешенең иң серле–сихерле урыны. Якты дөньяга ишек. Бу – шулай. Әмма күзләрнең сихри асылы, илаһи хасияте моның белән генә бетми әле. Күзләр һәрвакыт, һәрдаим җан карамагында, җан ихтыярында булган. Кеше җаны шушы күзләр аша хәрәкәтләнә. Күзләр – җан юлы, җан сукмагы… Халыкта "җансыз күзләр" дигән сүз йөри. Кеше үлгәч, җаны чыккач, иң беренче итеп аның күзләрен йомдырып куялар. Җан тәслим иткән, җаны башка кайтмаячак дигән сүз бу. "Күз саклау – җан саклау", "Күзсез калу – җансыз калу" дигән әйтемнәрдә дә бар "күз–җан" тәгълиматы [Гыйльманов 2007: 41].

Аңлашылганча, автор тәңгәллекнең нигезен яхшы гына аңлатуга ирешә. Бу аңлатма күп кенә халыкларның мифологиясендәге ышануларга нигезләнә. Ф.И. Урманче хезмәтләренә караганда, мәсәлән, "байтак халыкларның борынгы мифларында һәм әкиятләрендә күзсезләр үле җаннар буларак тасвирланганнар [Урманче 2009: 175].

Җан турында сүз алып барганда, Галимҗан Гыйльманов бары кеше җанын гына күздә тотмый. Борынгы мәҗүси бабаларыбыз шикелле үк, ул һәр тереклек иясенең, табигатьтәге һәр әйбернең җаны бар, дип исәпли. Мисал өчен, "Кырның җаны бармы?" парчасында ул үзе куйган сорауга уңай җавап бирә. "Элегрәк, хәттә әткәйләр–әнкәйләр чорында да әле, һәр басуның үз агачы, үз сакчысы, иясе булган. Мондый агачлар хакында әнкәй: "Кыр ияләре алар, балам, игеннәрне төрле афәтләрдән, зәхмәтләрдән саклыйлар", – ди торган иде" дип искә ала ул [Гыйльманов 2005: 377]. Хәзерге кырларда мондый агачлар булмауны автор кырларның җанын алу, аларны җансыз калдыру дип атый.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: Галимҗан Гыйльманов әсәрләрендә реаль һәм ирреаль дөньялар арасындагы чик үтә нечкә. Аерым кешеләр берьюлы ике дөньяның да йогынтысын тоеп яшиләр. Кеше җаны да үтә катлаулы категория буларак бирелә: ул бу дөньяда да яши (кеше тәнне эчендә), аерым хасиятләрдә (йокы һәм төш күрү, үлем мизгеле, үлем белән яшәү арасынды бәрәгәләнү мизгеле) ахирәт дөньясы, мәңгелек дөнья чигендә дә тасвирлана. Кеше җаны әдип тарафыннан ешрак күбәләк яки кош образы аша тасвирлана.

**Әдәбият**

1. Гыйльманов Г. Албастылар: хыялый кыйсса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 383 б.

2. Гыйльманов Г. Китек ай: повестьлар, хикәяләр, парчалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 383 б.

3. Гыйльманов Г. Оча торган кешеләр: роман, повестьлар, бәяннар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 463 б.
4. Гыйльманов Г. Тәкъдиргә юл: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Рухият, 2014. – 448 б.
5. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.
6. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.
7. Мартынова Н.В. Исследование орнаментальных символов образа бабочки в традиционной культуре народов мира // The scientific heritage. – 2021. – №58. – С. 9–14.
8. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. – Казан: Мәгариф, 2009. – 343 б.

## М.МӘҺДИЕВ ИҖАТЫНДА МӘДӘНИ МИРАС САКЛАНЫШЫ

**Әхмәтҗанова Х.Д.**
Арча районының "Утар–Аты төп гомуми белем мәктәбе" укучысы
Фәнни җитәкче: Касимова З.Г.

*“Бүгенге көндә татар халкы тормышын,*
*аның гореф – гадәтләрен, күңел серләрен,*
*халыкбуларакяшәүрәвешен*
*М.Мәһдиев кебек белүче олы зат юк*”
Аяз Гыйләҗев.

Арча ягы– республикабызның олы тарихлы, мәшһүр кешеләре белән дан тоткан иң зур районнарның берсе. Аларның һәрберсе туган җирен, туган туфрагын зур мәхәббәт белән искә алып, олылап яза. Ләкин якташ язучыбыз М. Мәһдиев әсәрләрендәге кебек туган ягының чын тәмен белеп язучы башка юктыр. Ул-безнең якташ язучыбыз, горурлыгыбыз, Татарстан Республикасының халык язучысы. Аның һәр әсәре белән әле танышып бетмәсәм дә, язучының “Без-41 нче ел балалары” әсәрен укыганнан соң, мин Мәһдиев иҗатында мәдәни мирас сакланышы кайсы яклардан ачыла икәнлеген ачыклауны максат куйдым. Нәрсә соң ул мирас? Ул кешедән кешегә, әби-бабайдан балаларга күчеп килүче иң кадерле әйбер. Димәк, мәдәни мирас дигәндә, без билгеле бер халыктан киләчәк буыннарга күчеп килгән, әһәмияткә ия булган мәдәни чараларны, гореф-гадәтләрне, традиция, йолаларны күз алдында тотабыз. Шулай ук бәйрәмнәребез дә безнең рухи мирасыбыз, байлыгыбыз булып тора. Мәдәни мирасыбызны без күз карасы кебек сакларга, өйрәнергә, киләчәк яшьләренә дә тапшырып калдырырга тиеш булабыз.

“Без-41нче ел балалары” повесте -Мөхәммәт Мәһдиевнең иң беренче әсәре. Анда сугыш чоры балаларының сугыш елларындагы белем алулары, җиңүгә керткән зур өлешләре, колхоз тормышы, авыл кешеләре сурәтләнә. Яп-

яшь малайлар-кызлар, тырышып-тырышып укытучы булырга әзерләнәләр. Уку аларга җиңел генә бирелми, тамаклары туйганчы ашый алмау-иң үзәкләренә үткәне була. Ләкин 12-14 яшьлек балалар авырлыклардан куркып калмыйлар, чын егетләр-кызлар булып үсеп җитәләр, тормышта һәрберсе үз урынын таба.

Әлеге әсәрендә Мөхәммәт Мәһдиев татар халкына хас булган бик күп яшәү рәвешләрен сурәтли. Ул авыл кешеләренең йорт-җирләрен безнең күз алдына картина кебек китереп бастыра, табигатен олылый. Язучы без хәзерге вакытта музейларда гына күрә торган авыл мичен, анда ипи, коймак, бәлешләр пешерүне шулкадәр оста итеп яза, шул вакыттагы ризыкларны ашап карыйсы килә башлый!

Мин үзем дә авыл баласы, ләкин бакчада үсә торган бәрәңгегә игътибар да иткәнем юк! Бәрәңге сабагының исе була икәнен уйлап та караганым юк икән! Җәен печән җыйнау вакыты бездә дә бар, ләкин ул Мөхәммәт абый язып калдырганча түгел шул инде...

“Без-41 нче ел балалары” әсәрендә кызык та, кызганыч та булган урыннар бик күп. Мин, бик яратып, “Таңнар кайда да матурдыр...” бүлеген укыдым. Язучы бу бүлектә авыл тормышын тулысы белән ача. Авыл кешеләренең характерлары авылның табигатенә карап төрле була икәнен раслап бирә. Мәсәлән, ул зур сулы авыллар белән сусыз авылларның халкын чагыштырып бирә. Урман буенда яшәгән кешеләрнең холкы бөтенләй башка була икән. Автор бик тәмләп авыл мунчасы, мунча миллеге әзерләүнең бөтен шартын яза.

Менә хәзер мәктәптә укучы егетләрнең күбесе сызгыра белми. Минем бу турыда уйлап та караганым юк иде. Булек белән танышкач, мин моның сәбәбен бик тиз аңладым, хәзер авылларда ат калмаган, ат көтәсе, ат эчертәсе юк икән. Шуңа күрә егетләр дә сызгырырга өйрәнми калалар икән!

Язучы үз әсәрендә авылларда сакланып калган төрле йолалар, гореф-гадәтләрне шулкадәр матур итеп сурәтли, бу йолаларны бүген дә уздырып карыйсы килә башлый. Көлдә бәрәңгене дә Мәһдиевчә пешереп ашыйсы килде, анысын этиемә кушарга булдым.

Мәһдиев иҗатында мәдәни мирасыбызның сакланышын ачыклар өчен, мин авторның берничә хикәясе белән дә танышып чыктым. Шуңа игътибар иттем, Мөхәммәт Мәһдиев үз хикәяләрендә халык җырларын да, төрле авторлар тарафыннан язылган җырларны да күп файдаланган. Мин укыган “Арслангали” хикәсендә Мөхәммәт абый без хәзер дә яратып җырлый торган “Матур булсын” җырын куллана. Бу хикәя 1968 нче елда язылган. Автор бик җиңел тел белән мәктәп тормышын сурәтли. Аның һәр җөмләсе елмаю тудыра, укыган саен укыйсы килеп тора. Хикәянең төп герое –укытучы Мәлик. Ул һәрвакыт дәрескә соңга калып килүче, гел “аркылыга” үсүче Арыслангалине тәртипкә өйрәтергә тели. Нинди генә чаралар кулланып караса да, уңышсыз булып чыга. Укытучыны Арыслангалиның җыр яратуы коткара! Мөхәммәт Мәһдиев татар халык җырын Арыслангалидан шулкадәрле матур итеп җырлата, әсәрне укыганда шул җыр колакка ишетелә дә, үзең дә сизмәстән, кушылып җырлап җибәрәсең!

...Илебезнең халыклары

Матур тормыш коралар.

Тыныч булсын, тыныч булсын,

Тыныч булсын дөньялар!..

Инде танылган артист булгач та, Арыслангали татар халкының “Матур булсын” җырын зур сәхнәләрдән башкара. Карт укытучы Мәлик радиоалгычтан шушы җырны башка бер тапкыр да дәрескә соңга калып килмәүче Арыслангали башкаруында тыңлый.

Мөхәммәт Мәһдиев бу хикәясенә башка бер җырны да кертә алган булыр иде. Тик халкыбызның тынычлык яратуын ул шушы хикәясендә тагын бер тапкыр искә ала. Хикәя үзе дә, халкыбыз җырлары да бүгенге көндә бик актуаль шул. Башка бик күп әсәрләрендә дә Мөхәммәт Мәһдиев җырларга мөрәҗәгать итә. Мәдәни мирасыбыз булган җырлар Мәһдиев әсәрләре аша безгә килеп җитә. Менә мин буген, шыпырт кына шушы җырны көйләп йөрим:

Тыныч булсын, тыныч булсын,

Тыныч булсын дөньялар!..

Язмамны да “Без-41 нче ел балалары” әсәрендәге сүзләр белән тәмамлыйсым килә. Бу сүзләр буген дә бик зур әһәмияткә ия, дип уйлыйм мин.

“...Юк, мондый табигате булган, мондый чыдамлыгы булган халык беркайчан да, беркемгә дә кол булмас! Мондый таңы, мондый һавасы булган халык иң зур бәхеткә- ирекле, тук тормышка лаек”.

**Әдәбият**


1. М. Мәһдиев. “Әсәрләр”, Милли әдәбият китапханәсе, “Мәгариф” нәшрияты, 2005ел-270 б.
2. М. Мәһдиев. “Язучы турында замандашлары”, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2004 ел-144 б.
3. “Без бит –Арча яклары” Арча төбәге әдипләре иҗаты, 9-11 нче сыйныф укучылары өчен хрестоматия, Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2016 ел-323 б.
4. Бөек тукай Ватаны син-Арча. – Казан: “Яңалиф” нәшрияты, 2007. – 328 б.


## УКЫТУЧЫМ ИҖАТЫНДА КҮҢЕЛ МАТУРЛЫГЫ


**Гарифьянова Р.В.**

Сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 9 нчы Зәй мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Хәйретдинова Р.Җ.


Роза Җәмил кызы Хәйретдинова 26 елдан артык гомерен балалар укытуга багышлаган. 26 ел күп тә, шул ук вакытта аз да. Мин “9нчы Зәй мәктәбе”нә укырга килгәнемә дә дүрт ел. Укытучым мине беренче көннән үк күреп, шигырь дөньясына алып кереп китте, чөнки ул иҗади кеше. Мин өч ел укытучым канаты астында, ул мине шигырь сөйләү осталыгына өйрәтә, мин елдан - ел шигырь сөйләү техникасын шомартам,

шигырь сөйләү үзенчәлекләрен ачам, нәтиҗәләребез дә куандыра. 2021нче елда укытучымның “Ак бүре” нәшриятында “Күңел тәрәзәләре” дип аталган китабы дөнья күрде. Шигырьләрнең тәрбияви ягы әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия. Шагыйрә табигать матурлыкларына укучыларын юнәлтә, дөрестән дә табигать матурлыкларын күргән кешенең начарлык эшләргә кулы бармый. Шигырьләре гади матур тел белән, балаларга аңлаешлы итеп язылган.

Уйнаклап-күбәләкләп,
Бөтерелеп-әйләнгәләп,
Сарылып-сырылып
Бии кар - буран [Хәйретдинова 2021: 21].

Шушы матурлыкка кереп эрисе килә. Матур туган җиребез нинди матур! Һәр ел фасылы кешегә үзенчә тәэсир итә, балачак мизгелләренә илтә, кечкенә малай белән берлектә сары тузганаклы дөнья белән танышасы килә.

Мин дәторамсокланып,
Гүясабыйчагымакайтып.
Сары тузганаклыболында
Ауныйсым килә ятып [Хәйретдинова 2021: 18].

Кеше табигатьтән аерылгысыз, аның иҗатында үз хис - кичерешләрен күрсәтүдә табигать күренешләре зур урын алып тора. Авыр чакларында шагыйрә табигатькә мөрәҗәгать итә, җанына тынычлык эзли һәм ул аны зәңгәр күкләрдән таба да.

Ак хыялларымочар канатөсти,
Зәңгәркиңлекләргә,күккәдәшә.
Мин битсиңадус, югарыгаоч, ди,
Биеклеккә уз, киңлекләрне коч, ди [Хәйретдинова 2021: 16].

Дуслыкны без уйлаганча, гади итеп күзалламый ул, ә дусның нинди булырга тиешлеген ачыклап бирә, төптән уйлап карасаң, дус “Дуслык кадере” ндәге кебек булырга тиеш тә.

Күңелем ташып җырлар җырлаганда,
Кушылып җырлый белергә дус кирәк.
Ипигә дә акчам бетте дип уфтанганда,
Азаккысын биреп бүлешергә дус кирәк [Хәйретдинова 2021: 5].

Ә язлар ничек матур сурәтләнгән, чөнки шаулы язлар белән сөекле шагыйребез Г. Тукай кайта, тирә - юньгә хуш ис тарата.

Гөрләвекләр кушылып җырлый
«Туган тел»е гимнына.
Сыерчыклар мактап сайрый
Сөекле улы Тукаена [Хәйретдинова 2021: 19] .

Туган җирне яраткан кеше генә үз иленең ватанпәрвары була ала дип уйлыйм мин. Бар нәрсә яратудан башлана, ә ятратканда никадәр матурлыклар тылсымлы ишекләрен ача, син бар эшкә, укуга җаның -

тәнең белән чумасың, күңелеңә хуш килгән шөгыль табасың, бар нәрсә синең кул сузымында була.

Матур ел фасылларым –
Сары көзем, аккышым,
Яшелязым, алсуҗәем,
Барысы – туганҗирем! [Хәйретдинова 2021: 20]

Укытучы апамны еллар узган саен, мәктәп тормышы, балалар дөньясы бөтереп алып кереп китә, укытучы һәрвакыт эзләнүчән укытучы булып кала. Ул безне - укучыларын олы тормышка әзерли һәм киләчәк өчен борчыла, һәр язмыш аның күз уңаенда.

Чал чәчләрен, маңгай сырларын
Күрсәтергә теләмичә, көлемсерәп,
Уйлары белән балачакка кайтып,
Укытучы басып тора, уйга батып.
Бөтенесе – аның күңел көзгесе...
Еллар шавы, гомер җыры өлгесе.
Бу һөнәрдә күпме кеше язмышы!.. [Хәйретдинова 2021: 26]

Мин шундый остазым булу белән горурланам. Роза Хәйретдинова югары белемне Алабуга педагогия институтында алган, ул бик тәвәккәл, бик күп бәйгеләрдә катнаша һәм җиңү яулый, аны республика күләмендә дә беләләр.

Әйтелмичә калган
Уйларым бар.
Сөйләнмичә калган
Сүзләрем бар.
Җырланмыйча калган
Җырларым бар.
Монда бар да бар!.. [Хәйретдинова 2021: 4]

Укытучым фикере белән йомгаклыйсым килә: сүзләр әйтә белү – иң зур бәхет, сүзләр таба белү – зур гыйлем, ә матур сөйләм - күңел бизәге. Һәрвакыт күңелебез матур булсын, үзебез бизәкле булыйк!

### Әдәбият

1. Роза Хәйретдинова - Мөсәгыйтова Р.Җ. Күңел тәрәзәләре.– Казан: Ак бүре, 2021. – 64 б.

# РӘДИФ ГАТАШ ПОЭЗИЯСЕНДӘ МИЛЛИ ҺӘМ ГОМУМКЕШЕЛЕК ПРОБЛЕМАЛАРЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

**Гатиятуллина Ю.С.**
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.к.,доц. Габидуллина Ф.И.

Рәдиф Гаташ шигъриятендә гомумкешелек өчен әһәмиятле темалар, проблемалар да күтәрелә. Аеруча калку чагылыш тапканнардан түбәндәгеләргә чыгарылыш квалификация эшебез кысаларында махсус игътибар бирелә:

– гомумкешелек кыйммәте буларак мәхәббәт белән бәйле проблематика;

– кече ватанга мәхәббәт темасы. Биредә без туган авыл, газиз әнкәй кебек образлар белән бәйле шигырьләрне дә карыйбыз;

– гомер, вакыт агышы, хәятнең кыйммәте белән бәйле фәлсәфи проблемалар;

– тарих, хәтер, халыкка хезмәт категорияләре белән бәйле проблемаларны үз эченә алган шигырьләр.

Рәдиф Гаташ шигърияте белән таныш булган һәр кешегә дә мәгълүмдыр: ул барыннан да элек мәхәббәткә дан җырлаучы. Аның лирик герое – тормышка да, гүзәл затларга да гашыйк шәхес. Иҗатының беренче чорына ук караган “Кеше – гашыйк” дип исемләнгән шигырендә ул һәркемнең сөеләсе килү, шуңа һәркемнең ашыгып сөюе турындагы фикер әйтелә.

Җир кешене һәрчак ашыктырган
Гасыр, еллар буе.
Ашыгып сөя кеше, аннан ашыгып
Уза, диләр, туе [Гаташ 2009: 3].

Әмма лирик герой уфтанып, гел зарланып яши торган кешеләр рәтеннән түгел, ә киресенчә, ул тормышка гашыйк, аңа сөю бүләк иткәне өчен рәхмәт кенә укый. Рәдиф Гаташ мәхәббәт эзләрен табигатьтә дә, җырларда да күрә. “Үзең итсәң дә, табигатьтә сүзең” шигырендә ул сөйгән ярын сагына, хатирәләргә чума. Хатирәләр төс яфрак булып күңелгә бәреләләр:

Юк, һәр яфрак синнән сәлам – кулъяулык.
Миләшләрне назлап үбәм – кулга алып [Гаташ 2009: 76].

Гашыйк күңеле түзми, мәхәббәт хисенә түз алмыйча, тезләнеп дога укый башлый. Соңгы юллардагы сүзләрдән аңлашылганча, биредә сөйгән яр Аллаһы Тәгалә һәм пәйгамбәрләр белән бер дәрәҗәгә җиткереп тасвирланган:

Дога укыйм тезләнеп – күктә күзем.
Өн ишетәм, валлаһи, синең сүзең [Гаташ 2009: 76].

Дога мотивы “Бу – сиңа кылган дога” шигырендә дә алгы планга чыга. Шагыйрьнең мәхәббәте шул кадәр зур, олы, ул үзе өчен түгел, сөйгәне, гүзәл кыз өчен Ходайга ялвара:

Раббым, иркә яз гөлеңә
Үзгәрмәс пакьлек бир.
Дөнья керен тидермәслек

Илаһи сафлык бир.
Ялварам: тел ачкычы бир
Сөю–имтиханда.
Үзең терәк бул ул ялгыш
Атлау ихтималда [Гаташ 2009: 56].

Әмма җор телле гашыйк зат үз мәнфәгатьләрен дә онытып бетерми: шушы ихлас догачыңны онытсаң Ходай сине кичерә алмас, дип кисәтеп тә куя.

Рәдиф Гаташның лирик герое күбрәк – җавапсыз мәхәббәткә дучар булган егет. Яшь аермасы булсын, күз аткан кешесенең башка яры булу булсын – алар кавыша алмыйлар. Лирик герой беркайчан да мәхәббәтне таләп итми, бергә булуга ирешер өчен ачулану–янау кебек алымнар сайламый. Аның бәхете – мәхәббәтнең үзендә, сагышлы булса да, ярата белүе белән бәхетле ул. Без моны "Бәхетле бул!" дип исемләнгән шигырендә аеруча ачык күрә алабыз. Лирик герой сөйгәненә туй көнендә бәхет теләп кала:

Сиңа багышланган шушы җырлар
Бәхетләргә озата барсын сине!
Туй атына таккан кыңгыраудай,
Сискәндереп шатландырсын сине
Җаныңа үтеп кергән көе белән... [Гаташ 2009: 16].

Ул бәхет теләп кенә калмый, хәтта үзен – мәхәббәттән шашар дәрәҗәгә җиткән үзен бу көнне искә төшермәскә куша. Мондый гамәлне ул – "үз–үземне җиңә алдым, ахры" дип аңлата. Аны бердәнбер үтенече – сөекле затның бәхетле яшәве.

Искәртеп үтәргә кирәк: шагыйрьнең шашкын мәхәббәт җырчысы булуы, бер яктан, җәмәгатьчелекне җәлеп итә, икенче яктан, сөйгәнен пәйгамбәр, Аллалар белән бер дәрәҗәгә куюю кискен тәнкыйть ителә. Шагыйрь Аллаһы исемен дә искә алса да, фольклорчы галим Ф.И. Урманче аны күбрәк мәҗүси шагыйрь дип таный, әмма биредә дә лирик геройның, шагыйрьнең мәҗүси кануннарны да мәхәббәт хакына бозуына каршы чыга. Сөйгән ярны "Тәңре"дип атаган шигыренә каршы Ф.И. Урманче болай искәртә: "Тик шулай да шагыйрь биредә "көфер сүзләр" дә әйтеп ташлый: үзенең сөйгәнен "Тәңремдер син!" дип куя. Бу сүзләр Тәңречелек мифологиясенә дә, Ислам тәгълиматына да туры килми: Тәңрене дә, Аллаһны да беркем белән дә чагыштырырга, бигрәк тә тиңләштерергә ярамый!" [Урманче 2003: 137].

Нәтиҗәләргә килеп шуны ассызыкларга мөмкин: Рәдиф Гаташ шигъриятендә мәхәббәт гомумкешелек кыйммәте беренче урынга чыга. Аның мәхәббәте ешрак моң, сагышка уралган, кайчак ул җавапсыз мәхәббәт, кайчак лирик герой сөйгәненә башка яр белән бәхет теләп кала, әмма һәрвакытта да шагыйрь ярату сәләтен югалтмый. Фәлсәфи лирикада шагыйрь вакыт агышы, шушы агыш дәвамында ирешкән һәм ирешмәгән казанышлары, намус сафлыгы турында уйлана. Аерым урынны кече Ватан, газиз авыл, арышларга мәхәббәт җырлаган мөлаем лирик әсәрләр алып тора. Кече Ватан – диңгез булып туарга

көч биргән чишмә белән чагыштырыла. Әдипне дөнья күләи барган тарихи–фаҗигале хәлләр дә битараф калдыра алмый.

**Әдәбият**


1. Гаташ Р.К. Гөлтуран: шигырьләр, газәлләр, робагыйлар, төрки шагыйрьләр иҗатыннан үрнәкләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 109 б.
2. Гаташ Р.К. Сайланма әсәрләр: 3 томда. 1 нче т.: шигырьләр, лирик цикллар, шигъри хатлар / кереш сүз авт. Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 239 б.
3. Гаташ Р.К. Сайланма әсәрләр: 3 томда. 2 нче т.: шигырьләр, поэмалар / кереш сүз авт. Р.Зәйдулла. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 271б.
4. Гаташ Р. Сайланма әсәрләр: 3 томда: 3 нче т.: Хиссият аятьләре / кереш сүз авт. Р.К. Ганиева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 352 б.
5. Урманче Ф. “Олыгайгач, бер дога” (“Борынгы миф һәм бүгенге шигырь” циклыннан: Рәдиф Гаташ иҗаты турында) // Казан утлары. – 2003 . – №4. – Б. 135–142.


## ЙОЛДЫЗ МИҢНУЛЛИНАНЫҢ ШИГЪРИЯТЕ ҺӘМ ПОЭТИКАСЫ


**Закирова Г.И.**

Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәният ара багланышлар институты студенты

Фәнни җитәкче: Каюмова Г.Ф.


Йолдыз Миңнуллина – хәзерге яшь буын шагыйрьләр арасында әйдәп баручы рольне уйнаучыларның берсе ул. Зыялы тәрбия, яшьтән әдәбият, сәнгать дөньясы эчендә үсү, Казан дәүләт университетында белем алу, юлында яшь иҗатчылар белән нәтиҗәле, ихлас күңелдән эшли белә торган шәхесләр – Галимҗан Гыйльманов, Илфак Ибраһимовлар очравы нәтиҗәсендә татар әдәбияты күгендә чын яңа йолдыз кабына. Яңалык – шигъриятктә яңа шагыйрь килүдә генә түгел, ә әдәбиятка яңа сулыш, яңа форма, яңа эзләнүләр һәм яңа иҗат алымнарын алып керүендә дә чагылыш таба.

Аның иҗатының тематик диапазонына килгәндә, ул темаларның киңкырлылыгы белән түгел, ә аларны оригинальяңгыратуы белән аерылып тора. Биредә фәлсәфи тема үзен шактый сиздерә. Мондый әсәрләрендә шагыйрә кешелек, яшәү мәгънәсе турындагы фикерләрен катлаулы образ–символлар аша җиткерә. Шунысы үзенчәлекле: мәгънәләрне бөтен тирәнлегендә ачу өчен укучының әзерлекле булуы таләп ителә, бу яктан аның шигърияте интеллектуаль әдәбиятка да якын тора. Мәхәббәт темасына караган шигырьләрендә дә фрагментарлы бирелеш нәтиҗәсендә мәхәббәт тарихы түгел, ә ул уяткан хисләр, ешрак моң, әрнү, газап кебекләр барлыгы ачыклана. Туган җир, ата–ана турындагы шигырьләрне еш очрый дип әйтеп булмый, монда беркадәр яшь буынның глобальләшү һәм интегральләшү чоры шәхесе, аңа бер шәһәр, бер ил генә түгел, бар дөнья кызык. Шуңа да карамастан, милли тема

әсәрләрендә үзенчәлекле яңгырый. Шагыйрә тарихи дәверләргә мөрәҗәгать итә, тарихи хәтерне активлаштыра, шул чорлардагы сабаклардан гыйбрәт алырга ашыга һәм укучысын да шуңа чакыра. Милли темага язылган әсәрләрендә дәүләт мөстәкыйльлеге, туган телне саклап калу мотивлары да шактый актив яңгырый.

Шагыйрә метафора, чагыштыру һәм сынландыру кебек алымнар белән эшләүнең чын остасы. Алар шигырьләргә үзенчәлекле яңгыраш, эмоциональлек өстәп кенә калмыйлар, аларны анализлау вакытында, әсәрнең яңа мәгънәләр катлаумы ачыклана. Йолдыз Миңнуллина иҗатында мифологик образ–символлар, интертекстуаль бәйләнешләр, эпиграфлар аерым кызыксыну уята. Шундыйлардан әсәрләрендә ана бүре, Ашина, Искәндәр–патша, Децебел, Иса һ.б. атарга була. Шагыйрә интертекстуаль бәйләнешләр аша хәзерге яшь шагыйрьләр (Луиза Янсуар һ.б.лар), үзләреннән өлкән буын әдипләре (Зөлфәт), рус һәм Европа әдипләре (Марина Цветаева) белән диалогка керә.

Йолдыз Миңнуллина шигырьләре ритм һәм рифма яңгырашы ягыннан да үзенчәлекле. Тикшеренүебез дәвамында шигъриятендә иҗек ритмик системасы роль уйнамый, ритмның, Владимир Маяковский шигырьләрендәгечә, сүзләр, сүз саны хасил итә, дигән нәтиҗә ясадык. Рифмаларга килгәндә, төгәл һәм якынча рифмаларның ешлыгы күзәтелде. Шагыйрә иҗатында шигырь юлы ахырында гына түгел, ә башында, уртасында да сүзләр рифмалашып килә ала. Тагын бер кызыклы күренеш буларак аерым шигырьләрдә татар һәм рус сүзләренең рифмалашуын атар идек.

Йолдыз Миңнуллина иҗаты үзеннән соң килгән яшь буын шагыйрьләргә дә йогынты ясый, аның алымнары, иҗади үзенчәлекләре, традиция булып формалаша башлый. Йолдыз Миңнуллинаның шагыйрь генә түгел, ә шагыйрьләрне үстерүче "әдәби агент" ("литературный агент") буларак та эшчәнлеккә тартылуын искә алганда, аның милләтебез мәдәнияте үсешенә керткән өлеше бәхәссез зур, дип әйтә алабыз.

**Әдәбият**

1. Юсупова Н.М. 2017 нче елда татар шигърияте: стиль тенденцияләре һәм жанрлар үсеше // Фәнни Татарстан. – 2018. – №1. – Б. 66–75.

2. Юсупова Н.М. XXI гасыр башы татар шигърияте: үсеш–үзгәреш тенденцияләре // Национальные литературы в контексте культурной интеграции: Сборник статей Международного круглого стола, Казань, 09 июня 2021 года. Том Выпуск 3. – Казань: Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2021. – Б. 313–321.

3. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Раннур, 2002. – 352 б.

4. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

5. Миңнуллина Й.Ф. Күк тирмәсе: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 47 б.
6. Миңнуллина Й. Чана юлы – ком. Кытыршы // Казан утлары. – 2019. – №8. – Б. 184.

## АВЫЛ ТОРМЫШЫН СУРӘТЛӘҮ ОСТАСЫ БУЛАРАК Р.ТӨХФӘТУЛЛИН

**Мәткаримова А.Х.**
Әлмәт шәһәре 13енче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Гарипова А.Ш.

Һәр кешенең туган җире бар. Ә күпчелек өчен бу туган шәһәре, авылы. Татар язучы һәм шагыйрьләренең күбесе чыгышы белән авыл балалары. Шундый авыл балаларының берсе – танылган язучыбыз Рафаил Төхфәтуллин. Ул Арчадан төньякка таба егерме чакрымнар җир китеп урнашкан Яңа Иябашның күршесендә генә Тукай–Кырлай урнашкан. Мәшһүр Казан арты бу! Тукай үз әсәрләрендә дан җырлаган табигатьле Казан арты.

Җир һәм кеше... Алар гел икәү бергә булган, аларны бер–берсеннән аерып карау мөмкин дә түгел. Кеше җирне тыңлаучанрак, мәрхәмәтлерәк һәм уңдырышлырак итә барган. Җир кешеләрне хезмәт сөючән, сабыр һәм түзем булырга өйрәткән, аларның холкын, табигатен үзгәрткән. Һәр җирнең үз табигате булган кебек Казан артында да аерым бертөрле табигать. Анда шактый басынкы һәм тыйнак, ифрат дәрәҗәдә тырыш һәм унган, хезмәт сөючән, җиргә гашыйк кешеләр формалашкан. Рафаил Төхфәтуллин нәкъ шундый кешеләрнең берсе. Аның әсәрләрен укыганда , шул якларның сабыр холыклы эшчән кешеләре белән очрашасың, барыннан да бигрәк, данлы Казан артының үзгә бер сулышын, рухын тойгандай буласың. Р.Төхфәтуллин күп санлы әсәрләренең нигезендә шушы табигать балаларының язмышы ята.

Язучының иҗатында күпчелек сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышы сурәтләнә. Р.Төхфәтуллин ул – берничә пьеса, унлап повесть, йөздән артык хикәя, очерк, рус һәм татар телләрендә басылган утызлап китап авторы. Аның «Җәйге челләдә», «Авылым хикәяләре», «Йолдызым», «Зәңгәр кыңгыраулар», «Җиләкле аланнар» кебек китаплар зур тиражлар белән басылып, ил күләмендә бәя алалар.

Аларда шул авыр һәм кырыс елларга хас тормыш күренешләре теркәлеп калган: кыйшаеп җимерелергә җиткән терлек абзарлары; ябык сыерлар һәм арык атлар; рәтләп эшкәртелмәгән, шуңа күрә чүп үләне басып киткән иген кырлары...

Болар белән беррәттән тулы канлы, катлаулы характерлар, тормышчан образлар иҗат итә. Ул укучыга җиргә карарга, халыкның матурлыгын гәүдәләндерерлек әйбәт кешеләрне, ат караучылар, балта осталары арасыннан эзләргә өйрәтә.

Әмма күп санлы һәм күп төрле сыйфатлар арасыннан аеруча әһәмиятлесе, иң мөһиме – язучы әсәрләренең тормышчанлыгы. «Р.Төхфәтуллин уз геройларының характерын, холык–фигелен һәм язмышын тормыш шартларына бәйләп, шулардан аерылгысыз итеп күрсәтә алды. Җир һәм кеше, колхоз һәм колхозчы, алар арасындагы мөнәсәбә, аларның үзара бәйләнеше һәм бер–берсенә йогынтасы– язучы әсәрләренең буеннан–буена кызыл җеп булып, сузылган төп сыйфат», – дип яза Фәрваз Миңнуллин автор турында.

Рафаил Төхфәтуллин – авыл язучысы һәм туган җирдән беркайчан да аерылып китмәс шикелле. Авылның сугыштан соңгы кыенлыкларын әдәбиятта яшермичә, турыдан–туры ачып салучыларның да беренчеләрдән ул булды. Тормышның чын күренешләрен сүрәтләү әдип иҗатында гаҗәеп бер лирик рух, эчке җылылык, самимлек белән аралаша. Шуның әсәрләренең берсе – «Йолдызым» повесте.

«Йолдызым» повесте үткәннәрне искә төшерү юлы белән язылган. Бу алым кулланып язылганлыгы белән бу повесть авторның тагын бер әсәре булган «Авылдашым Нәби» белән бик охшаш, ләкин аерымлыгы да бар. «Йолдызым» повесте – тирән эчтәлекле, актуаль тема һәм проблематикалы әсәр. Бу повестьнең идея–эчтәлеге дә үзенчәлекле. Ә ул үз чиратында авторның иҗади осталыгына бәйләнгән.

Алда әсәрнең идея–эчтәлеге өстендә сөйләшү алып барырбыз. Иң беренче нинди генә әсәрне кулга алсак та без аның исеме белән танышабыз. Чөнки нинди исемле булуы бик зур әһәмияткә ия. Һәр кешенең исеме ниндидер мәгънәгә ия булган кебек китапның, әсәрнең исеме дә безгә бик күп нәрсә турында мәгълүмат бирә. Автор аны ни өчен шулай атаган? Ул бу исем укучысына нәрсә әйтергә теләгән? Бу сорауларга укучы әсәрне уку процессында җавап таба ала.

«Йолдызым» исеме – символик исем. Йолдыз – күк җисеме. Ул – өмет һәм иман, ышаныч символы. Димәк, әсәрдә дә геройлар өмет, ышаныч, иман белән яшәячәкләр. Һәм бу шулай да.

Р.Төхфәтуллин үз повестен, алда әйтелгәнчә, үткәннәрне искә төшерү алымы белән язган. Әсәр түбәндәге сүзләр белән башланып китә: «Әни, әни, дим! Нигә минем исемне Йолдыз дип куштыгыз?... » Кызының әлеге соравы төп героиня Гөлзифаны үткән тормышын хәтерләргә мәҗбүр итә. «Йолдызым» повесте төп геройның бер көндә гомерен иңли. Без Гөлзифаның бер көн эчендәге уй–хисләре, кичерешләре белән танышабыз, шулар аша үткәндәге бөтен тормышы белән танышып чыгабыз. Әсәрдә җир һәм кеше язмышы мәсҗәләсе үзәккә куела, аларның аерылгысыз булуына басым ала.

Бу бәйләнешне күрсәтүче герой – Гөлзифа. Ул үзенчәлекле кеше. Автор бөтен әсәрдәге вакыйгаларны, образларны аның кичерешләре аркылы бирә. Бу әсәрне аңлаешлы, тирән мәгънәлештә ясый.

Гөлзифа – эшчән, тырыш, чөнки ул эштә үсә, чыныга, тәрбияләнә. Бу – авыр, ялгыз, физик хезмәт – сугыш елларында совет хатын–кызларның һичкайчан онытылмаска тиешле батырлыгы. Биредә хезмәтнең романтикасы,

матурлыгы, героикасы хакында уйланырга мөмкинлек тә, вакыт та юк. Чөнки башкача була алмый, башкча мөмкин дә түгел. Әгәр Гөлзифалар эшләмәсә, фронт ашсыз, җылы киемсез калачак. Гөлзифаның үзе турында, киенү, ясану кебек уйларына вакыты юк. Аның бар уе тагы да тырышыбрак эшләү генә. Җиңү хакына башкарылган бу батырлык әсәрнең патриотик яңгырашын билгели.

Чыннан да, моннан ике–өч еллар элекке оялчан гына, юка гына Гөлзифа түгел инде ул хәзер. Буйга әллә ни калыкмаса да, бу тыгыз, йомры гәүдәдә ташырга торган көч–куәт һәм сүнмәс дәрт сизәсең. Бармак төпләре уймак–уймак чокырлы бу куллар чыбыркы–дилбегәсен булсын, чалгы–тырмасын, балта–пычкысын булсын, нык итеп, җаен–әмәлен белеп тоталар; кечерәк кенә кытыршы гена бу куллар җил–салкынны уйлап та бакмый, тырналу–сыдырылуны бар дип тә белми...

Авторның хезмәт кешесенә олы ихтирамы бу әсәрдә дә ачык сизелә. Чын кеше– ул хезмәт кешесе, дигән төп фикер потрет билгеләре аша да гәүдәләнә.

Р.Төхфәтуллин героиняның нык характерлы, гадел, дөрес кеше икәнлеге хакында сөйли. Әсәрдә без Гөлзифаның һәртөрле ялганга, хаксызлыкка каршы көрәшкә чыгуына да, мәхәббәттә тугрылык сакчысы булганына да сокланып карыйбыз.

Әсәрдә автор үз идеясын тапшыру өчен башка образларны да куллана. Бу – Мөнир Гарапшин, Шәрәфи абзый, Җиһангирлар. Аларга капма–каршы Мортаза, Хәмдиев, Идрисовлар куелалар. Аларның үзара конфликтлары аша автор дөреслек барыбер җиңәчәк, ә ялган соң булса да фаш ителәчәген күрсәтә. Ничек кенә авыр булса да гаделлек өчен көрәшергә кирәк дигән идея үткәрә.

Автор һәр образның үзенә генә хас характерлы якларын тапкан, иң мөһиме, иң әһәмиятлесе шул: ул әлеге образларның фәлсәфәсен, аларның чын йөзен дөрес күрсәтә алган. Уңай геройлары аркылы автор иң четерекле мәсьәләсен берсе булган колхоз авылын аякка бастыру, аны үргә алып менү мәсьәләсен күтәреп чыга. Р.Төхфәтуллин бу кыенлыклар, авырлыклар турында «Йолдызым» повестена кадәр дә яза. Ләкин аның сәбәпләрен бер яклый гына карый. Ә «Йолдызым» повестенда язучы бу мәсьәләне яңадан күтәрә һәм шактый уңышлы хәл итә. Гөлзифалар колхозының язмышы бер заман бик тә әйбәт кешеләр кулына күчә: председатель итеп Шәрәфи абзый сайлана, Гөлзифаның үзен бригадир итеп куялар. ВЛКСМның райком секретаре Мөнир Гарапшин да хәттә искиткеч шәп кеше була. Әмма аңа карап кына Гөлзифалар колхозы алга китми. Р.Төхфәтуллин бары тик бергә, күмәк рәвештә үз–үзеңне аямыйча, тырышып эшләсәң генә, бу эшнең нәтиҗәсе булачак дигән фикер үткәрә.

Әсәрдә тагын кабатланып килгән мәсьәләләрнең берсе Давыт образы белән бәйләнгән. Колхоз эшен ташлап шәһәргә качкан, тегендә–монда китеп, акчалырак эшкә урнашкан кешеләр турында яза Р.Төхфәтуллин. Давыт – каршылыклы образ. Аны тискәре герой дип карау хата булыр иде, чөнки ул беткән җан түгел. Кайчандыр Давыт авылда иң алдынгы укучылардан саналып

йөргән. Халык арасында абруе да зур гына үзенең, намуслы һәм әдәпле дә. Кәефе булганда, җир җимереп эшләүдән дә курыкмый, кулыннан эш килә. Әгәр тормыш җай гына барса, кыенлыклар белән очрашырга туры килмәсә, кем белә, бәлки, алар Гөлзифа белән әйбәт кенә яшәгән дә булырлар иде. Ләкин тормыш авырлыксыз булмый. Хатыны белән чагыштырганда аның ихтыяр көче бик зәгыйфь була. Вакытлы кыенлыклардан чыгу юлын алар икесе ике төрле аңлыйлар. Гөлзифә авылны яхшырту, колхозны ныгыту ягында. Тормыш авырлыклары алдында куркып, каушап калган Давыт шәһәргә качып котылмакчы була. Ләкин үзеңнән качып булмый бит. Давыт тиз үзгәрүчән, аумакай табигатьле кеше. Бу – аның эшкә һәм укуга мөнәсәбәтендә дә, кешеләргә мөнәсәбәтендә дә ачык күренә. Давыт кебек, авылдан шәһәргә качып, анда кыенга туры килә башласа, кире авылга кайтырга теләүчеләрне аклап та, аларга ышанып– таянып та булмый дигән автор фикерен күрәбез без Давыт образы аша.

Р.Төхфәтуллин “Йолдыз” повестенда бер генә деталь да, бер генә вакыйга да, бер генә күренеш тә юкка гына бирелми. Бу әсәр лирик буяуларга, мәгънәле, күп сыйдырышлы эмоциональ– психологик детальләргә бай. Мондый детальләр күп очракта табигать бизәкләрен кешенең рухы, эчке дөньясы белән янәшә куеп, сынландыру рәвешендә биреләләр.

Гөлзифаның омтылышы – бәхет йолдызы – «Йолдызым» повестеның буеннан– буена үтә, бу образ героиняның нык ихтыярлы, максатына ирешүчән булуы хакында сөйли. Икенчедән, буш хыял түгел бу. Аның конкрет чагылышы – халыкка хезмәт итеп, ил–җәмгыять арасында лаеклы урын табу, дан–хөрмәткә ирешүендә яисә кыенлык белән яулаган гаилә бәхете – кызчыгы Йолдызы образында да күренә.

Тагын әсәрдәге бер детальнең булуы игътибарны үзенә тарта. Гөлзифа үзенең сөйгәненә һәм башка фронтовиклар өчен бияләйләр бәйли. Ул узенең күз нурын түгеп бәйләгән әйберләре белән фронт тормышын әз генә булса да җиңеләйтмәкче була, йорт җылысын өләшергә тырыша. Ә сөйгәненә хәбәр бирү өчен һәр бияләй эченә «Д.Г» дигән хәрефләрне ефәк җеп белән чигеп куя. Ләкин бу бияләй Давытка эләкми, ә Мөнир Гарапшинга фронтта килеп эләгә. Язмыш үзе алдан ук кисәтеп куйганлыгын Гөлзифә соңыннан гына аңлый. Бу бияләй Мөнир өчен йолдызы кебек үк була. Ул аның авыр көннәрдә, дәһшәтле сугыш вакытларында бердән– бер өмет, киләчәккә ышаныч бирүче әйбере – «йолдызы» була. Автор бу детальләр аркылы кечкенә генә нәрсә дә кеше язмышында зур роль уйнавын күрсәтә.

Р.Төхфәтуллин геройлары өчен туган–үскән җир табигате – тормышларының аерылгысыз, органик бер кисәге. Табигать әсәрнең идея– эчтәлеген бирүдә әһәмиятле өлешләрнең берсе булып тора. Табигатьтәге үзгәрешләр һичшиксез геройланың уй–кичерешләре, хисләре, эчке халәтләре үзгәрү белән бәйле.

«Көндезен җепшетеп, кичке салкын белән чиратып җибәргән аяк асты атлаган саен кетердәп– кетердәп кала, чана табаны эзләре буйлап аккан

гөрләвекләр күпереп–күпереп торган челтәрләргә әверелгәннәр, ә якында гына, Ашыт суы ягында, тыелгысыз бер гөрләвекнең һаман да челтерәп акканы ишетелә иде. Елга, узенең бу арымас шат нәни юлдашын тәбрикләгәндәй, куәтле–моңсу ухылдап куя, бу ухылдау кичке тынлыкта еракларга яңгырый; яңгырый да уң яктагы Чагыл таулары аңа җавап бирәләр, гүя, әйдәгез, бердәмрәк, дип дәрт–куәт авазы салалар кебек иде. Яз, бернигә карамый яз килә иде...»

Бу, әлбәттә, яз килү күренеше генә түгел. Бирелә Гөлзифаның күңел халәте дә сизелә. Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә күңел ачкычы булып һәрвакыт табигать күренеше хезмәт итә. Бу очракта без әлеге язны Гөлзифа кичерешләре, аның карашы аша кабул итәбез. Табигатьнең һәр үзгәрүе әсәрдәге вакыйгалар үзгәрүенә ишәрә ясыйлар. Моңа берничә мисал.

1.«Кояш шундый якты, шундый нурлы итеп елмая иде ул көнне, бар кешеләр дә шундый ягымлы, шундый әйбәт иделәр. Кулларга эш төткәзеп булмый, аякларга басып торыр урын табып булмый иде».

2.«...Көн аяз, кояшлы иде бугай, юл ташлары өстеннән бөтерелә–бөтерелә гөрләвекләр челтерәп ага иде шикелле. Ә асфальт тротуарлардан, гүя тирләгән ат сыртыннан, җиңелчә пар күтәрелә иде... Юк, көн һич тә аяз түгел, киресенчә, кап– кара болытлы көн иде, ахры. Гөрләвекләр дә челтерәми, бу шулай Гөлзифаның колаклары чыңлый иде бугай. Көне дә, бөтен дөньясы да томанга чумган иде. Кешеләр шул томан эченнән килеп чыгалар да шунда ук күздән югалалар, тагын күренәләр, тагын каядыр чумып юк булалар...».

Ә бу өзекне укыгач без ниндидер начар, җан өшеткеч вакыйга булуын аңлыйбыз. Бу өлешендә әсәрнең Гөлзифаның үзенең мәхәббәтен югалтуы сурәтләнә. Аның кичерешләрен, кайгысын бары тик табигать кенә аңлый бу вакытта.

Ләкин автор табигатьтән оста файдалану белән генә чикләнми, ул Гөлзифага ярдәмгә «таныш булмаган дус» кертә. Бу кешенең булуы, аның эмоцианаль ярдәмен тоеп яшәү героиняга каршылыкларга, кыенлыкларга ярдәм итә, яшәргә көч бирә. Ә кешегә башка кешенең ярдәмен тоеп яшәү бик мөһим нәрсә.

«Таныш булмаган дус» үзенә карата Гөлзифадан берни дә өмет итми, барын аның бәхетле булуын гына тели. Ләкин шул ук вакытта кайчан булса да аның мәхәббәтенә лаек булырмын дип яши. Һәм чын да бу түземлелек язмыш тарафыннан бүләкләнә – ул Гөлзифаның иң олы рәхмәтләренә лаеклы.

Автор белән героиняның уйлау, фикерләү рәвешләре, дөньяга карашлары да бер–берсенә бик якыная. Әсәрнең беренче кисәгендә автор белән Гөлзифа уйлары, кичерешләре узара тыгыз аралашкан, шушы алым ярдәмендә төп тема һәм идеяны ачардай барлык иҗади чаралар эшкә җигелә. Әсәрнең икенче өлешенә куйган проблемалар исә башка төрлерәк чаралар сорый – авторның бу өлештә үз сөйләме күбәя.

Әсәр ахырында композицион тигезлек кими башлагандай була, бу Гөлзифа тарихының озагракка сузылуы белән бәйли. Шулай дә әсәрнең азагы

оптимистик тоны, повестьның җанлы, табигый сулышы, яңгырашы өзенең ышандыру һәм тәэсир көчен арттыра гына.

Киң психологик анализ тарафдары Рафаил Төхфәтуллин бу повестенда хисләр, уйлар дөньясын эчтән яктырту алымын оста куллана. Бу әсәрнең идея–эчтәлеген бирүдә төп чараларның берсе. Шул ук вакытта автор башка чараларны да оста куллана. Р.Төхфәтуллин сурәтләвендәге күп санлы, мәгънәле деталь–штрихлар героиняның күңеленең олылыгын укучыга җиткерәләр. Кыен язмыш сынауларын үтүче кешегә теләктәшлек, үз итү хисләре белән беррәттән соклану хисләре дә уята.

Әсәрнең эчтәлеге әлеге чаралар ярдәмендә үзеннән–үзенә йомгак кебек вакыйгалар сүтелү рәвешендә ачылып бара. Повесть үзеннән–үзе укылып бара, укучы аңа бары тик ияреп кенә бара төсле. Бу әсәрнең язылу теле белән дә бәйле.

Әсәрнең язылу теле гади, аңлаешлы. Автор повестенда сүрәтләү чараларын урынлы кулланган. Метафораларның, чагыштыру, сынландыруларның бай булуы әсәрнең яңгыраш көчен тагы да арттыра. Ә бу исә әсәрнең идея – эчтәлеген ачуда зур этәргеч булып тора үз чиратында. Повесть төзелешен камиллегенә китерә.

Бу әсәрне укыгач, аның белән җентекләп танышкач бер нәрсә ачык күренә: сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышы турында язганда, Рафаил Төхфәтуллинның каләме тиңдәшсез иде. «Шул чор тормышы, аның кешеләре хакында никадәр әсәр иҗат итә. Ифрат отылышы әдәби детальләр, тотып–капшап карыйсы килерлек дәрәҗәдә җанлы һәм тормышчан булып чыккан образлар дисеңме, күңелнең әллә кай төшләренә барып җитәрлек җылылык кирәкме, гаять актуаль, барлык кешеләрне борчып–уйландырып килгән мәсьәләләр дисеңме – һәммәсе дә бер аның хикәя, повестьларында»,– дип яза аның әсәрләре турында Фәрваз Миңнуллин.

Чынлыкта да бу шулай. «Йолдызым» повесте – шул тормышка, шул чорга караган әсәрләрнең иң югары ноктасы. Сугыш һәм сугыштан соңгы колхоз авылына караган күзәтүләренең иң мөһим, иң әһәмиятлеләрен автор нигездә шушы әсәргә кертеп бетерә, аның авыл тормышы турындагы борчылу–уйлануларның да иң зур һәм иң төп өлеше шушы повестька сыеп бетә дияргә мөмкин.

Бу әсәрнең идея – эчтәлек ягыннан камил булуында ук күренеп тора. Р.Төхфәтуллин әсәрдә куелган проблема, мәсьәләләрне чишү рәвешендә әсәрнең идеясын биреп бара. Бу Гөлзифаның тормышы, аның кичерешләре аркылы бирелә. Кеше авырлыкларны, үз җилкәсенә, башына килеп төшкән кайгы–хәсрәтне, кыенлыкларны сыгылмыйча, сынмыйча күтәргәндә генә үз максатына ирешә ала. Бары тик горур рәвештә хакыйкатькә тугры булып, үз намусыңны, вөҗданыңны югалтмыйча, тап төшермичә яшәсәң генә бәхетле булырсың дигән идеяны ассызыклый Рафаил Төхфәтуллин.

Повестьның тәрбияви көче дә искиткеч. Төп героиняның сыйфатлары аркылы автор үз укучыларына, иң беренче чиратта, сабыр булырга куша. Юкка

гына татар халкы: «Сабыр төбе – сары алтын»,– димәгән бит. Бары тик сабыр кешеләр генә үз теләгәннәренә ирешә алалар. Икенчедән, максатчан булу зарури, әгәр дә кешенең киләчәктә берәр уңышка ирешеп үз теләген тормышка ашырырга уйлый икән, аның һичшиксез үз алдына максат куюы кирәк. Өченчедән, һәрвакыт үз туган җирен, туган туфрагын, кендек каны тамган җирен яратырга тиеш. Бары синең туган җирең булса гына, син чын мәгънәсендә узеңне бәхетле итеп саный аласың. Түбәндәге шәхси сыйфатлар бүгенге көндә бигрәк тә актуаль. Әсәр шушы ягы белән дә бик кыйммәтле.

Әсәрдә, гомумән алганда, чорның актуаль мәсәльләләре, өлгергән проблемалар күтәрелә, җәмәгатьчелек игътибарын шуларга юнәлтүе күренә. Р.Төхфәтуллин моның белән генә чикләнеп калмый, үзе күтәргән һәр мәсәльәләнең конкрет җавабын һәм чишелешен таба. һәр мәсьәләнең чишелешен дә табарга тырышу аркасында язучы кайбер җитди мәсьәләләрне чишү юлларын гадиләштереп, җиңелләштереп бирергә мәҗбүр була. Тик шунысы һичшиксез: повестьның идеясы ачык күренеп тора. Әсәрнең төп идеясы бары тик үз эшеңне, үз туган җиреңне, туфрагыңны яратып үз халкың өчен хезмәт иткәндә бәхетле була аласың дигәннән гыйбрәт. Бу идеяны ачуда, алда әйтелгәнчә, Р.Төхфәтуллин образларны (оста файдалана) табигать күренешләрен, вак детальләрне, вакыйгаларның алмашуын оста файдалана. «Йолдызым» повесте – татар әдәбиятында үз урынын тапкан әсәр.

**Әдәбият**


1. Миңнуллин Ф. Талантлар юлы – Казан: Татар кит. нәш., 1984.
2. Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында – Казан: Татар кит. нәш., 1994.
3. Сверигин Р. Язучының күңел кыңгыраулары. Р.Төхфәтуллинның лирик прозасы турында – Казан: Татар. кит. нәш., 1985.
4. Төхфәтуллин Р. Сайланма әсәрләр.– Казан: Хәтер, 2003.


## Г.УТЫЗ–ИМӘНИ ҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫ.


**Салахова С.Р.**

Лениногорск шәһәренең 4 нче урта мәктәп укучысы

Фәнни җитәкче: Мортазина А.Ф.


“Утыз Имәни исемен югалтырга ярамый. Аның шәхесен һәм әдәбиятыбызны бизәрлек иҗатын без бүгенге һәм киләчәк буынга танытырга тиеш. Утыз Имәнинең тирән фәлсәфи әсәрләрендәге кайбер юлларны ятлап, муенга бөти итеп тагып йөртерлек. Әмма аның хакында сөйләшүләр галимнәр арасында, тар даирәдә генә калмасын иде. Утыз Имәни исемен матбугатта, телевидениедән ешрак яңгыратырга кирәк. Халкыбыз үзенең улы – нинди фикер иясе барлыгын белергә лаек”. КДУ профессоры Хатыйп Миңнегуловның шагыйрь һәм дин гыйлеме белгече, мөгаллим Габдерәхим Утыз Имәнигә карата әйтелгән сүзләрен бүгенге конференциянең цитатасы итеп кулланырга мөмкин.

Шагыйрь Габдерәхим Госман улы Утыз Имәни Чистай өязе Утыз Имән авылында мулла гаиләсендә 1754 елда туа. Оренбург Каргалысында, аннан

Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укый. Харәзм, Әфганстаннарда сәяхәт итә. 1798 елны туган авылына кайтып, башта Тимәш, аннары Сарабиккол, Куакбаш авылы мәдрәсәләрендә укыта. Ахырда Тимәштә төпләнеп, гомеренең ахырына кадәр шунда яши, мөдәррислек эшен дәвам иттерә.Утыз Имәни туры һәм тапкыр сүзле, көчле характерлы шәхес булган, "Габдерәхим хәзрәт сүз сөйләргә бик тә сәләтле улып, кулындагы чукмары вә агызында чукмарыннан да куәтле теле улып, нә дөнья вә нә дин тугрысында бәхәс иткәндә җиңелеп калмамыштыр", –ди аның турында Ризаэддин Фәхреддин. Ул халык күңеленә туры сүзле, мөхтәрәм "Габдерәхим хәзрәт" буларак кереп кала. Аның тапкырлыгы, зирәклеге һәм үткенлеге, үзенчәлекле эш– гамәлләре турында күп санлы легендалар йөри.

XVIII гасыр азагында дөньяга килгән Габдерәхим Утыз Имәнине галимнәр татар әдәбияты тарихында ике гасырны тоташтыручы рухи күпер дип атый. Әдип йөздән артык әсәр язган. Аларның шактый өлеше гарәп һәм фарсы телләрендә. Әсәрләре арасында шигырьләреннән тыш тел, фәлсәфә, әхлак–хокук, сәүдә–экономика, медицина, астрономия мәсьәләләренә караган гыйльми хезмәтләр дә була. Әдипнең шигъри әсәрләреннән киң даирәгә иң мәгълүм булганы – «Мөһиммәтез–заман» («Заманның мөһим билгеләре») поэмасы. Ул аерым китап булып 1889 елда басылып чыга. Әсәр, тулысы белән әхлак мәсьәләләренә багышланып, кешеләрдә булган кимчелекләрне тәнкыйтьли, аларны белемле–мәгърифәтле булырга, үзара тату яшәргә, сабыр һәм инсафлы булырга, олыларга һәм кечеләргә, гариплəргә һәм мохтаҗларга мәрхәмәтле булырга чакыра. Күргәнебезчә, болар барысы да әхлакый сыйфатлар. Димәк, күңеленә шушы сыйфатлар хас икән, ул нурлы һәм якты булачак. Менә каян килә икән ул хәзерге вакытта кулланышка кергән сүзләр: нурлы өй, нурлы йөз.

Г.Утыз Имәни фикеренчә, белем– кеше идеалының зарури сыйфаты, бәхет ачкычы. Утыз Имәни белем төшенчәсен һөнәр, эш–гамәл белән тыгыз бәйләнештә карый. Шагыйрь карашынча, хакимият ияләренең, кеше белән идарә итүчеләрнең белемле, һөнәрле булулары зарури. Авторның идеалы – белемле, укымышлы, гадел, киң күңелле, сабыр, әхлаклы кеше. “Белем һәм акыл”,–ди автор – кешене кеше итә, әгәр бу сыйфатлар юк икән, ул–хайван мисалында”.

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.
Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә,
Баш ияләр һәрвакыт белемлегә.

Күрәсең, нәкъ шул гыйлемне булдыруда, ул–муллалар хөкемендә калмаска, ә мөстәкыйль өйрәнүне һәркем алдына бурыч (фарыз) итеп куя. Бу юлда нинди тапкырлыклар, тырышлыклар күрсәтү тиешлеген, «Гаварифез–заман» әсәрендә үзенең чит илләрдә–горбәттә нинди кыенлыклар кичереп, тырышлыклар күрсәтеп күренекле галим булып җитешүе мисалында күрсәтә.

Утыз Имәни инде законлашып беткән дини тәртипләрнең халык тормышыннан ераклыгын анлап кына калмаган, ә бәлки үзендә шул шәригать тәртипләрен үзгәртергә, аларга реформа–төзәтүләр ясарга житәрлек дәрәҗәдә көч һәм кыюлык таба алган.  Хөкем сөргән ислам дине тәртипләреннән, башка галим укымышлыларның өйрәтмәләреннән аерылып торган үз юлын, үз сукмагын барлыкка китергән. Ул юл халык арасына «Утыз Имәни мәсләге» исеме белән таралган.

Утыз Имәни мәсләге ислам дөньясында шактый зур резонанс тудырган. Мәсәлән, У. Беляева күрсәтүенчә, «Утыз Имәнинең бу карашлары үз вакытында татар дөньясын шаулаткан. Казандагы реакцион руханилар арасында аңа карата дингә ревизия ясаучы кеше чыккан дип гауга таралган. Доноср биреп, замандашлары аны төрмәгә дә яптырганнар. Ләкин үзе үлгәч тә, аның бу идеясе дәвам иткән һәм фикердәшләрен патша чиновниклары хәтта тикшергәләп торганнар» [Беляева 1956: 17]

Габдрәхим мәсләгенең нигезендә шагыйрьнең дини мәсьәләләр белән килешмәве, алар белән бәхәскә керүе ята.Шагыйрь үзеннән алда яшәгән укымышлылар сүзенә сукырларча иярмәүне яклый, фикергә хокук, акыл һәм зиһенгә ирек таләп итә.

Шагыйрь мәсләгендә күтәрелгән икенче бер мәсьәлә шул чор мәдрәсәләрендә тормыш өчен кирәкле булган фәннәр укытуга карый. Ул чор мәдрәсәләрендә шәкертләргә күбрәк дин белеме, ислам тарихы,гарәп  сарыфы, мантыйк,  идеалистик фәлсәфә, формаль логика, хикмәт укытканнар. Һәр күренешкә үзенчә карарга өйрәнгән Габдрәхим мондый хәл белән килешә алмаган. Ул яшь буынга әнә шундый формаль фәннәр укытып, аларны уку йортларыннан тормышка яраксыз кешеләр итеп чыгаруга каршы протест белдергән. Кирәксез өйрәтмә итеп шагыйрь идеалистик фәлсәфә һәм формаль логика фәннәрен саный. Шагыйрь болар урынына ислам юриспруденциясен укытуны алга куя, чөнки бу фән, шагыйрь карашынча, дөньяви тормышка, халыкның көнкүрешенә билгеле бер дәрәҗәдә якын тора, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә тәртип урнаштыра, тыныч һәм тату яшәүгә ярдәм итә. Шагыйрьнең мондый карашлары «Гаварифез–замана"' шигырендә чагылыш таба. Ул анда мантыйк ише фәннәр өйрәнүне шәригать күнекмәләре белән сыешмый торган эш итеп күрсәтә. Шул ук әсәрдә Габдрәхим үз чорындагы укымышлыларның  фәнгә кирәкле дәрәҗәдә игътибар бирмәүләрен тәнкыйтьли. Шагыйрьнең максаты – җәмгыятьнең матур һәм төзек яшәвенә ирешү, тормыштагы гаделсезлекләрне булдырмау.

Шагыйрь күтәргән мәсьәләләр, ул куйган таләпләр шул чор татар тормышы өчен яңа булып санала. Шагыйрьнең иҗатын характерлый торган зур күләмле әсәрләреннән берсе «Тәнзипел–әфкяр фи нәсаихел–әхъяр», ягъни «Фикерләрне пакьләндерә торган игелекле үгетләр» дип атала. Габдрәхим бу әсәрендә барыннан да элек үз дусларының икейөзле булуларыннан, бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләүләреннән зарлана, замандашларының белемнәре бертөрле булып та, гамәлләре шуңа туры килмәүгә борчыла.Биредә авторның

урта гасыр Шәрекъ галимнәре кебек үк, үз мәсләгенә, үз карашларына ияргән шәкертләр булдырырга, ягъни фикердәшләр тәрбияләргә омтылышы сизелә. Ул дин кешеләрне бер–берләреннән аера, ихтыярсыз, ирексез ясый дигән каршылыклы фикер әйтә бер әсәрендә,ләкин аны көчләп такмый, кешеләргә уйланырга да, үз фикерләрен әйтергә дә урын калдыра.

Патша хөкүмәте үз дәүләте карамагындагы күп халыкларга, шул исәптән татар халкына карата да милли–колониаль политика үткәреп килде. Бу политика еш кына бик тупас рәвештә, халыкларның милли хисләреннән көлү, көчләп руслаштыру, чукындыру рәвешендә алып барылды, һәм, әлбәттә, патша хөкүмәтенең мондый политикасы изелүче халыклар арасында ризасызлык тудырды. Каюм Насыйри бу хакта болай ди: «Янә риваять кылалар, Габдрәхим хәзрәт әйтер икән: «Русиядә тереклек кылучы мөселманнарга кырык бер фарыз –кырык беренчесе – урысча белмәк»,— диер икән».[Насыйри 1974: 23].

Габдрәхим ул чорда төрле халыкларның милли һәм дини аерымлыкларга карамастан, бер–берсе белән аралашып яшәргә омтылулары ачыграк күренә барганын әйтә.

Габдрәхим Утыз Имәни әл–Болгари күпкырлы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге, бай иҗат мирасы белән зур хөрмәткә һәм ихтирамга лаек шәхес. Аны халкыбыз тарихында–бөек шәхес, шигърияттә–яңа сүз әйтүче каләм иясе, иҗтимагый фикер тарихында яңа карашларга күпер салучы дип таныйлар.

**Әдәбият**

1. Беляева У.И. Творчество Утыз Имяни.– Казан: Таткнигоиздат, 1956.
2. Забиров Җ. Утыз Имәни иҗатына күзәтү. – Казан, Таткнигоиздат, 1989.
3. Насыйри К. Казан календаре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.
4. Фәхреддин Р. Асар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1954.
5. Шәрипов Ә. Габдерәхим Утыз Имәни. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.
6. Шигырьләр, поэмалар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

## АЛИЯ ЕМАКОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ӘХЛАК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Феткуллова А.К**.
Чувашия Республикасы беренче номерлы
Шыгырдан урта мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Айзатуллова Р.Р.

Татар әдәбияты талантлы язучыларга, шагыйрь, драматургларга искиткеч бай. Әдәбият дәресләрендә, сыйныфтан тыш чараларда авылдашларыбызның иҗатлары белән даими рәвештә танышып барабыз. Авылыбызның горурлыгы Рөстәм Сүлти, шагыйрьләребез Кәлиф Вәлиди, Гөлчәчәк Юсупова, Мөнир Нигъмәтуллов, язучы Алия Емакова. Татар әдәбиятында танылган якташларыбызның иҗаты да читтә калмый: Фәтхи Бурнаш, Кави Латыйп, Җәүдәт Сөләйман, Дамир Гыйсметдин.

Минем кулымда Алия Емакованың “Язмыш камчысы” исемле парчалар җыентыгы. Җыентыктагы әсәрләрне зур кызыксыну белән укып чыктым. Күңелгә үтеп кергән әсәрләрнең авторы белән якыннанрак танышысым килде. Шуңа күрә Алия апа белән очраштым һәм күңелемдә булган сорауларга җавап алдым.

Алия Ибатдин кызы Емакова 1957 елда Шыгырданда туа. Мәктәп елларында ук шигырьләр яза башлый һәм беренче тәҗрибәләре Батыр район газетасы “Авангард”та басылып чыга. Шулай ук тәүге иҗат җимешләре “Ялкын” журналы һәм “Яшь ленинчы” газетасы битләрендә дөнья күрәләр. 2009 елга кадәр Алия Ибатдин кызы Сембер төбәгендә яшәүче дин һәм кардәшләребез өчен чыгып килгән татар газетасы “Өмет”тә армый–талмый фидакарь хезмәт итә.

Алия апа иҗатының төп юнәлеше – милләтәшләребез тормыш–көнкүрешен һәрьяклап яктырту. Әмма кемнедер күккә чөеп мактаудан азат ул. Беренче чиратта, героеның эчке халәтен, яшәеш турында уй–фикерләрен, әхлакый сыйфатларын, тирә–юньдәгеләр белән мөгамәләсен күрсәтергә омтыла. Җәмгыятебездәге тискәре күренешләрне ачыклаеп һәм фаш итеп, вөҗдан, намус хөкеменә чакыру осталыгы да сокландыра. Тормыш тарафыннан кыерсытылган, кыйналган затларның ачы язмышын тасвирлау белән генә чикләнми, шушы халәтнең тирән сәбәпләренә төшендерә, хакыйкатькә гадел, туры карарга өнди. Килен–каенана, ата–аналар һәм балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең чыганакларын эзли.

“Язмыш камчысы” җыентыгындагы әсәрләрне берничә төркемгә бүлеп карап була. Җыентыкның шактый өлешенаналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдырган әсәрләр тәшкил итә.

Ана исеменә лаек аналарга карата ихтирам, хөрмәт, олылау хисләре белән язылган әсәрләргә “Ана бәхете”,“Иңендә ай урагы...”, “Язмыш камчысы”н мисал итеп китереп була.Ана мәхәббәте могҗизалар тудыра! Ана баласы хакына утка да, суга да керергә әзер. Ана балалары бәхетле булганда гына бәхетле була ала. “Ана бәхете" әсәрендәге анага кайгы килә. Улының хәле авыр, үлем хәлендә.Заһирә апа улына үз бөерен тәкъдим итәргә уйлый. Тикшерүләр үткәннән соң, табиблар ананың бер бөерен улына куярга мөмкин дип табалар. Ана үз тормышын куркыныч астына куярга да риза, бары баласы гына исән–сау булсын. Операция уңышлы үтә, улы терелә.

Алия Емакова әсәрләрендә ана – изге зат. Ул аларның гүзәллегенә дан җырлый. Хатын–кызга ана булудан да изге тойгы юктыр. Язучының "Ипи кыерчыгы" әсәренә игътибар итик. Монда ике ананы күрәбез. Берсенең дүрт баласы булуга карамастан, ул һаман исерек, ирләр белән тәртипсез тормыш алып бара. Балалары бер ипи кыерчыгын бүлешә алмыйча сугышалар. Өсләре пычрак.

Икенче ана – үз анам, ди автор. Сигез бала анасы. Эчү түгел, ул турыда уйларга да вакыты юк, көне – төне уракта. Чуенда пешкән кабыклы бәрәңге, бер шешә сөт биреп, яшь ярымлык баласын да калдырып, кырга китә. Ә үзе – бала

имезүче ана. Алып барган ашамлыгын да, балалар сорар дип, кире алып кайткан.

Әти–әниләренә карата мәрхәмәтсез булган кешеләрне без “Дәгъва”, “Тәрәзәдә күзләрем...”, “Эзлим әнкәй эзләрен...”, “Упкын”әсәрләрендә күрәбез.

"Эзлим әнкәй эзләрен...” әсәрендә Хәйри төш күрә. Төшендә әнисе: "Бодаеңны чәчәргә оныттың, улкаем", –ди. Бодай– игелек мәгънәсе. Димәк, яхшылык эшләр вакыт үтеп бара.

Шәрифә әби ике ул үстерә. Уллары ир уртасына җиткәндә, карчык сукырая, хәлсезләнә. Ике бертуган ызгыша, берсе дә әнисен карыйсы килми, сугышып бетәләр. Ахырда әниләрен адаштырырга уйлыйлар. Рамазан аенда авыз ачу мәҗлесенә үзебез озатабыз дип, аның адашып туңасына ышанып, каберлекләр арасына кертеп калдыралар. Озак йөри торгач, ана кырый йортка килеп чыга. Үз өенә кайтасы килмичә, бер атна хаста ята да, дөнья куя.

Еллра үтә. Хәйри әнисе кабере янында яшь түгә. Иреннәре туктаусыз пышылдый: “Кичер мине, әнкәй, зинһар гафу ит”.

Безнең кадерле кешеләребезгә борчу–хәсрәт китерергә хакыбыз булмаса да, хәзерге көндә дә үз әти–әнисең рәнҗеткән, олыгайган көннәрендә тәрбияләмәгән, картлар йортында яшәткән бәндәләр бар. Ул аналар да, таянычым булыр дип, өметләнеп, үзе кимәгәнне кигезеп, үзе капканчы баласына каптырып үстергән бит. Кеше ата–анасына нәрсә күрсәтсә, баласы аңа шуны күрсәтер.Без ни эшләсәк тә, аналар кичерер, ә аларны рәнҗеткән өчен ходай кичererме?

"Бер йотым су" әсәрендә Хәерниса әби алты бала үстерә, биш кыз, бер малай. Ире сугыштан кайтмый. Чәче белән җир себерсә дә, балаларын ким – хур йөртми. Кызлар кияүгә китә, малае өйләнә. Килен үз кагыйдәләрен урнаштыра, ә үзе "әни" сүзен әйтергә дә авырсына. Ирен “әйдә, читкә китик”, – дип котырта. Ләкин ир әнисенең аларны нинди авырлыклар белән үстерүен хәтерли. “Яңгыр түгел, таш яусын, сине барыбер ташламам”, – дип әнисенә сүз бирә. Бервакыт Хәерниса әби салкын яңгыр астына калып чылана. 40 градус белән ята, улы гына чәй биреп тора. Ләкин малае эш кешесе. Бер йотым суга аптыраган мизгелләре дә була ананың. Карчык терелә.Килен бала таба. Ләкин үзе каты авырый. Әби көн–төн аны карый, имчәк баласын тәрбияли. Килен дә аякка баса. Үзенең хаталарын аңлап, кайнанасыннан гафу итүне сорый.

әнисенә дә ихтирам белән карарга тиеш. Чөнки ул үстергән бит аны.

Тормышта килен һәмкайнана арасында төрле килешмәүчәнлекләр күп булуын күрәбез. “Фирүзә кашлы алка”да сукырайган Мөшфикә карчыкны килене Ниса ишегалдындагы сарайга чыгара. Көннәрен карчык сарай почмагындагы караватта иске–москыга чолганып үткәрде. Ә Ниса эштән арып кайткан иренә һаман әнисен яманлады.

Мөшфикә карчык үлеп китә. Кырыгын үткәреп җибәрүнең икенче көнендә үк, яшен сугып, Нисаның өе янып китә. Янгын вакытында Ниса киленнең кул–аяклары пешә, бер күзе сукырая. Ул сыкрап–әрнеп кайчандыр карчык яткан караватта иске–москы өстендә ауный.

Олыларга карата мәрхәмәтле булырга өйрәтә торган әсәрләр арасына “Язмыш камчысы” әсәрен мисал итеп китереп булыр иде. Авыр сугыш еллары. Кышның зәмһәрир суык көнендә ачлыктан шешенгән бичара карчык күршесе Фәхернисаның бусагасына килеп егыла. Ире Мингалимне сугышка озатканнан бирле көне–төне колхоз эшендә Фәхерниса. Өйдәге 4 баланы ашатырга санаулы бәрәңге, санаулы икмәк. Тик шулай да кычыткан ашы, крахмалга әйләнгән бәрәңге ашасалар да, сукыр карчыкны урамга куып чыгармыйлар. 9 ел буе Гыйльмиҗиһан карчыкның урыны түрдә була. Ялгыз әбине тәрбияләгән вакытларда сабыйлар күңеленә миһербанлылык орлыклары чәчелә. 92 яшенә җиткән Фәхернисаның да урыны түрдә.

Әсәрне укыганнан соң, шундый авыр вакытларда да мәрхәмәтле кешеләрнең ялгыз карт һәм карчыкларны ярдәмнән калдырмауларына гаҗәпләнәсең. Чөнки бүгенге мул тормышта чит кешеләргә ярдәм кулы сузу түгел, үз эти–әниләрен дә тәрбияләмәүче, картлар йортына тапшыручы кешеләр дә бар.

Ә Шыгырданда хәлләр ничегрәк соң? Мин авыл администрациясенә мөрәҗәгать иттем. Безнең авылда да ялгыз картлар һәм карчыклар бар.

Шунысы куанычлы, Шыгырдан авылыннан картлар йортында тәрбияләнүчеләр юк.

Олыларга карата җылы мөнәсәбәт гаиләдә кечкенәдән ук салына. Гаиләләрдә балалар әби–бабай белән тәрбияләнәләр. Элек–электән үк бала тәрбияләүдә әби–бабайларның өлеше әйтеп бетергесез зур. Алар оныкларында туган телебезгә, халкыбызның гореф–гадәтләренә, йолаларына мәхәббәт, югары әхлак сыйфатлары тәрбияләгәннәр.

Тормыш бик катлаулы. Кеше кайчак күп уйлап тормыйча, ниндидер зур хата эшләп ташларга булдыра ала. Хикәяләр арасыннан яшьләрне төрле ялгышлар эшләүдән кисәтергә теләгән кебек язылган әсәрләргә “Күке яше”, “Сулган гөл”, “Упкын”, “Мамуля, сәлам!” хикәяләрен китереп була.

"Сулган гөл" хикәясендә яшь вакытта эшләнгән хата турында сүз бара. Әхнәф шофер. Хатын–кызны бик тә ярата. Кичкә калып кайтучы авылдашы Зөләйханы утыртып кайта һәм юлда мәсхәрәли. Кызның киләчәк язмышы, кимсетелүе, алдагы көннәренең караңгы булуы аны һич борчымый. Зөләйха бала таба.

Еллар уза. Тормыш дәвам итә. Менә беркөнне Әхнәфнең Казанда укучы кызы соңлап кайта. Поездда аңа бер исерек бәйләнә. Шул чак янәшәдәге егет кызны яклап кала, өенә кадәр озата. Ә егет Зөләйханың улы була. Әхнәф, Ниязның Зөләйха малае икәнен белгәч, мендәргә капланып елый. Ул вөҗдан газабы кичерә.

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, эти–әни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзеңдә булдыру өчен Кеше булу кирәк.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, Алия Емакова әсәрләрендәге әхлак тәрбиясе кешеләргә яхшылык эшләргә, игътибарлы һәм ихтирамлы булырга, кыенлыклар алдында бөгелеп төшмәскә өйрәтә.

**Әдәбият**

1. Алия Емакова “Язмыш камчысы”, – Ульяновск, 2000.
2. Алия Емакова белән әңгәмә.
3. Шыгырдан авыл администрациясеннән мәгълүмат.

## Д.КАЮМОВА ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ТУГАН ЯК ТАБИГАТЕ

**Шакурова К.А.**

Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Минһаҗева Р.М.

Татар илендә Алабуга бик борынгы шәһәрләрдән санала.Ике гасырлык тарихы булган төбәгебез бик күп күренекле кешеләргә очар өчен канат биргән: Н.А.Дурова, И.И. Шишкин, М. Цветаева, Т. Гыйззәт, Э. КасыймовХабра Рахман, Фазыл Шәех, Гөлзадә Әхтәмова, Фәридә Хәбибрахманова, Владимир Мироваев...Шәһәребезнең иҗат шәхесләре турында сүз алып барганда, Дибәҗә ханым Каюмованы искә алмау мөмкин түгел.Ул– шагыйрә, прозаик, юморист, композитор, педагог, журналист, публицист.Фәнни эшемдә Дибәҗә Каюмованың лирик әсәрләрендә, шигъриятендә туган як темасының бирелеше турында сөйләргә телим.

Нинди гасырда яшәсәк тә , туган як темасы, минемчә , актуальлеген югалтмый. Чыгышымда Дибәҗә Каюмова шигырьләрендә туган як темасының бирелешен яктыртырга тырышырмын. Күңел лирикасы– нигезендә кешенең шәхси тормыш–яшәеше, хыял–өметләре, халәте–тойгысы белән бәйле хис–кичереш ята торган лирик жанр. [Заһидуллина 2004:160]

Дибәҗә Каюмованың “Йөрәк серләрем”, “Гомеремнең бетмәс моңы” җыентыкларында “күңел тарихына” бай шигырьләр тупланган. Бу шигырьләрне укыгач, Дибәҗә Каюмованың күңел дөньясын күрәсең, күңел күзенең дөньяны үткен итеп күрүен ачыклыйсың,туган ягын, кешеләрне, табигатьне, үз милләтен яратуын аңлыйсың.

«Унбер кыз, унбер малай» нәсерендә елларның авырлыгын язылган юллар аша тоясың. Дибәҗә апа «дөньяның иң җылы болыннарга–кулләргә бай бер почмагы» − туган авылын тасвирлый, дус, бердәм классташларын искә ала, күңел төбендә онытылмаслык булып уелып калган кайбер вакыйгаларны искә төшерә. Алар барысы да тормышчаң, табигый, су буенда самовар чистарту, Сөтлә атавында гөлҗимеш җыюлар, аны кул арбасы белән ташу − болар барысы да сугыш чоры баласының башыннан узган хәлләр[ “Алабуга нуры” газетасы, №121, 23 нче октябрь , 1997 нче ел.]

Дибәҗә ханымны башкалар белән бутау мөмкин түгел, ул лирикасында да, балалар шигъриятендә дә үзе булып кала белә. Табигый яза. Өянкеләргә ефәк шәл бүләк иткән кышы да, җәе дә, көзе дә табигый аның. Чөнки шагыйрә үзе дә “чәчәкле алан, былбыл бакча”. Хәтта ки Яңа ел аеның урагын да такыя итеп башына кияргә мөмкин ул...”, –дип яза Рәшит Бәшир. Мөхтәрәм язучыбыз

безне үзебезнең туган йортыбызны, халкын сөяргә, моңлы татар җырларын яратырга,бай табигатен сакларга чакыра. Шагыйрә туган ягын изге догалы як, нурлы як дип атый.Лирик герой “Тамырларым белән авылда мин” шигырендә авылының һәр каены, тәрәзәсе, чишмәсенең аңа кадерле булуы турында әйтә, тамырлары авылдан булуы белән горурлана.Ул әткәсе–әнкәсенең кабере белән дә аңа кадерле.

Тамырларым белән авылда мин.

Зәңгәр күген сагынам, күлләрен.

Нинди генә җирдә булмадым мин.

Андый гүзәллекне күрмәдем.– дигән юлларында туган якны сагыну, аның гүзәллегенә соклану хисләрен күрәбез. Дибәҗә Каюмованың туган ягына багышланган шигырьләре җылы хисләр белән тулы.”Актанышым”,”Тамырларым белән авылда мин”,”Туган ягым”,”Авылыма кайткан идем”,”Сагыну”,”Авылым үзгәргән”,”Туган авылым белән хушлашу”,”Үземнеке”,”Нурлы Мортым”,”Морт чишмәләре” шигырьләре шундыйлардан. “Сагыну” шигырендә туган якны сагыну хисе сурәтләнгән, чөнки язмыш лирик геройны чит җиргә ташлаган һәм ул гомере буе туган ягын сагынып яши.Хис–кичереш белән бәйле образ– туган як образы.Лирик герой күңелендәге сагыну хисе соңгы строфаларга, үсеп, рәхмәтле булу, ярату хисенә үзгәрә.Лирик герой туган авылын бәллүр бишеге дип атый.Дибәҗә Каюмова шигъриятендә чагыштыру, сынландыру, эпитет–метафоралардан, риторик эндәшләрдән иркен файдалана.”Үземнеке” шигырендә шатлык–куаныч хисе горурлык хисенә , киләчәккә теләккә үзгәрә.Куаныч хисенең сәбәбе– яз килүе , һәр якты таңга сөенү.Икенче строфада горурлык хисенең сәбәбе– туганң җиреңң үзеңнеке булу.Өченче строфада лирик геройның үз җирендә җырлап гомер итүеннән канәгатьлек хисе сурәтләнә һәм күңеленә эндәшүен күрәбез.Ул үзенең күңелен төшенке булмаска чакыра.

Шигырьләренең темасы: Туган як, туган йортыбыз,туган авылыбыз, ватаныбыз гомер–гомергә кешеләр өчен илһам чыганагы, яшәргә көч һәм дәрт бирүче, күңел терәге.

Идеясе: туган ягыбызны онытмыйк, аның белән горурланыйк, кадерен белик, аның киләчәге,кешеләре өчен файдалы гамәлләр эшлик!

III. Йомгаклау.

Чыннан да , Дибәҗә Каюмова –Алабуга төбәгенең күпкырлы талантлы шәхесе, туган як җырчысы.Мин Дибәҗә Каюмова иҗатының туган як, Алабуга төбәге турындагы шигырьләренә тукталдым һәм бу шагыйрәнең күңел байлыгының искиткеч булуын аңладым.Дибәҗә Каюмованың шигырьләрен укыганнан соң, шагыйрәнең көчле рухлы, туган ягына, иленә тугрылыклы булуын аңлыйсың.Аның кайбер шигъри юлларын үзебезнең яшәү девизы итеп аласыбыз килә.

**Әдәбият**

1. “Алабуга нуры” газетасы, №121, 23 нче октябрь , 1997 нче ел.

2. Заһидуллина Д.Ф.Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы.– Казан:Мәгариф, 2004.–367 б.

3. Каюмова Д.К.Гомеремнең бетмәс моңы.–Алабуга, 2003.– 8б.

4. Каюмова Д.К. Йөрәк серләрем.– Яр.Чаллы: Хәерле иртә,1999.–160б.

5. Чыгарылыш сыйныф укучыларының имтиханда язган сочинениеләре.– Казан: РИЦ, "Школа", 2003.–296 б.

## XIX ГАСЫР ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНҮЧЕ ГАЛИМНӘР ЭШЧӘНЛЕГЕ: ГАЙНУЛЛИН М.Х., ГАЙНЕТДИНОВ М., СӘГЪДИ Г. ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ XIX ГАСЫР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫНА МӘНӘСӘБӘТ

**Шәйхетдинова Ә.Р.**

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты.

Фәнни җитәкче: Каюмова Г.Ф.

XIX гасыр татар әдәбиятының үткән юлын игътибар белән карасаң, аның халык тормышының көзгесе икәнлеген күрәсең. Баштагы чорларда (1790–1830) анда наданлыкны бетерүгә, тәнкыйтьләүгә юнәлтелгән әсәрләр урын алса, икенче дәвердә (1830–1880) ул халкыбызның әхлагын яхшырту юнәлешендә хезмәт итә. Өченче дәвердә исә, җәмгыятьнең яңа баскычка күтәрелүе, тормыш шартларының үзгәрүе нәтиҗәсендә, иске йолаларның зәхмәтле богауга әйләнә баруын тасвирлый һәм аны үзгәртү юлларын тәкъдим итә [Әхмәтҗанов, 2001: 316].

XIX йөз татар сүз сәнгатен өйрәнүгә М.Госманов, М.Гайнетдинов, Г.Сәгъди, Х.Миңнегулов, М.Әхмәтҗанов, Ә.Сибгатуллина, Ф.Бәширов, И.Гомәров хезмәтләрендә киң урын бирелә. Әлеге эш кысаларында без М.Госманов, М.Гайнетдинов, Г.Сәгъди кебек әдәбият белгечләренең эшчәнлегенә тукталырбыз.

Әдәбият тарихында XIX йөз татар халкының иҗтимагый тормышында җитди үзгәрешләр башланган, милләтнең әдәби–эстетик башлангычын билгеләгән тарихи әһәмиятле әсәрләр дөнья күргән чор буларак бәяләнә. Татар әдәбиятында XIX йөз әдәбияты М.Гайнуллин, М.Гайнетдинов, Г.Сәгъди һ.б. хезмәтләрендә өйрәнелгән.

XX гасырның 60–70 нче елларында әдәбият тарихы һәм теориясенең актуаль проблемаларын яктырткан монографияләр барлыкка килә. Биредә бигрәк тә XIX йөз әдәбиятын өйрәнүгә үз өлешен керткән М.Гайнуллин хезмәтләре аерым урын алып тора [Гайнуллин, 1975, 1979].

Г.Сәгъди XIX йөз ахыры – XX йөз башы әдәбиятын өйрәнеп, түбәнәге хезмәтләре белән билгеле: "Татар әдәбияты тарихы" (1926), "Символизм турында" (1932) һ.б.

XX йөз башында формалашу һәм аякка басу процессы кичергән татар әдәбият белеме синкретик характерда булып, әдәбият теориясенә караган мәсьәләләргә дә игътибар итә. Г.Сәгъди һ.б.ның хезмәтләрендә әдәби процесс, аерым бер автор иҗатын һ.б.ны өйрәнүгә бәйле әдәби әсәрнең эстетик табигате, төр һәм жанрлар, термин–төшенчәләр турында да теоретик фикерләр урын ала.

Д. Заһидуллина фикеренчә, Г. Сәгъди эшчәнлегендә әдәбиятны система буларак укытуга һәм уку планына теория кертүгә юнәлеш тоткан яңа агым барлыкка килә [Заһидуллина, 2000: 25].

Э.Галиева фикеренчә, Г.Сәгъди татар әдәбиятын Көнчыгыш әдәбиятлары системасында һәм шул ук вакытта үзенә хас үзенчәлекләре белән үсеп–үзгәреп торучы сүз сәнгате контекстында тикшерә. Галим “Татар әдәбияты тарихы” (1926), “Символизм турында” (1932) кебек хезмәтләрендә тарихилык принцибын нигез итеп, әдәбип иҗатны чор, эпоха һәм җәмгыять белеме белән рухи бәйләнештә өйрәнә. Аның хезмәтләре нигезендә Көнчыгыш мәдәнияте материаллары торса да, ул әдәбият–сәнгать күренешләрен тикшерүдә Европа һәм рус культура–тарих мәктәбе принциплары белән эш итә, дип күрсәтә Э.Галиева [Галиева, 2002: 36].

Әлеге хезмәтләр бүген дә актуальлеген югалтмаганнар.

М. Гайнуллинның XIX йөз әдәбияты өлкәсендәге казанышлары, табигый рәвештә, XX гасыр башы татар әдәбияты һәм публицистикасын өйрәнүгә дә этәргеч биргәндер, чөнки нәкъ менә шушы вакыт аралыгы татар халкының тарихына һәм мәдәниятенә зур үзгәрешләр чоры булып теркәлгән. “XX гасыр татар әдәбияты һәм публицистикасы” дип исемләнгән хезмәт – галимнең зур уңышы. Монографиядә татар журналистикасының, публицистикасының, әдәби тәнкыйтенең барлыкка килүе һәм формалашуы, беренче рус инкыйлабы һәм аннан соңгы чор татар матур әдәбиятының үсеше тикшерелә.

М.Гайнетдинов хезмәтендә XIX йөзне татар халкының иҗтимагый тормышында җитди үзгәрешләр башланган, милләтнең әдәби–эстетик башлангычын билгеләгән тарихи әһәмиятле әсәрләр дөнья күргән чор буларак бәяли. Әдәби хәрәкәтне халык тормышындагы социаль–иҗтимагый күренешләр белән тыгыз бәйләнештә өйрәнеп, аның төп этапларын, алар арасындагы традиция–яңачалык мөнәсәбәтен, үсеш тенденцияләрен мәгърифәтчелек реализмына күчешнең мөһим фаторы буларак аңлата.

XX йөз башында формалашу һәм аякка басу процессы кичергән татар әдәбият белеме синкретик характерда булып, әдәбият теориясенә караган мәсьәләләргә дә игътибар итә. Г.Сәгъди һ.б.ның хезмәтләрендә әдәби процесс, аерым бер автор иҗатын һ.б.ны өйрәнүгә бәйле әдәби әсәрнең эстетик табигате, төр һәм жанрлар, термин–төшенчәләр турында да теоретик фикерләр урын ала.

**Әдәбият**

1. Абдуллина Д.М., Бәдертдинова Л.Ш. Мөхәммәт Гайнуллин – галим һәм остаз // Фәнни Татарстан. – 2014. – №4. – Б. 151–157.

2. Әхмәтҗанов М. Йомгак // Карурманны чыккан чакта...: Казан: Мәгариф, 2001. – Б. 308–316.

3. Галиева Э. Татар әдәбият белемендә культура–тарих мәктәбе. – Казан: Фән, 2002. – 360 б.
4. Госманов М. Сират күперендәге уйлар // Казан утлары. – 2006. – №12. – Б. 149–162.
5. Закирҗанов Ә.М. Татар әдәбият белеме: традицияләр һәм үсеш тенденцияләре. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 352 б.
6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 255 б.
7. Кадыйров Р. Гомер итмәк – тырышмактыр // Гайнетдин М.В. Гасырлар мирасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 3.

# М.ХӘБИБУЛЛИННЫҢ “КУБРАТ ХАН” РОМАНЫНДА ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ МОРФОЛОГИК-СИНТАКСИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Ахмадуллина Н.К.**
Казан федераль университетының
Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.д., проф. Камаева Р.Б.

Фразеологизмнар – әдәби әсәрдә төп тел-сурәтләү чараларының берсе. Алар әдәби әсәрдә ассоциатив сурәтләү чарасы вазифасын башкара. Бу очракта фразеологизм төшенчәсе халык телендәге мәкаль-әйтемнәрне дә, үткен образлы гыйбарәләрне дә үз эченә ала. Татар әдәбиятының классик язучылары телебезнең фразеологик фондыннан бик уңышлы файдаланганнар. Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, М.Җәлил, К.Тинчурин, Х.Туфан, Г.Бәширов, Ф.Хөсни, Т.Гыйззәт, И.Гази һ.б. күренекле язучыларның иҗатларында фразеологизмнарны күпләп табып була.

Язучының осталыгы аның телгә үзенең иҗади көчен ни дәрәҗәдә сала алуына бәйле. Бу тикшеренү кысаларында, М.Хабибуллинның “Кубрат хан” романыннан алынган фразеологизмнар морфологик-синтаксик яктан тикшерелде. Фразеологик әйтелмә мәгънә ягыннан таркалмый, бер төшенчәгә эквивалент булып тора. Шуңа күрә дә ул төрле сүз төркемнәре функциясендә килә ала.

*1. Фразеологизм исем булып килә:*

Шул мизгел эчендә ул ханның *сүз сөрешен* аңларга теләде. [Хабибуллин 2001: 221].

– Әйбәт *тутый кошны* эләктергәнсең, буйтур. Шул кеше булыр мине Биләмҗиргә димләүче [Хабибуллин 2001: 191].

– Патшакалага җитәрәк ирек бирәбез дигәч, *җан көчләрен* салып ишә башладылар [Хабибуллин 2001: 128].

Бүген алар бары тик *мәхәббәт теле* белән – йөрәкләре белән сөйләштеләр [Хабибуллин 2001: 127].

– Минем илдә батырлар күп иде, хәзер *акыл иянре* дә була башлады [Хабибуллин 2001: 122].

Төптәңре Ирсанның алай ук тәфсилләп сөйләмәсә дә, тел төбен аңлаган кавханнар теге якка да, бу якка да бер сүз әйтмәделәр [Хабибуллин 2001: 97].

*2. Фразеологизм сыйфат булып килә:*

Яратып бетерми иде император Ираклий *төче телле* дин әһелләрен [Хабибуллин 2001: 4].

Шул еллар эчендә әнә кызы җиткән, Аллага шөкер, *алтын куллы* кешегә кияүгә чыкты [Хабибуллин 2001: 132].

*3. Фразеологизм фигыль булып килә:*

Алдан атлаган патрикий Симеон иң әүвәл Кубрат хан каршына килеп *баш орды* [Хабибуллин 2001: 97].

Төптәңре моны күрде дә, ни кылырга белми тирә-ягына каранды, ханны, ханшаны, кавханнарны *күздән кичерде* [Хабибуллин 2001: 5].

Хан исән чакта император җирләренә көнчыгыш тарафтан бернинди дә дошман *аяк басмас* [Хабибуллин 2001: 6].

Кубрат-хан Мәрьям ана белән Христос сурәтләренә карап торды, шуннан соң *уйга калды* [Хабибуллин 2001: 11].

Симеонны төптәңре баштан ук *санга сукмады* [Хабибуллин 2001: 18].

Яралының авызыннан кан китте, менә ул күтәрелергә итте, әмма көче җитмәде – *җан бирде* [Хабибуллин 2001: 58].

*4. Фразеологизм рәвеш булып килә:*

Ул әйләнеп улына карады, улы да, гүзәллеккә *таң калып*, хан кызына карап тора иде. Илче Феофан, гомерендә беренче тапкыр *коты алынып*, чокырга үрелде [Хабибуллин 2001: 7].

Грек уты ясауның серен румнар *күз карасыдай саклыйлар* [Хабибуллин 2001: 12].

Төптәңре изге ташка *баш ора-ора* ялварды [Хабибуллин 2001: 15].

Кала *күзгә күренеп* үсте [Хабибуллин 2001: 16].

Өлкән илхан аларны *колач җәеп каршы алды* [Хабибуллин 2001: 28]. Үзе болай саран да түгел император Ираклий, *киң күңелле* булып күренергә тырыша [Хабибуллин 2001: 113].

Фразеологик әйтелмәләр шулай ук җөмләнең төрле кисәге булып та килә алалар.

*1. Фразеологизм җөмләдә ия булып килә:*

– Минем илдә батырлар күп иде, хәзер *акыл ияләре* дә була башлады [Хабибуллин 2001: 122].

– *Ана теле* онытыла буламы? [Хабибуллин 2001: 157].

*2. Фразеологизм җөмләдә хәбәр булып килә:*

Олуг хан янәшәсендә утырырга гадәтләнгән төптәңренең, бу хәлне күреп, *йөзеннән кан качты* [Хабибуллин 2001: 5].

Хан исән чакта император җирләренә көнчыгыш тарафтан бернинди дә дошман *аяк басмас* [Хабибуллин 2001: 6].

Олуг хан философ белән сөйләшә, беркемне дә күрми дә, белми дә, бөтенләй *дөньясын онытты* [Хабибуллин 2001: 11].

Симеонны төптәңре баштан ук *санга сукмады* [Хабибуллин 2001: 18].

Хан кызын очраткан саен *күңел җилкенә* [Хабибуллин 2001: 51].

Бернинди су анасы да юк, корабта карак бар һәм аның бүлмәсендәге алтынга *күзе кызган* [Хабибуллин 2001: 142].

*3. Фразеологизм җөмләдә тәмамлык булып килә:*

Бу хәл җизнәсе Кубрат ханны хөрмәт итүне, ниндидер күләмдә аның *канат астына керүне* – буйсынуны аңлата иде [Хабибуллин 2001: 15].

Иоанн Фасиан сиздерми генә *кеше күңеленә керә белә* [Хабибуллин 2001: 16].

Таң нуры белән килеп кергән кунакларны күрде дә, гаҗәпләнә калып, *чакырылмаган кунаклар* белән баш кагып кына исәнләште [Хабибуллин 2001: 146].

– Симеон мине чукындырды, муеныма *кош тәпие* такты [Хабибуллин 2001: 158].

Шул мизгел эчендә ул ханның *сүз сөрешен* аңларга теләде [Хабибуллин 2001: 221].

*4. Фразеологизм җөмләдә аергыч булып килә:*

Яратып бетерми иде император Ираклий *төче телле* дин әһелләрен [Хабибуллин 2001: 4].

Кайгы – дәвамлы сагыш, *кеше башына төшкән* яман чирдер [Хабибуллин 2001: 10].

Төркиләрдә хан кызларын баһадирларга бирү *тузга язмаган* гадәт түгел [Хабибуллин 2001: 20].

Кыска муенлы, иңенә бигүк *күзгә ташланмаган* чапан салган [Хабибуллин 2001: 26].

Кырысрак холыклы, *бер әйтеп ике сөйләргә яратмаган* Кубрат хан аны угланнарыннан ким яратмады [Хабибуллин 2001: 52].

*5. Фразеологизм җөмләдә хәл булып килә:*

Ул әйләнеп улына карады, улы да, гүзәллеккә *таң калып*, хан кызына карап тора иде [Хабибуллин 2001: 7].

Илче Феофан, гомерендә беренче тапкыр *коты алынып*, чокырга үрелде [Хабибуллин 2001: 7].

Грек уты ясауның серен румнар *күз карасыдай* саклыйлар [Хабибуллин 2001: 12].

Төптәңре изге ташка *баш ора-ора* ялварды [Хабибуллин 2001: 15].

Кала *күзгә күренеп* үсте [Хабибуллин 2001: 16].

Өлкән илхан аларны *колач җәеп* каршы алды [Хабибуллин 2001: 28].

Кайсы дин өстен чыкса, шуңа йөз тотар Болгар. Анда да *җиде кат уйлап* [Хабибуллин 2001: 45].

Греклар биналарны, аерата чиркәүләрне оста салалар, нык итеп, *җиренә җиткереп* эшлиләр [Хабибуллин 2001: 97].

Шулай итеп, язучылар үзләренең әсәрендә фразеологик әйтелмәләр составында төрле сүз төркемнәрен куллана, шулай ук алар җөмләнең төрле кисәге булып та килә алалар.

**Әдәбият**

1. Әхәтов Г.Х. Хәзерге татар теленең лексикологиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 110 б.
2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407

б.
3. Хәбибуллин М. Кубрат хан: Тарихи роман. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.

## ТЕЛ – ХАЛЫКНЫҢ ХӘЗИНӘСЕ

**Габдрахманов Т.В.**
Алабуга шәһәренең “Инженер-технология лицее” укучысы
Фәнни җитәкче: Шакирҗанова Н.Г.

Туган тел ул- бездән соң да
Яшәр өчен туган тел.
Бүгенгедән киләчәккә
Дәшәр өчен туган тел.
(Зиннур Насыйбуллин)

Кеше нинди телдә сөйләшсә, шул телдә уйлый. Бүгенге көндә татарча, русча, инглизчә һәм башка телләрне белүче кешеләр бик кирәк. Һәр милләт кешесе үзенең туган телендә яхшы сөйләшә, укый, яза белергә тиеш һәм шул телдә гаиләләрендә дә иркен аралашырга тиеш.

Туган телен кадерләгән халык кадерле була. Әйе, безнең телебез – бик борынгы һәм бай телләрнең берсе. “Без татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”,- дигән телебезне үстерүгә гаять зур өлеш керткән Каюм Насыйри.

Билгеле бер телдә күпме генә кешеләр сөйләшсәләр дә, телне сакларга кирәк. Чөнки тел – ул халыкның хәзинәсе. Шуңа күрә дә телне саклау бик мөһим эш булып санала. Теле барның иле бар дигән халык мәкале моны бик яхшы ассызыклый. Тел яшәсә, ил яши.

Татар халкы бербөтен милләт булып яшәсен, рухи байлыклары сакланып калсын, милли әдәбияты югалмасын өчен туган телне дә саклап калырга кирәк. Тел проблемасы бүгенге көндә иң актуаль мәсьәлә булып тора.

Тел дәресләре балаларны халкыбызның рухи-әхлакый идеалларына китерергә, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтләрен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерергә тиеш. Бүгенге тормыш шартлары укытучыга бала шәхесен тирәнтен һәм һәрьяклап өйрәнү бурычын йөкли.

Туган тел дәресләрендә балаларда кече яшьтән үк үз теленә карата кызыксыну, мәхәббәт тәрбияләү бик мөһим. Без нинди дә булса чарага барганда, театр булсынмы ул, концертмы, яки күргәзмәме, аның кызыклы һәм мавыктыргыч булуын өмет итәбез. Әгәр чара ошаса, без канәгать булып кайтып китәбез. Ошамаса, вакытны бушка уздырдык дип уйлыйбыз. Туган тел дәресләре дә кызыклы, файдалы булырга тиеш.

Бүгенге көндә туган телебезне саклап калу өчен без аны саклау һәм үстерүгә игьтибарны арттырырга тиеш. Һәр телнең үзенә генә хас үзенчәлекләре була. Аларны өйрәнергә , яхшылап үзләштерергә , ана телебездә белем алу өчен күбрәк ихтыяҗ тудырырга кирәк.

Хәзерге көндә татар мәктәпләрен, татар авыллары саклап калырга кирәк, аларның юкка чыгуына юл куймаска, аларның үсешенә күбрәк мөмкинлекләр тудырылсын иде.

Хәзер яшьләр дә, мәктәп укучылары да күп вакытларын интернетта үткәрәләр. Интернет, әлбәттә, бик күп мөмкинлекләр тудыра, тормышның төрле өлкәләрендә эшне тизрәк алып барырга ярдәм итә. Башка телләрдә интернетта кешеләрне кызыксындыра ала торган бик күп чаралар бар. Туган телдә дә мондый кызыксындыру чаралары эшләргә кирәк. Мәсәлән, татар телендә төрле уеннар, фильмнар, видеороликлар күбрәк урнаштырылсын иде. Татарча сайтлар булдыру да бик уңышлы булачак. Мәктәптә укучыларга татар халкының гореф-гадәтләре, тормыш-көнкүреше турында сөйләү, әдәби әсәрләр уку да бик яхшы булачак.

“ Халыкның теле - аның бөтен рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге. Телдә бөтен халык һәм аның ватаны җанлы рәвештә гәүдәләнә”, - дигән бөек рус педагогы Г. Ушинский. Шуның өчен дә туган телне – ана телен – яхшы белү, аның бөтен нечкәлекләрен өйрәнү һәм өйрәтү – безнең бурычыбыз.

**Әдәбият**


1. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан, тат.кит.нәшр,, 1947
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1974.- Т.1. – б.19
3. Сафиуллина Ф.С. Тел дигэн дэрья бар... – Казан:тат.кит.нщшр., 1979
4. Ушинский К.Д. Собрание сочинений. М., 1950, Т. 10, с.511


## “БЕЗ ТАТАРЛАР, ТЕЛЕБЕЗ - ТАТАР ТЕЛЕ, МӨСТӘКЫЙЛЬ ҺӘМ ТӨЗЕК КАГЫЙДӘЛЕ КАМИЛ ТЕЛ УЛ...”


**Галиев С.А.**

Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.


1860 нчы елдан башлап ярты гасыр дәвамында гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән Каюм Насыйри татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле булды. Ул бөтен тормышын, талантын халыкка хезмәт итүгә багышлады, татар халкының аң – белемен күтәрүдә, аны рус мәдәниятенә якынайтуда тарихи әһәмиятле хезмәтләр башкарды.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров – Каюм Насыйри 1825 нче елның 14(2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында туа. Булачак язучы балачак елларын укымышлы гаиләдә, туган авылында уздыра. Башлангыч белемне атасыннан ала. 1841 нче елда аны Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга бирәләр. 1855 нче елга кадәр шул мәдрәсәдә укып, ул гарәп, фарсы телләрен өйрәнә, яшерен рәвештә

русча укый, шәкертләрнең күпчелегеннән аермалы буларак, җәмгыятькә файдалы белемле кешебулып җитешә.

1855 нче елда К.Насыйрины христиан руханилары әзерли торган Духовное училищега татар теле укытучысы итеп чакыралар. Аның беренче практик эше –укытучылык хезмәте шунда башлана. Соңрак ул шул ук училищеның дәвамы булган Духовная семинариядә татар теле мөгаллиме булып эшли. Андагы укытучылар белән нык аралаша, рус телен өйрәнә. Соңыннан Казан университетында ирекле тыңлаучы булып керә.|Гайнуллин 2015: 229 |.

Каюм Насыйриның иң зур хезмәтләреннән берсе – тел өлкәсендәге эшчәнлеге. Телче буларак ул бик катлаулы, күпьяклы хезмәтләр башкара: татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын исбат итә. Татар телен практик һәм фәнни эшкәртү юлында гаять зур эшчәнлек күрсәтә. К.Насыйри тел гыйлеме, сүзлекләр төзү буенчааеруча күп тырышлык куя. Бу өлкәдә ул кагылмаган, өлеш кертмәгән бер генә тармак та юк диярлек. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген (“Ләһҗәи татари “, 1895) башлап үзе төзи. Русча –татарча, татарча русча сүзлекләр төзеп бастыра. Әдип математика, география, һәм табигать фәннәре буенча киң массага аңлаешлы терминнар булдыру өстендә дә эшли. Дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен аңлаткан беренче кулланма (“Кавагыйде китабәт”, 1892) яза. Татар теленең фәнни грамматикасын (“Әнмүзәҗ”, 1895) төзүдә бик мөһим эш башкара. Хәзер дә әле бу хезмәтләр, бигрәк тә “Әнмүзәҗ” үзләренең тарихи әһәмиятләрен, фәнни кыйммәтләрен саклыйлар.

К.Насыйри рус телен үзләштерү, рус китапларыннан файдалану өчен кирәк булган уку китапларын булдыру өстендә дә хезмәт куя (“Кыйраәте рус”, 1889 ). Рус теленең грамматикасын (“Нәмүнә”, яки Әнмүзәҗ”, 1891) төзеп, бастырып тарата. Бу эшләрен үзенең практик укыту процессындасынап, ул бер телне икенче тел белән чагыштыру методын куллана. Галим рус, татар грамматикаларында булган яңалыкларны, аермалыкларны, үзенчәлекләрне өйрәнеп, аларны укучыларына төшендерә |Гайнуллин 2015: 231 |.

Татар халкының олы мәгърифәтчесе һәм галиме булган Каюм Насыйриның тел гыйлемендәге эшчәнлеген зур диңгезгә коя торган зур һәм саф елгага тиңләргә мөмкин. Һәр елга агымын чишмәләрдән, вак елгалардан башлаган кебек, К.Насыйри да үзенә кадәр булган гыйлемнәрне тагын да үстереп, киңәйтеп, яңа тармаклар белән баета |Хуҗиәхмәтов 1998 :172|.

Киң колачлы галим Насыйри татар халкын төрле фәннәрнең нигезләре белән үз ана телендә таныштыру өчен тырыша. Математика, география дәреслекләре, ботаникадан үсемлекләрнең исемнәре китабын яза. Аның табигать белеменә багышланган “Буш вакыт” исемле китабы татар телендә чыккан беренче фәнни –популяр әсәр булып санала. Ул унбиш ел буе өстәл календаре чыгарып тора |Хуҗиәхмәтов 1998 :173|.

К.Насыйри китаплар язганда, дәреслекләр төзегәндә рус һәм көнчыгыш чыганакларыннан файдалана. Аның гарәп, фарсы, төрек, рус телләрен камил белүе күп белем тупларга, башка халыкларның казанышларыннан

файдаланырга ярдәм итә. Шул вакытта ул татарларны фән һәм алдынгы мәдәният белән таныштыру өчен,  рус телен дә өйрәнергә кирәклеге турында кыю фикерләр әйтә. Ләкин аңа каршы чыгучы кара фикерле кешеләр табыла. Шулай булса да, ул, беренчеләрдән булып, рус телен укыта торган мәктәп ача, кулланмалар төзи, татарларга рус теле укыту методикасын яза.

Галим башка телләр өйрәнүне хупласа да, кеше иң беренче чиратта үз туган теленең кагыйдәләрен яхшы белергә, аннан соң гына башка телләрне өйрәнү кирәклеген әйтә. Татар телен кимсетеп караучыларга кыю фикерләр җиткерә: “Без татарлар, телебез - татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”.

Каюм Насыйриның тарих, археология өлкәсендә дә күренекле хезмәтләре байтак. Ул халык авыз иҗатын, гадәт – йолаларын гомер буе өйрәнә, җыя. Бу турыда китаплар яза. (“Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары”, “Татар этнографиясе материаллары”). Татар халкын үз ана телендә туган ил тарихы белән таныштыручы да  - Каюм Насыйри(“Зөбдәтен мин тәварихи Русь”). Бу өлкәдә куйган хезмәтләре өчен аны 1885 нче елда К.Насыйри Казан университеты  каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлыйлар |Хуҗиәхмәтов 1998 :174|.

К. Насыйри тәрҗемә өлкәсендә дә күп эшли. Ул мәгърифәтчелек идеяләрен чагылдырган, яшьләргә  яхшы тәрбия бирә торган әсәрләрне сайлап алып тәрҗемә итә: “Әбүгалисина кыйсса”сы, “Кырык вәзир кыйсса”сы, “Кабуснамә”- әнә шундый әсәрләр.

Каюм Насыйри татар халкының матур әдәби әсәрләре бик аз булуын яхшы аңлый, шуңа күрә  аның телен әдби телгә якынайту, каилләштерү, үстерү максатыннан  Шәрык әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемә итеп,  аларны татар халкының  мәкаль – әйтемнәре, сынамышлары  белән  баетып, ана телендәбастыра. Кыскасы, мәкаль –әйтемнәрне тәрбия бирү, мораль чыгару өчен куллана. Шулай итеп, аның бу алымы укучылар тарафыннан җылы кабул ителә, чөнки ул зирәклеккә, тапкырлыкка өйрәтә.

Танылган татар язучысы Ф.Әмирхан 1907 нче елда “Әлислах” газетасында К.Насыйри хезмәтләренә зур бәя биреп:”Каюм Насыйрига кадәр мәктәпләрдә төп укыту теле булып гарәп теле исәпләнде. Каюм Насыйри татарларга, беренчеләрдән булып, үзләренең теле барлыгын күрсәтте. Аннан соң ул барлык кешеләргә дә аңлаешлы булган татар телендә әдәби әсәрләр тудырды”,- дип яза |Хуҗиәхмәтов 1998 :179|.

Каюм Насыйри  татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуңа хакы һәм сәләте барлыгын исбат итә. Һәм шуны тормышка ашыру юлында  зур эшчәнлек күрсәтә. Аның бу өлкәдәге язмалары әле хәзер дә тарихиәһәмиятләрен һәм гыйлми кыйммәтләрен югалтмый |Хуҗиәхмәтов 2002 :24|.

Шулай итеп, Каюм Насыйри  күпкырлы галим, телче, тәрҗемәче, мөгаллим  була. Татар телен әдәби һәм  фәнни яктан үстерә,  әдәби, тарихи, педагогик хезмәтләр яза, балаларга белем һәм тәрбия бирә.

**Әдәбият**

1. Гайнуллин М.М., Гайнетдинов М.В., Мәхмүтов Х.Ш.Татар әдәбияты тарихы. 3 том: XIX йөз. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2015.- 551 б.

2.Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы. - Казан: “Мәгариф” нәшр., 2002.-287 б.

3. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгариф тарихы һәм фәлсәфәсе.Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 1998.-398 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АНАЛИТИК ҖӨМЛӘЛӘРНЕҢ ӨЙРӘНЕЛҮ ТОРЫШЫ

**Гильметдинова Ф.Ф.**
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: ф.ф,к.,доцент Хәйруллина Ә.С.

Кушма җөмләләр, грамматик һәм семантик үзенчәлекләре буенча, ияченле һәм тезмә җөмләләргә бүленәләр. Иярченле кушма җөмләләр, үз чиратында, синтетик һәм аналитикка бүленәләр. Аналитик иярүче җөмлә төп җөмләгә предикатның өлеше булмаган ысуллар белән кушыла, ә буйсынган җөмләнең предикаты тулы формага ия булачак. Бәйләү чараларына ияртүче теркәгечләр, ияртүче теркәгеч сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр һәм хәбәрнең бөтенлегенә зыян китерми торган кайбер кушымчалар, бәйлек сүзләр һәм интонация (көттерү паузасы) керә. Бу синтетик һәм аналитик җөмләләр арасындагы төп аерма, чөнки синтетик иярүле җөмләләрдә синтетик чаралар хәбәрнең составына карый.

Аналитик җөмләләр дүрт төрле булырга мөмкин: баш җөмләгә хәбәр бөтенлеген бозмый торган бәйлек-теркәгеч сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр, баш җөмләгә ияртүче теркәгеч яки теркәгеч сүз аша ияргән аналитик җөмләләр, баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр аша ияргән аналитик җөмләләр һәм баш җөмләгә интонацион чаралар аша ияргән аналитик җөмләләр. Теркәгеч сүзләр һәм интонация ярдәмендә төзелгән аналитик кушма җөмләләр бәйлек төзелешлеләренә караганда иртәрәк барлыкка килә. Аларны VIII гасыр рун һәйкәлләрендә үк табарга мөмкин. Кайбер тел белгечләре мондый җөмләләр татар теленә бөтенләй хас түгел дип саныйлар, шуңа күрә аналитик төр җөмләләрне татар телендә өйрәнү башка грамматик категорияләрне өйрәнүдән соңрак башлана. Шул рәвешле, “төрки телләрдә аналитик кушма җөмләнең тулы бер системасы булу аларда кушма җөмлә юк дигән уйдырманы чыгара” [4, с. 371].

Беренче татар грамматикаларында аналитик кушма җөмләләр аерып күрсәтелми, ә бары тик синтетик кушма җөмләләр турында гына сүз алып барыла. Әмма аналитик кушма җөмләләрнең (рус телендәге сложноподчиненные предложения туры килә) фәнни дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы һич кенә дә татар телендә бу төр җөмләләр юк дигәнне аңлатмый.

Гарчә, карап узылган конструкцияләр турында беренче мәгълүматлар XVIII гасырда ук М.Иванов һәм М.А. Казембек хезмәтләрендә теркәлгән булса да, татар лингвистикасында аналитик һәм синтетик кушма җөмләләрне тирәнтен, системалы өйрәнү эше XX йөз башында гына гамәлгә куела. Аерым алганда, Г.Ибраһимов үзенең грамматикасында татар телендәге кушма җөмләләрнең беренче классификациясен бирә[3]. М.Корбангалиев һәм Х.Бәдиый грамматикаларында аналитик һәм синтетик конструкцияләр бергә карала. Монда, беренче тапкыр, кушма җөмлә компонентлары арасындагы бәйләнеш чаралары ачыклана һәм шәрехләнә.

Соңыннан, кушма җөмләләрне классификацияләү, кушма җөмләләрнең структур һәм семантик үзенчәлекләрен, аналитик конструкцияләрне ачыклау, Х.Бәдигый, Җ.Вәлиди, С.Атнагулов, Г.Алпаров, М. Зәкиев, С.М. Ибраһимов, Ф.С. Сафиуллина, К.З. Зиннәтуллина һ.б. кебек танылган тел белгечләренең грамматикаларында берничә тапкыр каралды [1, с. 34].

XX йөзнең 50-нче еллары төрки тел белеме өлкәсендәге тикшеренүләргә игътибар арту белән характерлана. Төрки телләрдә аналитик кушма җөмләләрне тикшерү эше аеруча активлаша. Мәсәлән, Н.К.Дмитриеваның “Башкорт теле грамматикасы” (1948), “Тел белеме мәсьәләләре” (1956) “Хәзерге казах теле (синтаксис)” (1959), Г.А. Абдурахманованың “Хәзерге үзбәк әдәби теленең кушма җөмлә синтаксисы” (1960), А.Н. Кононованың “Хәзерге үзбәк әдәби теленең грамматикасы” (1960), Э.Н. Нәҗипнең “Хәзерге уйгур теле”(1960), В.А.Гордлевскийның “Төрек телләренең чагыштырма грамматикасы буенча тикшеренүләр” (1961), “Төрек теле грамматикасы” (1961), Н.А. Баскаковның “Татар лингвистикасы проблемалары” (1965), “Төрек телләрен өйрәнүгә кереш сүз” (1969) һ.б.кебек хезмәтләрдөнья күрде [1, с.54].

Аналитик кушма җөмләләрнең классификациясенә килгәндә, бу проблема 1960-нчы елларга кадәр чишелмәгән.

1962 елда Башкорт университеты татар филологиясе бүлеге доценты Ә.Фатыхов “Башкорт һәм татар телләрендә кушма җөмләләрнең кайбер үзенчәлекләре” дигән монография чыгара. Автор кушма җөмләләрне ияртүле, тезмә һәм теркәгечсез дигән төрләргә бүлеп өйрәнә. Төп игътибарны Ә.Фатыхов шушы төрләрне бер-берсеннән аеруга юнәлтә, һәр төр кушма җөмлә эчендәге җөмләләрнең үзенчәлекләрен ачарга тырыша. Әмма алга таба бу автор үзенең синтаксик эзләнүләрен дәвам итми.

1964 елда С.М.Ибраһимов “Аналитические конструкции в татарском языке” дигән темага диссертация яклый, аның бу эше шул ук елда “Татар телендә аналитик төзелмәләр” дигән исем белән аерым китап булып басылып та чыга. С.Ибраһимов татар телендә аналитик төзелмәләрнең үзенчәлекләрен билгеләүгә һәм аларның кулланыш үзенчәлекләрен тикшерүгә бик зур өлеш кертә.

Татар синтаксисын тулысы белән яктырту бурычын куйган беренче махсус монография М.З.Зәкиевнең 1963 елда чыккан “Синтаксический строй татарского языка” дигән 464 битлек китабы булды. Бу монография дүрт төп

бүлектән тора.Өченче бүлек сөйләмдә җөмләләрнең үзара бәйләнешен тикшерүгә багышланган. М.Зәкиев монографиясенең “Татар сөйләменең структур төзелеше” дип аталган бүлегендә күп төрле проблемалар тикшерелә: татар сөйләменең синтагматик төзелеше, сөйләмдә сүзләр һәм җөмләләр тәртибе, татар сөйләмендә җөмләләрнең кимлеге, күп буынлы кушма җөмләләрнең структурасы, тезем үзенчәлекләре. Бу бүлектәге проблемалар, яңача куелыш табып, үзенчәлекле хәл ителгәннәр [2].

30-70 нче елларда кайбер тел белгечләре аналитик кушма җөмләләрнең өч төрен аералар, шуның белән Г. Ибраһимов, М.Корбангалиев һәм Х.Бәдигый карашларын хуплыйлар. Беренчедән, монда Г.Алпаровның “Шәкли нигездә татар теле грамматикасы” хезмәтен искә төшерү урынлы булыр.

Бу чорда “аналитик җөмлә” һәм “синтетик җөмлә” терминнары кертелә. Бу терминнар беренче тапкыр А.Кәримованың “Татар телендәге кушма җөмләләр” диссертациясендә очрый.

Шулай итеп, 40-70-нче елларда кушма җөмләләрне өйрәнү юлында зур күтәрелеш күзәтелә. Аналитик төр җөмләләргә күбрәк игътибар бирелә. Иярүче җөмләнең яңа төрләре аталды.

Гасыр ахырында кушма җөмләләр синтаксиста семантик синтаксис, коммуникатив синтаксис кебек яңа, перспектив юнәлешләр барлыкка килү һәм шулай ук фәнни тикшеренүләр өлкәсенә моңа кадәр җитәрлек өйрәнелмәгән телләргә (мәсәлән, төрки телләрне үз эченә алган урал-алтай телләре) игътибар арту белән стимуллаштырыла.

70-90-нчы елларда аналитик конструкцияләр проблемасы М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов, Ф.С. Сафиуллина, К.З. Зиннәтуллина, Ф.Ф. Фатыйхова, Р.Х. Мөхиярова, Б.М. Мифтахов һ.б. кебек күренекле галимнәр һәм тел белгечләре хезмәтләрендә каралды. Катлаулы җөмлә синтаксисы актив рәвештә М.З. Зәкиев, С.М. Ибраһимов, Ф.С. Сафиуллина һәм Б.М. Мифтахов тарафыннан өйрәнелде. Аларның дәреслекләре һәм кулланмалары, мәктәпләрдә, урта һөнәри уку йортларында, республиканың югары уку йортларында бүгенге көндә дә иң киң кулланыла.

XX йөз ахырыннан башлап, аналитик кушма җөмлә мәсьәләләре Л.Рәхимованың “XX гасыр татар грамматикаларында аналитик төзелмәләрне өйрәнү”, Г.Нәбиуллинаның “Татар мәкальләрендә кушма җөмлә синтаксисы”, Н.Шакированың “Хәзерге татар әдәби телендә күп компонентлы катнаш кушма җөмләләрнең структур-семантик модельләре” һ.б. кандидатлык диссертацияләрендә яктыртыла.

Күпчелек тел белгечләре кушма җөмләләрне тоташтыру ысулын билгеләү сораулары белән кызыксынган. Төрки телләрдә аналитик җөмләләрне генә кушма җөмлә дип атап була, чөнки бары тик алар һинд-европа телләренең кушма җөмлә компонентлары арасындагы иярү чараларына охшаш, ә синтетик ияртүче җөмләләр – төрки телләрнең үзенчәлеге булып тора. Шул рәвешле, татар телендә өч төрле кушма җөмлә төре билгеләнде: гади кушма җөмлә

(сложносочиненные), катлаулы кушма җөмлә (сложноподчиненные) һәм беркетелгән (сложноспаянные) кушма җөмлә төрләре.

**Әдәбият**


1. Гиниятуллина Л.М., Шакурова М.М.Исследование сложноподчиненных предложений с аналитической связью частей в учебниках XX века / Л.М. Гиниятуллина, М.М. Шакурова. – Казань, 2018. – 148 с.
2. Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка / М.З. Закиев. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1963. – 464 с.
3. Ибраһимов Г.Г. Татар нәхүе / Г.Г. Ибрагимов. – Казан: Сабахширкәте, 1919. – 52 б.
4. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм авторМ.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ,2017. – III. т. – Б.371.


## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ “КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР” ӘСӘРЕНДӘ ОБРАЗЛАР СИСТЕМАСЫ


**Зәкиева Д.Ф.**

Әлмәт шәһәренең “Адымнар-Әлмәт”гимназиясе укучысы

Фәнни җитәкче: Тамасова Я.И.


Галимҗан Ибраһимовның Октябрьдән соңгы чорда иҗат иткән тагын бер әсәре – романтизм һәм реализм иҗат методлары белән сугарылган “Кызыл чәчәкләр” хикәясе. Бу хикәяне язучы 1922 елда бастырып чыгара.

«Кызыл чәчәкләр» язучының инкыйлабтан соңгы чор иҗатындагы иң камил әсәрләрнең берсе булып, үзенең идея-эстетик эшләнеше, символлар теленә мөрәҗәгать итүе, образларның типиклаштырылуы ягыннан аерылып тора.

“Кызыл чәчәкләр” повесте социалистик реализмның нигез ташларын тәшкил иткән, татра совет әдәбиятының алтын фондына кергән әсәрләрнең берсе. Г. Ибраһимов бу уңышка идея-теоретик үсеше, бай революцион көрәш тәҗрибәсе ярдәмендә генә түгел, профессиональ осталыгын бертуктаусыз камилләштерү нәтиҗәсендә дә иреште.

Галимҗан Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повестында сабый чаклары, яшьлек чоры һәм ир булып җитү вакытлары беренче империалистик сугыш, Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларына туры килгән биш егетнең тормышы һәм язмышысурәтләнә. Аларның бишесе дә Башкортстанда туган, Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан боргаланып-боргаланып аккан җирендә, матур күл буена утырган Зәңгәр Чишмә авылында алар тормышка башлап аяк басканнар, шунда физик чыныгу алганнар.

Әсәрнең төп герое Солтан (повесть аның авызыннан хикәя кылына) авыл читендәге «өйләрнең» берсендә дөньяга килгән. Аннан бер баскычка югары — балтаостасы Зариф семьясында туган Гыйлаҗи, ә тагын да өстәрәк - Заһит хәзрәт малае Фазыйл. Гали — социаль иерархия баскычының иң югары ноктасында.УлГыйрфан бай улы. Ә бишенче егет Шаһбазның кайда

туганын берәү дә белми. Аның дөньяга килүе анасының кабергә китүенәсәбәп булган,ә этисенең, кем булуы берәүгә дә мәгълүм түгел. Шаһбаз үз гомерен чабата тукып, аркан ишеп үткәрә торган Әхми картның авыл читендәге балчык өендә сәкедә дөньяга килә. Шаһбаз җиде яшькә җиткәч, чабатачы Әхми карт та үлә,ул бөтенләй ятим, ялгыз кала.

Социаль чыгышлары төрле булган әлеге малайлар кечкенә чакта бергә уйнап үсәләр, бер-берсенә киләчәктурындагы хыялларын сөйлиләр, күңел планнары белән уртаклашалар.

Шаһбаз белән Солтан — ярлы крестьян сыйныфын тәүдәләндерүче типик образлар. Аларның тормышында бераз аерымлыклар бар икән, бу социаль яктан үзгәлекләр түгел, бәлки Шаһбазның ятим булуыннанкилеп чыккан аерымлыклар гына. Асылда алар икесе дә бер үк социаль катлау кешеләре. Гыйлаҗи образы урта хәлле крестьян сыйныфын гәүдәләндерә, шул социаль катлау психологиясенең чагылышы булып тора. Егетләрнең калган икесе — хаким сыйныф вәкилләре.Гали авыл баеның малае. Автор аның йөзендә кулак сыйныфын гәүдәләндерә, ә икенчесе - Фазыйл - мулла малае, авылның рухани катлавы вәкиле [Ганиева 1977: 136].

Бөек революция дулкыннары белән бу егетләрнең төрлесе халык хәрәкәте диңгезенең төрле ярларына барып чыгалар, бу инде алар белән идарә итүче төрле социаль көчләрнең революция нәтиҗәсендә килеп чыккан позициясенең конкрет бер чагылышы, гәүдәләнеше.

Язучы бу каһарманнарның һәркайсының үз-үзен тотышы, аларның эш-хәрәкәтләре белән билгеле бер социаль көчләрнең, сыйныфларның идарә итүенә әле әсәрнең башында ук аерым штрихлар һәм детальләр белән ишарә ясый.

Г. Ибраһимов Россиянең ерак почмакларындагы татар авылларының берсендә туып үскән биш егетнең тормышын һәм язмышын сурәтләү, алар образында авылда да, шәһәрдә дә сыйнфый аерымлануларның булуын күрсәтү аркылы татар халкының киләчәге гомум ил күләмендә җәелгән революцион көрәш, социалистик революция белән турыдан-туры бәйләнгәнлеген раслый.

Әсәрнең үзәгендә Солтан образы. Ул бит җиңел генә, ярлы крестьян малае булганга күрә генә үзеннән-үзе актив көрәшче булып җитешмәгән. Аңа характерына салынган табигый орлыкларның, яфрак ярып, матур чәчәкләр бирүе, Октябрь кояшы астындаКоммунистлар партиясе тәрбияләп үстергән “кызыл чәчәкләрнең” берсе булып җитеште өчен күпме тырышырга, көч куярга туры килгән [Ибраһимов 2002: 500].

Солтанның характер асылын капма-каршы ике тенденциянең көрәше билгели. Ул, ярлы сыйныф вәкиле, социаль тигезсезлекнең ачысын-төчесен яшьтән үк үз җилкәсендә татып үскән авыл егете. Аның социаль хәле үзе үк иҗтимагый гаделсезлек сәбәпләрен эзләргә, ил һәм халык язмышы турында уйланырга этәрә.

Калган дүрт иптәше арасында Солтан өчен иң якыны, иң кадерлесе Шаһбаз да социалистик революциягә килә, авторның символик чагыштыруын кулланып әйтсәк, ул да “кызыл чәчәкләрнең” берсе булып җитешә. Ләкин ул үткән юл, Солтанныкы белән чагыштырганда, турырак та, якынрак та. Социалистик революциягә булганар аны аның социаль хәле генә түгел, шәхси язмышы да якынайта. Аның үксез булуы, авылдан китеп озак та тормыйча, заводка, эшчеләр коллективына килеп эләгүе һәм пролетариатның сыйнфый көрәш учагы аша үтүе Шаһбазның социалистик революциягә тизрәктә, турырак та юл белән килеп кушылуын, гражданнар сугышында кызыл командир булуын тәэмин итәләр. Ләкин әсәрдә без Шаһбазны вакыйгалар эчендә түгел, аның турындагы хәбәрләрне Солтаннан гына белеп була. Шуңа күрә индивидуаль характер буларак ул Солтанга караганда йомшаграк.

Ләкин Гыйлаҗи образы бу биш егетнең башкаларына караганда тоныграк эшләнгән. Без аның рухи дөньясын, характерлы сыйфатларын күрмибез. Аның соңгы тормыш фактларын автор Солтан авызыннан сөйләп кенә үтә [3].

Биш егет башына төшкән сынауның иң авыры, иң катлаулысы Фазыйлга туры килә дисәк, бер дә хата булмас. Бу образга салынган идея-эстетик нагрузканың әһәмияте гаять зур. Г. Ибраһимов аның йөзендә революциягә кадәрге чорда «милли азатлык» дип йөреп тә, татар халкына милли азатлыкның бары тик гомумроссия күләмендә яулап алыначак социаль азатлык, пролетариат революциясе аркылы гына киләчәген аңламаган татар интеллигентларының язмышын сурәтли. Алар үзләренең контрреволюцион эшләреннән тәүбә итеп, Совет ягына, халыкка яңадан әйләнеп кайттылар, аларның гафу итүен үтенеп мөрәҗәгать иттеләр. Бу кешеләрнең язмышы ачы да, каһәрле дә һәм бик гыйбрәтле дә иде.

Г. Ибраһимов бу хәл революция елларында адашкан татар интеллигентларының күбесе өчен уртак булуын күрсәтә һәм шуның белән революция, Гражданнар сугышы чорында татар дөньясында булган фаҗигале бер күренешнең асылын, сәбәпләрен ачып бирә. Моның фаҗигалелеге шунда иде, ул интеллигентлар асылда халыкка дошман түгел, алар халык арасыннан чыккан, үзләренең акыл һәм каләм көчен халык интересларына хезмәткә багышларга теләгән, ләкин җәмгыятьнең үсеш законнарын, пролетариат революциясенең асылын аңламау һәм бөек борылышлар вакытында халыктан аерылган булу нәтиҗәсендә һәлакәт алдына килеп баскан кешеләр иделәр. [Заһидуллина 2004: 291]

“Кызыл чәчәкләр” повестының әһәмияте образлар системасы байлыгы белән генә һич тә чикләнми. Әсәр темасы, анда сурәтләнгән тормыш чынлыгы ягыннан гына түгел, үзенең стиле, сурәтләү чаралары белән дә татар әдәбиятына зур яңалыкалып килде. Ул татар прозасының, революцион рух белән сугарылган хәлдә, реализм юлыннан үсә башлавын күрсәтте.

**Әдәбият**

1. Галимҗан Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татарстан Республикасы “хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 543 б.

2. Ганиева Р. Галимҗан Ибраһимов һәм Көнчыгыш әдәбиятлары // Казан утлары. – 1977. - № 3. – 134-141 б.
3. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2004. – 306 б.

## XX ГАСЫРНЫҢ 90 НЧЫ ЕЛЛАРЫНДА ЧЫГАРЫЛГАН РУСЧА-ТАТАРЧА ТЕРМИНОЛОГИК СҮЗЛЕКЧӘЛӘР

**Исмагилова Г.Р.**
Казан федераль университетының
Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.д., профессор Камаева Р.Б.

Татар халкы тормышындагы иҗтимагый үзгәрешләр, татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә куелуы, туган телебезне аралашу-аңлашу чарасы буларак тагын да җанландыру, баету һәм камилләштерү ихтыяҗын да арттырды. Терминология өлкәсендә дә эш күп: яңадан-яңа төшенчәләрне терминнар белән тәэмин итеп өлгертергә, элеккеләрен яңартырга, термин кулланудагы төрлелектән һәм башка кимчелекләрдән арынырга кирәк. Шушы бурычларны хәл итү максатыннан 1995-1998 нче елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән Татарстан китап нәшрияты халык хуҗалыгының төрле һөнәри тармакларына, идарә, мәдәният, медицина, хокук, җәмәгать эшчәнлеге һәм башка өлкәләргә караган русча-татарча сүзлекчәләр чыгарды.

*“Русча-татарча иҗтимагый-сәяси сүзлекчә”* И.М. Низамов авторлыгында 1995 нче елда нәшер ителгән. Бу сүзлеккә башлыча дәүләт-идарә эше һәм җәмәгать эшчәнлеге өлкәсенә караган берәмлекләр – терминнар теркәлгән. Сүзлекчәгә шушы өлкәдә иң еш кулланыла торган, иң актуаль сүзләр һәм сүзтезмәләр генә кертелгән. Сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылганнар. Берьюлы берничә өлкә һәм тармакта кулланыла торган сүзнең шушы өлкәгә караган мәгънәсе генә алынган. Әгәр русча термин шушы өлкәдә берничә мәгънәне белдерсә, татарча төрләре гарәп саннары белән күрсәтелгән. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| *выбор (*ы) | 1) сайлау (лар) |
| ... в Верховный Совет | Югары Советка сайлау (лар) |
| ... в местные Советы | җирле Советларга сайлау (лар) |
| ... народных судей | халык судьяларын ... |
| | 2) сайлап алу, сайлау [3, 41]. |

Терминның татарчасы бер төрле тамыр сүз белән белдерелгән очракта русча терминның исем һәм фигыль формалары бер үк рәттә күрсәтелә. Мәсәлән:

*воздействие; воздействовать* йогынты ясау, тәэсир итү [3, 37].

Бу сүзлекчедә терминнарның кушымчалары параллель сызыклар аша күрсәтелгән. Мәсәлән:

*абонемент* // -ый, -ая, -ое                      абунә, абонемент ...-ы/-е
... билет                                       ... билеты [3, 9].

Бу сүзлекчә дәүләт-хакимият-идарә, хокук, хуҗалык органнарында, матбугатта, радио, телевидениедә эшләүче хезмәткәрләргә, депутаталарга, шулай ук җәмәгать оешмаларына, берләшмәләренә, татар теленең бүгенге торышы белән кызыксынучы күп санлы укучыларга ярдәмлек йөзеннән төзелгән.

“*Китапханәләр, нәшриятлар, мәгълүмат оешмалары хезмәткәрләре өчен сүзлекчә”* китапханә-библиография, мәгьлүмат, нәшрият һәм документлар белән эшли торган башка учреждениеләр өчен икетелле бу сүзлекне бер төркем авторлар (Г.Г.Габделганиева, Ф.С. Сафиуллина, Г.Г.Шаһиәхмәтова һ.б.) төзегән.

Бу басмада 3000 нән артык термин теркәлгән. Татарстан Милли китапханәсенең фәнни-тикшеренү эше планы буенча мондый сүзлек беренче тапкыр басыла һәм ул китапханә эше, китап гыйлеме, библиография эше, мәгьлүмат гыйлеме (информатика) һәм алар белән бәйле өлкәләрне (китап басу һәм полиграфия эше, китап сәүдәсе һ.б.) үз эченә ала. Сүзлек гамәли һәм фәнни хезмәткәрләр, югары һәм махсус урта уку йортлары укытучыларына атап чыгарылган.

Сүзлеккә телдә инде урнашып беткән  терминнар белән беррәттән, яңа терминнар да кертелгән. Терминнар системасы төрле күләмдә бирелгән. Материал алфавит буенча төркемләнгән. Аерым терминнарга җәяләр эчендә аларның кайсы өлкәдә кулланылышына караган аңлатмалар бирелгән. Аңлатмалар җәя эчендә курсив белән күрсәтелгән. Мәсәлән:

вставка *(изд.)*                                өстәмә текст *(бас.)*
вставка *(полигр.)*                             ялгау *(полигр.)* [2, 40].

Аерым сүзләр һәм сүзтезмәләр оялы рубрикаларга берләштерелгән. Мәсәлән:

*заголовок (полигр.)*                           *баш исем (полигр.)*
– в подбор с текстом                            текст белән бер тигезлектә ...
– в разрез с текстом                            текстан аермалы ...
– на спуске                                     буш калган урында ... [2, 52].

Русча терминнарны татарчага синонимнар белән тәрҗемә итү мөмкин булганда, вариантларның барысы да яки аеруча киң кулланыла торганнары бирелә. Мәсәлән:

*каллиграфия*                                   *хаттатлык*
(хөснехат,каллиграфия)

Әгәр тартым кушымчасы оядагы кайбер сүзләргә дә караса, ул төп термин янына куела. Мәсәлән:

аннотация                                       аннотация
– справочная                                    белешмә ...
– телеграфная                                   телеграф ... *(-се)* [2, 21].

Сүзлектәге кайбер терминнардан соң аларның кыскартылган, аббревиатура рәвешендәге кулланылышы (документларны алып бару гыйлемендә кабул ителгәнчә) күрсәтелә. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| “Библиотечно-Библиографическая Классификация”. ББК | “Китапханә-библиографик төркемләү”. КБТ [2, 168]. |

Бу басмада русча-татарча терминнардан тыш, файдаланылган чыганаклар, һәм әдәбият исемлеге, кыскартылган сүзләрнең русча һәм татарча исемлекләрен үз эченә алган кушымта бирелә.

1995 нче елда *Р.Р. Шәмсетдинов тарафыннан “Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлекчә” тө*зелеп бастырылган.

Сүзлекчә сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүчеләргә тәкъдим ителә.Ул шулай ук урта һәм югары медицина уку йортлары студентлары өчен һәм табибларның авырулар белән аралашуын җиңеләйтүче кулланма була ала.

Сүзлекче ике өлештән тора. Беренче өлешендә алфавит тәртибендә русча-татарча медицина атамалары сүзлекчәсе бирелә. Сүзлек өлешенә табибларның эш вакытында еш куллана торган сүзләре кертелгән. Икенче өлешендә русча-татарча сөйләшмәлек урнаштырылган. Сөйләшмәлектә табибларның авырулар белән көндәлек аралашуларында очрый торган сөйләм конструкцияләре китерелә. Алар авруга яисә табибка сорау бирү һәм “әйе” яисә “юк” сүзләре белән җавап кайтарып булырлык итеп эшләнгән.

Сүзлекчә урта һәм югары медицина уку йортлары студентлары өчен дә кулланма була ала.

Сүзлекчәдә 600 ләп медидина терминының тәрҗемәсе бирелгән. Сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылганнар. Сүзлекчәдә терминнарның русча варианты калын юл хәрефләре белән бирелгән, ә татарчага тәрҗемәсе – нечкә юл хәрефеннән. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| вертлюг | чукмар сөяге |
| веснушка | сипкел |
| висок | чигә [4, 11]. |

Әгәр дә сүзнең татар телендә эквиваленты булмаса, термин аңлату юлы белән тәрҗемә ителә. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| атересклероз | атересклероз (кан тамырлары авыруы) [4, 9]. |
| вирус | вирус(йогышлы авыру тудыручы кечкенә микроб) |

Гомумән алганда, бу хезмәттә анализланган терминологик сүзлекләрнең әһәмияте гаять зур. Аларны фәнни хезмәтләр язганда да һәм шулай ук уку-укыту эшчәнлеге барышында да җитештерү өлкәсендәге документларда һәм көндәлек тормышта да уңышлы файдаланырга була.

**Әдәбият**

1. Әхмәдуллин А.Г. Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1990. – 238б.
2. Валеев Р.И. Китапханәләр, нәшриятлар һәм мәгълүмат оешмалары хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлек / Р.И.Валеев. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1998. – 175б.
3. Низамов И.М. Русча-татарча иҗтимагый-сәяси сүзлекчә. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1995. – 189б.
4. Шәмсетдинова Р.Р. Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлекчә . – Казан: Татар. кит.нәшр., 1995. – 76б.

## РЕЧЕВОЙ ЭТИКЕТ В КЫРГЫЗСКОМ И БАШКИРСКОМ ЯЗЫКАХ (НА ОСНОВЕ ПРИВЕТСТВИЙ)

**Махамматал кызы Асемай**
М.Акмулла исемендәге башкорт дәүләт
педагогия университеты студенты
Фәнни җитәкче: Султакаева Р.А.

Приветствие – один из самых важных знаков речевого этикета. С его помощью устанавливается контакт общающихся, определяются отношения между людьми. Поэтому не владеть формулами приветствия – это значит быть всем чужим, не уметь общаться [Машиева 2015: 1]

С древних времён приветствие служило не только символом вежливости, но и способом выражения уважения, признанием значимости собеседника. В разных культурах оно принимало уникальные формы: от поклонов и рукопожатий до сложных словесных формул. В современном мире, несмотря на глобализацию, значение приветствия не утратило своей актуальности.

Оно остаётся первым шагом к построению диалога, ключом к взаимопониманию. Использование правильного приветствия в нужный момент помогает создать благоприятную атмосферу, подчёркивает культурный уровень человека. Пренебрежение этим элементом общения может привести к недопониманию, создать барьер между людьми.

Умение приветствовать – это не просто формальность, а искусство, которое требует внимания и чуткости. Оно открывает двери к новым связям, укрепляет старые и делает нашу жизнь более гармоничной.

Кыргызская формула приветствия также имеет свою историю и ему уделяется большое воспитательное значение. Приветствие на сегодняшний день считается наследием, который через века сохранил в себе нравственную чистоту и искренность человеческих отношений. Оно символизирует уважение к собеседнику и служит фундаментом для культурного обмена. Ни одно общение не начнется без доброго слова, произнесенного с теплотой и сердечностью. [Рахматуллина 2003: 146]

Речевой этикет представляет собой набор норм и правил, регулирующих речевое поведение людей. Он включает в себя не только словообразование и

интонацию, но и культурные и социальные аспекты общения. Важной частью речевого этикета являются приветствия, как одна из первых форм взаимодействия между людьми. [Хайруллина 2014: 80]

Изучение приветствий в киргизском и башкирском языках позволяет глубже понять культурные традиции и ценности этих народов. Более того, понимание речевого этикета способствует лучшему межкультурному общению.

Речевой этикет — это система правил, регулирующих способы общения между людьми различных социальных слоев и этнических групп. Он включает в себя нормы вежливости, формальности и уважения в речи.

Традиции и культура играют ключевую роль в формировании речевого этикета. Они определяют, какие формы приветствий и обращения к собеседнику являются приемлемыми, а какие – нет.

В кыргызском языке приветствия не только выполняют функцию общения, но и отражают социокультурные особенности народа. Они начинаются с обращения, которое может варьироваться в зависимости от возраста и статуса собеседника. Например, к пожилым людям чаще обращаются с уважением, используя специальные формы. Младшие могут применять более неформальные приветствия с равными или знакомыми.

Кроме того, характеристики ситуации также играют важную роль. В официальной обстановке приветствия могут быть более формальными и стандартными, тогда как в кругу семьи или друзей допускаются шутливые и теплые обращения. Пол партнера может влиять на выбор слов: среди друзей, например, мужчины и женщины могут использовать разные формы приветствия, отражая культурные традиции и нормы. Таким образом, грамотное использование формул приветствия в кыргызском языке является показателем уважения, понимания контекста общения и социальной ситуации.

В кыргызском языке встречаются как формальные, так и неформальные приветствия. Основные приветствия включают "Салам" (Привет) и "Саламатсызбы?" (Как поживаете?).

Самое простое и распространенное слово для приветствия и в кыргызском, и в башкирском языках — это «Салам» (в кыргызском) и «Сәләм» (в башкирском). Это короткое, но емкое слово, несущее в себе заряд позитива и открытости. По своей сути, «Сәләм» является аналогом русского «Привет». Его удобно использовать в большинстве неформальных ситуаций, будь то встреча с друзьями, знакомыми или даже с коллегами в непринужденной обстановке. Происхождение этого приветствия уходит корнями в арабский язык, что свидетельствует о богатом культурном наследии Башкортостана и Кыргызстана. Произнося «Сәләм», вы словно протягиваете руку дружбы и выражаете готовность к общению. Это легкий и эффективный способ начать разговор, располагая к себе собеседника своей простотой и искренностью.

Однако кыргызский язык не ограничивается одним лишь «Салам». Существует целый ряд других приветствий, которые позволяют выразить больше уважения, проявить заботу о здоровье собеседника и подчеркнуть

формальность обстановки. Эти приветствия не просто констатируют факт встречи, но и несут в себе пожелания благополучия.

«Амансызбы?» — это более формальное приветствие, которое можно перевести как «Здравствуйте! Вы здоровы?». Это выражение не просто вежливости, но и искренней заинтересованности в самочувствии человека. Использование вопросительной формы подчеркивает это внимание. Это уместно при обращении к старшим, к людям, занимающим высокое положение, или в официальной обстановке. Это демонстрация вашего уважения и почтения.

«Аман-эсенсиңби?» — это уже более неформальный вариант предыдущего приветствия, означающий «Здравствуй! Ты здоров?». Здесь чувствуется более близкое, дружеское отношение. Это подходящий вариант для общения с ровесниками, друзьями или близкими знакомыми. В нем сквозит непринужденность и теплота.

«Эсенсиздерби?» — еще одна форма вежливого приветствия, которую можно интерпретировать как «Здравствуйте! Как дела?». Это более широкий вопрос, нежели просто о здоровье, но он также выражает заботу и интерес к жизни собеседника. Это универсальное приветствие, подходящее для различных ситуаций, когда вы хотите проявить уважение, но при этом сохранить дружелюбный тон.

«Сак-саламатсыздарбы?» — это развернутое и особенно уважительное приветствие, которое можно перевести как «Здравствуйте! Будьте в безопасности и здравии!». Это пожелание благополучия во всех аспектах жизни. Оно подчеркивает ваше искреннее расположение и заботу о человеке. Это приветствие часто используется при обращении к уважаемым людям, старейшинам или в ситуациях, когда вы хотите выразить особое почтение.

Формальные приветствия чаще используются в официальной обстановке, тогда как неформальные приветствия более распространены среди друзей и семьи.

- Салам алейкум (Мир вам) – традиционное приветствие, отражающее ценности дружбы и уважения.

- Кандайсың? (Как дела?) – более неформальный способ общения между знакомыми.

В башкирском языке также имеются как формальные, так и неформальные приветствия. Наиболее распространённые формы: "Сәләм" (Привет) и "Хәлдәрегеҙ нисек?" (Как ваши дела?).

Формальные формы приветствий в башкирском языке используются при общении с незнакомыми людьми, тогда как неформальные — между близкими людьми и друзьями.

«Сәләм!» — это самое распространенное и универсальное приветствие, которое можно использовать практически в любой ситуации. В переводе оно означает просто «Привет!». Представьте себе солнечный день, легкий ветерок,

и вы встречаете знакомого, улыбаясь и произнося «Сәләм!». Это как лучик солнца, который согревает душу.

«Сәләм бирҙек!» — это более формальное приветствие, которое можно перевести как «Привет дали». В нем ощущается некоторая торжественность и уважение. Например, если вы впервые встречаетесь с человеком, или хотите выразить особое почтение, то «Сәләм бирҙек!» — отличный выбор.

«Һаумы?» — это еще один вариант приветствия, который можно перевести как «Как дела?». Это уже не просто формальное приветствие, а выражение заботы и интереса к собеседнику. Можно сравнить с тем, как вы спрашиваете у друга «Как дела?», проявляя искренний интерес к его жизни.

Как в кыргызском, так и в башкирском языках приветствия отражают культурные ценности и традиции. Оба языка содержат формальные и неформальные формы приветствий, однако различия могут заключаться в нюансах обращения и специфике употребления.

Культурный контекст, в котором используются приветствия, может меняться в зависимости от ситуации. В обоих языках имеется акцент на уважение к собеседнику, но форма этого уважения может варьироваться.

Изучение речевого этикета, в частности приветствий, позволяет не только лучше понимать культурные особенности народа, но и улучшить качество межкультурного общения.

Данное исследование подчеркивает необходимость дальнейшего изучения речевого этикета в различных языках и культурах, что может способствовать более глубокому пониманию национальной идентичности и традиций народов.

**Литература**

1. Машиева Р.К. Формула приветствия в русском и кыргызском языках // https://arch.kyrlibnet.kg/uploads/OSHGU%20MASHIEVA%20R.K.,2015-4.pdf

2. Рахматуллина З.Я. Уроки этикета: Учебное пособие.- Уфа:РИО БашГУ, 2003. – 222с.

3. Сынбулатова А.Ю. Башкирский речевой этикет: семантика и средства выражения (на материале произведений З. Биишевой): автореф.. дис. канд. филол. наук. – Уфа: 2011. – 27 с.

4. Формановская Н.И. Вы сказали: «Здравствуйте!» (Речевой этикет в нашем общении). – М., 1982. – С. 104.

Хайруллина Р.Х. Принципы сопоставительного лингвокультурологического анализа языковых единиц // Русский язык в диалоге культур. Межвузовский семинар с международным участием. – Уфа: изд-во БГПУ,2014. – 170 с.

6.Хайруллина Р.Х. Фразеологические формулы речевого этикета в русском и башкирском языках // Виноградовские чтения: Прагматические аспекты прагматической и лексической семантики. Тезисы докладов научной конференции – М.: Ин-т русского языка им.А.С.Пушкина.

7. Хисамова Г.Г., Латыпова Л.М. Национально-культурная специфика речевого этикета// Межкультурная-интракультурная коммуникация: теория и практика. Материалы Международной конференции. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2013. – С. 445-448.

## ОНЛАЙН МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ

**Мирхайдарова А.М.**
Алабуга районы Иске Юраш мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Юнусова Л.М.

Онлайн мәгълүмат чаралары татар милләтеннән булган төрле катлам укучылары өчен интернет челтәрендә татар мәгарифен һәм фәнен ныгыту өстендә эш алып бара; туган республикабызның тарихын, мәдәниятен һәм табигатен өйрәнү өчен белешмә һәм укыту базасы буларак төзелә. Шәхестә үсеш булдыру өчен, төрле бәйгеләр, марафоннар игълан итә.

Порталларның төп максатының тагын берсе – башка халыклар арасында Татарстанны таныту, аның мәдәниятен, рухи байлыгын популярлаштыру, республикабызга, татар дөньясына карата кызыксыну, хөрмәт уяту.

"Татар иле" мәгълүмати ресурсы башта Татар Социаль Челтәре буларак планлаштырылган. Хәзерге вакытта электрон китапханә, энциклопедия, аудио һәм фото ресурсларны үз эченә ала. Сайтта башка татар сайтларына сылтамалар җыелмасы бар. “Татар иле” проектының алга таба үсеше мәктәп электрон энциклопедиясе форматында (http://test.ebook.tatar/) күзаллана.

Мәктәп электрон энциклопедиясе - мәктәп программасының этно-региональ өлешенә багышланган коммерцияле булмаган мәгърифәтчелек проектын үз эченә ала. Болар: Татарстан тарихы һәм татар халкы, Татарстан Республикасының физик һәм икътисади географиясе, Татарстан районнары географиясе, татар музыкасы һәм сынлы сәнгате, халык иҗаты, татар теле һәм әдәбияты.

"Татар иле" сайтында интернет челтәренең татар сегментына караган сайтлары тупланган, татар китапханәләрендә урнашкан китапларны онлайн-режимда уку мөмкинлеге ачылган, энциклопедик мәгълүмат урын алган.

“Истәлекле даталар” бүлегендә татар шәхесләре уңышлары яктыртыла. “Татар иле”ндә сибелеп яшәгән татар халкының тормышы чагылыш таба.

Порталда татар халык җырлары һәм көйләренең сыйфатлы онлайн базасы да булдырылган. “Аудио” бүлегендә җырлар белән бергә аларның текстлары да урнаштырыла һәм һәр кулланучы караоке режимында теләсә кайсы җырны үзе дә кушылып башкара ала. Музыкаль әсәрләрнең авторлары, җыр исемнәре һәм җыр текстындагы сүзләр буенча эзләп табу мөмкинлеге каралган. “Видео” һәм “Фотогалерея” бүлекләре дә киң мөмкинлекләр ача. “Видео” бүлегендә фильмнар (документаль, фәнни-популяр, нәфис фильмнар), мультфильмнар, концертлар һәм спектакльләр, телевизион тапшырулар һәм әңгәмәләр урын алган. “Фотогалерея”дә Татарстан, татарлар, татар дөньясы

белән бәйле фоторәсемнәр, рәссамнарның картиналары, татар дөньясы өчен кызыклы һәм файдалы мәгълүматлар  урнаштырылып барыла.

Белем.рупорталы  –татартелендәге  интернет-белем үзәге–иң  уңайлы белем алу чыганакларыннан  санала. Аңа 2007 нче елда Гатауллин Раил Мәүлет улы нигез сала.

Яңартылган Белем.ру порталы киң катлам кулланучылар өчен үзгәртелеп тора. Порталның төп эшләү юнәлеше - татар телендә белем бирүче укытучыларның эшен уңайлату, аларны белем бирү ресурслары белән тәэмин итү, укытучыларның хезмәтен башкаларга таныту, квалификацион тәҗрибәләрен күтәрергә ярдәм итү, татар телендә белем бирү сыйфатын күтәрү өстендә эш алып бару. Моңа карамастан, портал ата-аналар, студентлар һәм мәктәп укучылары өчен файдалы һәм кызыклы. "Белем.ру" порталында көн саен үзеңә охшаган ресурс табып укырга, дөнья яңалыкларын укып барырга мөмкин.

Белем.руның игътибарга бик  лаеклы проекты – Мирас китапханәсе. Монда китаплар, аудиокитаплар, әсәрләр, романнар, хикәяләр, шигырьләр, поэмалар, бәетләр, балладалар, аларның авторлары турында белешмәләр урнашкан Татар китаплары, бигрәк тә элегрәк чыкканнары басмаханәләрдә сирәк яңартыла. Белем.ру монда да ярдәмгә килә. Бу проектта укытучылар һәм укучылар соравы буенча иң сирәк очрый торган, шулай ук яңа китаплар да бастырыла. Укырга теләге булган теләсә кем рәхәтләнеп укый ала.

Китапханәнең платформасы яңартылып тора, яңа мөмкинлекләр өстәлә. Яңа китаплар, аудиокитаплар белән тулыланып тора.

Белем Академиясе рубрикасы ( бүлеге) шәхес, җәмгыять, мәдәният, тел һәм коммуникация үзенчәлекләрен үстерү максатында,  мәгълүмати һәм цифрлы технологияләр буенча онлайн русча һәм татарча өйрәнү курслары үткәрә.

Максаты: татар телендә IT-технологияләрне яхшы белгән һәм оста кулланган белгечләр санын арттыру.

Белем Академиясе Иннополис лицее белән берлектә һәм Татнетны үстерү фонды ярдәме белән төрле бәйгеләр үткәрә. Мәсәлән,  «Яшь вебмастер» - «Юный вебмастер» дип исемләнгән республикакүләм IT-бәйгесендә 5-11 сыйныф укучылары 7 номинациядә татар һәм рус телләрендә чыгышлар ясап көч сынаша ала.

«Белем радиосы» - ул балалар һәм яшүсмерләр интернет-радиосы. Аның төп максаты -  билингваль белем бирү һәм мәдәни-агарту; мәдәни мирасны, гаилә кыйммәтләрен һәм традицияләрен саклау. балалар иҗатын популярлаштыру һәм тарату.

Аның төп эчтәлеген мәктәп балаларына кирәк булган мәгълүматлар тәшкил итә. Бу радио нигезенә татар әдәбияты, энциклопедик мәгълүмат, гомумән бала өчен кирәкле файдалы мәгълүматлар салынган. Радио утыздан артык билингваль тапшыру алып бара.  Мәсәлән,  «Белем энциклопедиясе», «Белем WiKi», «Путь к себе», «Читать или не читать», «Бездә кунак», «Сәламәт

тәндә – сәламәт акыл», «Әдәби дәрья», «Һөнәрләр иленә сәяхәт» һәм башка кызыклы һәм файдалы тапшырулар уздырыла.

«Белем радиосы» төрле бәйгеләр, кастинглар үткәрә. Монда иҗат белән шөгыльләнүче талантлы яшьләр өчен үзләре башкарган җырларны, иҗат иткән шигырьләрне бушлай эфирга чыгара алалар.

«Белем» радиосында тапшыруларны алып баручыларның күпчелеге – бәйгеләрдә җиңүләр яулаган, актив һәм сәләтле балалар һәм яшьләр. Алар үзләренә файдалы булган мәгълүматны яшьтәшләренә кызыклы итеп җиткерәләр.

2021нче елда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» ДБУ белән берлектә «Татарханә» проектын тормышка ашыра. «Татарханә» - «Татар киеме», «Татар табыны» рубрикаларында татар халкының этномәдәни мирасын тәкъдим итүче тарихи-агарту проекты. Әлегечаралар циклы онлайн-форматта(YouTubeмәйданчыгында)узачак.

«Татар табыны» рубрикасында белгечләр милли кухняның затлы ризыклары һәм татар чәй табыны үзенчәлекләре турында сөйләячәк, «Килен токмачы», «Кияү пилмәне», «Каклаган каз» әзерләү буенча мастер-класслар уздырачак. «Татар киеме» рубрикасы кысаларында Татарстан Республикасы Милли музееның күргәзмә залларында татар халкының костюм комплексы һәм заманча татар яшьләре стиле турында лекцияләр циклы узачак, шулай уку калап чигү, «Хаситә», «Изү» әзерләү техникасы һәм технологиясе белән дә таныштырачаклар. «Татарханә» проектын оештыручылар тарафыннан интернет флешмоб – кыйммәтле бүләкләр уйнату да каралган.

«Татарханә» дип аталган әлеге сайтта татар теле укытучылары өчен бөтен нәрсәдә бар: дәрес үрнәкләре, мастер-класслар, дәрес структурасы, дәрестән соң эшләр, анализлар, имтиханга, аттестациягә әзерлек һәм башка бик күп файдалы һәм кирәкле материаллар. Сайт һәркеше өчен ачык.

Цифрлы белем бирү ресурслары– ул кеше потенциалының матди, рухи һәм башка үсеш чаралары. Алар уку-танып белү эшчәнлегенә кызыксынуны гына тәэмин итеп калмый, универсаль сәләтләрне үстерүне, предмет эчтәлеген, әйләнә-тирәдә үз-үзеңне әхлакый тоту кагыйдәләрен үзләштерүне дә башкара. Яшәешне электрон технологияләрчолгапалганзаманда, белемалу процессы да үзгәрешсез кала алмый. Төрле электрон дисклардан, интернет челтәреннән әзер, бирелеше ягыннан үтемле эшләнгән мәгълүматны кыска гына вакыт эчендә күчереп алырга күнегеп килүче укучы өчен, аның кабул итү мөмкинлегенә туры килгән яңа белем бирүдә заманча мәгълүмати технологик чаралар уйлап табу – бүгенге заманның төп бурычы булып тора.

Мультимедия технологияләре бик зур эмоциональ һәм мотивацион мәгънәгә ия, тәкъдим ителә торган мәгълүматның күләме исәбенә дәреснең белем бирү эффектын арттыра, уку-укыту процессы белән идарә итүнең яңа мөмкинлекләрен ача. Мәгълүматлаштыру белем бирү процессына зур йогынты

ясый. Ул белем бирү процессын үтемлерәк итәргә, белемне кабул итү тизлеген арттырырга, зур күләмдәге материалны аңлап, тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә.

**Әдәбият**


1. http://www belem_ru
2. https://vk.com/belem_ru
3. https://t.me/s/belemletatar - акад
4. https://belem.ru/node/2723 мирас
5. https://radio.belem.ru/ радио
6. http://tatarile.tatar/
7. https://tatar-congress.org/yanalyklar/tatarhanege-rehim-itegez/ татарханә
8.https://nsportal.ru/shkola/distantsionnoe-obuchenie/library/2021/01/18/tsifrly-belem-biru-resurslary


## М.АКЪЕГЕТНЕҢ “ХИСАМЕТДИН МЕНЛА” ӘСӘРЕНДӘ ПОЭТИК ОНОМАСТИКА.


**Талыпова Л.Н.**
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.д., профессор Камаева Р.Б.


“Ономастика (грек. *onyma* – исем, *tike* – караган) ялгызлык исемнәрен өйрәнү белән шөгыльләнә” [Сафиуллина 2002: 129]. Бу дисциплинаны XIX гасырның икенче яртысында үстерә башлыйлар. Аның формалашуына Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Әхмәров, В.В. Радлов, В.К. Магницкий, Н.И. Золотницкий, С.М. Шпилевский, Н.И. Ашмарин, И.А. Износков, Г. Тукай һ.б. үзләреннән зур өлеш кертәләр.

М.З. Зәкиев дәреслегендәге классификациядән файдаланып, без М. Акъегетнең “Хисаметдин менла” әсәрендәге ономастик лексиканы берничә төркемгә бүлдек:

1. “Антропонимика - кеше исемнәре, әтисенең исеме, фамилия, кушамат, тәхәллүс килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш, кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын өйрәнә торган ономастиканың бер тармагы.” [Зәкиев 2017: 40]

Мәсәлән: *Хәнифә, Гали, Сибгатулла һ.б.*

Бу кыз мөсафирханә хуҗасы кызы гүзәл вә күркәм *Хәнифә* исемле иде. [Акъегет 1886: 51]

*Гали* бай бу губернада бөек һәм мәшһүр сәүдәгәр иде. [Акъегет 1886: 52]

*Сибгатулла* әфәнде бик шат булып, туй мәҗлесен зур һәм тантаналы итеп ясады. [Акъегет 1886: 77]

2. “Этнонимика – ыруг-кабилә, халык һәм милләт атамаларын өйрәнә торган тармак.” [Зәкиев 2017: 10]

Мәсәлән: *чук халыгы һ.б.*

Ләкин *чук халыклары* башка шәһәрләрә, мәсәлән, Астрахань, Ростов, Казан кебекләрә эш вә тиҗарәт өчен дагыларлар. [Акъегет 1886: 45]

3. “Зоонимика – ономастиканың хайван һәм кош-корт кушаматларын өйрәнә торган тармагы.” [Зәкиев 2017: 399]

Мәсәлән: *куян, үрдәк һ.б.*

Белешебез Бикбулат мулла үз вазифасын үтәү белән мәшгуль улып, муллаларга садака бирергә кирәклекне мәхәлләсенә киңәш итеп вә кисәтеп-искәртеп, аучы *куян* вә *үрдәкне* өмет итеп саклаганы кебек, бу да никахлар өмет итеп сакламакта иде. [Акъегет 1886: 57]

4. “Космонимика – барлык тәр күк җисемнәре атамаларын өйрәнә торган тармак.” [Зәкиев 2017: 10]

Мәсәлән: *кояш һ.б.*

*Кояш* үзенең нурларын вә эсселеген чуар булып җәйрәп яткан кырларга чәчә. [Акъегет 1886: 77]

5. “Поэтик ономастика – матур әдәбиятта һәм фольклор әсәрләрендәге ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган тармак.” [Зәкиев 2017: 10]

Мәсәлән: *Хисаметдин менла, Бикбулат менла һ.б.*

Моның аркасында *Хисаметдин менла* рәхәт вә башкаларга ихтыяҗсыз тормыш итәр иде. [Акъегет 1886: 46]

*Бикбулат менла* түрдә утырган. [Акъегет 1886: 54]

6. “Топонимика – ономастиканың географик объект атамаларын, аларның килеп чыгышын, төзелеш-ясалышларын, кулланылыш үзенчәлекләрен, таралыш ареалларын өйрәнә торган тармагы.” [Зәкиев 2017: 10] Үз чиратында, өйрәнү объектларына карап, әлеге тармак үзе берничә бүлекне берләштерә: гидронимика (су чыганаклары атамалары); оронимика (урын исемнәре); микротопонимика (теге яки бу төбәктәге урам, тыкрык, чокыр, тау, болын һ.б. төшенчә атамалары) һәм микротопонимиянең ике төре: ойконимика - торак урыннары атамалары, полисонимнар - шәһәр исемнәре атамаларын өйрәнә торган тармаклар.

Мәсәлән: гидронимика (*Идел елгасы, Һинд елгасы һ.б.*); оронимика (*Пиренеи таулары һ.б.*); ойконимика (*"Н" авылы һ.б.*); полисонимнар (*Астрахань, Ростов, Казан һ.б.*).

Русия уртасында *Идел елгасыннан* ерак түгел бер татар авылы бардыр. [Акъегет 1886: 45]

Исламият нәтиҗәсендә тырышлык вә гайрәтләре артып, гарәпләр хәлифәләр заманында шундый бер мәмләкәт төзеделәр ки, ул вакыт гарәп җиреннән олуг җир юк иде: Азиядә булган *һинд елгасыннан* Аурупадагы *Пиренеи тауларына* кадәр гарәп җире, ислам дәүләте булып, бу дәүләттә исламият аркасында никадәр булдыклы хакимнәр, никадәр камил табиблар вә голямалар мәйданга чыкты! [Акъегет 1886: 59]

Шунда *"Н" авылында* урта мәчеттән ерак түгел бер кечкенә йорт бар. [Акъегет 1886: 45]

Ләкин чук халыклары башка шәһәрләрә, мәсәлән, *Астрахань, Ростов, Казан* кебекләрә эш вә тиҗарәт өчен дагыларлар. [Акъегет 1886: 45]

М. Акъегетнең “Хисаметдин менла” әсәрендә кулланылган поэтик ономастикадан антропонимнар – 20%, этнонимнар – 7%, зоонимнар – 13%, космонимнар – 7%, поэтик онимнар – 13%, топонимнар - 47% ны тәшкил итә.

**Әдәбият**


1. М. Акъегет "Хисаметдин менла" / М. Акъегет // kitaphane.tatarstan.ru : [сайт]. — URL: https://docs.yandex.ru/docs/view?tm=1737554292&tld=ru&lang=tt&name=pub_26755.doc&text=хисаметдин%20менла%20читать&url=https%3A%2F%2Fkitaphane.tatarstan.ru% (мөрәҗәгать итү датасы: 20.01.2025).

2. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта йортлары өчен д-лек. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 129-131.

3. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2017 – Т. III. 1 кис.– 536 б.


## СТИЛИСТИК ЧАРА БУЛАРАК ОКСЮМОРОННАР


**Хаматнурова З.М.**

КФУ ның Алабуга институты студенты

Фәнни җитәкче: ф.ф.д., проф. Камаева Р.Б.


Стиль сүзенең килеп чыгышын галимнәр түбәндәгечә аңлата: “Стиль (лат. stylos) борынгы заманнарда һәм урта гасырларда язу коралы булып хезмәт иткән таяк, таякчык мәгънәсенә туры килә. Борынгы греклар һәм римлылар балавыз белән капланган такталарга стиль белән яза торган булганнар. Шул язу коралын аңлаткан сүз соңга таба башка төшенчәләргә дә беркетелә һәм стиль сүзе төрле мәгънәләрдә кулланыла башлый” [Хаков 1999: 10]. Хәзерге вакытта галимнәр стиль дип “билгеле бер фикер яки тойгыны урынына, вакытына һәм максатына ярашлы итеп әйтеп бирү”не атыйлар [Курбатов 2002: 3].

Әдәбият белемендә стиль дип “заман рухын, теге яки бу әдәби агым яки юнәлешнең эстетик принципларын, авторның дөньяга карашын белдерүче әдәби алымнар системасы” атала [Әдәбият белеме сүзлеге 2007: 180]. Шәхси стиль – автор катнашуын әдәби әсәрдәге барлык әһәмиятле элементларда (композиция, интонация, тел чаралары системасында) “турыдан-туры белдерү” дигәнне аңлата [Әдәбият белеме сүзлеге 2007: 180]. Х.Курбатов та теге яки бу әдипнең шәхси стилен тикшерүдә тел чараларын өйрәнүнең әһәмиятен ассызыклап, түбәндәгечә яза: “Матур әдәбият әсәренең стилен тикшерү – фикер йөртүнең гадәттәге алымнарын барлап чыгу гына түгел, бәлки, тормыш күренешләрен теге яки бу язучының үзенә генә хас күңел күзенең әсәрдәге билгеле бер төп образны барлыкка китерү өчен тормыштагы нәрсәләргә игътибар итүен, аларны бер-берсе белән ни рәвешле бәйләнешкә кертүен һәм,

билгеле инде, бу төр иҗат эшендә тел мөмкинлекләреннән ничек файдалануны өйрәнү дигән сүз” [Курбатов 2002: 3].

Стилистика сүзе борынгы Греция һәм Италиядә матур сөйләм сәнгате, риторика дигәнне аңлаткан. Хәзерге вакытта стилистика “тел гыйлеменең телдәге стильләр, аларга хас закончалыклар, телнең сүзлек байлыгы, фразеологиясе, морфологиясе һәм синтаксисы белән бәйләнешле стилистик-семантик үзенчәлекләрне, сөйләмнең поэтик яңгырашын, эмоциональлеген барлыкка китерә торган сәнгатьчә сурәтләү алымнарын, фонетик-стилистик чараларны өйрәнә һәм тикшерә торган әһәмиятле тармагы” буларак аңлашыла [Хаков 1999: 14].

Стилистика – сүзләрнең мәгънә үзгәрешләре һәм сөйләм төзелеше белән бәйләнешле фән. Аның өйрәнү объекты – тел чараларының һәм сәнгатьчә сурәтләү алымнарының бер максатка ярашлы рәвештә кулланылу һәм алардан нәтиҗәле итеп файдалана белү юллары. Тел фәненең бу тармагы телдәге стильләрне, аларга хас үзенчәлекләрне, сөйләмнең сәнгатьчә чараларын, сүзлек хәзинәсендәге мәгънә үзгәрешләрен, фонетик, морфологик һәм синтаксик категорияләргә караган стиль күренешләрен үз эченә ала. Теге яки бу стильгә карап, сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең, грамматик формаларның мәгънә үзгәрешләре барлыкка килә. Мондый үзгәрешләр стилистик категорияләр, телнең тарихи үсеше, тел күренешләренең эволюциясе белән дә тыгыз бәйләнештә торалар. Стилистиканың күптөрле тармаклары бар: фонетик стилистика, лексик стилистика, грамматик стилистика, сөйләм стильләре. Аларның һәркайсының үз өйрәнү даирәсе билгеләнгән. Мәсәлән, сөйләм стильләрен өйрәнүче тармак сөйләшү һәм язма стильләренең төрләре белән эш итә. Фонетик стилистика интонация, пауза, логик басымның дөрес куелышын, ритмлылыкны өйрәнә. Грамматик стилистикада төп игътибар сүз төркемнәрен дөрес куллануның кайбер үзенчәлекләренә, поэтик синтаксис алымнарын куллану серләренә юнәлтелгән. Лексик стилистиканың өйрәнү объекты булып стилистик яктан битараф һәм аерымланган, сүзлек хәзинәсенең төрле катламнарына караган сүзләр торалар. Болар арасында күчерелмә мәгънәле сүзләр (ассоциатив сурәтләү чаралары) аерым урын алып тора.

Ассоциатив сурәтләү чаралары дип, “күчерелмә мәгънәне төрле әйберләр, күренешләр, предметлар арасындагы бәйләнеш аша барлыкка китерә торган гыйбарәләргә әйтәләр” [Әдәбият белеме сүзлеге 2007:191]. Алар барлык телләргә дә хас. “Сүзләрнең болай кулланылышы – үзенчәлекле күренеш. Бу үзенчәлек шуннан гыйбарәт: сүзләрдән гадәти булмаган мәгънәдә файдалану ике төрле төшенчәне – беренчел һәм яңа төшенчәне куллану белән бергә бара. Һәм менә шушы ике төшенчәне янәшә кую, чагыштыру, безгә үзенә бер төрле йогынты ясап, образлылык, тәэсирлелек барлыкка китерә”, – диләр галимнәр [Юсупов 2003: 32].

Ассоциатив сурәтләү чараларының тексттагы вазыйфасы шактый катлаулы һәм әһәмиятле. Урынлы кулланылу очрагында алар әдәбиятта образ тудыруга хезмәт итәләр, текстның укучыга тәэсир көчен арттыралар, шул

рәвешчә, сурәтләнә торган күренеш яки геройның эчке дөньясындагы үзгәрешләр укучының күз алдына төгәл бер картина булып килеп баса. Оксюмороннарның каршылыклы фикерне, күренешне кыска һәм төгәл рәвештә сыйфатларга мөмкинлек бирүе аларны ассоциатив сурәтләү чаралары рәтендә тикшерергә җирлек булып тора. Күчерелмә мәгънәлелеккә нигезләнеп ясалу ягыннан оксюмороннар метафора, метонимия, эпитет, синекдоха, гиперболаларга, чагыштыруларга, чыннан да, беркадәр тартым. Бер мисалны карап китик:

Хәзер менә *яңа әни* алып кайтырга барам, – дип уйлады ул, нигәдер көләсе килде (Р.Зәйдулла).

Биредәге *яңа әни* сүзтезмәсе оксюморон хасил иткән. Әлеге *сыйфат + исем* шәкелендәге сүзтезмә семантик яктан бер-берсе белән ярашмый торган сүзләрнең мөнәсәбәткә керүе нәтиҗәсендә хасил булган. Әни – кешене җиһанга китерүче, тәрбияләп үстерүче изге зат – яңа һәм иске була алмый. Ул – бердәнбер. Укучы аңлаганча, әлеге сүзтезмәнең нигезендә күчерелмә мәгънәлелек ята, *яңа әни* дигәне – әни вазифаларын башкарырга тиешле хатын-кыз, *үги әни* дигәнне аңалата.

Оксюмороннарны стилистик сурәтләү чаралары белән якынайта торган сыйфатлар да бар. Билгеле булганча, стилистик чараларны 4 төркемгә аералар:

1) кабатлауга нигезләнгән чаралар;
2) сүзләрнең сөйләмдә гадәти булмаган тәртибеннән хасил булган чаралар;
3) автор ихтыярын чагылдыручы чаралар;

мәгънә каршылыгы барлыкка китерүче чаралар [Әдәбият белеме сүзлеге 2007:191]

Боларның беренчеләренә рәдиф, анафора, эпифора, градация, хиазм кебек чаралар керә. Икенче төркемне хасил итүче стилистик чаралар сүзләрнең сөйләмдәге гадәти тәртибе үзгәрү җирлегендә хасил булалар. Инверсия ярдәмендә автор әдәби текстка яңа эмоциональ төсмер бирә. Автор ихтыярын чагылдыручы фигуралар, исеменнән үк күренгәнчә, автор позициясен, мөнәсәбәтен белдерүгә хезмәт итә. Матур әдәбият әсәрләрендә аеруча риторик сорау, риторик өндәү, риторик эндәш кебек чараларның кулланылышы еш күзәтелә. Әмма оксюмороннар бары мәгънә каршылыгы барлыкка китерүче чаралар белән уртаклык хасил итә. Мәгънә каршылыгын белдерүче стилистик фигуралар укучы игътибарын көтелмәгән, кайбер очракта логикага каршы килгән яисә пародоксаль ситуация тудырып үзләренә тарталар. Мисалга мөрәҗәгать итик:

– Җибәр! – дип йодрыгы белән аның җилкәсен төйде. – Битеңне умырам, җибәр, оятсыз!

– Умыр, – диде Бакир, – *чырайлары ямьсезләнгән саен ирләр матурая* бара (Н.Гыйматдинова).

Биредә көтелмәгән ситуация, мәгънәви каршылык хасил булган: ямьсезләнгән саен матураю күренеше мантыйкка сыймый шикелле. Әмма

контексттa укучыга әлеге гыйбарә болай аңлашыла: яралар, җәрәхәтләр ир-егетне бизи, аның сугышчы, көрәшче, дошманнардан яклаучы сыйфатын күрсәтеп тора.

Ф.Бәйрәмованың “Кырык сырт” романыннан алынган җөмләгә игътибар юнәлтик:

Бу *бөек төзелеш астына* татар *сөякләре түшәлгән* (Ф.Бәйрәмова).

Биредәге каршылык шуннан гыйбарәт: кеше аңында *бөек* сүзе, кагыйдә буларак, уңай эмоцияләр хасил итә. Атаклы шагыйрьләребез күп булуга карамастан, без Тукай турында гына бөек дип әйтәбез; танылган җырчыларыбыз шактый булуга карамастан, бөек эпитетын И.Шакиров кебек мәшһүр шәхесләребезгә карата гына кулланабыз. Димәк, бөек төзелеш тә барча халыкка, милләтебезгә файда китерүче, озак гасырлар буена киләчәк буын вәкилләрен сөендерүче күренеш буларак кабул ителә. Әмма җөмләнең икенче яртысында бирелгән мәгълүмат – астына татар *сөякләре түшәлгән* – әлеге бөек сүзенең мәгънәсен юкка чыгара, укучыда милләт өчен әрнү, ачыну тойгылары уята.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: әдәби текстларда оксюмороннар чагыштырмача сирәк очрауларына карамастан, зур әһәмияткә ия. Алар, нигез итеп күчерелмә мәгънә мөнәсәбәтләрен алуларында ассоциатив сурәтләү чараларына, үз эчендәге сүзләрнең капма-каршы яисә каршылыклы мәгънә мөнәсәбәтләрендә тору ягыннан мәгънә каршылыгы барлыкка китерүче стилистик чараларга тартым. Әмма аларның үзенчәлекле ягы да бар: парадоксаль семантик ситуация хасил итеп, телдәге мөмкин һәм мөмкин булмаган күренешләр арасындагы чикләрне юалар, чынбарлыкның иң тирән структур төзелешенә үтеп керергә мөмкинлек тудыралар. Матур әдәбиятта оксюмороннар башка тел-сурәтләү һәм стилистик чаралар көчсез булганда, кыска тәгъбир белән каршылыклы, четерекле халәтне белдерәсе булганда куллану мөмкинлеге белән бәяләп бетергесез чара булып торалар.

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге/ Төз.-авторлар: Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Йосыпова, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Г. Р. Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. Бәйрәмова Ф. Кырык сырт: романнар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005 – 672 б.

3. Гыйматдинова Н. Парлы ялгыз: повестьлар, хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 191 б.

4. Зәйдулла Р. Ташка ордым башны: хикәяләр, эсселар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 399 б.

5. Курбатов. Сүз сәнгате: татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

6. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 304 б.

7. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 223 б.

# И.ЮЗЕЕВНЫҢ “ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ” ӘСӘРЕНДӘГЕ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫ ТӨП МӘГЪНӘЛӘРЕ ЯГЫННАН ТӨРКЕМНӘРГӘ БҮЛҮ

**Юнусова Э.Ф.**
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.д., проф. Камаева Р.Б.

Телдәге төшенчәләр бер сүз белән генә түгел, ә үзгәртелми, таркалмый торган тотрыклы сүзтезмәләр белән дә белдереләләр: *авыз еру – көлү, авызы колагына җитү – шатлану, авызына су кабу – дәшмәү, авыз турсайту – үпкәләү, авыз сулары килү – кызыгу, аваз ачмаслык итү – оялту* һәм башкалар.

Телдәге мондый сүзтезмәләрне фразеологизмнар дип атыйлар. Фразеологизмнарны өйрәнә торган тармакны фразеология диләр [Сафиуллина, Зәкиев 2002: 110].

Фразеология – грек сүзе. Ул *фразис* һәм *логос* сүзләренең кушылмасыннан тора, төп мәгънәсе – *сүз фәне*. Термин буларак, фразеологиянең ике мәгънәсе бар:

1) билгеле бер телнең үзенә генә хас фразеологик әйтелмәләре;

2) аерым бер телдәге фразеологик әйтелмәләрне өйрәнә торган фән. [Галиуллина, Зәкиев 2015: 197]

Фразеологизмнарны ирекле сүзтезмәләр белән бутарга ярамый. Ирекле сүзтезмәләр телнең грамматик законнары нигезендә һәрвакыт ясалып торалар, составындагы сүзләрне алыштырырга мөмкин, аларның мәгънәсе компонентларының мәгънәләре суммасына тигез була. Фразеологик сүзтезмәләр кимендә ике сүздән торалар, телдә үзгәрешсез яшиләр, сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр, алар составындагы сүзләр арасына башка сүзләрне өстәп кую мөмкин түгел. Фразеологизмның мәгънәсе компонентларының суммасына тигез була алмый: *сай йөзү – белмәү, борын салындыру – үпкәләү, йөз төрле – ике төрле, уклау йоткан – бөгелер-бөгелмәс эшләүче (ялкау кешегә карата әйтелә)* һәм башкалар. Димәк, тел берәмлекләре буларак, фразеологизм мондый дифференциаль билгеләргә ия:

1) сүзләрнең аерым булуы (кимендә ике сүз булу);

2) компонентларның мәгънәви кушылуы;

3) мәгънәнең һәм аны белдерүче лексик-грамматик чараларның тотрыклылыгы;

4) сөйләмдә әзер килеш кулланылуы.

Мәгънәсе буенча бер төшенчә белдерүче үзара тыгыз бәйләнешле сүзләр группасына фразеологик әйтелмә диләр. Мәсәлән: *сабын куыгын очыру (ялганлау), чәч үрә тору (курку), трай тибү (эшсез йөрү)* [Сафиуллина, Зәкиев 2002: 111].

Фразеологик әйтелмәләр ирекле тезмә сүзләрдән түбәндәге үзенчәлекләре белән аерылалар:

1) Фразеологик әйтелмәләр күчерелмә мәгънәгә ия, ә ирекле сүзтезмәләр туры мәгънәдә генә кулланылалар.

2) Фразеологик әйтелмәләр сөйләм барышында яңадан төзелмиләр, сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр, ә ирекле сүзтезмәләр телнең грамматик законнары нигезендә сөйләм барышында бернинди чикләнүсез ясалып торалар.

3) Фразеологик әйтелмәләрнең составы даими, бу составка, мәгънә бөтенлегенә зыян китермичә, яңа сүз өстәү, я компонентларның берсен төшереп калдыру, я башка сүз белән алмаштыру күренеше чикләнгән, үзгәртелгән очракта да катгый рамкаларда башкарыла, ә ирекле сүзтезмәләрдәге сүзләрне бернинди каршылыксыз төшереп калдырырга, араларына башка сүз өстәргә, бер сүз урынына башка сүз кулланырга була. Мәсәлән: *боз киптерү (тик яту) – кер киптерү*.

4) Фразеологик әйтелмәнең мәгънәсе аның компонентларының гади суммасына тигез түгел, ә ирекле сүзтезмәләрнең мәгънәсе аерым компонентларның мәгънәләре суммасына тигез.

5) Фразеологик әйтелмәнең семантик яктан бөтенлеге аны гади бер сүз белән алыштырып булуында да күренә: *тамырына балта чабу – бетерү, теңкәгә тию – аптырату, түбәсе күккә тию – шатлану*.

6) Фразеологик әйтелмәләргә сурәтлелек хас, ягъни алар кешеләрнең эмоциональ-эстетик кичерешләрен сурәтләүгә хезмәт итәләр. Мәсәлән: *эч яну, йөрәк әрнү, җан телгәләнү, ут йоту.*

7) Фразеологик әйтелмә составында берәр сүз, тулысынча яисә өлешчә ирекле мәгънәсен югалтып, фразеологик чикле мәгънәгә ия була башлый. Мәсәлән: җиде юл чаты дигәндә җиде сүзе, «күп» мәгънәсен белдерә башлап, фразеологик берәмлек барлыкка китергән.

8) Фразеологизмнар составында хәзерге телдә мөстәкыйль кулланылмый һәм аңлашылмый торган, архаиклашкан, диалекталь сүзләрнең булуы – гадәти күренеш: *гөрбәт чигү; сөмсере коелу; трай тибү; акылга сапкан* [Галиуллина, Зәкиев 2015: 199].

Фразеология кеше сөйләмен баетуда, аны үткенрәк, көчлерәк итүдә, әдәби әсәр теленә, аның стиленә сәнгатьлелек, образлылык бирүдә, фикерне тулырак ачуда әһәмиятле роль уйный. Тел осталары фразеологик берәмлекләрне әдәби әсәрләрдә еш кулланалар. Аларны куллану сөйләмне бизәкле, образлы, тәэсирле итә.

Илдар Юзеевның “Гашыйклар тавы” әсәрендәге фразеологизмнарны мәгънәләренә карап, берничә төркемгә берләштерергә мөмкин. Тикшерелә торган фразеологизмнар арасында кешенең халәтен белдерүче сүзләр күпчелекне тәшкил итә. Бу фразеологик берәмлекләр кешенең эчке психологик халәтен белдерәләр. Язучы аларны геройларга характерлы сыйфатларны ачу, әдәби образны тулы итеп тудыру өчен куллана. Әдәби геройларның үз-үзләрен

тотышын, хисләрен фразеологизмнар аша бирү укучыга образларның характерын тулырак ачарга ярдәм итә.

1. *Гажәпләнү.* Мәсәлән: *сүзсез калу, ут-боз эчендә, бозлы су сиптемени, телсез калу, җан тетрәү, таң калу* һ.б.

Сине күргәч, *сүзсез калдым,*

Адаштым, дип алдаштым. [Юзеев 2002: 270]

Бер ел, ике, өч ел *ут-боз эчендә*. [Юзеев 2002: 273]

Бу сүзләре белән кыз минем дөрләгән хисләремә *бозлы су сиптемени:* иреннәре җиләктән алсурак тоелган сөйкемле кыз – укучы бала гына икән. [Юзеев 2002: 268]

С ә е т. Мине күргәч, *телсез калдың,*

Адаштым дип, алдаштың. [Юзеев 2002: 288]

М ө н и р ә. Кайтып керсәң, *җаннарың тетрәр...* [Юзеев 2002: 290]

Беренче тапкыр аяк баскан һәрбәр кеше, экиятләрдә күрелмәгән манзарага *таң калып*, “аһ” иткән, тәүге күрүдә үк гашыйк булган. [Юзеев 2002: 291]

2. *Кайгыру, күңелсезләнү, борчылу*. Мәсәлән: *җан әрнү, харап итү, күңел сүрелү* һ.б. *Җаным әрни* көн-төн – ник аттым? [Юзеев 2002: 265]

М ө н и р ә. Минем хәлем ярыйсы ла ул... Таллыкүл өчен *җаным әрни*. [Юзеев 2002: 290]

М ө н и р ә. *Хараплар иткәнсең*, Сәет абыкаем... [Юзеев 2002: 272]

М ө н и р ә. Их, *харап иттең*!.. [Юзеев 2002: 290]

Кырын каравыңны белгәч,

*Күңелләрем сүрелде*. [Юзеев 2002: 270]

3. *Кызыксыну-кызыксынмау*. Мәсәлән: *күзләрен ялтырату, күз төшерү, йөрәк буйсынмау, ваз кичү, өметен өзмәү, өзелеп көтү, күз алмау, кул бармау* һ.б.

– Әйе... Әйе! Ул легенда... чындыр, бәлки... Ул, зәңгәр *күзләрен ялтыратып*, миңа карады. [Юзеев 2002: 267]

Шнапс чөмерәбез, типтерәбез, кызларга *күз төшерәбез!* [Юзеев 2002: 274]

Ә *йөрәк буйсынмый*: «Кызның яшьлек тилерүе генә булмаса ярар иде»,– ди. [Юзеев 2002: 269]

– Бездән ни калыр: яңа Тукай, Сәйдәшләрме, әллә “заман өчен искергән” дип, үз халкының рухыннан *ваз кичкән* нәсел-нәсәпсезләрме? [Юзеев 2002: 295]

Чыннан да, Сәлимә апа ике тапкыр “Ирегез Хәнәфи Вафин геройларча һәлак булды” дигән хәбәр алган, *өметен өзмичә* көткән. [Юзеев 2002: 264]

М ө н и р ә. Шулай да мин *өметне өзмим*. [Юзеев 2002: 290]

“Кайта!” диеп *өзелеп көткәндер* дә,

Көтә-көтә түземе беткәндер. [Юзеев 2002: 265]

Буранда маяклар тезәм мин:

*Күз алмыйм* син кайтыр юллардан. [Юзеев 2002: 281]

Ө м е т. Әнкәй өен сүтәргә дә *кул бармый*, торсын, әйдә, рухын саклап... [Юзеев 2002: 293]

4. *Курку*. Мәсәлән: *йөздән кан качу, йөрәк ярылырга җитеп кагу, тез буыннары калтырау* һ.б.

Нәни генә, йомшак кына кулларына кагылгач, *йөздән кан качты*, тәнем дерелдәп китте. [Юзеев 2002: 268]

*Йөрәк ярылырга җитеп кага иде*. [Юзеев 2002: 272]

Әллә инде *тез буыннарым калтырый*, үз хәлемне үзем генә беләм. [Юзеев 2002: 269]

Кешегә хас сыйфатларга бәйле фразеологик әйтелмәләр: *кулы кору, күз тону, ми шулпалану, сак колаклы*

Мәсәлән: Исемдә: мәчет манарасын кискән авылдашымның *кулы корыган*, дип сөйләгәннәр иде. [Юзеев 2002: 274]

*Күзе тонган, мие шулпаланган* Ләйлә сүзсез генә Илтан артыннан теркелдәде. [Юзеев 2002: 288]

Сез мине аңларга тырышыгыз: урманда туган балаларның *колагы сак*: кошлар әнә шулай бер-берсен эзлиләр. [Юзеев 2002: 268]

Процессны, эшне белдерүче фразеологик әйтелмәләр: ант бозу, сүз бирү, юл тоту, гомер өзелү, тормыш итү, ант бирү, баш вату, тормыш кору, җан бирү һ.б.

Мәсәлән: Кем дә кем *антын боза*, күр дә тор, аңа нинди дә булса бәла-каза килә: йә авырый, йә үлә, йә бәхетсез язмышка дучар була. [Юзеев 2002: 271]

Яңавыл станциясендә иртә-таң белән төшеп, эти-әниләрне сөендердем дә, кайтышлый тагын керергә *сүз бирдем* һәм Таллыкүл ягына юнәлгән автобуска утырып киттем. [Юзеев 2002: 276]

Димәк, аларның да *тоткан юлы* – Таллыкүл. [Юзеев 2002: 278]

Әнкәемнең *гомере өзелгән*. [Юзеев 2002: 283]

М ө н и р ә. Яраланган, канатлары сынган кош җирдә *тормыш итә башлаган*. [Юзеев 2002: 284]

М ө н и р ә. Анда борынгы бабаларыбыз-әбиләребез, әтиләребеә-әниләребез бер-берсен ташламаска, яратырга *ант биргәннәр*, вәгъдәләшкәннәр. [Юзеев 2002: 285]

Озак кына *баш ваттылар* әле:

“Моңа нинди җәза табарга?” [Юзеев 2002: 286]

Ө м е т. Без аны тар-мар итеп, хәрабәләрендә яңа *тормыш корабыз*. [Юзеев 2002: 285]

М ө н и р ә. Мин, Сәет... Барыбер мин бәхетле, сине күреп, кайнар кулларыңда, туган җиремдә *җан бирәм*... [Юзеев 2002: 290].

Илдар Юзеевның “Гашыйклар тавы” әсәреннән җыйнап алынган фразеологизмнарның күпчелеге кешенең эчке психологик халәтен тасвирлый.

## Әдәбият

1. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. Тутыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407б.

2. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘҺСИ, 2015. – 352 б.

3. Юзеев Илдар Сайланма әсәрләр. 5 томда, 4 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 264-299.

# V. ЗАМАНЧА МӘКТӘП ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ

---

## МӘКТӘПТӘ М.ХӘБИБУЛЛИН РОМАННАРЫН ӨЙРӘНҮ

**Ахмадуллина Н.К.**
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.д.,проф.Камаева Р.Б.

Мөсәгыйт Хәбибуллин – танылган язучы, Россия Федерациясенең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кол Гали исемендәге халыкара премия лауреаты. Аның “Җиде юл чатында”(1969), “Чоңгыллар”(1976), “Кубрат хан”(1985), “Илчегә үлем юк”(1990), “Шайтан каласы”(1993), “Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный”(1996), “Хан оныгы Хансөяр”(1997), “Аллаһы бүләге”(1999) һ. б. китапларын укучылар яратып кабул итте. Мәскәүдә “Современник”, “Советская Россия”, “Советский писатель” нәшриятларында русчага тәрҗемә ителгән китаплары дөнья күрде.

М. Хәбибуллин үзенең иҗатын татар халкы тарихына багышлый, романнарында татар халкының дөнья халыклары арасында тоткан урынын билгели. Язучының романнары уку өчен кызыклы һәм мавыктыргыч, сюжетлары көрәш-сугыш күренешләренә, мәхәббәт маҗараларына, интригалы, идеологик һәм психологик каршылыклы конфликтларга бай булулары белән аерылып тора. Аларда һәрбер тарихи чор автор хыялы фараз иткән конкрет сыйфатлары белән – халык көнкүреше, борынгы бабаларыбызның рухи дөньясы, фольклоры, гореф-гадәтләре, уйлары-хыяллары, кайгылары-шатлыклары, истә калырдай үзенчәлекле кеше образлары, легендар шәхесләре белән күз алдына килеп баса. Әлбәттә, моңа ирешү өчен язучы телнең барлык чараларыннан, сүзлегеннән һәм грамматик формаларыннан файдалана. Чөнки, билгеле булганча, фикер һәм идеяләр сүзләрдә, әйтелмәләрдә, грамматик формаларда гына үзенең реаль чагылышын таба.

Милли тарихи романның барлыкка килүе дә һәм алга таба үсеше М.Хабибуллин иҗаты белән бәйле, ди саный галимнәр [Галитзуллина 2017].

М.Хабибуллин иҗатын өйрәнү мәктәп программасына да кертелгән.Мәктәп программасына язучының “Кубрат хан” романы кертелгән. – “Кубрат хан” романы – М.Хабибуллинның Болгар дәүләте тарихын яктырткан беренче әсәре. Авторның бу романы Ф.Ф. Хәсәнова авторлыгындагы дәреслекләрдә 11 сыйныфта өйрәнелә. Язучының иҗаты дәреслекнең “1960-1990 нчы еллар әдәбияты” бүлегенә кертелгән. Өйрәнү өчен авторның тормыш юлы, романнан өзек бирелә. Шулай ук дәреслектә әдәбият теориясеннән “тарихи роман” төшенчәсенә аңлатма бирелә.

Беренче дәресне язучының биографиясен, иҗатын өйрәнүгә багышларга мөмкин. Бу дәрестә авторның әсәрләреннән күргәзмә оештыру, әсәрләрнең язылу тарихын сөйләү, укучыларның чыгышларын тыңлау, портрет белән

эшләү, әсәр язылган чорга характеристика бирү, истәлекләр уку максатка ярашлы. Дәреслектә кайбер галимнәрнең язучы турында эчтәлекле фикерләре дә китерелгән. Аларны да дәрестә уңышлы кулланырга мөмкин. Күренекле галим Ф.Галимуллин болай дип яза: “ Тарихтан хәбәрдар булган кешеләр Болгар тарихында иң күренекле фигураларның берсе Кубрат хан икәнен яхшы беләләр. Тик шулай да әлегә кадәр Кубрат хан дигәндә күз алдына килеш-килбәте, холык-фигыле, акылы сәләте мәгълүм булган кеше түгел, ниндидер бер абстракт исем генә шәйләнә иде. Мөсәгыйт Хәбибуллин “Кубрат хан” романын язып, шушы тарихи фигураны җанлы образ итеп күзалларга ярдәм итте. Бу әсәре белән язучы иҗади мөмкинлекләренең яңа сәхифәсен ачты” [Хәсәнова 2017: 161].

Романнан өзекне өйрәнүгә ике сәгать планлаштырырга мөмкин. Беренче дәрес әсәрне өйрәнүгә багышлана. Сүзлек өстендә эш, әсәрнең жанрын ачыклау, төп образларны билгеләү, бирелгән өзек буенча аларга характерлы сыйфатларны ачу, таблица төзү, романнан цитаталар язып алу, сайлап уку, сорауларга җавап бирү, образлар бирелешенең моделен төзү, тел-стиль чараларына характеристика бирү һәм башка шундый эш төрләре дәреснең төп өлешен алып тора.

Өченче дәрес сөйләм телен үстерү дәресе буларак үткәрелергә мөмкин. Дәрес-конференция, дәрес-түгәрәк өстәл, дәрес-дискуссия формасында оештыру да уңай нәтиҗәләр бирәчәк. Аны уздыру өчен алдан әзерлек эшләрен алып барырга кирәк. Укучыларга алдан “Кубрат хан” романын тулысынча укып чыгарга тәкъдим ителә. Чыгышлар әзерләү, мәкаләләр язу, әсәрдә чагылдырылган гореф-кадәтләрне тасвирлап язу кебек эшләрне укучыларга алдан биреп куярга кирәк.

**Әдәбият**

1.Галитзуллина Л.К. Китапларда – тарих сурәте (милли тарихи роман мәсьәләсе): Монография / Л.К.Галитзуллина. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр.,2017. 207 б.

2.Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 11 нче с-ф / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ф. Җамалиева. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр.,2017. 439 б.

## ТАТАР БӘЕТЛӘРЕН ӨЙРӘНҮДӘ ИННОВАЦИОН УКУ-УКЫТУ АЛЫМНАРЫ АША МӘДӘНИЯТАРА ДИАЛОГКА ИРЕШҮ АЛЫМНАРЫ

**Гимадиева Р.А.**

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты.

Фәнни җитәкче: Каюмова Г.Ф.

Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы фәне традицияләре буенча әдәбиятны өйрәнү фольклор әсәрләре белән танышу, аларны анализлаудан

башлана. Агымдагы 2024 нче елда Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләрдә, мәсәлән, “Туган телдәге әдәбият”ны өйрәнү бишенче сыйныфта мифлар, әкиятләр, легенда һәм риваятьләр белән; алтынчы сыйныфта татар халык җырлары белән; җиденче сыйныфта бәетләр белән; сигезенче сыйныфта дастаннар белән танышудан башлана. Эшнең бу рәвешле корылышы мантыйкка ярашлы булып тора: халык авыз иҗаты әдәбиятның чишмә башы булган шикелле, әдәбиятны өйрәнүне дә шуннан башларга кирәк. Әмма хәзерге вакытта тагын бер аспект игътибарга алынырга тиеш: фольклор әсәрләрен өйрәнү аша дәресләрдә мәдәниятара диалогка ирешү мөмкинлеге зур, ягъни укучылар үз милли тарих, ядкярләрне тирәнтен өйрәнүгә генә түгел, шулар белән бәйлелектә башка – гарәп, фарсы, төрки, рус, европа мәдәниятләре турында да күзаллау булдыра алалар; алай гына да түгел, бу күзаллау үз һәм башка милләтләргә ихлас хөрмәт, тирәнтен кызыксыну, мәхәббәт буларак үсә ала. Моның зарурлыгы бүгенге реалияләрдә милләтара коммуникациянең әһәмияте арту белән билгеләнә. Тагын бер аспектка игътибар итмичә мөмкин түгел: хәзерге вакытта уку-укыту традицион мәгънәсендә, ягъни белем, осталык һәм күнекмәләрне үзләштерү буларак кына аңлашылмый, ә бәлки шәхес үсеше процессын тәэмин итү рухи-әхлакый тәҗрибә булдыру, социаль компетенция формалашу буларак та билгеләнә [Канзафарова 2013: 5]. Инновацион метод һәм алымнар да шушы үзенчәлекне истә тотып эшкә җигеләләр. Мәкалә кысаларында игътибарыбыз боларны әдәбият дәресләрендә бәет жанрын өйрәнүдә куллану өлкәсе белән чикләнә.

Бәетләргә килгәндә, яңа дәреслекләрдә аларны жанр буларак өйрәнү җиденче сыйныф укучыларына тәкъдим ителә. Дәреслек авторлары аның, бер яктан, җыр жанрына охшаш булуын да, шул ук вакытта аннан аерып торган аерым жанр хасиятләре барлыгына да игътибар бирәләр: “бәетләр көйле, рифмалы булулары, ритмик төзелешләре, ике яки дүрт юлдан торулары белән җырга ошаган. Шулай да алар арасында аермалары да күзәтелә. Җыр эчтәлегендә гомумилек бар, ә бәетләрдә исә тормышның җанлы вакыйгалары турында сөйләнелә. Бәетләр якыннарын, дусларын, туганнарын югалтучы кешеләрне юату өчен языла, ә җырлар кешенең күңел дөньясы, кичерешләрен тасвирлап, тормышка бәя бирәләр. Җырның эчтәлегендә вакыйга беренчел түгел, хис өстенлек итә. Бәетләр исә аерым вакыйганы нигез итеп ала һәм хискә төреп бирә” [Мөхәрләмова, Абдуллина 2024: 14]. Җиденче сыйныфта укучылар жанр төре буларак бәет турында төшенчә алалар һәм “Сак-Сок бәете” мисалында халык авыз иҗатының шушы жанрын анализлау күнекмәләрен алалар. Әйтергә кирәк, “Сак-Сок бәете” типик бәет түгел, аның нигезендә күп кенә башка бәетләрдәге шикелле реаль вакыйга түгел (рус-төрек сугышы, Герман сугышы, янгын, кемнең дә булса янгында, суда батып яки башка төрле һәлакәтле үлемгә дучар булуы түгел), ә ана каргышы белән бәйле әкияти-мифологик сюжет ята. Бәетне өйрәнү вакытында мәдәниятара диалогка чыгуның ике юлы бар дип уйлыйбыз. Беренчедән, бәетнең формасы һәм эчтәлеген өйрәнү, тугандаш халыклардан башкортларда “Сак-Сок бәете”н

өйрәнү үзенчәлекләрен анализлау. Бу юлдан барганда нигездә татар-башкорт-чуаш мәдәниятләре диалогына чыгарга була. Әлбәттә, уртак баба тел, уртак тарих, уртак мәдәни багланышлар да бу очракта дәрестә искә алына ала. Мондый дәреснең тәрбияви кыйммәте, башка милләтләргә ихтирамлы, мили үзаң үсеше тиешле дәрәҗәдә булган шәхес формалаштыруга юл ачыла.

Икенчедән, башка, тугандаш булмаган халыклар фольклорына мөрәҗәгать итәргә була. Бу очракта бәетләрнең жанр үзенчәлекләрен өйрәнгәннән соң, "Сак-Сок бәете" үзәгендә торган каргыш мотивына тукталырга була. Укучыларга "Төрле халыкларның фольклорында каргыш мотивы" дигән темага проект эшен башкарырга тәкъдим итү уңышлы кебек тоела. Тема кызыклы, шулай ук аның тәрбияви әһәмияте дә бар. Темага тирәнрәк кереп киткәнче, Ф. Урманче хезмәтендәге мәгълүмат белән танышырга киңәш итү максатчан кебек тоела. Галим: "Сак-Сок бәете"нә якын сюжетлар башка халыклар фольклорында да бар", – дип яза [Урманче 2009: 311]. Аерым алганда, ул мондый мисаллар китерә: "Яраткан сеңел антына тугрылыклы була" бирма халык әкияте сюжетында үги ананың, корольнең улларын каргап, кыргый кошларга әверелдерүе; молдованнарның "Баһадир һәм елан" эпик җыруында ана каргышының көче; славян халыкларының күпсанлы тарихи балладалары; борынгы һиндләрнең "Вивасват һәм аның балалары" дастаны һ.б. Укучылар шулай ук европа халык әкиятләренә мөрәҗәгать итеп, каргыш иясенең ана түгел, ә башка зат, әйтик, рәнҗетелгән сихерче карчык була алуын да искәртә алалар, мондый әкиятләрне дә проект эшләрендә куллана алалар.

Нәкъ менә проект эшчәнлегенә тукталуыбызның сәбәбе буларак, шуны әйтергә була: Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча, бу метод уку-укытуда системлы рәвештә кулланылырга тиешле, һәм ул хәзерге заман уку-укыту процессына куелган таләпләргә тулысынча җавап бирә. Проект – күңел биреп эшләүне таләп итә, шуңа күрә, эш нәтиҗәле булсын өчен, укучыларның мотивациясен булдыру да сорала. Моның өчен мәгълүмати-коммуникацион технологиялардн файдаланып, "Сак-Сок" бәете белән бәйле презентация тәкъдим итәргә була. Визуальлеккә бай презентация укучыларның игътибарын җәлеп итәр кебек тоела; интернет ярдәмендә бәетне яки бәеттән өзек тыңлау да кызыклы тоела ала. Прагматик буын вәкилләре булган замана укучыларына перспектив планда проект эшләре буенча ярышларда катнашу, фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгыш ясау, яхшы билге алу кебек стимул-тәкъдимнәрне җиткерү дә максатка ярашлы булып тора. Моннан кала проект эше эзләнү-тикшеренү эшләрен башкару күнекмәләрен формалаштыра; укучыларны мөстәкыйль эшчәнлеккә тарта; укучыларның иҗади сәләтләрен үстерә; креатив фикер йөртергә өйрәтә; татар әдәбиятыннан предмет һәм метапредмет, шәхескә юнәлгән нәтиҗәләрне үстерә.

Проект эшенең эчтәлеге аның төренә дә карый. Без иҗади яки фәнни-тикшеренү характерындагы проект башкаруны аеруча уңышлы дип санар идек. Беренче очракта укучылар "Каргышлардан сак булыгыз" темасына халык авыз

иҗаты кичәсе; “Сак-Сок бәете” – сәхнәдә” дигән инсценировка тәкъдим итә алалар. Һәр очракта да эшне башкарыр алдыннан аларга татар һәм башка халыкларда “Сак-Сок” сюжеты бирелешен тирәнтен өйрәнергә тиеш булалар.

Фәнни-тикшеренү проекты аеруча катлаулы, әмма заманыбыз шәхесе өчен уңышлы сыйфат һәм күнекмәләр формалаштыруда аның куәте әйтеп бетергесез зур. Проект эше бүлекләре болай формалаша ала:

- Беренче бүлек: ана каргышы мотивының мифологик нигезләре.
- Икенче бүлек: тугандаш халыклар фольклорында ана каргышы мотивы.
- Өченче бүлек: тугандаш булмаган халыклар фольклорында ана каргышы мотивы.

Укучылар мөстәкыйль рәвештә, әмма укытучының консультатив рәвештә юнәлеш бирүе нәтиҗәсендә теманың актуальлеген ачыкларга тиеш булалар, эшләренең максаты, бурычларын билгеләргә өйрәнәләр, әйдәп баручы фәнни-тикшеренү методларны билгелиләр.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: яңа дәреслекләрдә халык авыз иҗатының аерым ядкярләрен жанр буларак өйрәнү бишенче – сигезенче сыйныфларда актив рәвештә алып барыла. Фольклор әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен өйрәнү, шушы дәресләрдә мәдәниятара диалогка ирешү чаралары буларак тәнкыйди фикерләү технологиясе алымнары, проект технологиясе уңышлы кулланыла ала. Мәкаләдә болар бәетләрне өйрәнү үрнәгендә күрсәтелде.

**Әдәбият**


1. Канзафарова Р.Х. Системно-деятельностный подход – методологическая основа требований ФГОС // Сборник материалов конференции. – Нефтекамск: ИМЦ, 2013. – С.5 – 11.
2. Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М. Туган телдәге әдәбият. 7 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кис. Төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар өчен). – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшр., 2024. – 119 б.
3. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. 2 нче т. (Д – С). – Казан: Мәгариф, 2009. – 3543 б.


## УРТА СЫЙНЫФЛАРДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КВИЗ ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ АЛГОРИТМЫ


**Зинатова Т.А.**

Казан (Идел буе) федераль университет, филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты

Фәнни җитәкче: Каюмова Г.Ф.


Тарихи «квиз» сүзе инглиз телендәге "quiz" сүзеннән килеп чыга. Сүзне тәрҗемә итүнең Америка форматын караганда - ул язма, әзерлексез үткәрелә торган имтихан. Квиз үзенә күрә ярыш тәкъдим итә, аның барышында бер

катнашучы бөтен төркемгә бирелгән сорауга җавап бирә. Әмма биремне төзегәндә катнашучылар контингентын исәпкә алырга кирәк. Бу очракта бу урта сыйныф укучылары, аларның игътибарын җәлеп итү өчен, аларга артык гади сораулар һәм артык катлаулы сорауларны бирергә кирәкми, чөнки бу уенчыларның игътибарын читкә юнәлтә ала, яки гади сораулардан, мәктәп укучыларының кызыксынуын арттыру өчен, эзлекле рәвештә, катлаулы сорауларга күчеп, уткәрергә мөмкин.

Татар әдәбияты укытучысының фундаменталь компетенцияләрен исәпкә алып, квиз белән эшләүнең түбәндәге алгоритмы бар:

I этап – квиз биремнәре һәм махсус символлар ярдәмендә укучылар эшчәнлеген тикшереп тору;

II этап – укучылар эшен бәяләү, белемнәрне тикшерү һәм дөрес җавапларны аңлату;

III этап – квиз эчтәлеген кулланып, монологик сөйләм рәвешендә берничә укучының телдән җавап бирүе.

Квиз технологиясен куллану алгоритмы

Беренче этап укытучының эшен үз эченә ала. Укытучы әдәбиятның төрле өлкәләрендәге сорауларын бирә ала. Шул ук вакытта сорауларны дүрт категориягә бүләргә була: сурәтләр белән бәйле мәсьәлә, яки сурәтнең үзендә сорау булган мәсьәлә; икенче төркем - татар әдәбиятының жанрлар өлкәсенә караган сораулар; өченче төркем музыкаль тематика буенча сорауларны үз эченә ала. Һәм «чиста интеллект» категориясе укучыларның фикерләү мантыйгына һәм үсешенә юнәлгән. Соңгы 2 сорау 4 раундта төркемнәр капитаннары арасында уйнатыла. Сораулар җыентыгын уенны алып баручы (укытучы) гына белә.

Икенче этап якынча ярты сәгать дәвам итә. Алып баручы сорауларны укый һәм 1 минут тирәсендә уйларга вакыт бирә. Сорауга җавап табу өчен вакыт музыкаль пауза белән тула, бу аерым атмосфера бирү өчен дә, командаларда катнашучылар бер-берсен ишетә алмасын өчен дә эшләнә. Шуннан соң сорауларга җаваплар махсус бланкка кертелә, һәм ул жюри әгъзаларына тикшерү өчен тапшырыла.

Уен ахырында тәнәфес башлана, ул 10-15 минутка якын дәвам итә, бу вакыт эчендә төркемнәр буенча нәтиҗәләр исәпләнә һәм беркетмә төзелә. Соңыннан алып баручы шулай ук сорауларга дөрес җаваплар атый һәм кызык булып тоелган җаваплар турында фикер алып бару да уенга күңелле төс кертә ала. Җиңүче дип иң күп балл җыйган төркем танyла.

Йомгак ясап, квиз технологиясен татар әдәбияты дәресләрендә куллану түбәндәге өстенлекләрне ачыкладык:

-дәрес берьюлы барлык укучылар төркеме өчен үткәрелә, бу эшне тикшерүгә вакыт чыгымнарын киметә;

-технологияне уку башында да, йомгаклау эшләре вакытында да кулланырга мөмкин;

-яңа технология ярдәмендә барлык укучылар өчен тигез шартлар саклана;

квиз нәтиҗәле, чөнки бу технология укучыларның белем алу дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итә.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕНДӘ СҮЗЛЕКЛӘРДӘН ФАЙДАЛАНУ

**Исмагилова Г.Р.**
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: ф.ф.д., проф. Камаева Р.Б.

Мәктәптә татар теле дәресләрендә сүзлекләр белән эшләү укучыларның сөйләмен дөрес оештыруга йогынты ясый, җирле диалект шартларында диалекталь хаталарны төзәтүгә ярдәм итә. Орфографик һәм орфоэпик күнекмәләр камилләштерүдә, сөйләм культурасын үстерүдә орфографик һәм диалектологик сүзлекләр белән эшләүнең әһәмияте зур.

*Диалектологик сүзлекләр белән эшне оештыру*

Диалектологик сүзлекләр белән эшне 5 сыйныфта “Фонетика. Орфоэпия, графика, орфография” һәм “Лексикология һәм лексикография” бүлеген өйрәнгәндә башларга кирәк. Программада “Фонетика” бүлеген өйрәнүгә 33 сәгать вакыт бирелгән “Лексикологияһәм лексикография” бүлеген өйрәнүгә 14 сәгать вакыт каралган. Тел белеменең бу бүлекләре 10 сыйныфта да өйрәнелә. “Фонетика. Орфоэпия. Графика. Аваз. Фонема” бүлеген өйрәнүгә 10 сәгать, «Лексикология» бүлеген өйрәнүгә 20 сәгать вакыт бирелгән.

5нче сыйныфта диалектологик сүзлекләр белән эш җиңел күнегүләрдән башланып китә. Диалектологик сүзлекләр белән эш ничәнче сыйныфта алынса да, беренче чиратта укучыларны сүзлек белән якыннан таныштырырга кирәк. Моның өчен сүзлеккә тулы характеристика бирү таләп ителә. Сүзлекнең төзелеше, төзелү принциплары, сүзлек статьялары белән таныштыру кебек эшләр башкарыла. 5 нче сыйныфларда сүзлекләр белән таныштыруны укытучы үзе үткәрә, ә югары сыйныфларда бу эшне берничә укучыга бирергә мөмкин. Анализ түбәндәге схема буенча булырга мөмкин.

1.Сүзлекнең басылып чыгу вакыты, тулы чыгышы.

2.Авторлары.

3. Сүзлектә күпме сүз тупланган.

4.Сүзлекнең төзелү принципларына тулы характеристика.

5. Сүзнең статьясының төзелеше.

6. Сүзлектәге шартлы билгеләр, кыскартылмалар.

Ел ахырында үткәннәрне кабатлау дәресләрендә диалектологик сүзлекләр кулланып эшләү өчен түбәндәге биремнәрне тәкъдим итәргә була. 1.Бирелгән диалект сүзләрен әдәби варианты белән парлап таблицага урнаштырырга.

Дөнҗа, җөрәк, бармай, җакшы, шәхәр, хөнәр, тушы, минга, синга, сүләй, фамидур, җигерме, бусысы, сымак, кечерткән, иртәнчәк, жул, җокы, яңы, бушлый,тегели, сыу.

Үрнәк.

| Фонетик диалектизмнар | Морфологик диалектизмнар |
| --- | --- |

| | |
|---|---|
| Фамидур –помидор, ... | Бармай – бармый, ... |

2.Бирелгән диалект сүзләреннән лексик диалектизмнарны аерып алып, мәгънәсен сүзлек ярдәмендә аңлатырга.

Бидрә, кайткачтын, тегел, эшләмәй, ызба, алма, алмай, җук, аңга, тегесесе, тымызык, тастымал, барадырые, чарык.

3.Диалект сүзләрен әдәби вариантка китереп күчереп язарга.

Ашарга утырыш юк, сак булың, кереңнәр, ала керермен, үткәзү, нәмә, нәстәкәй, җурган, сүләдем, андае, беген, шышы, андары.

5нче сыйныфта да, 10 нчы сыйныфта да мондый төр биремнрне эшләргә мөмкин, ләкин югары сыйныфларда лексика катлауландырыла.

*Орфографик сүзлекләр белән эшне оештыру*

Дәрестә һәм өйдә төрле язма эшләрне эшләгәндә, теге яки бу сүзне язарга икеләнгәндә, укучылар орфографик сүзлекләрдән файдалана алалар. Аларны системалы рәвештә файдалану укучыларда күзәтүчәнлек сыйфатларын булдыруга ярдәм итә, сүзләргә аваз һәм хәреф составы ягыннан анализ ясау күнекмәләре камилләшә, сүзләрнең язылышын хәтерләрендә ныгытылар һәм шул рәвешле диалект үзенчәлекләренә бәйле орфографик хаталарны булдырмаска да ярдәм итә. Сүзлекләрдән дөрес файдалану максатыннан төрле күнегүләр үткәрергә мөмкин. Методистлар түбәндәге күнегүләрне тәкъдим итәләр:

1. Алфавиттагы хәрефләрне тәртибе белән кабатлау. Укучыларны алфавитны тиз әйтергә күнектерергә һәм укытучы әйткән хәрефнең алдыннан яки артыннан нинди хәреф торганын күрсәтә алу күнегүләре үткәрергә кирәк.

2. Билгеле бер хәрефләр белән башланган төрле сүзләрне сүзлекләрдән эзләп табарга өйрәтү.

3.Төрле хәреф белән башланган сүзләрне бик тиз эзләп табарга күнектерү максаты белән уеннар үткәрү.

4. Теге яки бу кагыйдәгә караган сүзләрне сүзлекләрдән таптыру.

5.Орфоэпия, лексика һәм стилистика белән бәйләнешле эшләр үткәрү. [Вәлиева, Саттаров, 2000: 293].

Орфографик сүзлекләр белән эш башлангыч сыйныфларда башлана һәм 11 сыйныфка кадәр дәвам итә. Тел белеменең барлык бүлекләрен өйрәнгәндә дә орфографик сүзлекләр актив кулланылышта булырга тиеш. Укучыларны дөрес язарга өйрәтү өчен мондый сүзлекләр белән эшләү бик мөһим. Бигрәк тә “Фонетика. Орфоэпия, графика, орфография” бүлекләрен өйрәнгәндә орфографик сүзлекләр буенча эш даими рәвештә махсус оештырыла. Диалект шартларында дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү максатыннан орфографик сүзлекләр белән эшләү бик мөһим. Орфографик сүзлекләр кулланып, түбәндәге күнегүләрне эшләтергә мөмкин.

1.Сүзлектән **җ** хәрефенә башланган 10 сүз күчереп языгыз.

2. Сүзлектән **җ** хәрефе кергән 10 сүз күчереп языгыз.

3. Сүзлектән беренче иҗегендә **о** хәрефе булган 10 сүз күчереп языгыз.

4. Сүзлектән беренче иҗегендә **ө** хәрефе булган 10 сүз күчереп языгыз.

5. Сүзлектән беренче иҗегендә **ө** хәрефе булган 10 сүз күчереп языгыз.

6. Сүзлектән беренче иҗегендә **ө** хәрефе, икенче иҗегендә **е** булган 10 сүз күчереп языгыз.

7. Сүзлектән беренче иҗегендә **о** хәрефе, икенче иҗегендә **ы** булган 10 сүз күчереп языгыз.

8. Хаталы сүзләрне төзәтеп языгыз: яңы, тырмыш, хәм, халык, балык, хава, сиңга, шылай, ышык, барырга, рөксәт, ефәк, ел җылы, үрәнә.

9.Нокталар урынына тиешле хәрефләр куеп, текстны күчереп языгыз.

Бал...чакта мин әнием белән б...лынга ...иләк җы...рга бара идем. Бол...н г...лчәчәкле келәмгә тиң. Һәр чәчәкнең үзгә матурлыгы. Әнием карап т...рышка гап-гади бер ч...ч..кне өзә дә, соклану тулы к...зләрен ала алмыйча, аның камил матурлыгы белән х...зурлана. Җиләк җы...рга хир...слыгым булмаса да, миңа шул рә...әт бол...нда әнием белән җит...кләшеп йөрү бик ...шый иде.

Орфографиягә өйрәтү максаты белән, төрле иҗади эшләр дә (изложение, сочинение, эш кәгазьләре язу) үткәрелә.

Системалы рәвештә грамоталылык дәрәҗәсен, орфографик күнекмәләрнең сыйфатын һәм ныклык дәрәҗәсен өйрәнеп, барлык төр язма эшләрне вакытында тикшереп, анализ ясап, нинди шартларда һәм ни сәбәпле орфографик хаталарны җибәрүне ачыклаганда һәм аларны төзәтү өчен эшне дөрес оештырганда гына укучыларның дөрес язуына ирешә ала.

**Әдәбият**

1.Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы/Ф.С.Вәлиева,Г.Ф.Саттаров.– Казан: Раннур, 2000. – 455 б.

2.Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш: югары уку йортларының филология факультеты студентлары өчен дәр-к. – Казан: Тарих, 2001. – 383 б.

3.Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.

## КОМИКСЛАР: ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ФАЙДАЛЫ ЯҢАЛЫК ЯКИ ЗАМАНГА ИЯРҮМЕ?

**Мөхәммәтҗанова Л.Р.**

Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәният ара багланышлар институты студенты.

Фәнни җитәкче: Каюмова Г.Ф

Татар әдәбияты бер урында тормый: гел үзгәрешләр кичереп тора.Әле моннан бер-ике гасыр элек кенә әдипләр бары тезмә жанр төрләрендә генә иҗат итсә, хәзерге заманда повесть, роман жанрларында иҗат итүче язучылар һәм аларның әсәрләре укучыларда инде яңалык хисләре уятмый. Ә моннан берничә ел элек яңалык булып татарча комикслар дөнья күрә: “Татарча комикслар”, Татар хатын-кызлары”. [Гаязова, 2023: 2,3]

*Комикслар җыентыгы*хәзерге заманда бик популяр әдәбият, китап төре, жанры. Комикс үзе (ингл. comic «көлке») – рәсемле тарих, рәсемнәр рәвешендә бирелгән хикәя, әсәр. Комикс үзендә әдәбият һәм рәсем сәнгате кебек сәнгать төрләренең сыйфатларын берләштерә. Китап-журнал иллюстрациясенең әлеге төре кайвакыт басма массакүләм мәгълүмат чараларында да кулланыла.

Бу төр сәнгатьнең аерым төрләре, башкача аталучы исемнәре дә бар. Аерым бер зур сюжеты булган масштаблы комикслар график романнар (яки график новеллалар), кыскалары – стриплар дип атала. Интернет челтәрендә веб-комикслар буларакбирелә.

Кайбер илләрдә әлеге жанр индустриясе бик нык алга киткән һәм аларның үз атамасы да бар. Французлар комиксны - bande dessinée (рәсемле лента) яки BD дип атыйлар, япон комикслары манга, кытай - маньхуа, ә Кореядәге комикслар манхва дип атала. Рус телендәге кайбер авторлар “ясалган тарихлар” (“рисованные истории”) терминын кулланырга тәкъдим итә.

Татар яшьләренә татар телендәге комикслар бары бу гасырда гына барлыкка килә. Кызганыч, бу жанрда иҗат итүче авторлар юк диярлек була. Тик барысы да Регина Гаязова авторлыгында чыккан комикслар җыентыгынннан соң үзгәрә. Ул комикс басмалары арасында татар телендәгеләре юклыгын аңлый һәм үзе әлеге комиксны язарга була. Шулай итеп, аның тырышлыгы белән татар телендәге “Татарча комикслар. Казан хикәяләре” дигән комикслар җыентыгы барлыкка килә. Монда берничә авторның Кабан күле, Казан мәчесе татар халкының башка танылган шәхесләре турында рәсемле тарихлар урын ала.[Гаязова, 2022: 2]

Әлбәттә, бу комикслар яхшы кабул ителә, чөнки әлеге комикс актуаль мәсьәләләрне юмор аша киң җәмәгатьчелеккә җиткерә. Озакламый әлеге автор командасы тарафыннан “Татар хатын-кызлары” исемле комикслар китабы дөнья күрә. Әле комикс татар халкының бөек хатын-кызларына багышлана. Комикс беренче татар артискасы Сәхибҗамал Гыйззатуллина-Волжская, беренче татар математика профессоры Сара Шакулова, беренче хатын-кыз татар профессиональ композиторы Сара Садыкова, очучы, Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланованың тормыш юлы, кылган батырлыкларын, татар милләте өчен эшләгән хезмәтләре турындагы мәгълүматны үз эченә ала.[Гаязова, 2023: 3]

Әлеге комикслар белән илһамланып, шуларга таянып татар комикслары нигезе итеп танылган, шулай ук онытылып бара торган татар әсәрләрен дә алып була дигән фикергә килдек. Хәзерге заман укучылары әдәбият белән артык кызыксынмыйлар, укымыйлар. Аларны кызыксындыру, шулай ук әдәбият дәресләрендә өстәмә әдәбият буларак куллану өчен комикслар форматында эшләнеп бирелгән әсәрләр бик файдалы булыр иде.

Бу форматка балалар һәм яшүсмерләр өчен язылган хикәя, повестьләрне файдалану отышлы була, чөнки анда сюжет сызыгы бар, димәк, вакыйганы рәсемдә чагылдыру, бирү дә бермә-бер уңайлы һәм андый әсәрләр мәктәп

укучыларында да кызыксындыру уятыр дигән өмет бар. Шул әсәрләрнең берничәсен мисал итеп атап китәбез:

1) Мөхәммәт Мәһдиевнең "Без – 41 нче ел балалары" әсәре бу жанрга батып тора. Мәһдиевнең әсәренең сюжеты вакыйгаларга бәйле, ә аны рәсем форматын бирү авыр түгел, шуның өстенә әсәр бүлекләр белән бирелгән. Әсәрнең теле җор, аңлаешлы. Бу әсәр үзе дә яшүсмерләр турында һәм яшүсмерләр телендә язылган, вакыйгалар тартмалы композициябелән бирелгән. Беренче бүлекне генә алып карыйк: "Менә дигән бер майор" бүлегендә сугыш чорында җәйге ялдан соң училищега яңа гына килгән авыл малайларың яңа рус теле укытучысы белән танышу вакыйгасы сөйләнелә:

"...Менә зәңгәр сырма кигән Карадуган малайлары – һәммәсе кишер ашый. Мөрәле малайлары кесәләрен өйләндереп бер төрерлек тәмәке эзлиләр, шул арада ду килеп бәргәләшеп алалар.Чабыш атлары кебек барысының да борын тишекләре киңәйгән. Беренче кыңгырау чылтыраса да, класска керергә уйлап та караган кеше юк.

Кинәт өлкән курс малайларыннан берәү:

– Завуч!.. - дигән бер сүз кычкырды да класска кереп юк булды. Аның артыннан коридорның яртысы бушап калды. Коридор буйлап электр тогы узгандай булды, һәм без туң миләребезне кыймылдатып өлгергәнче, тузан болыты эченнән ялтыравыклы күзлек пыялалары күренде. Миләр кыймылдады. "Әһә, шул ике пыяла - завуч икән", дип уйлап алдык."[Мәһдиев, 2019: 17]

Бу өзек буенча вакыйгаларның сурәтләнешендә детальләрнең бирелеше үзенчәлекле дип әйтә алабыз, ягъни укыган вакытта вакыйгаларның сурәте шунда ук күз алдына килеп баса. Комиксны ясаучыга бу эшне бик җиңеләйтә. Әсәрдә язылган сурәтләү кәгазь битенә җиңел ята. Мәсәлән: тузан эчендәге күзлек пыялалары, туң ми һ.б. Ә әсәрдә бирелгән сөйләм генә языла: "– Завуч!..", "Әһә, шул ике пыяла –завуч икән" һ.б.

2) ФатихӘмирханның "Нәҗип" хикәясе комиксның жанрына шулай ук уңайлы әсәр. Бу хикәя төп герой кечкенә Нәҗипнең уй-фикерләре, борчылулары һәм аның белән булган вакыйгаларны үз эченә ала. Әле яңа гына зурлар дөньясыбелән таныша башлаган Нәҗипнең абыйсы кебек күрше Мәрфуга апасына һәм башкаларга файдалы, кирәкле буласы килә. Бу әсәрдә әдип Нәҗип образы белән кемгәдер яхшылык эшләүнең мөһимлеген, кирәклегенә басым ясый.[Әмирхан, 2020: 5] Дәрес программасыннан төшеп калган әсәрне комикс сыйфатында уку, танышу бик кулай булыр.

3) Гаяз Исхакыйның "Кәҗүл читек" хикәясе бик эчтәлекле, вакыйгаларга бай әсәр. Балалар күңелен, холкын ачык итеп күрсәткән бу хикәяне юкка гына Кариев театрында спектакль форматында да сәхнәгә чыгармаганнар. Бу әсәр белән төрле яктан танышкач, комикс форматында да балалар игътибарына кызыклы һәм тәрбияви максатны да үз эченә ала дигән фикергә килдем. Кечкенә Әхмәт образы аша Гает бәйрәменең төп бизәге кәҗүл читек түгел, ә синең башкаларга кылган, эшләгән гамәлләрең икәнен язучы кечкенә укучыларга җиткерә.[Исхакый, 2002: 22]

Бу жанрның *уңай* якларына килгәндә:

1. Әсәрне аңларга ярдәм итә;
2. Укучыга әсәр укуны кызыклы ясый;
3. Әсәрнең күләмен киметә;
4. Укучы кызыксынып, тулы әсәрне укырга теләк белдерә, укучыны әзерли дип әйтә алабыз.
5. Дәрес вакытында өстәмә әдәбият буларак файдаланыла ала.

Ә *тискәре* якларын барласак:

1. Рәсемнәр төп вакыйгаларны бирмәскә мөмкин;
2. Бала бары рәсемнәрен генә карап чыгарга мөмкин;
3. Язучы әйтергә теләгән фикер җиткерелми;
4. Комикста язучы теле тулы итеп бирелми.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕН ОЕШТЫРУ

**Салихова И.Ф.**
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: ф.ф.д., проф. Камаева Р.Б.

.

Бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару заруриылыгы да артты. Дәресләрдә әле моңа кадәр билгеле булмаган чаралар кулланыла, элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә. Укыту-тәрбиянең бүгенге көндәге уңышы укытучының бу процессны сыйфатлы башкаруында, укучыларны танып-белү процессы белән кызыксындыра алуында; иҗади уйларга, мөстәкыйль белем алырга өйрәнүенә, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләвенә бәйле. Әйләнә-тирәне, кешелек дөньясын өйрәнү һәм аны укучыга дөрес аңлату, укучыны тормышка яраклаштыру – укытучылар алдына куелган мөһим бурыч.

Хәзерге чорда укытучы күптөрле мәгълүматлар чолганышы эчендә калды. Алар алдында яңа педагогик технологияләрнең яңа алымнарның иң нәтиҗәлеләрен сайлап алып аны үзләштерү зарурлыгы туды.

Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Аларның күбесе дәресләрдә уңышлы кулланыла. Ул процесста укучының тыңлап утыруы гына түгел, ә төрле эшчәнлектә катнашуы бик мөһим. Укытучы һәм укучылар эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен алдан уйлап, башкарырга тиешле эшләрне системага салып кую укыту-тәрбия процессында уңышка ирешергә ярдәм итә. [Камаева 2012:3]

“Дәрес – мәктәптә укыту-тәрбия процессын оештыруның төп формасы. Ул процесс– укытучы һәм укучының бердәм-эзлекле эшләве. Укучылар зур активлык күрсәткәндә, укытучы аның активлыгын уңышлы оештырганда гына дәресләр нәтиҗәле була ала” [Вәлиева 2000: 66].

Дәресләрне ничек оештырырга кирәклек турында укытучылар һәм педагог-методистлар арасында төрле карашлар булды һәм, әлбәттә, дәресләр төрлечә үткәрелеп килде.

Дәрес актив (нәтиҗәле) яки пассив (нәтиҗәсез) булырга мөмкин.

Түбәндәге таләпләргә җавап биргән дәресләрне нәтиҗәле дәресләр дип әйтергә мөмкин:

1)материалның характерына, алда торган бурычларга, укучыларның яшь һәм белем дәрәҗәсенә карап оештырылган;

2) алынган кма конкрет булып, дәреснең максаты һәм өйрәнелә торган теманың гамәли әһәмияте ачык аңлашылган;

3) дәрес өчен сайланган материал аңлаешлы, җиңел үзләштерерлек, укучыларның акыл сәләтен, танып белү активлыгын үстерерлек һәм аларга төрле яклы тәрбия бирерлек булган;
4) тема үткән дәресләрдәге материалга бәйләнешле һәм моннан соң үтелә торганына нигез булырлык итеп бирелгән;
5) эшләү методы һәм алымнары, укыту чаралары, аларның уңышлы чиратлашуы укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндергән;
6) укучылар дәрескә битараф булмыйча, аларның тойгылары һәм эмоцияләре эшкә җигелгән;

7)материалны укучылар яхшы үзләштергән, аны гамәли эшендә файдалана белү һәм тел үстерү күнекмәләре биргән;

8)укучыларда дөньяга караш, тормышта үзенең урынын таба белү һәм башка шундый сыйфатлар тәрбияли алырлык дәресләр [Вәлиева 2000: 66-67].

Укучы актив эшләгән, укытучы аның активлыгын уңышлы оештыра алган дәресләр генә нәтиҗәле була ала.

«Традицион дәрестән аермалы буларак», — ди академик М. И. Мәхмүтов, – хәзерге дәреснең төп үзенчәлеге: ул – балаларның акыл сәләтен үстерү. Моның өчен укучыларның фикерләвен, белем алуга һәм хезмәткә теләк-омтылышын үстерү, дөрес мөнәсәбәтләр трбияләү буенча максатчан эш алып барыла. Әлбәттә, зиһенгә алу, дикъкать, күзәтүчәнлек, хәтер, күзаллау, яхшы сөйли белү, физик хәрәкәтләрне үстерү кебек традицион дәресләргә куела торган максатлар да игътибардан читтә калмый».

Татар телен электрон-техник чаралар аша өйрәтү – уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү.

Укытучылар татар теле дәресләрендә компьютер технологияләрен куллануның эффектив булуын һәм укучыларда тел өйрәнүгә карата кызыксынулары артуын билгеләп үтә. Алар профессиональ форумнарда, шәхси сайтларында, матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләрендә, фәнни конференцияләрдә ясаган чыгышларында татар теле дәресләрендә компьютер технологияләрен куллану тәҗрибәләре белән уртаклашалар. Хәзер мәктәптә кабинетлар компьютер, мультипроектор белән җиһазландырылган һәр дәрестә компьютер технологиясен куллану мөмкинлеге бар. Бу исә үз чиратында дәрестә укучыларның эшчәнлеген активлаштыруга да, дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрүгә дә ярдәм итә. Инновацион белем бирү, иң беренче чиратта,

мәгълүмати – комьютер технологияләренең үсеше белән бәйле. Дәрестә компьютер технологияләрен куллану күрсәтмәлелекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә.

Дәрестәге эшнең күләме һәм эзлеклелеге дәүләт программасы тарафыннан билгеләнә. Дәреснең максаты укучыларга билгеле бер күләмдә белем бирү генә түгел, программада каралган кадәр күнекмәләр булдыру. Шуңа күрә дәрестә эш өйрәнүне дә ныгытуны да кабатлауны да үз эченә ала. Дәрестә өйрәнелә торган материал барлык укучылар өчен дә мәҗбүри, шуңа күрә аңлау дәрәҗәсен күзәтү, игътибарда тотуны, бәяләүне таләп итә.

**Әдәбият**


1. Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С. Вәлиева, Г.Ф.Саттаров. – Казан: Раннур, 2000. – 455б.
2. Габдуллин Г.Г. Педагогик сүзлек / Г.Г.Габдуллин, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: КДПУ, 1997. – 190 б.
3. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – Алабуга: АИ КФУ нәшрияты, 2012. – 136 б.


## МАҺИНУР ФӘЙЗУЛЛИНА МӘКАЛӘЛӘРЕН ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МУСА ҖӘЛИЛ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН КУЛЛАНУ


**Сәхәбетдинова Ә.Б.**

КФУның Алабуга институты студенты.

Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Габидуллина Ф.И.


Татар әдәбияты дәресләре белем бирү процессында һәм укучыларга мәдәни тәрбия бирүдә мөһим роль уйный. Бу дәресләр үзенчәлекле әдәбиятны өйрәнүгә генә түгел, милли аң, үз мәдәниятенең, үз халкының кыйммәтен аңлаучы шәхес формалаштыруга да ярдәм итәләр, шулай ук анализ һәм тәнкыйди фикерләү күнекмәләрен үстерәләр.

Татар әдәбияты татар мәдәниятенең һәм тарихының аерылгысыз өлеше булып тора. Әдәбият дәресләре укучыларга татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре белән таныштыра, бу исә татар халкының телен, гореф-гадәтләрен саклап калуда ярдәм итә.

Дәресләрдә әдәби текстларны анализлау һәм әсәрләр турында фикер алышу аша укучылар сүзлек запасы байлыгын һәм тәнкыйди фикерләү күнекмәләрен үстерәләр.

Әдәбият дәресләрендә язучылар иҗатының үзенчәлекләрен өйрәнү мөһим урын алып тора. Бу конкрет авторга хас уникаль стилистик алымнарны һәм темаларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Татар теле дәресләрендә Муса Җәлилнең тормыш тарихын, аның иҗатын өйрәнү укучыларга әдәби һәм мәдәни тәрбия бирүнең мөһим өлешен тәшкил

итә. Муса Җәлил-рухи көч, ватанпәрвәрлек һәм тирән кешелеклелек белән тулы шигырьләре һәм әсәрләре белән танылган күренекле татар шагыйре һәм революционеры. Аның иҗатын уку процессына кертү укучыларны аның әдәби мирасы белән таныштыру гына түгел, туган телгә, халык мәдәниятенә һәм тарихына хөрмәт уяту да.

Беренчеләрдән булып Муса Җәлил иҗатын Маһинур Фәйзуллина тирәнтен өйрәнә һәм анализлый. Ул язган материал өлкән сыйныфлар өчен татар әдәбияты дәресен әзерләгәндә яхшы чыганак була ала.

1924 елда М. Фәйзуллина гаиләсе белән Мәскәүгә күченә. Галимә Н. Нариманов исемендәге татар мәктәбендә укытучы булып эшли. Мәктәп янында татар эшчеләре клубы урнашкан була. М. Фәйзуллина клуб рәисенең урынбасары һәм татар мәдәнияте эшлеклеләре белән очрашулар оештыру өчен җаваплы итеп куела. Клубта еш кунаклар Муса Җәлил, җырчы һәм композитор Сара Садыйкова да була. Маһинур Гайнулловна шагыйрь белән таныша һәм дуслаша.[2].

1939 елда М. Фәйзуллина Оренбург педагогия институтыннан татар бүлеге студентларына Совет әдәбияты курсы буенча лекцияләр укырга чакырыла. Курслар программасына Муса Җәлил иҗаты керсә дә, тема буенча мәгълүмат бик аз була. Ләкин М. Фәйзуллина аның шигърияте белән күптән мавыгып йөргәнлектән, аңа бу лекцияләрне алып бару авырлык китерми. Студентларны ул тиз арада үзенә җәлеп итә, аларда зур кызыксыну хисе уята. Шуннан соң Маһинур Фәйзуллинаның Муса Җәлил иҗатына багышланган мәкаләсе 1940 елда «Совет әдәбияты» журналының 3 санында дөнья күрә. [2].

Бу мәкаләсендә М. Фәйзуллина Муса Җәлил иҗатына гомуми анализ гына түгел, язучының кайбер шигырьләренә, аерым поэмаларына тирәнтен анализ ясый. Галимә шагыйрьнең әсәрләрен чор вакыйгаларына бәйләп тә, М. Җәлилнең кичерешләренә бәйләп тә тикшерә. Маһинур Гайнулловна авторның әсәрләрендә чакылган темаларны да бүлеп күрсәтә. Мәсәлән, көрәш героикасы, рәхимсез кешеләр, яшьләр темалары.

М. Фәйзуллина мәкаләсендә «Җиһан», «Хат ташучы» поэмаларын анализлауга мөһим урын бирә. Бу анализларда поэмаларның темасыннан алып алардагы геройларның хис-кичерешләренә кадәр яктыртыла. Әдәбият дәресләрендә бу тирәнтен анализларны куллану укучыларга автор әсәрләрен яхшырак аңнарга, ә укытучыга тәрбияви максатларга ирешергә ярдәмлек булып тора.

Маһинур Гайнулловнаның бу эше әдәбият дәресен әзерләү өчен төп материал була ала, әмма заманча белем бирү системасы укытучы лекциясен генә түгел, заманча технологияләрне дә куллануны таләп итә. Шулай итеп, Муса Җәлил иҗатын өйрәнгәндә, укытучы галимә мәкаләсендәге төп мәгълүматны кыска схемалар ярдәмендә тапшыра ала.

Мәсәлән,



Бу схеманы һәрбер темага язылган әсәрләр мисаллары белән тулыландырырга була.

Әдәбият дәресләрендә схемаларны файдалану укыту процессын төрлеләндерергә генә түгел, укучыларның дәрестә катшашу, фикер алышу теләген арттырырга мөмкинлек бирә. Визуаль чаралар мәгълүматны яхшырак истә калдырырга, текстның төрле элементлары арасындагы бәйләнешне күрергә һәм тәнкыйди фикерләүне үстерергә ярдәм итә. Схема ярдәмендә авторларның кыскача биографиясе өйрәнгәндә, әсәрнең сюжет элементларын билгеләгәндә, геройларга характеристика ясаганда да кулланырга була.

Шулай ук хәзерге заман укучыларын кызыксындыру өчен төрле интерактив технологиялар да шактый. Joyteka — шундый технологияларның берсе. Joyteka — укыту материаллары: видеороликлар, викториналар, тестлар, терминнар буенча уеннар һәм хәтта квестлар ясау өчен биш онлайн-сервисны берләштерелгән белем бирү платформасы.

Бу программа ярдәмендә укытучылар үзләре ясаган видеоматериалларны укучыларга күрсәтә алалар. Аудиозма рәвешендә Маһинур Файзуллинаның М. Җәлил иҗатына анализын кыскача сөйләүне, фоторәсемнәрне һәм тема буенча схемаларны берләштергән видеоматериал әдәбият дәресендә укучыларның игътибарын җәлеп итәргә, аларга өйрәнә торган теманы истә калдырырга ярдәм итә.

Дәресләрдә видеоматериаллар куллану укучыларны өйрәнеләсе тема белән кызыксындырырга ярдәм итә. Визуаль һәм аудиовизуаль элементлар язучыларның тормыш юлы, иҗат үзенчәлекләре, әсәрләрендәге тематик төрлелек белән танышканда кулланыла ала. Мәсәлән, укытучы әсәрне анализлау видеоязмаларын куллана ала. Видеоны караганнан соң, укытучы укучыларга өйрәнелә торган әсәр турында фикер алышырга яки кечкенә тест үтәргә тәкъдим итә ала, тесттагы сорауларга җаваплар видеоязмада яшерелгән була.

Маһинур Фәйзуллинаның Муса Җәлил иҗатының үзенчәлекләренә багышланган хезмәтләре югары сыйныф укучылары өчен татар әдәбияты дәресенең мөһим бер өлеше булып хезмәт итә ала, чөнки язучы иҗатына хас барлык үзенчәлекләрне яктырта, укучыларга шагыйрь әсәрләрендә чагылган темаларны аңларга, туган телне, илне ярату хисе уятырга ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Агишина Т. Оставь свое имя в веках // Музейный вестник. − № 11 (43). − 2006. − Б. 5

2. Валеева Ария «Она успела сказать Джалилю, что он – большой поэт» [Электронный ресурс]. – URL: https://rt-online.ru/p-rubr-obsh-37191/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 16.01.2025)

3. Файзуллина М.Г. Муса Җәлил иҗаты турында // Совет әдәбияты. - 1940. - №3. - 85-95б.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МОНОЛОГИК СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ МЕТОДИКАСЫ

**Тинбакова Л. Р.**
Казан (Идел буе) федераль университеты,
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты
Фәнни җитәкче: ф.ф.к.доц. Г.Ф.Каюмова

Сөйләм – телнең яшәеш формасы. Сөйләм кысаларында кеше тарафыннан төрле тормыш ситуацияләрендә тел мөмкинлекләрен куллану; фикерне тел чаралары белән формалаштыру һәм җиткерү процессының нәтиҗәсе аңланыла. Һәр кешенең сөйләме әйтелеш, лексика, җөмлә төзелеше үзенчәлекләренә ия. Шул рәвешле, сөйләм индивидуаль характерга ия. Ләкин, сөйләмнең башка характеристикалары да бар. Продуктив эшчәнлек төре буларак аның диалогик һәм монологик формалары бар. Курс эшебез темасына бәйле рәвештә безне монологик сөйләм кызыксындыра.

Г.В. Рогова фикеренчә исә, монолог – телдән җиткерелә торган бәйләнешле әйтелмә формасы, бер затның үз фикерләрен бәян итүе, хикәяләве.Монологик сөйләм бер генә кеше тарафыннан төзелә һәм нәкъ менә ул сөйләм структурасын билгели, аның композициясен төзи, сөйләме өчен тел чараларын сайлый. Монологик сөйләм, кагыйдә буларак, өзлексез, эзлекле, планлаштырылган һәм диалогик сөйләмгә караганда киңрәк төзелешле. Эчтәлек ягыннан ул логиклык, тәмамланганлык белән аерылып тора. Монологик сөйләмнең түбәндәге типлары бар: хикәяләү, фикер йөртү, тасвирлау яки хәбәр. Кайвакыт барлык әлеге типлар бер-берсе белән керешеп китә.

Мәктәптә укучыларның сөйләмен үстерү-аны төгәлрәк, логик, аңлаешлырак, образлырак, бәйләнешле, интонациягә бай итү. Бу очракта күптөрле сөйләм күнегүләре, төрле сөйләм төрләре, текстлар һәм күнегүләр төзү, фикерләрне телдән һәм язма формада бәйләнешле итеп сөйләү күнекмәләрен формалаштыру аерым роль уйный.

Укучыларның сөйләм үсеше дәресләрендә эшчәнлекнең иң нәтиҗәле төрләре, төрле әсәрләр, сөйләмнәрдән тыш, материалны эзләү һәм сайлап алуда ориентацияне үстерүче, үз фикерләрен, укыган китапка, каралган фильмга, спектакльгә рецензия язу осталыгын үстерүче докладлар һәм хәбәрләр булып тора.

Татар теле һәм әдәбияты программалары буенча укучылардан иҗтимагый һәм тарихи-әдәби темаларга доклад белән чыгыш ясау осталыгы таләп ителә. Укучылар материалны сайлап алу, нәфис әсәрнең, әдәбият белеме һәм тәнкыйть

чыганакларының текстын үз фикерләре белән бәйләү, структураны сайлау, стиль бердәмлеген саклау һ.б. ешрак Интернетта тулысынча алынган, хәтта эшкәртелмәгән, яңадан уйлап чыгарылмаган материалны ишетергә туры килә.

Логик фикерләүне үстерүгә, сөйләмнең логик төзелеше күнекмәләрен формалаштыруга ярдәм итүче күнегүләр кулланырга кирәк. Мәсәлән:

Гади хикәя җөмләләрен катлаулы җөмләләргә берләштерегез;

Әйтемнәрне тәмамлагыз (тәкъдим ителгән вариантларны кулланып);

Бу тезисларга тиешле аргументларны сайлагыз;

Сәбәбен аңлату…;

Исбатла…;

Тавыш ситуациясен (тавышлар чылбыры, музыкаль әсәр һ. б.) тыңла һәм вакыйгалар урыны турында үз фикереңне әйт.

Шулай итеп, монологик сөйләмне өйрәнү ярдәмендә укучылар:

Үзе, гаиләсе, дуслары, кызыксынулары һәм киләчәккә планнары турында сөйләү, үз шәһәре / авылы, үз иле һәм өйрәнелә торган тел иле турында кыскача мәгълүмат бирү;

Кыскача хәбәрләр ясау, вакыйгаларны, күренешләрне тасвирлау (үткән темалар кысаларында), укыганның яки ишеткәннең төп эчтәлеген, төп фикерен тапшыру, укыганга үз мөнәсәбәтеңне белдерү, персонажларга характеристика бирү;

Темалар буенча үткән төрле ликаны, перифразаны, синонимик чараларны телдән аралашу процессында кулланырга.

**Әдәбият**

Рогова Г.В. «Методика обучения иностранным языкам в средней школе». - М. Просвещение, 2019. - 287 с.

## ЮГАРЫ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КОММУНИКАТИВ УКУ ГАМӘЛЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ

**Фәсхиева Г.А.**

Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты.

Фәнни җитәкче: Каюмова Г.Ф.

Гуманитар дисциплиналарны, атап әйткәндә тел һәм әдәбият фәннәрен укытучыларның төп максатларының берсе булып коммуникациягә сәләтле, һәр яктан үсеш алган шәхес тәрбияләү тора. Әлеге максатка ирешү өчен уку–укыту процессында укучы коммуникатив уку гамәлләренә ия булырга тиеш. Коммуникатив уку гамәлләренә галимнәр түбәндәгеләрне кертеп карый:

- әйләнә–тирәдәге кешеләр белән хезмәттәшлекне планлаштыру (максат кую, аралашу һәм хезмәттәшлек ысулларын билгеләү);
- сораулар кую (мәгълүмат эзләү һәм җыюда инициативалы хезмәттәшлек);

- конфликтлы ситуацияләрне хәл итү (проблеманы ачыклау, аны анализлау, мөмкин булган хәл итү ысулларын эзләү һәм аларны бәяләү, карар кабул итү һәм аны гамәлгә ашыру);
- аралашу белән идарә итү (аралашу партнёры һәм үзең арасында корылган үзара элемтәне контрольгә алу, аңа бәя бирү);
- үз фикереңне белдерә белү (коммуникация бурычлары һәм шартларына ярашлы рәвештә фикереңне тулы һәм төгәл итеп белдерү; аралашу бурычларына ирешүгә йөз тоту; телнең грамматик һәм синтаксик нормаларына, заманча коммуникация чараларына ярашлы рәвештә сөйләмнең монологик һәм диалогик формаларында аралашу белү) [Новичкова, 2017: 134].

Татар әдәбияты дәресләрендә югары сыйныф укучыларында коммуникатив уку гамәлләрен формалаштыруда без тәнкыйть мәкаләләре белән эш алып барырга тәкъдим итәбез. Беренчедән, әлеге өлкә татар әдәбиятын укыту методикасында аз эшкәртелгән, әмма уку–укытуда укучыларның иҗади, тәнкыйди, мөстәкыйль фикер йөртү потенциалы зур булган материал, икенчедән О.Ю. Богданова, С.А. Леонова һәм В.Ф. Чертова кебек галимнәр ассызыклаганча, укытучы әдәби тәнкыйть мәкаләсе белән эш алып барганда, аның эчтәлегенә генә түгел, форма, ягъни жанрына да игътибар юнәлтә: стилистик үзенчәлекләр, фикерне дәлилләү алымнары һ.б. өйрәнү дәвамында укучы үзе дә дәлилле бәйләнешле сөйләм кору осталыгы күнекмәләрен үстерә [Богданова, Леонова, Чертова, интернет–ресурс]. Фундаменталь хезмәт – Д.Ф. Заһидуллинаның “Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы”нда да тәнкыйть мәкаләсе белән эшләү әдәбият укыту ысулының берсе булган әңгәмәнең бер алымы буларак каралып кителә [Заһидуллина, 2004: 21].

Татар телендә урта гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга атап төзелгән дәреслек һәм методик әсбапларда тәнкыйть материаллары, шул җөмләдән тәнкыйди материал белән эш беркадәр күзаллана, укытучыларга атап төзелгән ярдәмлекләрдә урын алган мәкаләләр дә дәрестә кулланылышка кертелеп, анализлана ала. Әмма тәнкыйть материалының – шул чор әдәби, мәдәни, хәтта иҗтимагый тормыш көзгесе булу үзенчәлеге алар аша ачыкланмыйча кала. Шуны истә тотып, эшебездә бер үк әдип иҗатының төрле чорларда тәнкыйтьчеләр тарафыннан төрлечә, кайбер очракта хәтта поляр бәягә дучар ителүе очракларын карап китүне, тәнкыйть мәкаләләрен чагыштыру буенча эшне тәкъдим итәбез. Моны, мәсәлән, унынчы сыйныф укучылары белән Һади Такташ иҗатын өйрәнгәндә башкарырга мөмкин. Программа буенча унынчы сыйныфта Һади Такташ иҗатын өйрәнүгә дүрт сәгать вакыт бирелә, төп игътибар аның “Җир уллары трагедиясе”н өйрәнүгә юнәлтелә. Әмма вакытның бер өлешен методист–галимнәр, программа авторлары түбәндәгеләргә юнәлдерүне күздә тоталар: “Һади Такташ иҗатының төп этаплары: 1916 – 1923 (“Җир уллары”); 1924 – 1931 (“Ак чәчәкләр”), “Болай... гади җыр гына”, “Югалган матурлык”, “Мокамай”. Милли әдәбиятның үзенчәлекле агымы буларак гыйсъянчылык (Һади Такташ “Гыйсъян”, 1923; “Такташ үлде”, 1923) [Примерная рабочая программа..., 2017: 92]. Ягъни

программа буенча Һади Такташ иҗатының каршылыклы булуына да басым ясау сорала. Укучылар моңа кадәр алтынчы сыйныфта “Урман”, “Пи–би–бип”, җиденче сыйныфта “Мокамай” әсәрләрен өйрәнеп, шагыйрь иҗаты турында беркадәр күзаллау алалар. Унынчы сыйныфта исә Һади Такташ әсәрләрендә трагик мотивларның, чор трагедиясенең матур пейзаж тасвиры кебек күренгән әсәрләрдә, мәсәлән “Ак чәчәкләр” шигырендә эзоп теле ярдәмендә яшерелгәнен күрергә өйрәнәләр. Чор һәм шагыйрь каршылыгын өйрәнү өчен укучылар мөстәкыйль рәвештә Фәүзия Бәйрәмованың “Талант фаҗигасе”, М. Таҗетдинованың ““Яңа” Такташ – ул нинди?” мәкаләләре белән эшли ала [Бәйрәмова, 2000; Семенова, 2005]. Тәнкыйть мәкаләләрен өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларга түбәндәге сораулар нигезендә әңгәмә корырга тәкъдим итәргә була:

1) Ни өчен Фәүзия Бәйрәмова Һади Такташ язмышын “фаҗига” дип атый? Сез бу фикер белән килешәсезме?

2) Сез совет чоры тәнкыйтендә Һади Такташның “революциянең бөек шагыйре” дигән сүзләре белән килешәсезме? Әдипнең кайсы шигырьләре нигезендә бу сүзләрне әйтеп булган, дип уйлыйсыз? Ни өчен? Бүген ул шигырьләргә бирелгән бәя нинди?

3) Төркемнәрдә эшләгез: Һади Такташ иҗатына караган тәнкыйть материалларының 1–3ен файдаланып, шулай ук үз фикерләрегезне дә белдереп, тәнкыйди мәкалә яки эссе языгыз. Исегездә тотыгыз: “эсседа беренче планда тәнкыйтьче шәхесе тора. Тәнкыйтьче укучылар белән әңгәмә алып бара, әдәби вакыйга турындагы фикерләре белән уртаклаша. Эссе югары культура һәм интеллекта ия булуны таләп итә” [О жанре статьи, интернет–ресурс].

Мондый эш дәвамында укучылар логик фикерләү, сәбәп–нәтиҗә бәйләнешләре чылбырын төзү, чагыштыру кебек операцияләрне башкарып, коммуникатив уку гамәлләрен үстерәләр. Барлык бу күнекмәләр тәнкыйди материалларны укып анализлау дәвамында үстерелә. Эшкә нәтиҗә буларак эссе язганда, укучыларның иҗади, мөстәкыйль фикерләүләренә зур игътибар бирелә. Эсселар икенче дәрестә укыла, анализланган тәнкыйть мәкаләләре атала. Дәрестә якынча мондый нәтиҗә ясала: Һади Такташ иҗаты үзе исән вакытта ук тәнкыйтьчеләрдә бәхәсле фикерләр уятуга сәбәпче була. Без бер үк әдипнең бер үк әсәре төрле тарихи дәверләрдә төрлечә интепретацияләнә, аңлатыла алуын яхшы беләбез. Һади Такташ иҗатында бу аеруча ачык чагыла. Иҗатын башта колач җәеп алган җәмәгатьчелек шактый тиз һәм әдипнең үзенә, һәм иҗатына тәнкыйть уты, аерым очракларда хәтта әхлак кысаларына сыймаган пычраклар яудыра башлый. Әлеге бәхәс–талауларга хәтта исемнәре бүген дә билгеле булган язучылар, тәнкыйтьчеләр катнаша. Соңгырак елларда, совет чоры тәнкыйтьчеләре, Һади Такташ иҗаты турында сөйләгәндә, әдипне “революциянең бөек шагыйре” дип атадылар. Аларның уртак фикеренчә, гыйсъянчы–бунтарь шагыйрь, иске тормышка ризасызлык белдереп, Аллага, төрле кануннарга, дини богауларга каршы протест белән чыга. Бүген без әдәбиятны яңача, тарихи чынбарлык принципларына таянып өйрәнәбез. Яңача

өйрәнү Һади Такташның һич тә совет идеологы булмавын танырга мәҗбүр итә. Әмма шул чорның символына әверелгән “мыштым гына ияреп йөрүче җил” аны сак булырга мәҗбүр итә. Бүгенге галим, тикшерүчеләр әдип иҗатындагы символларның шифрларын ачып, мондый нәтиҗә ясыйлар: “Һади Такташ башлангыч чор иҗатында җир йөзендәге бөтен сугышларга каршы нәфрәт белдерә һәм, шул исәптән, революциянең, гражданнар сугышынын да барлык башка кан коюлар кебек ук ерткычлыгын тасвирлый, Жирдәге вәхшәт, гаделсезлек очен борчыла, кан кою бәрабәренә төзелгән тормышның шатлык, бәхет китерәсенә ышанмый шагыйрь” [Таҗетдинова, 2007: 126].

Шул рәвешле, татар әдәбияты дәресләрендә югары сыйныф укучыларында коммуникатив уку гамәлләрен әдәби тәнкыйть мәкаләсе өстендә эш алып бару кысаларында формалаштырырга мөмкин. Әлеге эшнең уңышлы яклары буларак иҗади, мөстәкыйль фикер үсеше, дәлилле бәйләнешле сөйләм күнекмәләре камилләшү атала ала.

**Әдәбият**


1. Бәйрәмова Ф.Ә. Талант фаҗигасе // Идел. – 2000. – № 12. – Б. 16 – 25.
2. Богданова О.Ю., Леонова С.А., Чертова В.Ф. Методика изучения систематического курса литературы в старших классах. Изучение литературно–критических статей. – URL: http://www.infoliolib.info/philol/bogdanova/7_4.html; мөрәҗәгать итү датасы: 26.12.2023.
3. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.
4. Новичкова В.С. Сущность понятия “коммуникативные универсальные учебные действия” в научной литературе // Евсевьевские чтения. Серия: Педагогические науки: Сборник научных статей по материалам Международной научно–практической конференции с элементами научной школы для молодых ученых – 53–х Евсевьевских чтений, Саранск, 09 – 10 февраля 2017 года / Редколлегия: Т.И. Шукшина (председатель), В.И. Лаптун (отв. ред.) [и др.]. – Саранск: Мордовский государственный педагогический институт имени М.Е. Евсевьева, 2017. – С. 131–135.
5. О жанре статьи. – URL: https://mydocx.ru/5–96339.html; дата обраәения: 27.12.2023.
6. Примерная рабочая программа учебного предмета «Татарская литература» для общеобразовательных организаций с обучением на татарском языке ( 1 – 11 классы). Одобрена решением федерального учебно–методического объединения по общему образованию (протокол от 16 мая 2017 г. № 2/17) / Загидуллина Д.Ф., Юсупова Н.М., Хасанова Ф.Ф. – Казань. – 100 с.
7. Семенова С.Д. Методика изучения романа в стихах А.С. Пушкина “Евгений Онегин” в IX классе якутской школы с привлечением материала литературной критики: автореф. дис. … канд. пед. наук. – Якутск, 2005. – 25 с.
8. Таҗетдинова М. “Яңа” Такташ – ул нинди? // Казан утлары. – 2007. – №4. – Б. 117 – 126.

# ДӘРЕСЛӘРДӘ УЕН ТЕХНОЛОГИЯСЕ КУЛЛАНУ

**Хаматнурова З.М.**
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: ф.ф.д.,проф.Камаева Р.Б.

Дәресләрдә уен технологиясе уенга корылган төрле ситуацияләр аша тормышка ашырыла һәм уку эшчәнлегендә кызыксындыру, эшкә дәртләндерү чарасы буларак файдаланыла. Уен технологиясе укучыларның танып белү активлыгын үстерә, акыл үсешен активлаштыра, аларда яңа сыйфатлар булдыруга ярдәм итә. Уен вакытында фән белән кызыксыну көчәя, мөстәкыйльлек, ихтыяр көче, игътибарлылык арта, хәтер яхшыра, уйлау күнекмәләре камилләшә.

Хәзерге көндә мәктәпләрдә уку-укыту процессын активлаштыру һәм интенсивлаштыру максатыннан уен эшчәнлеге түбәндәге очракларда файдаланыла:

1) фәнне өйрәнүдә мөстәкыйль технология;

2) нинди дә булса технологиянең бер состав өлеше;

3) дәрес яки аның бер этабы (кереш өлеше, яңа теманы аңлату яки ныгыту, күнегүләр эшләү яки контроль эш һ.б.);

4) дәрестән тыш эшләр технологиясе.

Укытучы педагогик уенның төп асылын аңлаганда гына уку белән уенны аралаштыру процессы уку-укыту эшчәнлегендә уңай нәтиҗәләргә китерә. Уен аша укытучы укыту һәм тәрбия бурычларын уңайлы хәл итеп кенә калмый, ә укучы белән аралашуны да җайга сала. Балалар коллективын берләштерүдә, туплауда, дусларча мөгамәлә урнаштыруда да уенның әһәмияте зур.

Галимнәр уеннарны эшчәнлек төре буенча берничә зур төркемгә бүлеп карылар: хәрәкәтле уеннар, интеллектуаль уеннар, психологик уеннар, иҗтимагый уеннар.

Педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә түбәндәге уен төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин: дидактик уеннар (бу төр уеннар укучыларда белем-күнекмәләр формалаштыруга һәм камилләштерүгә, танып-белү эшчәнлеген киңәйтүгә юнәлтелгән), тәрбияви уеннар, иҗади уеннар, коммуникатив уеннар.

Үткәрү методикасы буенча уеннар бик күп төрләргә бүленә: предметлы уеннар, сюжетлы уеннар, рольле уеннар, эшлекле уеннар һ.б.

Төрле фәннәргә бәйле рәвештә уеннар берничә төргә бүленә: математик уеннар, химик уеннар, физик уеннар, экологик уеннар, музыкаль уеннар, әдәби уеннар, спорт уеннары һ.б.

Уеннар яңа теманы үзләштерү, белемнәрне ныгыту, гомумуку күнекмәләрен формалаштыру, иҗади сәләтләрен үстерүдә куелган бурычларны уңай хәл итүдә зур мөмкинлекләргә ия.

Башлангыч сыйныфларда уен – татар теле дәресләрендә уку эшчәнлеген оештыруның югары нәтиҗәле чарасы. Аны белем бирүнең барлык этапларында да кулланып була. Ул әзерләнгән һәм әзерләнмәгән сөйләмне формалаштыру

һәм үстерү өчен уңай шартлар тудыра, кыенлыкларны җиңү шатлыгын тоярга булыша, коллекивизм рухы тәрбияли. Уен балаларның фикерләвен, сөйләмен һәм хәтерен үстерә [Вәгыйзов 1993].

Башлангыч сыйныфларда укучылар предметлы уеннарны, экият геройларына бәйле булган рольле уеннарны теләп башкаралар. Ә урта һәм югары мәктәп укучылары тарафыннан тормыш-көнкүреш темаларына аралашуга багышланган рольле уеннар, хезмәт эшчәнлеген чагылдыра торган һөнәри (эшлекле) рольле уеннар уңышлы башкарыла.

Уен технологиясен уку-укыту процессында куллана башлаганчы, иң башта кайсы темаларны уен аша өйрәнү максатчан булуын ачыкларга кирәк. Уенны оештырганда вакыт бүленешен төгәл билгеләргә кирәк, чөнки ял вакытларында уен кагыйдәләре бозылырга һәм уенның нәтиҗәлелеге түбән булырга мөмкин. Рус балаларына татар телен өйрәтүдә уен технологиясе куллану бигрәк тә нәтиҗәле. Уеннар куллану балаларга тел материалын гамәли эшчәнлектә үзләштерергә булыша.

**Әдәбият**


1. Вәгыйзов С.Г. Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы. – Казан: Мәгариф, 1993. – 415 б.
2. Вәгыйзов С.Г. Кызыклы грамматика. – Казан: Мәгариф, 2002. – 207 б.
3. Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С. Вәлиева, Г.Ф.Саттаров. – Казан: Раннур, 2000. – 455б.
4. Гайфуллин В. Педагогик технологияләр // Мәгариф, 2000. – № 4. – Б.7-10.
5. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресендә яңа педагогик алымнар. – Алабуга, 2012. – 137 б.


## МӘКТӘПТӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТӘНКЫЙДИ МАТЕРИАЛЛАРНЫ КУЛЛАНУ


**Шарифуллина А.И.**

КФУның Алабуга институты магистранты.

Фәнни җитәкче: ф.ф.к.,доц.Хәйруллина Ә.С.


Соңгы елларда мәктәп укучыларының әдәби текстны аңлау сәләтен формалаштыру, шулай ук әдәби әсәрне аңлатуда катнашкан әдәби тәнкыйть материалларын киңәйтү мөмкинлеге күтәрелде, бу мәкаләләр һәм аңлатмалар еш кына тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре тарафыннан текстны аңлату өчен бер вариант булып торалар. Контраст, төрле фикерләр бәхәссез, “канонизацияләнгән” хакыйкатьләрне ассимиляцияләү мәгариф өлкәсендә күбрәк тәрбияви максатлардан бирелә. Әдәби тәнкыйть материалы катнашканда, бәяләүләр һәм карашлар бәрелеше котылгысыз. Еш кына тәнкыйтьче үзе укучысын “котырта”, кайвакыт тәнкыйтьче белдерелгән карарларга төзәтмәләр кертә.

Тәнкыйди язмаларны әдәбият дәресләрендә куллану татар әдәбиятын укыту методикасы фәненең эчтәлеген баету, яңарту эшендә зур ярдәмлек булып тора. Шул ук вакытта, сәнгать әсәрен критик материалны тирәнтен өйрәнмичә өйрәнү мөмкин түгел; ул мәктәп укучыларының әдәби белеме өчен мөһим булган дәрес этапларын чишүгә ярдәм итә, беренче чиратта, сәнгать әсәрен аңлау эшен тирәнәйтә. Тәнкыйтьчеләрнең, язучыларның мәкаләләре, язмалары мәктәп укучыларына әдәби текстны анализлау өчен үрнәк булып методик яктан хезмәт итәләр. Башта укытучы җитәкчелегендә, аннары мөстәкыйль рәвештә тәнкыйть мәкаләсе белән танышу, тезисларын яки рефератларын туплап, укучылар әсәрне анализлау юлын үзләштерәләр: аның социаль-фәлсәфи һәм эстетик позицияләрен аңлау; бу әсәрдә куелган актуаль проблемаларны эзләү һәм чишү; критик текстта авторның өземтәләрен цитаталар һәм текст материалы белән берләштерү ысулларына ия булалар. Болар барысы да укучыга өйрәнелә торган матур әдәбият әсәренә анализ ясау аша, үз фикерен, карашын формалаштырырга булыша. Бу эш укучыга әсәрнең образлар системасының төрле аңлатмалары белән тирәнтен танышырга, үзенең тәнкыйди фикерен булдырырга мөмкинлек бирә. Югары сыйныфларда, сәнгать әсәрләрен өйрәнү белән беррәттән, укучылар аерым әдәби-тәнкыйть мәкаләләре һәм язмалары, шулай ук бу әсәрләрне аңлату һәм анализлауга багышланган әдәби әсәрләрнең кечкенә кисәкләре белән танышалар. Бүгенге көндә әдәби белем бирү проблемаларының берсе – әдәби тәнкыйтьне өйрәнү тора.

Хәзерге вакытта, мәктәптә татар әдәбияты дәресләрендә әдәби тәнкыйтьне укыту, кабул итү һәм ассимиляцияләү формаларын махсус максатчан өйрәнү кирәк [Хатипов, 2000: 38]. Шуннан чыгып эшебезнең максаты итеп: татар әдәбиятының мәктәп курсында әдәби тәнкыйтьне өйрәнүнең үзенчәлекләрен ачыклау итеп алдык.

Өйрәнү объекты булып – татар әдәбиятының мәктәп курсында әдәби тәнкыйтьне өйрәнү процессы тора.

Өйрәнү предметы – татар әдәбиятының мәктәп курсында әдәби тәнкыйтьне өйрәтү методикасы.

Теманың фәнни яңалыгы: мәктәп курсында әдәби тәнкыйтьне өйрәнүнең төрле ысулларын чагыштыру, укучыларның әдәби компетенциясен формалаштыру өчен методик тәкъдимнәр булдыру өчен нигез булып методик эш тәҗрибәсен гомумиләштерүдән гыйбарәт.

Мәкаләнең теоретик әһәмияте: хәзерге вакытта, татар әдәбиятының мәктәп курсында әдәби тәнкыйтьне сайлау һәм методик аңлау проблемасы кискен, чөнки бу проблемага әдәби тәнкыйтьчеләрнең һәм методикларның төгәл карашлары тулысынча формалашып бетмәгән.

Тикшеренүнең практик әһәмияте әдәбият процессын яки аерым авторлар әсәрен өйрәнү процессында татар әдәбияты дәресләрендә фактик һәм методик материал куллану мөмкинлегендә тора.

Тәнкыйть мәкаләләре тарихи һәм әдәби контекстны реконструкцияләү өчен уникаль мөмкинлек бирә. Тискәре һәм бәхәсле мәкаләләргә мөрәҗәгать

итү дәрестә проблемалы ситуация булдыра. Тәнкыйтьчеләр белдергән әдәби әсәргә төрле карашларны иң нәтиҗәле чагыштыру. Әдәби-тәнкыйть текстын өйрәнү кешегә әдәби әсәрне аңлатуның үзенчәлекләрен аңларга мөмкинлек бирә.

Әдәби-тәнкыйть фикере әсәрләренә тәнкыйть мәкаләләре генә түгел, ә хатлар, очерклар, бәяләмә һәм хөкемнәр кертелгән рецензияләр, тәкгъзияләр дә керә. Мәктәптә әдәби тәнкыйтьне өйрәнү зарурлыгы, укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә аның мөһимлеген беренчеләрдән булып В.П. Острогорский күтәрә.

Танылган методистлар әдәбият дәресләрендә әдәби тәнкыйть язмаларын өйрәнүнең әһәмиятлелеген ассызыклап, “әдәбият тәнкыйте ярдәмендә художestволы әсәрне җанлы, кызыклы һәм җитди өйрәнү мөмкин” (Ц.Балталон), аларның “тәнкыйди фикерләүләрен”, “тәнкыйтьчеләрнең капма-каршы фаразларын аңлау сәләтен” үстерү, “әдәби әсәрне шәхси аңлауны белдерү” (В.В. Голубков) аша укучыларда тәнкыйтьчеләрнең җитди өйрәнүләренә кызыксыну уятырга кирәк дип саныйлар [Проблемы преподования..., 1985: 120].

Әдәби тәнкыйть мәкаләләрен өйрәнү мәктәп укучыларының әдәби белем дәрәҗәсен күтәрә, әдәби тәнкыйть төшенчәсен әдәби иҗатның бер төре итеп кабул итүләрен формалаштыра, аның максаты –укучыларга сәнгать әсәрләрен аңлату, шулай ук тормыш күренешләре белән дә таныштыру. Татар әдәби тәнкыйте – ул мәдәни күренеш. Табигате буенча теоретик белемнәр һәм сәнгать иҗаты арасында универсаль арадашчы булу, татар әдәби тәнкыйтен өч төрле көчнең үзенчәлегенә әйләнде: сәнгать, фән (фәлсәфә, эстетика), чынбарлыкның үзе – абсолют эстетик чынбарлык. XX гасыр башында татар тәнкыйте үзенчәлекле урын били, ул чор культурасында әдәбиятның үзе кебек үк мөһим роле һәм дәрәҗәсе белән чагыштырыла. Татар әдәби тәнкыйте әдәбиятны гына түгел, ә әдәбият чагылдырган һәм аңлаткан теманы да – тормыш, мәдәниятның социаль чагылышы булып тора. Татар тәнкыйте бер үк вакытта эстетика, этика һәм социология кебек фәннәрне дә үз эченә берләштерә.

Мәктәп укыту практикасында әдәбиятның императив схемасы кайвакыт әле дә булса дәвам итә, бу укучыларның сәнгатьчә тойгыларына каршы килә. Шедеврларга карата салкын хөрмәт яшәвеәсәрне индивидуаль кабул итү хисенә комачаулый. “Мәдәни классицизм” куркыныч, чөнки чын мәхәббәт аның темасына тәнкыйть карашын читләтеп үтми. Эстетик кыйммәтләрне үстерү кызыксыну белән, мәҗбүриятсез алып барылырга тиеш. Бу мөмкинлек программа әсәрләрен төрлечә аңлату, өйрәнелгән язучы шәхесенең төрле яклары белән танышу аша тормышка ашырылаТәнкыйть, барлык мәктәп курслары кебек, шәхси аңлауга мохтаҗ.

Шулай да, мәктәп курсында татар әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди язмаларны кулланганда, вакытлы матбугат басмаларына мөрәҗәгать итү кирәк. Мәсәлән, XX йөз башы татар әдәбиятын укыткан чакта, шул чор башында дөнья күргән “Аң” журналы басмасында басылган тәнкыйди язмаларны

куллану мөмкин. Бу әдәбият дәресләрендә аерым иҗатчыларның дәреслекләрдә бирелгән һәм популяр булган әсәрләрен укытудан тыш, бу язучының иҗатына кагылышлы журналда басылган тәнкыйди мәкаләләрне дә тәкъдим итеп була. Шул рәвешле без язучының иҗат лабораториясен яхшырак күзаллау мөмкинчелеге алабыз. Үсештәге иҗатчының иҗат үрнәкләре һәм аларга карата шул чорның тәнкыйть фикере белән танышу аша, аның кайсы елларда нинди фикер яклы булуын, нинди стильгә ия булуын күзәтәбез.

Бу мәктәптә әдәби тәнкыйть мәкаләләрен өйрәнүнең мөмкин ысуллары. Укытучының бурычы – бу өйрәнүне иҗади итү; бу мәкаләләрне анализларга өйрәтү генә түгел, ә укучыларның әдәбиятка бөтен сораулар һәм биремнәр белән кызыксыну уяту мөһим, аннары тәнкыйть мәкаләләрен уку бурычка түгел, ә укучыларга ихтыяҗ булып китәчәк. Тәнкыйть мәкаләләрен карау мәктәп укучыларының сәнгатьчә тәмен үстерә, аларның мәдәни офыкларын киңәйтә, әхлакый идеаллар үсешенә ярдәм итә. Тәнкыйть белемнең объекты гына түгел, ә белем коралына әйләнергә, текстны фәнни анализлау күнекмәләрен формалаштыру, критик фикер йөртү тәрбияләүгә булышлык итәргә тиеш.

Шулай итеп, сыйныфта һәм мөстәкыйль өй эше процессында методик яктан дөрес оештырылган тәнкыйди язмалар белән эш мәктәп укучыларының әдәби белемен, аларның рухи, сәнгать һәм эстетик үсешен, сөйләм эшчәнлеген яхшырта ала.

**Әдәбият**


2. Проблемы преподавания литературы в средней школе: пособие для учителя / под ред. Т.Ф. Курдюмовой. – М. : Просвещение, 1985. – 192 с.

3. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. Югары уку йортлары, педогогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф. – 2000. – 351 б.


## ЗАМАНЧА МӘКТӘП ШАРТЛАРЫНДА ИНТЕРАКТИВ МАТЕРИАЛЛАР ЯРДӘМЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ


**Шәмсивәлеева З.Р.**

Казан (Идел буе) федераль университеты

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты

Фәнни җитәкче: ф.ф.к. доц.Хөснетдинов Д.Х.


*К.Д. Ушинский*
*«Мәгарифнең максаты — кешене тормышка әзерләү, әмма бу әзерлек фәнни белемнәр белән генә чикләнмәгән, ул кешенең рухи һәм әхлакый үсешен дә үз эченә алырга тиеш»*

Бүгенге көндә мәктәптә уку процессында заманча технологияләрнең кулланылышы — зур әһәмияткә ия. Укучыларның игътибары, кызыксынуы һәм активлыгы — укытучыларның төп максаты булып тора. Заманча мәктәп шартларында белем бирү системасы үзгәрә, һәм безгә традицион методларны

яңартып, интерактив алымнарны кертү зарур. Татар телен укыту процессында инновацион технологияләр һәм интерактив материаллар укучыларның тел белән эшләү сәләтен үстерүдә һәм мотивациясен арттыруда мөһим роль уйный.

Теманың максаты: татар телен укучыларга кызыклы һәм нәтиҗәле рәвештә өйрәтү өчен заманча методикалар һәм интерактив материаллар куллануның әһәмиятен, мөмкинлекләрен һәм нәтиҗәләрен өйрәнү.

Бурычлар:

1. Интерактив материалларның төрләрен өйрәнү: Татар телен укытуда кулланыла торган интерактив материалларның (уйнау, тестлар, мультимедиа ресурслары) төрләрен һәм аларның уку процессында ничек файдалы булуын ачыклау.
2. Укучыларның мотивациясен арттыру: Интерактив материалларны кулланып, укучыларның татар теленә карата кызыксынуын һәм мотивациясен ничек арттыруны өйрәнү.
3. Практик күнекмәләр формалаштыру: Укучыларда сөйләм, тыңлау, уку һәм язу күнекмәләрен интерактив методикалар ярдәмендә формалаштыру.
4. Технологик ресурсларны интеграцияләү: Заманча технологияләрне (онлайн платформалар, мобиль кушымталар) татар теле укыту процессында ничек кулланырга икәнлеген өйрәнү.

Хәзерге заманда цифрлы технологияләр көнкүрешнең һәм белем бирүнең барлык өлкәләренә үтеп кергән. Татар телен укыту да бу үзгәрешләрдән читтә калмый. Татар телен саклау һәм аны яңа буыннарга тапшыру милли мәдәниятне һәм тәңгәллекне саклау өчен мөһим булып тора. Укучылар арасында татар телен өйрәнүгә карата мотивациянең түбән булуы инновацион методлар куллануны таләп итә.

Татар телен укытуда мультимедиа, онлайн платформалар һәм виртуаль экскурсияләр кебек яңа методлар куллану яңалык булып тора. Интерактив материаллар укучыларның үз темпы белән эшләвенә мөмкинлек бирә, бу аларның белем алу процессын җиңеләйтә. Виртуаль экскурсияләр һәм мультимедиа ресурслары ярдәмендә татар мәдәнияте һәм тарихы белән танышырга мөмкинлек бирә.

Заманча мәктәп шартларында татар теленә өйрәтү процессын интерактив материаллар һәм цифрлы технологияләр куллану аша нәтиҗәлерәк, кызыклырак итү. Бу юнәлеш укытуның сыйфатын яхшыртырга гына түгел, ә татар телен һәм мәдәниятен саклап калырга да ярдәм итә, аларны хәзерге дөнья таләпләренә яраклаштыра.

Инновацион технологияләр нинди мөмкинлек бирә:

1. Белем бирү процессын яхшырту. Мәсәлән, интерактив технологияләр һәм онлайн-ресурслар куллану интерактиврак һәм сыгылмалырак белем бирү мохите тудыра.
2. Тәнкыйди фикерләүне һәм иҗади потенциалны үстерү. Мәсәлән, проект эшчәнлеген кертү һәм проблемалы мәсьәләләрне чишү укучыларга

мәгълүматны истә калдыру гына түгел, ә үз белемнәрен һәм күнекмәләрен гамәлдә кулланырга ярдәм итә.

3. Заманча хезмәт базары таләпләренә әзерләү. Мәгълүмат технологияләрен кертү һәм цифрлы күнекмәләргә өйрәтү укучыларга киләчәктә һөнәри эшчәнлекләрендә кирәк булырлык яңа кораллар һәм технологияләр үзләштерергә мөмкинлек бирә.

Интерактив материаллар укучыларга конкрет темаларны тирәнрәк өйрәнергә һәм анализ ясарга ярдәм итә. Заманча мәктәп шартларында татар телен укытуда интерактив материаллар куллану — бу процессны эффектлы, кызыклы һәм нәтиҗәле итә. Укучыларның актив катнашуы, белем дәрәҗәсенең артуы һәм технологик грамоталылыгының үсеше — бу методиканың төп уңышлары булып тора. Шулай ук, татар телен өйрәнүгә булган кызыксынуны арттыру һәм социаль компетенцияләрне үстерү — заманча укыту методларының мөһим аспектлары булып тора.

**Әдәбият**


1. Габдуллина, Г. Ш. Методы преподавания татарского языка в условиях современной школы. Казань: Казанский университет, 2019.
2. Гельманова, И. Р. Интерактивные технологии в обучении татарскому языку. Казань: ТГПУ, 2020.
3. Нургалиева, Ф. Р. Актуальные проблемы преподавания татарского языка. Казань: ТГПУ, 2019.
4. Шарипова, Р. А. Новые технологии в преподавании языка. Казань: ИНТЕК, 2023.
5. Юсупова, Д. К. Способы активизации учащихся на уроках языка. Казань: ТГПУ, 2019.
6. Педагогика. Избранные работы / К. Д. Ушинский. — 2-е изд., стер. — М. : Издательство Юрайт, 2017. — 284 с. — Серия : Антология мысли.

# ТАТАРСТАН – ТУГАН ЙОРТЫМ

**Гайнуллина З.Ш.**
Алабуга районы Иске Юраш мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.

Аллаһе Тәгалә һәрбер тереклек иясенә үз орлыгын сала. Бу Ходай биргән “зурлык”ны таптамас өчен, һәрбер тереклек, җан иясенең яшәү көче ала торган урыны була. Ул, әлбәттә, туган җир! Туган як! Туган туфрак! Туган төбәк! Туган табигать! Һәрбер кеше өчен нинди газиз, тирән мәгънәле сүзләр! Алар һәркем йөрәгендә яши һәм, вакытлар үтү белән, тагын да байый, тулылана, ачыграк төс ала бара. Туган якның бай тарихы һәм мәдәнияте, табигате һәм көнкүреше-болар барысы да кече яшьтән үк тормышыбызның бер кисәгенә әверелә. Безнең аңыбыздагы һәм тойгыларыбызда чагылган таныш урыннар, акрынлап, Ватан образын күзалларга ярдәм итә.

Нәрсә ул Туган ил? Ул — синең әтиең, әниең, апаң, энең, сеңлең, әбиең, бабаң. Ул — синең туган, яшәгән йортың, урамың, шәһәрең, авылың. Ул — синең сулаган һаваң, басып йөргән җирең. Безнең барыбыз өчен дә газиз туган илебез — Татарстан Республикасы.

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, диләр. Безнең бай тарихыбыз, мәдәниятебез, мәгарифебез, батыр, эшчән халкыбыз бар. Тарихыбызны өйрәнү, үзең яшәгән төбәк белән горурлану хисләре тәрбияләү – һәрберебезнең бурычы.

Татар нигездә Евразиядә яшәүче төрки халык. Бөтен дөнья буенча саны җиде миллион тәшкил итә, шуның 5 млн. 300 е Россиядә яши. Идел-Урал төбәгендә – дүрт миллион алты йөз татар исәпләнә. Россиядә сан буенча татар халкы икенче урында тора.

Татар халкының, аерып әйткәндә Казан татарларының, хәзерге вакыттагы милли дәүләт формасы булып Татарстан Республикасы тора. Ул 1920 елда Татарстан АССР буларак төзелә.1990 елның 30 августында дәүләт суверенитеты игълан ителде, ә 1991 елның 12 июнендә Татарстан Республикасының беренче Президенты сайланды.Беренче булу бервакытта да җиңел түгел. Шулай да нәкъ менә беренчеләр, кабатланмас булып, тарихта үз урыннарын алалар һәм милләт хәтерендә калалар.Төрки-татар дәүләтләрен төзегән Атилла, Кубрат хан, Казан ханлыгының нигез ташларын салучы Олуг Мөхәммәд һәм, ниһаять, Минтимер Шәймиев - хәзерге Татарстан Республика- сын оештыручы, бөек тарихлы татар дигән милләтнең горур исемен дөнья күләмендә ишеттерүче. Безне хәзер таныйлар, фикерләребезгә колак салалар, исәпләшәләр.Без аяк терәп: “Мин - татар!..” дип горурланып әйтәбез, рәхәтләнеп, туган телебездә аралаша алабыз.

1992 елның 21 мартында республикада Татарстанның мөстәкыйльлеге турында бөтенхалык референдумы үткәрелде, ә шул ук елның 6 ноябрендә ТР

Югары Советы Татарстан Республикасының Конституциясен кабул итте, анда Татарстан халыкара хокуклы субъект дип игълан ителде.

Татарстан 67,8 мең кв.км җир мәйданын били. Республикада 4 млн. га якын кеше яши. Татарстан Идел буе республикалары һәм өлкәләре арасында халык саны буенча беренче урында тора. Республика халкының 48,5%ы - татарлар, 43,3% ы – руслар, 8%- башка милләт вәкилләре.

Республикада 43 административ район, 19 шәһәр, шул исәптән республика буйсынуындагы 11 шәһәр бар. Татарстан Республикасының башкаласы - Казан шәһәре. Анда 1 млн 100 мең кеше яши. Казан - Көнчыгыш Европадагы бик зур индустрия, фән һәм мәдәният үзәге. Зурлыгы ягыннан караганда, ярты миллионнан күбрәк халкы булган һәм күп йөк сыйдырышлы «КамАЗ» автомобильләре җитештерүче индустрия гиганты белән бөтен дөньяга танылган Чаллы шәһәре икенче урында тора.

Бүгенге көндә идеологиябез бар, ул мәдәниятебез, мәгърифәтебез, гореф-гадәтләребез, дин һәм башка проблемаларыбызга кагылган җыелмадан тора, һәм шуларның иң төп идеясе — ул милли идея. Ул байрактай балкып тора. Нинди байрак һәм нинди идея? Милли идея ул һәммә халыкның тарихтагы, бүгенге һәм киләчәктәге урынын күрсәтә торган идея, һәм аның асылы - һичшиксез дәүләт. Дәүләтле чорларында татарлар һәм аларның бабалары дөньяга шул дәүләтләр аркылы мәгълүм булганнар. Дәүләт аларның иминлегенә һәм исәнлегенә гарантия тудыган һәм ул шулай булырга тиеш тә. Татар милләте, дәүләте булгач, беренчедән, үзенең санын, сыйфатын, гореф-гадәтләрен саклардай мохит тудыра алды. Икенчедән, күпләрне сокландырырдай мөстәкыйльлеккә, үз мөмкинлекләренә көйләнгән мәгариф системасын булдырды һәм инде, чыннан да, Россиянең укымышлы халыкларыннан берсенә әверелде. Өченчесе, татар кешесе кайда гына яшәмәсен, Россиядәме, башка илләрдәме, ул үзенең лаеклы урынын таба алды. Без аны бүгенге Россиядә дә, бүгенге дөньяда да күрәбез, беләбез. Безнең милләт арасында хәерчелек юк. Безнең милләт арасында мескенлек юк һәм милләтебезнең вәкилләре һәрвакыт, һәммә илдә лаеклы урын биләп торалар.

Ләкин, менә шушы инде барлыкка килгән милли яшәешкә һәрвакыт инкыйраз куркынычы туа килде һәм моны безнең бөекләребез һәрвакыт әйтә килделәр. Алай гына да түгел, безнең шушы бөек әһелләребез менә шушы милли сыйфатларыбызны, саныбызны һәм милләтебезне саклауның юлларын эзләде.Ул юллар табылды да кебек. Милли яшәешебезне саклау — аның беренче юлы. Икенче юлы, ул дәүләтчелегебезне торгызу һәм инде һич кенә дә Россияне таркату рәвешендә түгел, Россияне федератив дәүләт итеп үзгәртеп һәм инде шушы федерациядә татарларга лаеклы урын табу идеясе.

Татарларның Россия дәүләте хезмәтендә Ватанны ныгытуга керткән өлеше гаять зур. Күп кенә хәрби җитәкчеләрнең, дәүләт эшлеклеләренең, галимнәрнең һәм зыялыларның нәселләрендә татарлар булган.Милләттәшләребез бүген дә, кешелек алдында торучы дөньякүләм мәсьәләләрне хәл итүгә үз

өлешләрен кертеп, Россия Федерациясе икътисадының төрле өлкәләрендә, дөньяның төрле почмакларында уңышлы эшлиләр.

Татар халкының XXI гасырдагы үсешендә милли дәүләт автономиясе төзелү аерым урын алып тора. ТАССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтүче Татарстан Республикасы икътисад, мәдәният, инновацияләр, фән-мәгариф үсеше буенча Россия Федерациясе төбәкләре арасында алдынгы сафта бара. Ул татар телен һәм мәдәниятен үстерүнең, татар халкының милли тәңгәллеген һәм бердәмлеген саклауның тарихи үзәгенә, ә меңьеллык башкалабыз Казан — татарларны үзенә тартып торучы милли-мәдәни үсеш мәркәзенә әвереле.

Зирәк Алмыш әмирнең, шигъри фәлсәфәче Кол Галинең, бөек вәгазьче һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең, халык күңелен кузгаткан Габдулла Тукайның, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең һәм башка бик күп күренекле шәхесләрнең мәңгелек образлары —лаеклы үткәнебезнең символлары, хәзерге һәм киләчәк буыннарга рухи маяклар. Без, яшь варислар, күңелендә ата-бабалары гамәлләре өчен горурлык хисләре тудыра, бүгенге көндә алар үрнәгендә үз халкыңа фидакарьләрчә хезмәт итү, үз киләчәгеңне, милләт киләчәген яхшыга үзгәртү мөмкинлеген күрсәтеп тора. «Мин татармын» — татар халкының бай мәдәни тәҗрибәсеннән чыгып иҗади фикер йөртү формуласы ул.

Татарларның, тарихи сәбәпләр аркасында, бөтен дөнья буйлап сибелеп яшәве үзен сиздерә. Кайбер территориаль һәм милли-дини төркемнәрнең аерылып чыгуга омтылышы күзәтелә. Җирле тәңгәллеккә генә басым ясалса, өстенлекле мәдәниятләрдә «эреп югалу» котылгысыз. Аерым бер урындагы сөйләм үзенчәлекләре һәм җирле гореф-гадәтләр белән мавыгу татар дөньясының бердәмлегенә зыян китерергә мөмкин. Мондый мәдәни-географик күптөрлелекне халкыбызның зур һәм уртак мөмкинлеге дип кабул итәргә кирәк. Җирле мәдәниятләр байлыгы, аларның туктаусыз багланышта булуы яңа ачышларга, яңа мәгънәви төсмерләр туууга нигез булып тора.

Милли-территориаль оешмаларның зарурлыгын шик астына куярга маташучылар,милли тәңгәллек үсешен бары сәясәткә генә кайтарып калдыручылар, гадәттәгечә, аз түгел.

Мондый карашлар хәзерге заманга хас һәм алар дөньяның бик күп халыкларына кагыла. Әмма татарларның эчке көч-куәте зур, бу исә әлеге таләпләрне үтеп чыга алмаслык киртәләр дип түгел, ә алга барганда исәпкә алынырга тиешле күренешләр дип кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Эчке каршылыклар исә таләпләр күпкә катлаулырак. Кешенең үз шәхси каршылыкларын җиңүгә, милли хисләрне баетуга, ата-бабалардан калган барлык хәзинәне яңа мәгънәви төсмерләр белән тулыландыруга омтылыш мөһим. Милли мәдәниятнең халәте өчен киләчәк буыннар каршында һәрберебез җаваплы.

Елга үзенә инешләрне җыйган сыман, татар халкы да үзенең бай һәм катлаулы тарихы дәвамында Евразия киңлекләрендә таралып яшәүче төрле ыругларны һәм милли төркемнәрне акрынлап үзенә куша барган. «Бердәм-

лектә — көч» дигән татар халык мәкале бүген моңарчы булмаганча көнүзәк яңгырашка ия.

Җайлашучылыктан һәм битарафлыктан, «агым уңаена йөзүче» сүлпәнлектән арынырга вакыт. Үз халкыңның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын өстән-өстән генә күзаллау, туган телне белүнең әһәмиятен бәяләп бетермәү кебек үк, котылгысыз рәвештә милли тамырларны югалтуга алып бара.

Татар халкының киләчәге безнең һәрберебездән, эчке максатларыбыздан, омтылышларыбыздан һәм гамәлләребездән тора. Гамәл стратегиясенең вазыйфасы - татар халкының үткәне, хәзергесе һәм киләчәге арасына күперләр салу.

Татарларның үз-үзләрен тотышын, үзенчәлекле фикер сөрешен нигездә татар тарихының барышы һәм характеры билгеләгән. Милли холкыбызның ата-бабалар тәҗрибәсе тәрбияләгән иң яхшы чалымнары ирекккә омтылуда, яңалыкка ачык булуда чагылыш тапкан. Чиксез киңлекләрне үзләштереп чыныккан татар холкы хәрәкәтчәнлектән, аралаша һәм җайлаша белүдән, хезмәт сөючәнлектән һәм булдыклылыктан башка була алмый. Татар кешесе ачык йөзле һәм кунакчыл, төпле һәм үз карашларына тугрылыклы. Ата-бабаларның рухи горефләре әхлак, иман тудыра, өлкәннәргә карата ихтирам, сабырлык, вөҗданлылык һәм тыйнаклык, гаиләгә карата хасиятле мөнәсәбәт тәрбияли. Холкыбызның шушы үзенчәлекләре дөньядагы бөтен татарны берләштерә.

Татарларның милли тәңгәллеге асылында ни ята? Бу сорауга бары тик без генә — татарлар гына җавап бирә алабыз. Үз-үзеңне һәм үз йөрәгеңне тыңлый белергә генә кирәк.

Татарларның үзаңы милли рухка таяна, ә милли рух милли хисләрдә чагыла.

Язмамны тәмамлап, шуны әйтәсе килә: мин үземнең Туган илем, аның табигате, байлыклары, танылган шәхесләре белән горурланам. Халкыбызның, илебезнең киләчәге- безнең кулларда. Ә киләчәкне без үткәнне белмичә, әти-әниләрдән, әби-бабайлардан киңәш алмыйча төзи алмыйбыз.

Мин уйлыйм: без – киләчәк буын - үткәнне берничек тә үзгәртә алмасак та, киләчәкне матур итеп төзү – ул безнең куллардан килә.

Теләгем: республикада яшәүче барлык милләт халкы, бер-берсе белән дус-тату, бердәм булып, әби-бабаларыбыз тарафыннан яулап алынган бәхетле тормышның кадерен белеп, аларга рәхмәтле булып, исәннәренә кадер- хөрмәт күрсәтеп, һәрберебезнең аңына, гаиләсенә би-бабайларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне, йолаларны, асыл сыйфатларны сеңдереп, милли хис дигән төшенчәнең нәрсә икәнен аңлап, әдәпле, миһербанлы, кешелекле, игелекле булып яшәсен иде.

**Әдәбият**

1.Замалиева З.А. сост. Народные обряды и праздники татар /НБ РТ; Отв. ред. И.Г.Хадиев.– Казань: “Милли китап”, 2000.– 42 с.- (В библиотеках республики: Из опыта работы; Вып. 4).

2.Замалиева З. Асост..; Обычаи и праздники татар /НБ РТ: Отв. ред. И.Г.Хадиев. – Казань: Милли китап, 2003. – 31 с. (В библиотеках республики. Из опыта работы; Вып. 2

3.Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1984

4.Саттаров Г. Ф. Татар антропонимикасы. – Казан, 1990

5.Саттаров Г. Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт.– Казан, 1992.

6.Солтанбәков Ф. Эш күрсәткән ирне – Ил онытмас... – Казан:«Матбугат йорты» нәшр., 2001.

7. Петров Ю.А.Татарстан һәм татар халкы тарихы – Казан: Татар балалар нәшр., 2016.

8. Хуҗин Ф . Әлмөхәммәт тарихы , 2010.

Интернет челтәре.

## ГӨЛЕГЕМ – ГОМЕР БИШЕГЕМ

**Закиров И.И.**

Минзәлә шәһәренең 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Мингалиева И.М.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.
(Г. Тукай)

Соңгы елларда олы һәм кече төбәкләр, районнар вә авыллар тарихы белән кызыксынучылар арта бара. Республика һәм район газета битләрендә үткәнебез, авыллар тарихының аерым эпизодлары турында кызыклы язмалар ешрак күренә башлады. Мин дә үз авылым тарихын барлап, авылымдагы мәчет мәхәлләләр тарихы турында фәнни эш язарга булдым эле. Төп максатым: авылның өлкән яшьтәге кешеләре белән аралашып, авыл тарихы турында язылган китапларны, архивтагы документларны укып чыгып, мине кызыксындырган сорауга җавап табу.

Туган як һәр кешегә газиз, кадерле. Мин Татарстанның Минзәлә районы Гөлек авылында туганмын. Минем әти-әнием төп бу авылдан. Без язучы, шагыйрь Рәфкать Закировлар нәселеннән. Мин авылымның табигатен, уңган кешеләрен хөрмәт итәм һәм яратам.

Ләкин туган як дип, кешенең беренче тапкыр аваз салган җирен генә түгел, ә тормышның күп өлешен шунда үткәргән урынны әйтсәң дә була. Мин моны үз язмыш мисалында исбатлый алам. Мин Минзәлә районының Гөлек

авылында туып, балачагымның күп елын шунда яшәдем. Авыл табигате, аның кешеләре, авылымның тарихи урыннары минем күңелемә шулкадәр үтеп керде ки, мин бер дә тартынмый: “ Минем туган ягым – Гөлек авылы”, - дип әйтә алам. Хәзер Минзәлә шәһәрендә яшәсәм дә, туган ягыма булган хөрмәт һәм мәхәббәт элеккечә калды. Халык: “Җан тартмаса, кан тарта” – дип белеп әйтә бит.

Гөлек авылы турында үзебезгә мәгълүм тарихи вакыйгалар белән таныштырганчы , авыл исеме турында берничә җөмлә. 1917 нче ел гарасатына чаклы рәмиләштерелгән архив чыганакларында авыл “Кулюкова” исемендә булган. 1920 һәм 1926 елларда үткәрелгән җан исәбе алу документларында да торак пункты Кулюкова дип теркәлгән. Авыл Гөлек (Гулюква) дип аталган тәүге документ 1930 нчы елга карый. Гөлек авылы, Минзәләнең үзе һәм Минзәлә төбәгендәге бшка торак пунктлары кебек, тарихның төрле чорында төрле административ берәмлек составында булган. Гөлек – татар авылы. Шагыйрь Рәфкать Закировның “Туган җир – изге бишек” шигырендә шундый юллар бар.

Туган җирең гомерлеккә
Рәхмәтле булсын өчен,
Тырыш син дәвам итәргә
Ата-бабаңнар эшен.

Ә хәзер мин ата-бабамнарның эшен дәвам итеп, үзем сайлаган теманы архив материалларына таянып, күпмедер күләмдә ачарга тырыштым. Мин аны сезнең игътибарга тәкъдим итәм хәзер.

Авыллардагы дини җәмгыять эшчәнлеге һәмм мәчет хакында сөйләүче документлар Диния нәзарәте оешкан вакыттан ук теркәлеп калганнар. Бу үзе генә дә безгә Нәзарәт оешканчы авылда дин йорты эшләп торган дип уйларга нигез бирә.

Өфе архивының 295 нче санлы фондында саклanучы шундый документларның берсенә 1791 нче ел, 4 нче март датасы куелган. Ул вакытта имам итеп Абдулла мулла Исмәгыйлевне, ә мөәзин итеп Имамсутый Уразаевны куюлары турында язылган. 1821 нче елның 29 нчы гыйнварында авыл кешеләре үз имамнары итеп авылдашлары Мөхәммәтсалих Морзакаевны һәм күрше Дәвек авылы кешесе Сагындык Батыровны сайлаганнар. Алар Диния идарәсендә имтихан тотып, имам булыр өчен указ алганнар дип уйларга кирәк. Шулай да алар озак хезмәт итмәгәннәр, чөнки 6 елдан соң мәхәллә халкының мәчет имамын сайларга мәҗбүр булганнар. 1827 нче елның 20 нче февралендә мәчетнең имамнары вазифасына 22 яшьлек Мөхәммәтвәли Габдуллин белән Гыйзәтулла Миңнекаевны сайлаганнар. Алар бик озак хезмәт итәләр изге эштә. Ә инде 1854 нче елның 3 нче октябрендә мәхәллә имамы вазыйфасына 22 яшьлек Габделгалим Мөхәммәтгалин килгән.1867 нче елның гыйнварында мәчетнең имам-хатыйбы булып Мөхәммәтша мулла Мөхәммәтшин эшли бшлый. Ул әлеге вазифаны 1889 нчы елга чаклы башкарган. 1903 нче елда авыл мәчетенең имамы булып указлы мулла

Г.Гатауллин эшли башлаган. Гөлеклеләр үтенече белән 1906 нчы елдан икенче мәчет төзетелә. Икенче мәхәллә мәчетенең имам-хатыйбы булып Фатыйхов Фоат хәзрәт була. Ул 2000 нче елга чаклы бу хезмәтне башкара.

Гөлек авылындагы изге йорт 1994 елда ачылды. Мәчет төзүгә бик күпләр үз өлешләрен керттеләр. Әлеге төзелештә колхозның да өлеше бик зур булды. Авылның дин тотучылары үзләренә бүләк итеп биргән Аллаһ йорты өчен ул чагында хуҗалык җитәкчесе булып эшләгән Сибгатулла улы Насифулла Тимеровка, төзегәндә зур өлеш керткән Ильяс Әһлиятдинов, газ керткән нәсыйх Фатыйх улы Исмәгыйловка рәхмәтләрен әйтәләр. Авыл кешеләре Ислам динен тотканнар. Бер мәчеткә намазга йөргәннәр алар. Якты дөньяны калдырып, бакый йортка күчкәннәрен дә бер зиратка җирләгәннәр.

Авылда 2008 елның 1 гыйнварына 162 хуҗалык бар. Барлыгы 378 кеше гомеритә. Шуларданпенсионерлар 132 кеше. Мәктәпяшендә 25 бала. Шулардан 8 бала Гөлек башлангыч мәктәбендә, 17 бала Урыс урта гомум белем бирү мәктәбенә йөреп укыйлар. Мәктәпкәчә яшьтә 13 бала бар.

Авылда социаль көнкүреш объектларыннан 3 кибет, мәдәният йорты,фельдшер-акушерлык пункты, балалар бакчасы, башлангыч мәктәп бар. Авыл мәчетендә көн саен намазлар укыла, балаларга һәм өлкәннәргә дин дәресләреукытыла (мөгаллимә Гайнетдинова Дания).Авыл халкының төп шөгыльләре игенчелек һәм терлекчелек. Шәхси хуҗалыкларда һәркемнең бәрәңге, яшелчә, җиләк-җимеш бакчасы бар. Умартачылык, балыкчылык, балта, төзү эше, кәрҗин үрү, тегүчелек белән шөгыльләнүчеләр бар. Авылның терлекчелек фермасында 588 баш терлек асрала ( 2009 елның гыйнварына ), Гөлек товарлыклы-сөтчелек фермасы районда күрсәткечләребуенча алдынгы санала. Гөлектә эшмәкәр Рәис Хәмәтдиновның районда бердәнбер булган «Ак он»тегермәне эшли. Ул шулай ук Тукай районының Туйра, Боерган, Таулар, Иске Байлар, Күзкәй авылларына да хезмәт күрсәтә.

Мин – авыл баласы. Җаным-тәнем белән авылымны сөям. Мәңге яшәсен авылым минем! Аның нәсел дәвамчылары авылыбызда кәбрәк калсыннар иде. Ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен саклап, шунда гомер итсеннәр иде дигән теләктә калам мин.

Авылым турындагы язмамны төгәллим, ләкин әле монда язылган тарихи фактлар барсы да ачылып бетмәде. Шуңа күрә, әле мин фәнни эшемне алга таба да үстерермен дигән өметтә калам. Минем авылым мактауга лаек. Үземнең дә авылдашларыма лаек булып җирдә тирән эз калдырасым килә минем.

**Әдәбият**

1. Борынгы документларның Руссия дәүләт архивы, 113 Я ф., 1 оп., 1962 нче ел, - 124 б.

2. Башкортстан Республикасы үзәк дәүләт архивы, Краткий список-справочник фондов. Уфа, 1975 г.,- 20б.

3. И. Лотфуллин Гөлек шагыйре(Р.Закиров турында). 2001 нче ел, 19 июль саны, 2 нче бит.

4. Ю.Юсупов “Гөлегем – гомер бишегем”, 2009 нчы ел, “Минзәлә” китапханәсе.

## ПРОИСХОЖДЕНИЕ И ЭТНОГЕНЕЗ ТАТАРСКОГО НАРОДА

**Камалова Л.Д.**

студентка Арского педагогического колледжа им. Г.Тукая

Научный руководитель: Шамсиева М.Н.

История татарского народа насчитывает множество веков и включает в себя разнообразные события, культуру и традиции. Татарский народ, представляющий собой один из крупнейших этносов России, имеет богатое наследие, которое формировалось под влиянием различных исторических, культурных и политических факторов.

История народа, ныне известного как татары, начинается с V-VI веков на территории Великой степи, где кочевали тюркские племена, предки многих современных народов. Языком, от которого произошёл татарский, скорее всего, был кыпчакский. Поскольку тюрки были соседями китайцев, те очень скоро начали узнавать их среди остальных кочевых племен. Одному из народов жители Поднебесной дали название «дада» — очевидно, именно так для них звучало слово «татар», которое очень рано начинает встречаться в древних тюркских памятниках.

Позднее тюрки создали огромную кочевую империю, которую позднейшие историки назовут Тюркским каганатом. После его падения в ходе противоборства с Китаем некоторые из племён, его составлявших, отправились на запад. Дойдя до Балкан и Поволжья, предки татар встретились с булгарами и создали вместе с ними обширное государство, известное как Волжская Булгария. И татары, и булгары являлись тюрками по происхождению, просто булгары раньше мигрировали на территорию Восточно-Европейской равнины. Сейчас на месте, где находилось это развитое средневековое государство, располагается территория Татарстана, Ульяновской области и Чувашии.

Вскоре после возникновения Волжской Булгарии правитель этого государства эльтебер, или князь, Алмуш принял ислам. Согласно источникам, это произошло 21 мая 922 года, после чего торговые и дипломатические отношения булгар, перешедших под покровительство аббасидского халифа, ещё более оживились. Однако не прошло и трёх веков, как процветающее государство было завоёвано потомками Чингисхана. Когда сам великий завоеватель был жив, он отдал своему старшему сыну Джучи особый улус — удел, находившийся на севере реки Сырдарья. Так как Джучи умер раньше отца, его владения достались его детям. Например, Булгария считалась улусом Тука-Тимура, но позднее подпала под власть младшего сына Джучи, известного как хан Бату или Батый. [Юзеева 2000: 98]

Вскоре после возникновения Волжской Булгарии правитель этого государства эльтебер, или князь, Алмуш принял ислам. Согласно источникам, это произошло 21 мая 922 года, после чего торговые и дипломатические отношения булгар, перешедших под покровительство аббасидского халифа, ещё более оживились. Однако не прошло и трёх веков, как процветающее государство было завоёвано потомками Чингисхана. Когда сам великий завоеватель был жив, он отдал своему старшему сыну Джучи особый улус — удел, находившийся на севере реки Сырдарья. Так как Джучи умер раньше отца, его владения достались его детям. Например, Булгария считалась улусом Тука-Тимура, но позднее подпала под власть младшего сына Джучи, известного как хан Бату или Батый.

Батый и его потомки стали правителями Золотой Орды, под властью которой находилось множество народов, включая русских. Однако самым большим по численности этносом были тюрки, часть которых со временем стала предками современных татар. Несмотря на то что правителями Орды были монголы-чингизиды, их придворными были в основном тюрки, дочери которых часто вступали в браки с представителями правящего рода. Постепенно государство создало свою культуру, систему сбора налогов, перешло на тюрки — язык, предшествовавший старотатарскому — и приняло ислам в качестве государственной религии. Со временем Золотая Орда распалась на несколько ханств, которые часто воевали друг с другом. Главными из них традиционно считаются Казанское и Астраханское ханства, завоёванные царём Иваном IV Грозным: в 1552 и 1554 годах соответственно. После этих событий татары стали подданными русских самодержцев, а часть из них стала христианами и известна сегодня как татары-кряшены, то есть крещёные. [Юзеева 2000: 145]

Татары, как и всякий крупный этнос, обладают довольно сложной внутренней структурой и состоят из трех этно-территориальных групп: волго-уральских, сибирских, астраханских татар и субконфессиональной общности крещеных татар. К началу XX века татары прошли процесс этнической консолидации. Народная культура татар, несмотря на ее региональную вариативность (она варьирует у всех этносов), в своей основе едина. Народноразговорный татарский язык (состоящий из нескольких диалектов) является в основе единым. С XVIII -по начало XX вв. сложилась общенациональная (так называемая «высокая») культура с развитым литературным языком. Этот слой культуры, создаваемый весьма разветвленными институциональными механизмами (СМИ, школа, театры, ансамбли, научные учреждения, издательства и т.д.) обслуживает всех татар. [Ногманова 2005: 171]

На консолидацию татарской нации оказало сильное воздействие высокая миграционная активность татар из Волго-Уральского региона. Так, к началу XX в. 1/3 астраханских татар состояла из переселенцев, причем многие из них были перемешаны (через браки) с местными татарами. Такое же положение

наблюдалось и в Западной Сибири, где уже к концу XIX в. Около 1/5 татар были выходцами из Поволжья и Приуралья, также интенсивно смешивавшихся с коренными сибирскими татарами. Поэтому сегодня выделение «чистых» сибирских или астраханских татар практически невозможно.

История татарского народа – это глубокая и многослойная тема, охватывающая тысячелетия. Она включает в себя формирование татарской идентичности, влияние различных культур и цивилизаций, взаимодействие с соседними народами, а также важные события и процессы, которые повлияли на судьбу народа.

Сегодня татарский народ продолжает сохранять и развивать свои традиции, интегрируясь в динамично меняющийся мир. Сохраняя свою самобытность, татары вносят значительный вклад в многонациональную культуру России и мира, оставаясь при этом приверженными своим корням и языку.

Таким образом, история татарского народа – это не только история борьбы и преодолений, но и символ стойкости, культурного богатства и многообразия, которой продолжает развиваться в современном обществе.

**Литература**

1. Ногманов А.И. Самодержавие и татары. Очерки истории законодательной политики второй половины XVI -XVIII вв. – Казань, 2005. – 215 с.
2. Сабирова Д.К., Шарапов Я.Ш. История Татарстана. Казань, 2000.
3. Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII – XIX вв. – Казань: Тат. кн. изд-во, 2000. – 200 с.

## ТАТАР РУХИ МӘДӘНИЯТЕН ҮСТЕРҮДӘ “БОЛГАР” РАДИОСЫНЫҢ РОЛЕ

**Мостафин А.Р.**
Алабуга шәһәренең “Инженер-технология лицее” укучысы
Фәнни җитәкче: Төһбәтуллина Р.Р.

Теләсә-нинди халыкның мәдәниятен өйрәнүдә матди һәм рухи мәдәниятне аерып тикшерү гадәткә кергән. Беренчеләре рәтендә кеше тарафыннан ясалган йорт җиһазлары, эш кораллары, бизәнү әйберләре, киемнәр кебек атрибутлар керсә, икенчеләре рәтендә “аң, акыл һәм эмоциональ-психик процессларга бәйле күренешләр – тел, сәнгать, гореф-гадәтләр, белем системасы, дин-ышанулар”ны тикшерәләр [Скворцов, 2009: 48]. Хәзерге вакытта татар милли мәдәниятен саклап калу һәм үстерү иң актуаль проблема буларак аерылып тора. Телебезне, динебезне, гомумән, милли мәдәниятебезне үстерүдә “Болгар радиосы” да сизелерлек өлеш кертә. 2012 елдан ул “Болгар радиосы” һәр татарның йөрәгендә” девизы белән эшли башлый, тапшыруларның 95% татар телендә алып барыла. Радио тыңлаучыларның күңел, рух үсешенә татар телендәге җырлар гына түгел, мәгънәле тапшырулар

да йогынты ясый. Алар арасында “Булган бит, ә” тапшыруы үзенчәлекле урын алып тора. Мәсәлән, аның 2021 елның 10 март чыгарылышында Нәүрүз бәйрәме турында сөйләнә, Нәүрүзнең дөньяда иң борынгы бәйрәм булуы, тарихы, бәйрәм итү рәвеше турында мәгълүмат бирелә [https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=46], башка чыгарылышларда аулак өй, өйләнешү йолалары, май чабу бәйрәме турында сөйләнелә, бала туу белән бәйле йолалар хакында да кызыклы чыгарылыш бар; һәр тапшыру җыр-музыка белән үрелеп бирелә. Татар матбугаты, шул исәптән радиожурналистикада да дини тема әһәмиятле урын алып тора. Дөньяви дәүләттә яшәсәк тә, ислам дине – безнең милләтебез мәдәниятенең аерылмас өлеше булуы шиксез.Ислам дине һәм мөселман цивилизациясе төрки бабаларыбызга зур йогынты ясавы билгеле. “Озак гасырлар дәвамында төрки халыклар, шул исәптән татар халкы мәдәнияте, нигездә, гарәп-фарсы мәдәниятләре синтезын тәшкил иткән мөселман дөньясы кысаларында үсеп китә”, – дип яза Л.И. Хәйдәров [Хәйдәров 2004: 5]. Миссионерларның мәшһүр идеологы Н.Ильминскийның “Татарлык ислам белән көчле” дигән сүзләрне әйтүе мәгълүм[Миңнегулов 1998: 112]. Чынлап та, мең елдан артык ислам дөньясында яшәү безнең телебезгә, гореф-гадәтләребезгә, фикерләвебезгә, мәдәниятебезгә гаять нык йогынты ясаган. Ислам дине татар кешесен шәхес буларак нык, сабыр, яхшы күңелле итеп формалашуына да этәргеч биргән, бөтендөнья әдәбияты-мәдәниятендә үз урыныбызны табырга да ярдәм иткән.Ислам идеологиясе икътисад, сәясәт, мәгариф, мәдәният, фән, тәрбия һәм башка бик күп өлкәләргә тәэсир ясый. Барлык бу үзенчәлекләрне истә тотып, ислам дине кануннары милләтебезгә хас кыйммәтләрне, әдәп-әхлак кануннарын, яшәү нормаларын регуляцияләүче көч дип кабул ителергә һәм татар җәмәгатьчлеегнә шушы юнәлештәге мәгълүмат тәкъдим ителергә тиеш, дип уйлыйбыз. “Болгар радиосы” дулкыннарында һәр җомга яңгырый торган “Хак дин” тапшыруы чыгарылышларының рухи мәдәниятебезне үстерүдәге роле турында да без югары фикердә. Тапшыру саф дини тематиканы гына түгел, тәрбияви, кыйммәтләр формалаштыруны да күздә тота. Мәсәлән, агымдагы елның 10 сентябрьчыгарылышында Йосыф хәзрәт Дәүләтшин белән тапшыруны алып баручы Ф.Гыймадов, мәсәлән, кыямәт көнендә иң зур гөнаһлардан саналучы тәкәбберлек турында әңгәмә алып баралар. Әңгәмәдә кызыклы фикерләр яңгыратыла: тәкәбберлек – матур күлмәк кию, яхшы йортта яшәү түгел, болар ислам буенча инкяр ителми, тыелмый, ә менә үзеңне башкалардан өстен кую, үзеңнән ярлыны, зәгыйфьрәкне түбәнсетү исә зур гөнаһ булып тора. Тапшыруны тыңлаганда элекке татар байларының, кайбер чыгармаларны искә алмаганда, башларын югары чөймәүләре, матди байлыкны халык файдасына да тота белүләре, үз хисапларына мәктәп-мәдрәсә ачулары да әнә шул ислам мәдәнияте йогынтысыдыр, дигән фикер уята.

Милли тарихны, милли мәдәниятне онытмау идеясе “Без тарихта эзлебез” тапшыруының һәр чыгарылышында да теге яки бу дәрәҗәдә яңгыратыла.Мәсәлән, “Без тарихта эзлебез” тапшыруының 2020 елгы бер

чыгарылышында чакырылган кунак рәссам Нияз Таҗетдинов татар рәсем сәнгатенең дизайн юнәлешендә үсүен бөтен дөньяда, рус мәдәниятендәге тенденцияләр белән бәйли, шул ук вакытта бу юнәлештә татар рәсем сәнгатенең үзенчәлекле мотивлар тәкъдим итә алуын да искәртә[https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=41]. Икенче бер чыгарылышта татар яшьләре хәрәкәтенең беренче карлыгачы булган "Татар яшьләре көннәре"н беренче оештыручылардан Ирек Гариф белән әңгәмә тәкъдим ителә. Әңгәмәдә милләт язмышы – яшьләр кулында, дигән фикер кызыл җеп белән уздырыла.Болгар радиосы" сайтында "Без тарихта эзлебез" тапшыруның 2020 елның 21 декабрь чыгарылышында язучы Р.Батулла белән милли темага сөйләшү алып барыла. Р.Батулла фикерен кыю, ачыктан-ачык әйтә белүе белән билгеле шәхес, шуның белән ул гамьле әңгәмәне тагын да ямьләндерә, тыңлаучыга фикерләрен үтемле итеп җиткерә. Тапшыру Р.Батулла иҗатына түгел, ә беренче чиратта татар тарихына багышлана. Язучы, җәмәгать эшлеклесе, милләтпәрвәр зат бу әңгәмәдә ул Россия һәм Татарстанның уртак тарихына, уртак пространствода яшәвенә дә ишарәт итә. Бу уртак тирәлектә татарларның урынын ассызыклап, ул "Татар бар җирдә хәтәр бар" дигән мәкальне башкача әйтергә кирәк, "хәтәр бар җирдә татар бар" [https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=41]. Мисал итеп Р.Батулла французлар белән сугыш, Чернобыль фаҗигасын һ.б.ларны китерә. Һәр аталган "хәтәр" очрак Россия тарихына карый, әмма куркынычның алгы сызыгында татарлар торганлыгын искә төшерә язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Р.Батулла. "Димәк, татар милләтен милләт иткән күрсәткечләргә (тел, тарих, мәдәният һ.б.) ихтирамлы мөнәсәбәт булырга тиеш", дигән нәтиҗә ясала әңгәмәне тыңлаучылар тарафыннан. Шәмсия Җиһангирова тарафыннан алып барылган "Яшәү яме" тапшыруы үз тирәсенә Ф.Яхин, Р.Вәлиев, С.Әхмәтҗанова кебек олпат фикерле, шигъри, иҗади фикерле шәхесләрне җыя. Бу әңгәмәләрдә дә татар мәдәнияте, атаклы шәхесләре турында үтемле фикерләр яңгыратыла [https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=24].

Атаклы татар шәхесләре язмышы, эшчәнлеге, иҗаты "Милли мөнбәр" тапшыруында да игътибар үзәгендә. Биредә Г.Тукай, В.Имамов, Ә.Рәшит, Р.Мингазов, һ.б. шәхесләргә багышланган чыгарылышлар урын ала. Мондый язмалар, тапшыруларда кызыл җеп булып түбәндәге фикерләр җиткерелә: татар мәдәни тормышында аеруча хөрмәткә лаеклы шәхесләр бар, аларның тормышы, иҗаты – милли үзаңы югары үсешкә ирешкән шәхес тормышына мисал, башкалар өчен үрнәк булып тора.

Югарыда язылганнар шуны ачык күрсәтә: "Болгар" радиосы татар халкының рухи мәдәниятен – телне, музыка сәнгатен, динне, милләт тарихын саклап калуда, алдагы буыннарга тапшыруда үз вазифасын лаеклы башкара. "Милли мөнбәр", "Булган бит, ә!", Без тарихта эзлебез", "Хак дин" кебек авторлык тапшырулары сыйфатлы, мәгънәле, милли журналистиканың үрнәге саналырга лаеклы күренешләр дип атау хакыйкатькә туры килә.

**Әдәбият**

1. Болгар радиосы сайты. Булган бит, ә! – URL: https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=46; мөрәҗәгать итү вакыты: 18.10.2021.
2. Болгар радиосы сайты. Без тарихта эзлебез. – URL: https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=41;и мөрәҗәгать итү вакыты: 18.10.2021.
3. Болгар радиосы сайты. Хак дин. – URL: https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=32; мөрәҗәгать итү вакыты: 1810.2021.
4. Болгар радиосы сайты. Яшәү яме. – URL: https://bolgarradio.com/media-content/audio/?SECTION=24; мөрәҗәгать итү вакыты: 1810.2021.
5. Миңнегулов Х. Татарларда ислам дине // Мирас. – 1998. – № 4. – Б. 109-116.
6. Скворцов В.Н. К вопросу об определении понятия “духовная культура” // Вестник Ленинградского государственного университета им. А.С. Пушкина. – 2009. – Т.2. – №3-1. – С. 48-55.
7. Хәйдәров Л.И. XX йөз башы татар әдәбият белемендә гарәп әдәбияты мәсьәләләре: филол. фәннәр канд. дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен тәкъдим ителгән дис. – Казан, 2004. – 190 б.

##ҺӘР ҖӘҮҺӘРДӘ – ХАЛКЫМ ТАРИХЫ

**Шәрифуллина З.А.**
“Адымнар – Алабуга” күптелле белем бирү комплексы укучысы
Фәнни җитәкчеләр: Комиссарова Ф.Г., Данилова З.С.

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син.
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен...

( Р.Фәйзуллин)

Һәр кеше үз халкының үткәнен, ата-бабаларның ничек көн иткәнен,ниләр белән шөгыльләнгәнен, гореф-гадәтләрен, йолаларын белергә тиеш. “Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк” ,- ди бит татар халкы. Әлбәттә, милләтебез гасырдан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан эти-әнигә, эти-энидән балага үзләренең гореф-гадәтләрен, йолаларын, нәсел-ыру тарихларын югалтмыйча тапшырып килгән. Алар күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, безнең көннәргә дә килеп җиткән. Мин дә еш кына үзебезнең нәселебез турында, аларның эшләгән эшләре , кәсепләре һәм кылган яхшылыклары турында уйланам.” Гомер үтә - кешеләр кала. Кешеләр күчә - нәселе кала, изгелекләре җирдә, киләчәк буыннар

хәтерендә, күңелендә кала”, диләр. Бу, чыннан да, шулай. Инде күптәннән үзебезнең нәсел җепләрен барлыйм. Карт әбием еш кына миңа гаилә тарихын сөйли. Үзебезнең шәҗәрәбезне өйрәнүемне белгәч, ул безгә бик күп истәлекләр сөйләде. Шулай да быел җәйге ялларда чорнада эленеп торган көянтәгә күзем төште.Бу бөгелмәле көянтәне нинди максаттан кулланганнар? Кем ясаган?Сорау арты сорау туды. Бу сөйләшү кызыклы булып китте. Әбием кирәкле мәгълүматлар биреп, татар халкының көянтәләре белән бәйле йолалары турында сөйләп кенә калмады, ә мине кызыксындырган сорауларга да җавап табарга булышты.

Шулай итеп,Иң элек Көянтә сүзенең мәгънәсен ачыклап китик. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә түбәндәге билгеләмәне таптым. Көянтә : чиләк, кәрзин кебек нәрсәләрне асып йөртү өчен очларында уентыгы яки тимер ыргаклары булган, җилкәгә салына торган озын иңсәле, махсус бөгеп ясалган агач җайланма.

Көянтәне ничек ясаганнар соң? Көянтә өчен өрәңге, шомырт агачы кулай булган. Чимал әзерләү өчен иң уңайлы чор – көз азагы яки яз башы. Нәкъ шул чакта үзагач сыгылучан була, димәк, көянтә өчен дуга ясарга менә дигән вакыт. Яхшы көянтә чыдам да, шул ук вакытта, җиңел дә, сыгылмалы да булырга тиеш.

Агачны йомшарту өчен буе 2 метрлы, диаметры 35-45 сантиметрлы металл торба куллана. Осталар бөгеләчәк агач борысны торба эченә тыгып, торбага 2-3 чиләк су салып кайнаталар: каен – 4 сәгать, имән – 5-6 сәгать, көянтә ясала торган шомырт агачы 15-20 минут кайнатыла.Парланган агачны махсус станга куялар. Ә стан дигәнебез өске ягы дугаланып торган агач түмәре.

Өлкән буын кешеләренең сүзләренә караганда, көянтә аерым очракларда 50 елга кадәр һәм аннан да күбрәк хезмәт иткән. Хуҗалыкта ул махсус кагылган чөйгә эленеп куела торган булган.

Хәзерге вакытта көянтәләрне Татарстанда «Ива мебель» фабрикасы ясый. Ул Балтач районының Янгул авылында урнашкан. Фабрика 2012 елдан бирле үз җирлегендә традицион һөнәрчелекне торгызу белән шөгыльләнә. «Ива мебель» көянтәләрне талдан бөгә. Осталар әйтүенчә, алар елына 100-200 көянтә ясый ала, әмма аңа ихтыяҗ зур түгел. Хәзерге вакытта татарларда көянтә ясау һөнәре дә, ясау технологиясе дә югалып бара. Көнкүрештә исә берничә дистә ел элек ясалган көянтәләр кулланыла. Бүгенге көндә көянтәләрне күбрәк фольклор һәм театр коллективлары өчен җитештерәләр.

Беренче карашка, көянтә авыр әйберләрне күчерү өчен хезмәт итә торган гап-гади җайланма. Ә бит уйлап карасаң, ул татар халкы йолаларының бик кирәкле бер атрибуты. Мәсәлән, татарларда «су юлы күрсәтү» йоласы бар. Туй көнендә яшь килен көянтә-чиләк белән суга барырга һәм тамчысын да түкмичә су алып кайтырга тиеш. Авыл халкы киленнең судан кайтуын күзәтергә чыга, шулай рәвешчә аның уңганлыгын бәяли.

Сабантуйның иң матур ярышларыннан берсе – көянтә-чиләк белән су ташу. Ярышта катнашучылар суны түкмичә финишка килеп җитәргә тиеш.

Чиләгендә суы күбрәк булып, финишка иң беренче килеп җитә алган кеше – җиңүче. Бу уен билгеле бер тәҗрибә таләп итә, чөнки көянтәне беренче тапкыр иңенә куйган кеше җиңүгә артык өметләнә алмый.

"Авылда күрше-күлән безгә суга керә иде. Ул вакытта карт әби белән бабайның коесы булган вакыт. Суга керүнең дә йоласы бар. Буш чиләк-көянтәләрне капкадан кулга тотып керәләр.Берәү дә бу йоланы бозмый. Чыкканда, чиләкләр-көянтәгә, көянтә -иңнәргә күчә. Буш көянтә-чиләкләр белән , узып баручының каршысына чыгарга ярамаганын без, бала-чага да, белә торган идек", дип сөйли әбием. Чиләкләрең су белән тулы икән , барасы юлың уңа!

Чыннан да,татар халкында көянтәгә бәйле ышанулар да киң таралган. Татар авылларында түбәндәге ышанулар яши:

– Көянтә аша атлап узсаң, аягыңны көзән җыера.

– Мал-туарны көянтә белән кусаң, көянтә кебек кәкре балалар туа.

– Юлда буш чиләкле хатын очраса ,юлың уңмый, ә чиләкләре тулы булса, юлың уңа.

– Җомга көнне тәһарәт вакытында чишмәгә суга төшәргә ярамый, ул вакытта фәрештәләр су ала.

Гасырлар дәвамында халыкның күңеленә сеңгән йолалары рухы безнең әдәбиятыбызда чагылыш тапкан.Татар халкында элек-электән яшәп килгән шундый бер йола бар. Яшь кыз белән егет беренче тапкыр чишмә буенда очрашалар .Борынгыдан килгән шушы ук изге йола Наилә Әюпованың «Олы чишмә» хикәясендә, Лена Шагыйрьҗанның « Мәхәббәт көянтәсе », Нәкый Исәнбәтнен «Уракчы кыз»,Шәйхи Маннурның «Олы чишмә» шигырендә дә матур гәүдәләнә.

Тарихи сүзләр турында: "Кайбер предмет, күренешләләрнең тормышта булмавы нәтиҗәсендә, сүзләр кулланылыштан төшеп кала", диелгән 5 нче сыйныфның дәреслегендә. Берничә елдан "көянтә" сүзе дә әнә шул тарихи сүзләр исемлеген тулыландырмасмы? Дөрес, җирдә бернәрсә дә мәңгелек түгел. Кайбер төшенчәләр, кулланылыш әйберләре бөтенләе белән юкка чыга, югала. Алмашка уңайлыраклары, камилләшкәннәре килә тора. Моның шулай булуы табигый. Кешелек дөньясы алга барырга тиеш. Ләкин мин уйлыйм, халкыбызның гореф-гадәтләре, традицияләре, йолалары буыннан-буынга тапшырылып халкыбыз яшәешендә, күңелләрендә уз урынын югалтмас. Чөнки рухи ядкәрләр, йола, гореф-гадәтләребез – безнең байлыгыбыз. Халкының үткәнен, тарихын өйрәнгән, матурлыкны күрә белгән һәр баланың киләчәге өметле, - дип әйтеп калдырган үз вакытында күренекле фикер иясе, мәгърифәтче - Ризаэддин Фәхреддин. Мин бу сүзләр белән тулысынча килешәм.

**Әдәбият**

1. Брусько З.М., Завгарова Ф.Х. В круге жизни. – Казань: Ихлас, 2013. – 224 с.

2. Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.У. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. – М.: Советский художник, 1990. – 210 с.

3. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959-1967.

4. Сабантуй: методическое пособие / под ред. Ф.Х. Завгаровой. – Казань, 2012. – 76 с.

5. Хасанова З.Ф. Домашние производства из дерева у башкир Инзерского бассейна // Ватандаш. – 2017. – С. 174-193.

6.Ганиева Ф.А., Сабирова Л.Г. Әдәбият: татар телендә гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.

## ЭЧТӘЛЕК


| | | |
|---|---|---|
| 1 | **Акмурзин Д.А**, ( Яр Чаллы шәһәренең 13 нче урта мәктәп укучысы. Фәнни җитәкче: Харитонова Г.П.). ***Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗаты. Мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеге.*** | 2 |
| 2 | **Ахунҗанова М. И. (**Алабуга шәһәренең «Инженер-технология лицее» укучысы. Фәнни җитәкче: Әхмәдуллина Р.Ф. ). ***Каюм Насыйри һәм аның иҗади мирасы.*** | 5 |
| 3 | **Басырова Д.В.** (Алабуга районы Иске Юраш мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Юнусова Л.М.). ***Сәламәт рух - сәламәт милләт...*** | 7 |
| 4 | **Бахтиярова З.Р.** (Алабуга районының “2 нче урта гомуми белем мәктәбе” укучысы. Фәнни җитәкче: Сәхәбиева А.М.). ***Каюм Насыйри һәм татар терминологиясе үсеше.*** | 10 |
| 5 | **Биба Н.А (**ученик МБОУ «СОШ №19» г. Набережные Челны. Научный руководитель: Фатихова С.Г.). ***Просветительская деятельность Каюма Насыри.*** | 12 |
| 6 | **Борнашева С.Р**. (Алабуга шәһәре 10 нчы күппрофильле лицее укучысы. Фәнни җитәкче: Усманова Р.Н.). ***Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты.*** | 14 |
| 7 | **Габдрахманова Г.Р.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Габидуллина Ф.И.). ***Каюм Насыйри һәм татар фольклористикасы*** | 17 |
| 8 | **Гайнанов Б.С**. *(*Алабуга муниципаль районы «1 нче гимназия-Милли белем бирү үзәге» гомуми белем мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Вагизова Л.Г.). ***Каюм Насыйриның мирасы–мәңге тутыкмас могҗизалы бер гәүһәр.*** | 20 |
| 9 | **Гайнетдинова Л.Д. (**Алабуга шәһәре “Инженер-технология лицее” укучысы. Фәнни җитәкче: Гатауллина М.Г.). ***Каюм Насыйри татар милли әдәби теленә нигез салучы.*** | 23 |
| 10 | **Гилмуллина А.Л**. (Алабуга шәһәре 10 нчы күппрофильле лицее укучысы. Фәнни җитәкче: Гилмуллина Л.С.). ***Каюм Насыйри һәм аның иҗади мирасы***. | 26 |
| 11 | **Гобәйдуллин К.Р**. (Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.). “***Әбугалисина кыйсса”сында мәгърифәтчелек идеясе.*** | 28 |
| 12 | **Зайнагутдинов Б.А**. (Алабуга шәһәренең «Инженер-технология лицее» укучысы. Фәнни җитәкче: Агмалова Э.Э.). ***Каюм Насыйри – татар дөньясына юл күрсәтүче.*** | 31 |
| 12 | **Захарова А.В.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Габидуллина Ф.И.*).* ***К. Насыйриның тел өлкәсендәге эшчәнлеге.*** | 32 |
| 14 | **Зиязиева Н.Ф**. (Минзәлә шәһәренең "2 нче урта гомуми белем | 34 |

| | | |
|---|---|---|
| | бирү мәктәбе" укучысы. Фәнни җитәкче: Хамаева Г.А.). ***Каюм Насыйриның иҗади мирасы буларак халык авыз иҗаты үрнәкләре.*** | |
| 15 | **Искәндәрова А.Р., Нәгимова Р.Р**. (Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкчеләре: Шакирова Л.М., Тимофеева Л.М.). ***Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗаты. Мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеге***. | 36 |
| 16 | **Кәримова Т.И., Фәтхуллин Н.Р**. (Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Низамбиева Р.Р.). ***Каюм Насыйриның "Китаб-әт-тәрбия" китабы һәм автор нәсихәтләренең тел үзенчәлекләре.*** | 39 |
| 17 | **Лотфуллина Л.В**. (Яр Чаллы шәһәренең 13 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Лотфуллина З.З.). ***Татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле.*** | 43 |
| 18 | **Минголова А.Ф**. (Әлмәт шәһәре 17 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Ибраһимова Г.А.). ***Каюм Насыйри безнең якты йолдызыбыз.*** | 44 |
| 19 | **Муфтиева З.Р**. (Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе "Салават күпере талантлары" "Краеведение " түгәрәге әгъзасы. Фәнни җитәкче: Набиуллина Л.З.). ***Каюм Насыйри – күренекле тел белгече.*** | 47 |
| 20 | **Мухаметдинов К.Р.** (Әлмәт шәһәре 17нче урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Кашипова Н.Җ.**).** ***Каюм Насыйриның "Китаб-әт-тәрбия" хезмәтендәге нәсыйхәтләрнең бүгенге көндәге әһәмияте.*** | 50 |
| 21 | **Мухлисуллина А.Х.** (Әлмәт шәһәре 17 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Махиянова Р.М.). ***Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗаты.*** | 52 |
| 22 | **Нуриева Д.Р.** (Алабуга шәһәре "Университет" гомум белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Сахабиева Г.Х.). ***Каюм Насыйриның педагогик мирасы.*** | 55 |
| 23 | **Прохоров К.Е**. **(**Алабуга шәһәре "Университет" гомум белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Назмутдинова А.И***).*** ***Влияние трудов и идей Каюма Насыри на последующие поколения.*** | 58 |
| 24 | **Салихов И.Р. (**Алабуга шәһәре "Университет" гомум белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Назмутдинова А.И.). ***Просветительская деятельность Каюма Насыри.*** | 60 |
| 25 | **Сафина А.И.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Хәйруллина Ә.С.). ***Каюм Насыйриның тормыш баскычлары.*** | 62 |
| 26 | **Сафина Л.И**. (Алабуга шәһәре "1 нче гимназия – Милли белем бирү үзәге" укучысы Фәнни җитәкче: Илдарханова З.М.) ***К.*** | 65 |

| | | |
|---|---|---|
| | ***Насыйриның “Әбүгалисина” әсәрендә белем темасының бирелеше.*** | |
| 27 | **Сафина Н.И.** (Алабуга шәһәре 10 нчы күппрофильле лицее укучысы. Фәнни җитәкчеләре: Ашрафуллина Р.И., Гөмәрова Л.М). ***Каюм Насыйриның әдәби эшчәнлеге.*** | 69 |
| 28 | **Ситдикова А.А.**. (Алабуга шәһәре “Университет” гомум белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Хәйруллина Ә.С.). ***Каюм Насыйриның фән өлкәсендәге эшчәнлеге***. | 70 |
| 29 | **Ситдикова Р.Х. (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Габидуллина Ф.И..). ***Каюм Насыйри – тәрҗемәче***. | 72 |
| 30 | **Фазлиева З.Р**. (“Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте” укучысы. Фәнни җитәкче: Гыйләҗева А.Ф.). ***Каюм Насыйриның сәләтле балалар белән эшләүдә педагогик мирасы.*** | 775 |
| 31 | **Фархуллина Р.Р**. (“Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте” 1 нче курс студенты. Фәнни җитәкче: Шаһиева Д.Г.). ***Каюм Насыйри – күпкырлы шәхес.*** | 78 |
| 32 | **Фәсхетдинов И.Р**. (Арча районының "Г. Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта гомуми белем мәктәбе" укучысы. Фәнни җитәкчеләре: Сәләхова И.Г., Шиһапова Г.Х. ). ***Каюм Насыйриның математик хезмәтләре.*** | 80 |
| 3334 | **Хәкимова Р.А**. (Алабуга шәһәре 10 нчы күппрофильле лицее укучысы. Фәнни җитәкче: Хайбрахманова А.А.) ***Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты. Мәгърифәтчелек эшчәнлеге.*** | 83 |
| 35 | **Хөсәенов А**. С. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Хәйруллина Ә.С.). ***Каюм Насыйри – укытучы һәм дәреслекләр авторы.*** | 85 |
| 36 | **Ягудина Р.Р.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Хәйруллина Ә.С). ***Каюм Насыйриның фәнни-педагогик эшчәнлеге***. | 89 |
| 37 | **Яковлева В.В.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Даутов Г.Ф.***). Каюм Насыйриның гыйльми – мәгърифәтчелек эшчәнлеге.*** | 93 |
| 38 | **Арсланова А.Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Габидуллина Ф.И.). ***Галимҗан Гыйльманов әсәрләрендә реаль һәм ирреаль дөнья бирелеше*** | 97 |
| 39 | **Әхмәтҗанова Х.Д. (***Арча районының "Утар-Аты төп гомуми белем мәктәбе" укучысы. Фәнни җитәкче: Касимова З.Г.***). М.Мәһдиев иҗатында мәдәни мирас сакланышы.*** | 103 |
| 40 | ***Гарифьянова Р.В. (****Сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 9 нчы Зәй мәктәбе” укучысы. Фәнни җитәкче: Хәйретдинова Р.Җ.****). Укытучым иҗатында күңел матурлыгы.*** | 105 |

| | | |
|---|---|---|
| 41 | **Гатиятуллина Ю.С.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Габидуллина Ф.И.). ***Рәдиф Гаташ поэзиясендә милли һәм гомумкешелек проблемаларының бирелеше.*** | 108 |
| 42 | **Закирова Г.И. (**Казан (Идел буе) федераль университеты филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к. доц. Каюмова Г.Ф.). ***Йолдыз Миңнуллинаның шигърияте һәм поэтикасы.*** | 110 |
| 43 | **Мәткаримова А.Х.** *(Әлмәт шәһәре «13енче урта гомуми белем 41бирү мәктәбе» укучысы. Фәнни җитәкче: Гарипова А.Ш.).* **Авыл тормышын сурәтләү остасы буларак Р.Төхфәтуллин.** | 112 |
| 44 | **Салахова С.Р. (***Лениногорск шәһәренең 4 нче урта мәктәп укучысы. Фәнни җитәкче: Мортазина А.Ф.***).** **Г.Утыз-Имәни һәм аның иҗади мирасы.** | 118 |
| 45 | **Феткуллова А.К**. *(Чувашия Республикасы беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Айзатуллова Р.Р.*). **Алия Емакова әсәрләрендә әхлак мәсьәләләре.** | 121 |
| 46 | **Шакурова К.А.** *(Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Минһаҗева Р.М.).* **Д.Каюмова шигырьләрендә туган як табигате.** | 125 |
| 47 | **Шәйхетдинова Ә.Р.** *(Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к. доц. Каюмова Г.Ф.).* **XIX гасыр әдәбиятын өйрәнүче галимнәр эшчәнлеге: Гайнуллин М.Х., Гайнетдинов М., Сәгъди Г. хезмәтләрендә XIX гасыр әдәбияты тарихына мәнәсәбәт.** | 127 |
| 48 | **Ахмадуллина Н.*К.*** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф.Камаева Р.Б.). ***М.Хәбибуллинның романнарында кулланылган фразеологик синонимнар һәм антонимнар.*** | 130 |
| 49 | **Габдрахманов Т.В.** (Алабуга шәһәренең «Инженер-технология лицее» укучысы. Фәнни җитәкче: Шакирҗанова Н.Г.) ***Тел – халыкның хәзинәсе.*** | 133 |
| 50 | **Галиев С.А. (**Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.). ***Без татарлар, телебез - татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул.*** | 134 |
| 51 | **Гильмутдинова Ф.Ф**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Хәйруллина Ә.С.). ***Татар телендә аналитик җөмләләрнең өйрәнелү торышы***. | 137 |
| 52 | **Зәкиева Д.Ф. (**Әлмәт шәһәренең “Адымнар-Әлмәт”гимназиясе укучысы. Фәнни җитәкче: Тамасова Я.И.). ***Галимҗан Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” әсәрендә образлар*** | 140 |

| | | |
|---|---|---|
| | ***системасы*** | |
| 53 | **Исмагилова Г.Р.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф.Камаева Р.Б.). ***XX гасырның 90 нчы елларында чыгарылган русча-татарча терминологик сүзлекчәләр.*** | 143 |
| 54 | **Махамматал кызы Асемай (**М.Акмулла исемендәге башкорт дәүләт педагогия университеты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Султакаева Р.А.). **Речевой *этикет в кыргызском и башкирском языках (на основе приветствий).*** | 146 |
| 55 | **Мирхайдарова А.М.** (Алабуга районы Иске Юраш мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Юнусова Л.М.). ***Онлайн мәгълүмат чаралары.*** | 150 |
| 56 | ***Талыпова Л.Н.*** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф.Камаева Р.Б.). ***М.Акъегетнең "Хисаметдин менла" әсәрендә поэтик ономастика.*** | 153 |
| 57 | **Хаматнурова З.М.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф. Камаева Р.Б.). ***Стилистик чара буларак оксюмороннар***. | 155 |
| 58 | **Юнусова Э.Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф.Камаева Р.Б.). ***И.Юзеевның "Гашыйклар тавы" әсәрендәге фразеологизмнарны төп мәгънәләре ягыннан төркемнәргә бүлү.*** | 159 |
| 59 | **Ахмадуллина Н.*К.*** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф.Камаева Р.Б.). ***Мәктәптә М.Хәбибуллин романнарын өйрәнү.*** | 164 |
| 60 | **Гимадиева Р.А.** (Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к. доц. Каюмова Г.Ф.).***Татар бәетләрен өйрәнүдә инновацион уку-укыту алымнары аша мәдәниятара диалогка ирешү алымнары.*** | 166 |
| 61 | **Зиннатова Т.А. (**Казан (Идел буе) федераль университеты филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к. доц. Каюмова Г.Ф. ***Урта сыйныфларда татар әдәбияты дәресләрендә квих технологиясен куллану алгоритмы.*** | 169 |
| 62 | **Исмагилова Г.Р.** *(КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф.Камаева Р.Б.).* ***Татар теле дәресендә сүзлекләрдән файдалану.*** | 170 |
| 63 | **Мөхәммәтҗанова Л.Р. (**Казан (Идел буе) федераль университеты филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к. доц. Каюмова Г.Ф.). ***Комикслар: татар әдәбиятында файдалы яңалык яки заманга иярүме?*** | 173 |

| | | |
|---|---|---|
| 64 | **Салихова И.Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф. Камаева Р.Б.). ***Татар теле дәресен оештыру.*** | 175 |
| 65 | **Сәхәбетдинова Ә.Б..** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к, доц. Габидуллина Ф.И.). ***Мәһинур Файзуллина мәкаләләрен әдәбият дәресләрендә Муса Җәлил иҗатын өйрәнү өчен куллану.*** | 177 |
| 66 | **Тинбакова Л.Р. (**Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к, доц. Каюмова Г.Ф.**)**. ***Татар әдәбияты дәресләрендә монологик сөйләм үстерү методикасы.*** | 180 |
| 67 | **Фәсхиева Г.А. (**Казан (Идел буе) федераль университеты филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к. доц. Каюмова Г.Ф.). ***Югары сыйныф укучыларында татар әдәбияты дәресләрендә коммуникатив уку гамәлләре формалаштыру.*** | 182 |
| 68 | **Хаматнурова З.М.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: ф.ф.д, проф. Камаева Р.Б.). ***Дәресләрдә уен технологиясе куллану*** | 185 |
| 69 | **Шарифуллина А.И.** (КФУның Алабуга институты магистранты. Фәнни җитәкче: ф.ф.к., доц. Хәйруллина Ә.С.). ***Мәктәптә татар әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди материалларны куллану.*** | 187 |
| 70 | **Шәмсивәлеева З.Р. (**Казан (Идел буе) федераль университеты филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты. Фәнни җитәкче: Хөснетдинов Д.Х.**)**. ***Заманча мәктәп шартларында интерактив материаллар ярдәмендә татар телен укыту.*** | 190 |
| 71 | **Гайнуллина З.Ш.** (Алабуга районы Иске Юраш мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.). ***Татарстан – туган йортым.*** | 192 |
| 72 | **Закиров И.И.** (Минзәлә шәһәренең "2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" укучысы. Фәнни җитәкче: Мингалиева И.М.). ***Гөлегем – гомер бишегем.*** | 196 |
| 73 | **Камалова Л.Д**. (студентка «Арский педагогический колледж им. Г.Тукая». Научный руководитель: Шамсиева М.Н.). ***Происхождение и этногенез татарского народа.*** | 199 |
| 74 | **Мостафин А.**Р. (Алабуга шәһәренең “Инженер-технология лицее” укучысы. Фәнни җитәкче: Тухбатуллина Р.Р.). ***Татар рухи мәдәниятен үстерүдә “Болгар” радиосының роле.*** | 201 |
| 75 | **Шәрифуллина З.А.** (“Адымнар – Алабуга” күптелле белем бирү комплексы укучысы. Фәнни җитәкчеләр: Комиссарова Ф.Г., Данилова З.С.). ***Һәр җәүһәрдә – халкым тарихы.*** | 204 |

*Научное издание*

**«ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК И ЛИТЕРАТУРА. ИСТОРИЯ: ПРОШЛОЕ, НАСТОЯЩЕЕ И БУДУЩЕЕ»**

Сборник научных статей XVI Всероссийской науно-практической конференции

Редакционная коллегия:

**Р.Б.Камаева, Ф.И.Габидуллина, Г.Ф.Даутов, А.С.Хайруллина**

Подписано к публикации 20.02.2025 г . Гарнитура «Times»